# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ленар ШӘЕХ. Кеше булып калыйк соң чиктә! *Шигырьләр*. ....3
Зөлфәт ХӘКИМ. Хирург. *Повесть*. ....8
Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Гасырларга еллар үрелгән... *Шигырьләр*. ....55
Зиннур ХӨСНИЯР. Канатсыз фәрештәләр. *Хикәя*. ....60
Рифкать ИМАЕВ. Табасы иде чишелешен... *Шигырьләр*. ....81
Рүзәл МӨХӘММӘТША. Хәл бу ки. *Кыйтгалар кыйссасы*. ....85
Зимфира ИСЛАМОВА. Тапшырыла дәвер үтенече. *Шигырьләр*. ....126
Нәсих ТАҖИЕВ. Чиккән кулъяулык. *Хикәя*. ....130

ЯҢА ИСЕМНӘР

Алинә БИКМУЛЛИНА. Уйда – таулар, ымсындыргыч үрләр... *Шигырьләр*. ....142
*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....145

«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Гөлзәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА. Сукмак. *Хикәя*. ....147
Гөлфәгыйзә ЮЛЫШЕВА. Мин исән! *Хикәя*. ....154

«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ

Рәдиф СӘГЪДИ. Идарәче дә, иганәче дә. *Очерк*. ....162

ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАР ҺӘМ ЗАМАН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Төрки әдәбиятларда пост-постмодернизм:
Борһан Сонмезнең «Истанбул Истанбул» романы ....165

Абдулла ДУБИН. 2020 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. ....167
*Фотоархив:* Марсель Сәлимҗановның тууына 85 ел. ....168

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Таяну ноктасын эзләгәндә... ....170

2019 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге. ....180

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Миңлегөл ӘХМӘТХАНОВА әзерләде.* ....186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН
УТЛАРЫ
*(«Огни Казани»)*
*№ 12 (1166) 2019*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Мөдәррисова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.11.2019, график буенча 29.11.2019, басылып чыгу вакыты 13.12.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-3342. Тираж 4351.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2019 ел



Ленар
Шәех

# КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫЙК СОҢ ЧИКТӘ!

## Хуш, Иске ел!

Бер тукталыйк,
Табигатьне тыңлыйк –
Әйтер сүзе шактый җыелган.
Киләчәктә яшәр кешелеккә
Җиребезне саклыйк быелдан!

Динебезне, телебезне саклыйк,
Колач җәеп, очыйк биектә!
Калтыранып яфрак коелганда
Кеше булып калыйк соң чиктә!

Дөньяныкы – дөньялыкта, әйе,
Калачакбыз бер мәл ансыз да...
Якты киләчәкнең каршысында
Әверелмик җансыз-сансызга!

Күңел тулы өмет булган чакта
Йөрәкләрдә яшәү уты бар!
Яңа елда бәхет аргамагын
Көмеш ялларыннан тотып ал!

Әй кешелек!
Еллар кабатлана,
Ә гомерләр акмый кирегә.
Яңа елда якты уйлар белән
Канатланып язсын йөрергә!

Ленар ШӘЕХ (1982) – *шагыйрь, филология фәннәре кандидаты; Муса Җәлил исемендәге республика, Абдулла Алиш премияләре лауреаты. «Авылдан килгән мендәр», «Дүртенче кат... Бишенче кат...», «Үзем белән очрашу» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Хуш, Иске ел!
Йөз меңенче тапкыр
Фатихаңны калдыр тапшырып!
Ахырзаман якынайган мәлдә
Без китәрбез, бәлки, яхшырып!
Без китәрбез әле... яхшырып!

* * *

*«Мы пойдем другим путем...»*
В.И.Ленин

Юк икән – юк, бетте-китте,
Башка сүз катып тормам.
Ятып калганчы атсам да,
Атсам да ятып тормам! –

Яңадан алга барырмын
Агымга, җилгә каршы.
Барыр юл тәмамланса да,
Көтә яңа юл башы. –

Яңа уйлар, яңа җырлар
Яктылык, сафлык тулы.
Юк икән – юк, барып чыга
Алмады шул бу юлы –

Тырышу – җәза түгел лә,
Нишлисең, шулай язган.
Шөкер, без түгел дөньяда
Байлыктан, юлдан язган!

Юк, без түгел бу җиһанда
Көнләшкән, кара янган!
Һәр кешенең үз бәхете
Аерым араланган!

Юк икән – юк, бетте-китте,
Күп сүз болгатып тормам.
Ике кулымны селтим дә
Мин китәм башка юлдан!
Мин китәм башка юлдан!!!

* * *

Буран дулый. Ә күңелдә –
Мәхәббәт өермәсе.
Яннарыңа очып кына
Их, бер кайтып киләсе!..

Кар булып, димим, буранны
Җитез акбүз ат итеп,
Иярлисе дә яныңа
Кайтасы иде җилеп.

Уралып каласы иде
Кайнар сулышларыңа...
Син генә йөрәк түремдә,
Исемең – тел очларымда.

Орчыгы зыр-зыр... Табигать
Ак кардан җепме эрли?
Буран дулый. Ә күңелдә
Хисләрем тынгы бирми.

Уемда уйчан карашың,
Тылсымлы сурәт кенәң... –
Ак бураннар уртасында
Сагынудан ярсып тибә
Моң тулы йөрәк кенәм.

## Бишкәктә

Шыбыр-шыбыр, шыбыр-шыбыр… –
Бишкәктә яңгыр ява.
Иртә ява, кич тә ява...
Дымлы, салкынча һава.
Яңгыр бер дә киртә түгел,
Мин ашыгам кибеткә –
Китаплар мәгарәсенә...
Тамчылар бәрә биткә.
(Тәүге очрашуыбыздан
Бер ел үткән дә киткән).

Такси туктатам. Шофёры
Белми кая барасын.
Җәлилне белә.
                    – Айтматовның
Татар булган анасы!..
Ә Шәймиев татар халкын
Ничек алга җибәрде!..
Барыбыз да тигез идек
Зур ил таркалган мәлне...

Кайсы урам, беләсеңме?
– Белмим, әмма хәтерлим:
Шәһәр үзәгенә таба –
Күргәч, үзем әйтермен.
Китап кибете янында
Язучылар берлеге...
Шофёр белми. Кыргызларның
Чиклеме мөмкинлеге?
Аларның үз дәүләтләре,
Азат, мөстәкыйль халык. –
Шофёрның күңеле тыныч,
Мин барам дулкынланып.

Күпме була кызынырга
Үзеңнең кояшыңда?..
Белергә телим: ниләр бар
Кыргызлар дөньясында!..
Яңа китаплар чыкканмы?
Кемнәр бар арасында?..
Шофёр белми күз карашым
Кайда тукталасын да.

Татар китапка табына,
Китапсыз яши алмый.
Үз дигәнен итми калмый –
Уйлап тормый, оялмый.
Шуңа, бәлки, яшидер дә
Телен, тарихын саклап.
Урау-урау юллар үтә,
Китапның хакын хаклап.

...Таныш урам. Мин шофёрны
Кинәт кенә туктатам.
Ни буладыр күңелемә,
Бу кадәр ашыкмаса?!
Төшеп калдым. Таныш йортлар.
Мин үз өемдәмени?!
Хикмәт исемдәмени дә,
Хикмәт киемдәмени?!

Әнә ул – китап кибете –
Таптым, ниһаять, таптым!..
Җаным әллә каян тоя
Җылылыгын, яктылыгын
Таныш төрки учакның!

## Ностальгия

Авылымның капкаларын
Ачасым килгән иде.
Таш каладан шунда гына
Качасым килгән иде.

Туган авыл капкалары
Ябылган шул, ябылган.
Мин генәдер авылымны
Өзелепләр сагынган.

Сагынган, гамьгә уралган,
Саргайган таш калада,
Авылга мәхәббәт хисе
Йөрәгемдә яна да,

Ялкыны җанны дөрләтә,
Өзәдер үзәгемне.

Ни хакына таш эчендә
Түзелгән, түзәменме?..
Түзелгән шул, яшьлек уе
Тирәндә түгел, өстә.
Авылым җаны – йөрәктә,
Сурәте – бары төштә.

Еллар узган саен нигез
Тарта авыл баласын.
Биек йортлар арасында
Югалыплар каласың...

Адашыплар каласың да
Гаҗизләнә башкаең.
Их, авылым урамнары,
Өй артындагы каен!..

Ул миләшләр, ул шомыртлар,
Чияләр!.. Чирәм исе!..
Тынлык, хозурлык һәм муллык,
Борынгылык!.. Гамь исе!..

Тамыр тарта, бәгырь тарта,
Әби-бабай тупсасы!
Ефәккә төреп йөртерлек
Ул бәрәңге бакчасы!..

Ул мунча, ул төтен исе,
Түгәрәк икмәк исе!
Күпләр ташын-ташка сүткән
Акшарланган өй миче!..

Сайгаклар һәм кашагалар,
Тәрәзә йөзлекләре... –
Авылның тузан каплаган
Сүзләре, сүзлекләре...

Һәммәсе дә җан түрендә
Качып кына ята да
Ташкын булып башка бәрә,
Ябыша күк якага.

...Авылымның капкаларын
Ябык булса да ачам!
Монда – сыенып урыным,
Ярсу җанга куначам!*

---

* Куначa (диал.) – ак бүлмә, кунак бүлмәсе.

*«Шифалы куллар» әдәби конкурсы*



Зөлфәт
Хәким

# ХИРУРГ

ПОВЕСТЬ

**1**

Ноябрь азагында машинаның җәйге көпчәкләрен кышкыга алмаштырырга дип, йорт астындагы гаражга кердем. Гараж түрендә яңа машина торганын күрдем һәм, аның капкачын ачып, моңарчы таныш булмаган ир-егетнең аккумулятор беркетеп маташуын абайладым.

Мин үз эшемә керешкәндә, ул машинасын бикләде дә гараж капкасына таба юнәлде. Язын-көзен билем авырткалап тора, менә хәзер дә бер тәгәрмәчне урнаштыргач, туктап хәл алырга булдым. Көч-хәл белән маташуымны чамалаптыр инде, минем турга җиткәч, ул туктап исәнләште һәм:

– Абый, ярдәм кирәк түгелме? – диде.

Мин сөенеп, аңа кул бирдем. Һәм без, икәүләшеп, тиз арада көпчәкләрнең калган өчесен алыштырып куйдык.

Бу Рәмис исемле ир-егет күрше подъезддагы фатирга әле яңа гына күченгән булып чыкты. Онкология диспансерында хирург булып эшләве, хатыны да медицина өлкәсендә хезмәт итүе, бәби көтүләре хакында сөйләшә-таныша торгач мәгълүм булды.

Казанда туып үскән, укымышлы, зыялы егетнең татарча матур иттереп сөйләшүе күңелемә бигрәкләр дә хуш килде.

Эре сөякле, уртачадан озынрак буйлы, киң җилкәле бу егеттән яхшы энергия бөркелеп тора. Төз, туры борынлы, кысыграк коңгырт күзле булгангадыр, башта мин аны Урта Азиядән килгән кешедер дип уйлаган идем. Бу турыда үзенә әйткәч, ул көлеп куйды.

– Мине әллә кемнәргә охшаталар. Базарда йөргәндә, Үзбәкстаннан түгелме дип сораганнары бар. Сакал җибәреп йөргән чакта Кавказ кешеләре дә якташларына караган кебек карыйлар.

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) – *драматург, прозаик. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Дистәдән артык китап, иллегә якын пьеса һәм күпсанлы җырлар авторы. Казанда яши.*

– Чын Казан татары шундый булырга тиеш инде ул, – дидем мин. – Безнең урам очында кафе бар. Кереп тамак чылатып, капкалап алмыйбызмы?

– Була ул. Бүген рульгә утырмыйм инде, иртәгә, берсекөнгә – ял. Өйдә бүген ашарга пешерүче юк. Хатынны әбиләренең авылына саф һава суларга илтеп куйдым. Якшәмбе кичендә барып алам. Өйгә кереп кулларны юып чыгарга кирәк.

– Кафеда юарбыз, – дидем мин.

Без кафе ябылганчы сөйләшеп утырдык. Ул миңа бер вакыйганы, язмышына кинәт көтелмәгән борылыш ясаган тетрәндергеч хәлне сөйләде.

– Бу турыда язарга ярыймы, рөхсәт бирәсеңме? – дип сорадым мин, инде өйгә кайтып җитәрәк.

Ул беравык башын аска иеп, дәшми барганнан соң:

– Үзеңә кара, – диде.

Бу инде аның ризалыгын алдым дигән сүз.

**2**

Ике мең дүрт йөз җитмеш сигез ел элек Кос утравында дөньяга килгән грек табибы монда туса, кем булыр иде икән? Табиблар нәселеннән җиргә аяк баскан бу бөек зат бүген, безнең илдә, безнең шартларда дәвалаучы яки минем кебек хирург булып эшли алыр иде микән? Сәер сорау. Хәтта мәгънәсез сорау түгелме? Ләкин менә шундый карап торуга тозсыз тоелган сораулар, телисеңме-теләмисеңме, гел калкып торалар. Әгәренки алар туа икән, бәлки, тикмәгә түгелдер? Бәлки, кайсыдыр бер җитди, төпле, иң зур сорауга җавап кирәклектән мондый вак-төяк уйлар да яшәргә хаклыдыр.

Шушы уйлар белән Рәмис машинасына таба атлады. Нишләп болай соң: һәр операциядән соң, уңышлы үтүгә карамастан, әллә нинди сораулар баш миен тинтерәтә. «Ни җитми сиңа, Рәмис?!» – дип куя ул үзенә. Аллага шөкер, баш бар, куллар нык, эшлисе килә, белем җитәрлек, коллективта абруе зур.

Әллә соң алга таба да тормыш һәрвакыт шулай талгын агым белән бармаячагын сиземләүдәнме бу? Ә нигә әле гел каршылыклар, киртәләр, авырлыклар көтеп яшәргә?..

Киләчәктән шүрләү, алда буласы котылгысызлыклардан курку табигыйдер инде ул. Ялгышларсыз, хаталарсыз яшәү мөмкин дә түгелдер. Иң оста пешекче дә суган тураганда, еш кына бармагын кисеп җәрәхәтли. Иң оста атлетның да егылмый калганы юк. Төзеклеге камил саналган самолётлар да кайчак һәлакәткә юлыга. Дөрес юлдан барам дигән зур җитәкче дә кайвакыт чалыш юлга кергәнен соңыннан гына аңлый. Ә хирургның эше, ахыры уңышлы тәмамланган сурәттә дә, шундук сөенә торган түгел, күпмедер вакыт үткәнен көтәргә кирәк, хәтта еллар узгач кына бәяләп була торганнары да бар.

Машинаны кабызгач та кузгалырга ашыкмады әле ул. Тагын бөек грек тынгылык бирми.

«Медицина – иң затлы, иң игелекле сәнгать, – ди ул. – Әмма кайбер надан әтрәк-әләмнәр аркасында, алар җәзасыз кала биргәндә, медицина башка сәнгать үрнәкләре фонында бик түбән төште. Бу күренешнең иң төп сәбәбе – дәүләт тарафыннан оятсыз, намуссыз бәндәләрнең җәзага тартылмаулары. Иң зур җәза – залимлек икәнне онытучылар күбәйде...»

Оятсыз, намуссыз кешегә залимлек нәрсә ул? Кем икәнен чыраена бәреп әйтсәң дә, төкерә ул синең сүзеңә һәм синең үзеңә.

Бөек грекның медицинаны сәнгатькә тиңләве кызык. Бәлки ул заманнарда сәнгатьнең дәрәҗәсе кеше җанын дәвалау югарылыгында булгангадыр.

Уй-фикерләр бер логика буенча гына барса, мондый киеренкелек кичермәс идем. Һәр уемның әллә ничә тамыры, әллә ничә тармагы бар. Һәр тармакка яңа уй-сораулар ялгана, ә яңаларының исә һәрберсе әллә ничәгә ботаклана да, аларында янә яңа уйлар бөреләнә.

Һәр өлкәдә, һәр нәрсәдә, һәр кешедә җитешсезлекләр күрү – синең камиллеккә омтылуыңның галәмәтедер ул, бәлки. Алайса, асылда, үз-үзеңнән канәгать булмауның аермачык билгесе түгелме соң ул?

Димәк, җиң сызганып, үз принципларыңа таянып, үз эшеңне дәвам итү мәслихәт. Фәкать шул гына кала. Ә бит моның өчен уңай шартларның булуы зарур. Икенче яктан караганда, беркемгә дә аерым уңай шартлар беркайда әзерләп куелмаган. Бер тарафта да: «Хуш киләсең!» – дип колач җәеп каршы алмыйлар. Кешеләр дөньясы бу.

Бәлки, арада комсызлар, хөсетләр, акча белән саташучылар булганга бу уйлар киләдер? Ришвәтчелек, гаделсезлек, әшнә-кодалык, профессиягә җиңел карау, җавапсызлык – боларның барысы да теге яки бу формада көн саен диярлек күзгә ташлана. Медицина өлкәсендә имәнгеч кенә түгел, гайре табигый булырга тиешле күренешләр дә гел очрап тора...

Ә менә бу уйларны бөтенләй баштан алып атарга кирәк. Юкса, кулларның бөтенләй салынып төшүе ихтимал.

Стоянка сакчысы белән берничә яшүсмер талаша. Кеше өчен иң кадерле нәрсә сәламәтлек икәнне болар әле аңламый. Сәламәтлекнең бөек байлык икәнен бу яшьләргә аңлатып та булмый. Тыгыз гәүдәлесе аты-юлы белән сүгенә. Шунысы кызык: яшәү мәгънәсе һәркемнеке үзгә һәм үзенеке – үсмерләрнеке бер төрле, сакчыныкы икенче төрле, минеке бөтенләй башка, баш табибныкы исә беребезнекенә дә охшамаган.

Ни гаҗәп: караңгы уйлар күңелнең кайсыдыр почмагына җайлы гына ятып, күпмедер дәрәҗәдә аңлатып булмаслык рәхәтлек тә бирә. Күрәсең, андый уйлар кирәк. Ник операциядән соң андый уйлар өере ныграк кайный? Җавапны әллә каян эзлисе юк. Пациент белән операция өстәлендә «очрашып», аның фаҗигасен күзең белән күреп, аң белән аңлап, җаның белән тоеп, ике куллап аны упкыннан тартып чыгарырга тырышканнан соң, хисләреңне, уйларыңны йөгәнләү, авызлыклау ничек мөмкин булсын?!

Дөньяның асылында фаҗига ята. Моны үзе бәлагә дучар булганчы, кеше аңламый, белми. Кешелек дөньясының фаҗигалелеге һәр кешенең үзенә күпмедер өлешенчә салынган, аның үзегендә акыл белән генә абайланмаслык яман чыганак бар. Тирән акылга ия булмаса, кеше моңа гомере буена төшенмәскә мөмкин. Шуңа күрә дә бит халык һәм бала-чага шау-шулы, фейерверклы, салютлы, чуар чәчәкле, кабартма шарлы буш бәйрәмнәрне ярата.

Кайчан да булса бәлагә дучар буласын белсә, кеше, мөгаен, бөтенләй башкача яшәр иде, дөньяга һәм башка кешеләргә мөгамәләсе икенче булыр иде. Әмма киләчәктә көткән фаҗигаләр турында белү дә кешене яхшы якка үзгәртер, миһербанлы итәр дип ышанырга мөмкинме икән?..

Булды, җитте. Бу уйларның бер мантыйк һәм бер сызык буенча гына барасы юк. Бер-берсенә бәйләнерлек булмасалар да, алар бөтенләй көтмәгән яктан үзара ялганалар да, аларны ни чишә, ни өзә алмыйсың. Булды, җитте.

Әнә, җәнҗал куптарган үсмерләр дә китеп барды. Стоянка сакчысы читкәрәк каерылып, бер төкерде дә, будкасына кереп китте.

Менә машина янында чыпчыклар чыркылдаша. Нинди ямьле күренеш – нәни генә кошчыклар үзләренең яшәү мәгънәсен тапканнар түгелме? Алар яшәү бәхетен аңламасалар да, Әбелхәятнең ямен-тәмен мизгел саен, һәр күзәнәкләре белән тоеп, кешеләргә үрнәк бирергә теләгәндәй, аваз салалар, пырхылдыйлар, кыска гына канатларын кагып, барлык җан ияләрен куанырга өндиләр. Аларның яшәү сөенечен күзәткәч, апрель аеның тәмамланып килүенә, озакламый җәйнең чәчәк атачагына ышанмый мөмкин түгел.

Тагын бер хезмәт көне үтте. Операция уңышлы тәмамланды. Миңа егерме сигез яшь. Алда гомер диңгезе җәйрәп ята. Перспективага хилафлык килерлек бернәрсә сизелми.

Аны, гадәттәгечә, сөйгәне Мәликә көтә. Һәрвакыттагыча, ике күзе тәрәзәдәдер.

**3**

Мәликә инде әллә ничәнче тапкыр тәрәзәдән тышка күз салды һәм плащын җилфердәтеп эре адымнар белән килүче Рәмиснең кул болгавын күргәч, йөрәгенең ешрак тибә башлавын тойды. Нәкъ беренче очрашулардагы кебек. Тагын буянып-ясанып куярга җитешә алмадым бит инде, дип үзен битәрләп куйды ул.

Бусагада чәчәк бәйләме тотып Рәмис пәйда булгач, никтер үзен гаепле сизгәндәй булды, йөзенә кызыл төс йөгерде.

– Исәнме, тәти кыз! – диде Рәмис, чәчәк бәйләмен кызга тоттырып.

Ул аңа гел «тәти кыз» ди, чөнки Мәликә ярата алай диюен. Аның бу ике сүзеннән Мәликәнең чынлап та нәни кызчык та буласы килә, курчакка әверелергә дә риза, хәтта бу көчле куллы чибәр ир-егетнең башка төрле бер кечкенә уенчыгы булып калырга да әзер.

– Исәнме! Көннән-көн затлырак чәчәкләр алып киләсең, – диде ул, аларга бите белән кагылып.

– Син үзең дә көннән-көн гүзәлләнә барасың.

– Кая инде... – диде Мәликә, читенсенеп. – Әле бүген син килүгә кыяфәтемне дә рәтләргә өлгермәдем.

Рәмис аны кочып битеннән, иреннәреннән, чәчләреннән үпте.

– Синең рәтлисе җирең юк, син һәрчак гүзәл, – дип пышылдады ул.

Алар шактый вакыт бер-берсеннән күзләрен алмый елмаеп тордылар.

– Ашыйсың киләме? – диде Мәликә, Рәмиснең плащын элеп.

Ә Рәмис кызның менә шушы ике сүзен бик ярата. Ашыйсы килмәсә дә, хатын-кыздан бу сорауны ишетү һәрбер ир-атка рәхәт.

– Юк, минем тамак тук. Операциядән соң үзебезнең ашханәдә ашадым.

Рәмис диванга барып утырды һәм хәзер әйтәсе сүзе кызга ничек тәэсир итәр икән дип уйланып торганнан соң, тәвәккәлләде:

– Өйдәгеләргә: «Бүген кичке ашка Мәликәмне алып киләм», – дидем.

Мәликә дерт итеп куйды:

– Бүген?! Әй, юк, әйдә башка көнне.

– Кайчаннан бирле шулай дип киләсең. Үзебез өйләнешергә йөрибез, ә синең әле әниемне бер тапкыр да күргәнең юк, – диде Рәмис, чак кына шелтә белгертеп.

– Анда бит синең әниең генә түгел, – диде Мәликә һәм чәчәкләрне вазага урнаштырырга тотынды.

– Мәҗит Нәҗипович та куркыныч кеше түгел. Аның бездә яшәп ятучы

улы гына килде-киттеле шалапай, әмма син аспирантка башың белән аның ишеләрдән оялырга тиеш түгел, – диде Рәмис.

Аның тавышында эчке борчылу чагылды – Мәликә ул малайның зур проблема икәнлеген Рәмистән гел ишетеп тора.

– Укый аламы соң ул ичмаса? – диде Мәликә, янәшә утырып.

– Әтисе абруйлы кеше булгач, укытып йөрткән булалар инде шунда. Институтта укырлык егет түгел инде ул. Әтисе зур вазифада, әшнәләре күп. – Рәмис көлемсерәп куйды. – Таптык сөйләшер сүз, – диде ул, кызның кулын тотып. – Мин сагындым сине. Операциядән соң, караңгы уйлар, томанлы күренешләр арасында синең сурәтең чагылып-чагылып китә дә, күңелгә яктылык керә. Ярый син бар әле. Әйдә, хәзер үк безгә киттек.

Мәликә хәтта сискәнеп куйды:

– Туктале... Уф, йөрәгем...

– Курыкма, минем кардиохирург дустым бар, ул-бу була калса, йөрәгеңне тиз арада рәткә кертербез, – дип шаяртты Рәмис.

– Алар мине ничек кабул итәрләр икән соң?

– Минем сөйгәнемне ничек кабул итсеннәр инде, – диде Рәмис, кызны иңеннән кочып. – Иманым камил, син әнигә бик тә ошаячаксың.

– Ә үги әтиеңә?

– Ә аңа нишләп ошамаска тиеш син! Мәҗит Нәҗипович – зыялы кеше. – Рәмис көтмәгәндә уйга калды. – Ул безнең белән тора башлаганда миңа сигез яшь кенә иде... Егерме ел үткән... Мине тәрбияләүгә өлеш кертсә дә, үземә бигүк якын кеше булалмады инде ул. Башлы, акыллы кеше үзе. Әйбәт кеше... – Ул кинәт уйларыннан арынып җанланды: – Әйдә, җыен!

Әмма Мәликә кузгалмады:

– Туктале, ашыктырма.

Рәмис текәлеп карады:

– Кәефең кырылган шикелле...

– Әле генә уйга калганыңны күргәч, миңа да моңсу булып китте. Әнине кызганам, – диде Мәликә боек тавыш белән. – Алар да әти белән аерылыштылар. Әти, үзенә яңа хатын табып, Можга тарафларына олакты. Әни башка иргә чыкмады. Мин бердәнбер бала. Аерылышканга әни үкенми дә, уфтанмый да. Әти – бик авыр холыклы, үзен генә яратучы, каты кеше. Көнләшеп, әнине бимазалады. Алар аерылышканда, миңа ундүрт яшь иде. Үсмер вакытта андый конфликтлар бик авыр тәэсир итә бит.

– Әти барыбер әти инде ул. Аралашасызмы соң?

– Телефоннан. Былтыр ел азагында мин аларга барып та кайттым әле. Тормышлары бигүк тынычка охшамаган. Аларның уртак балалары булмады. Әти дә кызганыч инде. – Ул тирән итеп сулап куйды. – Рәмис, дөресен әйткәндә, минем кәефсезлегем әтием өчен борчылудандыр, мөгаен. Аңа бик куркыныч хәбәр әйткәннәр бит әле. «Рак предстательной железы» дигән шик белдергәннәр. ПСА нәрсә ул?

– Простато специфический антиген. Онкомаркер.

– Канында менә шул ПСА дигән нәрсә егермене тәшкил итә икән. Күпме ул?

– Күп. Нормада дүрттән артмаска тиеш. Томография үткәнме?

– Үткән.Томографиядә төгәл ачыклый алмаганнар.

– ПСА саны егерме булгач, кичектермичә, биопсия ясатырга кирәк.

– Анысы нәрсә тагы?

– Анализ өчен простатаның җепселләрен алалар да, гистология үткәрәләр.

Анда инде барысы да төгәл ачыклана – ракмы, юкмы. Рак булса, аның нинди төре, стадиясе... Һәм нинди дәвалау кирәклеге, операцияме, лучевая терапияме... Әйдә, этиеңне монда алып киләбез дә яхшылап тикшертәбез. Үземнең күзәтүем астында. Бездә яңа җиһазлар. Яман шешнең башлангыч стадиясе булса, озакка сузмыйча, радикаль операция ясау мәслихәт. Кирәк булса, операцияне үзем ясармын.

– Аны монда алып килеп, операция ясарга рөхсәт булырмы соң?

– Оештырам мин аны. Иртәгә үк сөйләшә башлыйм.

Мәликәнең күзләре дымланды, елаудан чак кына тыелып:

– Кайлардан очрадың син миңа?! – дип, дерелдәгән иреннәре белән егетне битеннән үпте.

– Язмыш ул, – диде Рәмис.

– Язмыш... – дип уйга калды Мәликә һәм кыюсыз гына сорап куйды: – Никахны кайда укытабыз соң?

– Аны кыз ягында укыталар инде, – диде Рәмис һәм торып киерелеп куйды. – Ә туйны, әлбәттә, үзебездә гөрләтәчәкбез, – дип, көр тавыш белән өстәде ул.

– Кайда яшәрбез?

– Бездә. Монда, синең съемный фатирыңда яшәмәбез бит инде. Бераздан фатир сатып алырбыз, бер бүлмәлене булса да.

Рәмис Мәликәнең кинәт пошаманга калганын күрде һәм моның нидән икәнен дә аңлады. Рәмисләр фатирында бөтенесе бер түбә астында яшәячәкләр – Мәликә шуңа шөбһәләнә.

– Үги этинең малае тагын ике елдан укуын тәмамлый да Уфасына кайтып китә, – диде Рәмис. – Бәлки, иртәрәк тә ычкыныр, чөнки укуын тәмамлыйсына бигүк ышанып җитмим әле мин. Әйдә инде, утырма. Киттек.

– Каушыйм, – диде Мәликә, чыннан да каушаганына ышанырлык итеп.

– Әни – менә дигән олы җанлы кеше, Мәҗит Нәҗипович та тар күңелле түгел.

– Нәрсә киим икән? – дип, әрле-бирле йөри башлады Мәликә.

– Ни кисәң дә ярый. Сылу кешегә солы капчыгы да килешә, – диде Рәмис, елмаеп.

Мәликә күкрәк тутырып сулыш алды да:

– Мин тиз генә юынып чыгыйм инде алайса, – диде.

Мәликә ванна бүлмәсенә кереп киткәч, Рәмиснең башында бер генә уй урын алды: Мәликәнең этисен монда алып килеп, җентекле диагностика үткәрү. Кичектерергә ярамый!

Шифоньер ишеге ачык. Анда Мәликәнең киемнәре. Танышканда, әнә теге сары көрән курткадан иде ул. Рәмис ял көннәрнең берсендә Сәүдә үзәгенең йорт җиһазлары кибетенә барды – өйгә яңа диван аласы бар иде. Ошаган диван табылмады, үтеп барышлый шул ук сәүдә йортының ОБИ дигән кибетенә керде. Анда күз явын алырдай гөлләр, чәчәкләр саталар. Шунда йөргәндә, төз буйлы, мөлаем йөзле, матур тавышлы бер кызның сатучы хатын белән сөйләшүе колакка чалынды. Сүз нindидер экзотик гөлләр хакында бара иде. Озынча буйлы, төз гәүдәле бу кызның тавыш тембры да, бераз көйләп сөйләве дә матур. Зәңгәр күзләр, төз борын, ике кызыл чияне хәтерләткән иреннәре, чәчләрен артка җыеп куйганлыктан йөзенең һәр сызыгы, һәр чалымы дөрес һәм төгәл яратылган икәне аермачык беленә. Төс-битеннән күренеп тора – моңарда угро-фин каны бар. Казан татарлары арасында азмыни марига, удмуртка охшаган кешеләр.

Рәмис кызларның сөйләшкәнен тыңлап торды. Әңгәмәнең эчтәлеге түгел, сатучыга акыллы киңәшләр бирүче гүзәл кызның күңел грациясе үзенә тартты.

Аларның әңгәмәсе тәмамлангач, Рәмиснең дә үсемлекләр буенча гыйлемле бу гүзәл зат белән сөйләшәсе килә башлады.

Исәнләшеп, гафу үтенеп, Рәмис аңардан юри генә киштәдәге берничә гөл турында сораштырган булды. Кыз акыллы итеп аңлатып бирде. Исеме Мәликә, университетның биология факультетын тәмамлап, аспирантурада укый икән. Мәликә орхидея чәчәге алырга килгән. Рәмис аңа орхидеялар арасыннан иң матурын алып, бүләк итте. Аннары кафега кереп, кичке ашны ашадылар. Шул көннән үк башланды аларның мәхәббәте.

Мәликә – тыйнак, акыллы, зыялы кыз, Мари республикасында туып-үскән. Әтисе гомер буе йә завсклад, йә учётчик булып сәүдә складлары тирәсендә хезмәт иткән. Әтисенә түгел, әнисенә охшагандыр Мәликә. Әнисе турында ул шундый матур итеп сөйли, хәтта шигырь яки җыр тыңлаган кебек буласың. Әнисе мәдәният институтын тәмамлаган, озак еллар музыка училищесы директоры булып эшләгән, хәзер исә Волжск районының мәдәният һәм спорт бүлеге белән идарә итә икән.

Гаҗәеп хәл – танышканнарына инде бер ел була, ә тәрәзә төбендәге Рәмис бүләк иткән орхидея шушы ел эчендә инде өченче тапкыр киерелеп чәчәк атты. Бу бит тикмәгә түгел – димәк, бу гөлне Мәликә җан җылысы белән яратып карый.

## 4

Хәлилә белән Мәҗит ашарга утырганда, Навил кайтып керде – гадәттәгечә, йончыган кыяфәттә. Кыршылып беткән күн курткасын элмәде, ишек катындагы утыргычка ташлады, шуннан соң пычранып каткан кроссовкаларын көч-хәл белән аякларыннан ычкындырды.

– Син, малай актыгы, кая югалдың? – дип җикеренде Мәҗит.

– Кая югалыйм мин, югалмадым, – дип, борын төбенә мыгырдады Навил.

– Бер атна өйгә кайтмадың, укырга да йөрмисең икән...

– Йөрим, нишләп йөрмәскә.

– Алдама! Ректор үзе шалтыратты. Күпме мине оятка калдырып йөрерсең икән син?! Укыйсың килмимени?

Навил чыраен сытты:

– Нишләп килмәсен.

– Кайда йөрдең?

– Бөтенесен сөйлиммени?

– Кайда кундың атна буе?

– Дусларда.

– Син кайчан азгынлыктан туктыйсың?

– Ник кайтып кермәс борын ябырыласың соң син миңа?! – дип көтмәгәндә тавышын күтәрде Навил.

Бу малайдан инде тәмам туйса да, Хәлилә аны барыбер кызгана. Әтисе төпле, акыллы, җитди кеше. Әгәр дә Навил тулы гаиләдә тәрбияләнсә, Мәҗит кебек булмас идемени? Әнә бит ул төс-биткә, кыяфәткә әтисенә ничек охшаган. Әтисе кебек үк базык гәүдәле, бераз кәкрерәк аяклы. Чырае да Мәҗитнеке – җәйпәк борын, юка иреннәр, шакмаклы ияк, куе кара чәч. Әтисеннән аермалы буларак, башы гына бәләкәй һәм чем-кара күзләре бер-берсенә чамадан тыш якын урнашкан. Һәм инде холкы һич кенә дә әтисенекенә охшамаган.

Беркавым ата белән улның әрләшүен тамаша кылып тыңлап утыргач, Хәлилә ике якның да чамадан тыш кайнарлануын чамалап, телгә килде:

– Навил, балакай, атаң әйткән сүзне инкарь итмә. Егерме бер яшь бит инде сиңа. Сиңа яхшылык кына телибез бит, шуны аңламыйсыңмыни? Утыр, ашарга салам.

Навил өстәл янына утырды һәм:

– Ашыйсым килми, – диде. – Кайтып керү белән талый башлагач, нинди аппетит булсын!

– Юынып чык та ятып йокла! – диде Мәҗит усал тавыш белән. – Кыяфәтең эт ялаган төсле.

– Хәлилә апа, чәй яса әле, – диде Навил, чак кына ишетелерлек итеп.

Чәен теләр-теләмәс кенә эчеп утырган Навилгә ике яклап нотык укып, бусагада Рәмис белән Мәликәнең пәйда булганын абайламый да калдылар.

– Менә без дә кайтып җиттек! – диде Рәмис ишек катыннан тантаналы тавыш белән.

Мәликә каушавын һич җиңә алмыйча, көчкә:

– Исәнмесез, – дип әйтә алды.

– Менә, таныш булыгыз, минем Мәликәм шушы инде.

Хәлиләнең шатлыгы ташып чыкты:

– Исәнмесез, исәнмесез. Әйдә, кызым, уз. Рәмис синең турыда көн саен сөйли, – диде ул, кызның курткасын үзе элеп. – Мин сине нәкъ шушындый итеп күз алдыма китергән идем, сөбханалла. Әйдә, уз, кызым.

– Мәҗит Нәҗипович булам, – диде гаилә башлыгы.

Мәликә чак кына баш иеп җавап бирде.

– Монысы минем улым Навил, – диде Мәҗит, тавышындагы усаллыкны яшермичә.

Навил исә эреләнеп, кирәгеннән артык кылану белән:

– Навил Мәҗитович булам, – диде. Шуннан соң чәен шопырдатып эчеп куйды да: – Туйны кайчангарак планлаштырасыз? – дип, пырдымсыз сорау бирде.

– Телеңә салынма! – дип ысылдады Мәҗит.

Навил күзләрен әйләндереп башын читкә борды:

– Бу фатирда һава кими бара...

Рәмис, малайның тәрбиясезлегенә ригаясез була белсә дә, бу юлысы аны урынына утыртырга кирәк тапты:

– Монда һава җитмәсә, Уфаңа кайтып китәрсең.

– Белә-ә-әм миннән туйганыгызны, – дип киерелеп куйды Навил.

– Туярсың да. Синең дорфалыгыңнан, пырдымсызлыгыңнан инде сару кайный башлады, – диде Рәмис коры гына.

Хәлиләнең куанычы эченә сыймый, шуңа күрә боларның әйткәләшүе эчне пошырса да, күңелдәге шатлыкны таркатырлык түгел иде.

– И балалар, кунак янында әйткәләшеп утырмагыз инде, – диде ул, ягымлы итеп.

– Мәликә кунак түгел, ул инде безнең гаилә кешесе, – диде Рәмис, энисенең канатлануыннан зур канәгатьлек белән.

Өстәл янына утырышканда, Хәлилә үзалдына:

– Күз генә тимәсен, – дип куйды.

Навил моны ишетте һәм кулларын як-якка җәеп киерелеп куйды да:

– Минем күзем тигәнче ятып йоклыйм әле мин, – дип көлемсерәде. – Минем

күз тисә, кешенеке ише генә булмас, – дип өстәде дә кет-кет көлә-көлә йокы бүлмәсенә кереп китте.

Рәмис Мәликәнең кулына кагылып алды:

– Игътибар итмә кыргыйга, аның сөйләшү манерасы шундый.

Мәҗитнең күңелендә исә буран купкан иде инде. Урынынннан торып, ул:

– Мәликә, мин бик шат сезнең белән танышуыма, – диде һәм, Хәлиләгә карый-карый, җиңел пәлтәсен, эшләпәсен киде. – Минем барып кайтасы җирем бар.

– Кая җыендың? – диде Хәлилә, аптырап.

– Ректорны барып күрим әле. Җан тыныч түгел.

Өчесе генә калгач, Мәликә иркен сулап куйды.

– Мин бик шат, – диде Хәлилә, тәлинкәләргә пилмән салганда. – Кызым, син тартынып утырма. Кайчан безгә күрсәтәсең Мәликәне дип, Рәмиснең теңкәсенә тидем инде мин.

Рәмис көлә-көлә әнисенең кайчан өйләнәсең инде дип, көн саен бәйләнүен, һәр иртәнең шул сорау белән башлануын һәм һәрбер кичнең шул сүз белән тәмамлануын әйтеп куйды. Шуннан соң өйләнешү турында һәм яшь гаиләләр хакында төрле мәзәк хәлләрне сөйләштеләр, хәтта бер-ике анекдот та әңгәмәдә урын алды.

Өйгә бәйрәм төсе керде. Кичке аш җан ризыгына әверелде.

Ана үзенең улы белән булачак киленгә карап сокланып туймады. Әңгәмә дә бер артык сүзсез, ниндидер табигый агым сыман талгын гына акты. Өч үзәктән саркыган күңел тынычлыгы бу йортта мәңгелек иминлек урнаштырыр һәм монда беркайчан, бернинди кайгы-хәсрәт, михнәт-афәт керә алмас сыман тоелды. Өч сәгатькә якын вакыт өч минуттай сизелми дә үтеп китте. Рәхәт вакытның үтеп китүе сизелми шул. Бәхетле минутлар, якты көннәр бик тиз үтә ул – сизми дә каласың. Әллә соң гомер тиз үтмәсен дип, Ходай бәхетле көннәрне аз бирәме кешегә? Хәер, бәхетне кайда, кайчан, нәрсәдә табасың, Ходай кушканның кай төшендә үзеңне бәхетле тоясың – һәр кешенең үзеннән тора түгелме? Туганнан бирле, гомер кояшы баеганчы, рәхәт чигеп кенә, гел кәеф-сафа корып, бәйрәм итү насыйп булса, яшәмәгән дә төсле булыр идең. Кайгы-хәсрәт башыңа төшсә генә, вакытны чын-чынлап тою һәм гомереңнең юлын, бормаларын, сикәлтәләрен, чорларын хәтерләү мөмкиндер.

Бу кич бик якты булып чыкты, хыял-ниятләр омтылган киләчәкнең ерак офыкларына кадәр сузылды аның яктылыгы.

Мәликәнең куна калырга теләмәвенә генә бераз аптырадылар. Әмма кызны аңлап була – читенсенә, ояла. Бу аны яхшы яктан күрсәтә торган сыйфат лабаса.

Мәликәне илтәсе булганга, Рәмис машинасын җайлабрак куйыйм дип чыгып киткәч тә, ана белән Мәликә арасында бернинди уңайсызлык сизелмәде. Алай гына да түгел, Мәликәгә Хәлилә белән генә калгач, тагы да рәхәтрәк булып китте. Рәмиснең әнкәсен инде ярата ук башлады ул. Үз кешеләр алар, үз кешеләр.

Мәликә игътибар итте: Хәлиләнең йөзе мөлаем, тавышы да матур. Сүзләрен көйгә салып әйтә шикелле, сөйләгәндә, һәр җөмләсе җанга ятыш килеп чыга.

– Берүк, Алла кушып, бәхетле булыгыз, балакайлар, – диде ул, никтер әле генә улы чыгып киткән ишек тарафына карап. – Улымның өйләнүен түземсезлек белән көтәм инде мин. Язмыш бик бормалы булды да, күңел гел тынгысызланып тора, тизрәк улымның үз гаиләсе булуын телим.

Хәлиләнең ихласлыгыннан Мәликә хәтта артык кыюланып та китте:

– Сез үзегез Рәмиснең әтисе беән өйләнешергә дә өлгерә алмагансыз икән, – дип әйтеп ташлаганын үзе дә сизми калды.

Телен тыя алмаганга үкенеп куйды, әмма Хәлиләгә авыр тәэсир итмәгәнне күреп, шундук тынычланды.

– Әйе шул. Васил белән никах укытырга өлгермәдек. – Хәлиләнең тавышында матур тембрлар югалмады, бары тик тирәннән калыккан якты сагыш төсмерләре генә өстәлде. – Никахсыз килеш бала тапкан икән дип гаҗәпләнүең дә ихтимал. Илнең асты өскә килә башлаган чак иде... Бик ярата идек без бер-беребезне... Тормыш ыгы-зыгысында бер-беребезне югалтудан курыктык. Мин авырга уздым... Ә теге көнне... Васил бергә эшли торган дусты белән кемнеңдер туган көнендә иде. Йөкле икәнемне белгәч, мин аңа елап шалтыраттым. Ул вакытта кесә телефоннары юк иде әле... Шул фатирның телефон номерын белә идем. Шалтыраттым. Васил, машинасына утырып, минем янга чапкан... Чуйков урамыннан Ибраһимов проспектына борылганда, тәгәрмәче ычкынып, баганага бәрелгән.

Азагы тетрәндергеч, фаҗигале булуга карамастан, вакыйганың романтикасы да юк түгел иде. «Баланы сакларга ничек батырчылык иттең?» – дип, чак кына сорамый калды ул. Ә Хәлилә аның нинди соравы туганны, әлбәттә, сизенде һәм яңгырамаган сорауга җиңел генә җавап итеп әкрен генә аңлатты:

– Әти-әнидән шактый эләкте миңа. Капма-каршылыклы тәкъдимнәр ясый-ясый, бик каты орыштылар. Минем белән бергә кайгырдылар да. Ә Рәмис тугач, бернинди шелтә калмады. Васил белән безнең бер-беребезне ничек яратканыбызны алар бит күреп-белеп тордылар. Без Дәрвишләр бистәсендә яши идек, үз йортыбыз белән. Мин тегүчегә укыган идем. Әти-әни ярдәменнән башка, бала белән, аякка басу мөмкин түгел иде. Баланы саклап калуыма сөенеп туймыйм. Күз генә тимәсен берүк улыма. Сигез ел иргә чыгу турында уйламадым. Менә, Мәҗит очрагач, ышанычлы кеше икәненә инангач, Рәмискә дә мөнәсәбәте яхшы булгач, аңа чыктым инде. – Хәлилә сөйләүдән туктап, хәл алды. – Әмма егерме ел эчендә Рәмис аңа бер генә тапкыр да әти дип эндәшмәде. Гел исем-отчествосы белән генә атады. Әтисе һәлак булганда карында гына иде югыйсә, әмма үз әтисен бер тапкыр да күрмәгән килеш, аны сагынып яши, балакаем. Үсмер вакытында ук: «Ник Мәҗиткә әти дип эндәшмисең инде, улым?» – дигәч, «минем үз әтием бар, ул мине каяндыр гел күзәтеп тора», – дип җавап биреп мине шаккатырган иде. Мәҗит белән очраштырганы өчен дә Ходайга гел рәхмәтләр укыйм. Мәҗитнең ярдәме белән, берничә кеше җыелып, үзебезнең ательены ачтык. Ул хәзер минем шәхси ательем. Элеккеге кебек керемле түгел, әлбәттә. Шулай да, кем әйтмешли, «тамып тора» һәм, иң мөһиме – үземнең яраткан эшем бар. Мәҗит үзе әллә ничә төрле бизнес белән шөгыльләнде, хәзер инде зур оешмада абруйлы вазифада. – Хәлилә сөйләүдән туктап елмайды. – Балакаем, мин бик күп сөйлим бугай, ялыктырмадыммы?

– Юк, – дип кенә әйтә алды Мәликә. Башка сүзе чынлап та юк иде, күз яше генә бите буйлап муенына төшеп эреде.

Әйтерсең лә, боларның тынып калуларын гына көткән – йокы бүлмәсеннән күзләрен чекрәйтеп, аякларын көчкә сөйрәп, Навил чыкты.

– Башкалар кайда? – дип сорады ул тыңкыш тавыш белән.

– Әтиең ректор янына китте, Рәмис машинасын күчереп куярга чыкты.

Навил чәйнектән чынаякка су салып, голт-голт иттереп эчте дә:

– Хәлилә апа, ике мең сум бир әле миңа, – диде.

– Әтиең биш мең биргәние бит, бетте дәмени?

– Биш меӊ акчамыни ул? – дип мыгырдады Навил.

– Әтиең рөхсәт итсә генә бирәм.

– О-о-о, алайга калгач, булмый икән. Яратмыйсыз сез мине, – диде Навил.

– Оят түгелме алай дияргә! Болай да сине өф-өф итеп кенә торабыз бит инде. Шалтай-балтай йөрүдән туктарга кирәк. Әтиеңнең сүзенә колак сал, сиңа бит инде егерме бер яшь, акыл керер вакыт.

– Ярар, син дә миңа вәгазь укыма инде, әтинеке дә колакта гел чыңлап тора, – диде Навил һәм беравык Мәликәгә текәлеп карап торганнан соң, янә йокы бүлмәсенә кереп китте.

– И бала, бала, – дип авыр сулап куйды Хәлилә. – Уфада әнкәсенең теңкәсенә тиеп үскән, хәзер монда әтисенең җелеген суыра. Аны гаепләп тә булмый бер карасаң. Мәҗит гаиләсеннән киткәндә, аңа бер яшь кенә булган. Атасыз үскәч, ачу-үпкә күңеле тутыруктыр инде.

«Ата булуы-булмаудан гына тормыйдыр инде ул, – дигән уй белән Мәликә бер ноктага текәлде. – Әнә бит, Рәмис тә әтисез үскән...»

Хәлилә аның ниләр уйлаганын аналарга хас акыл зирәклеге белән аңлады.

– Рәмиснең әтисе үзе дә бик әйбәт егет иде, – дип, күз яшен сыпырып алды ул. – Егерме дүрт яшендә харап булды шул Василым.

Мәликәнең уйлары кинәт башка юнәлеш алды, аның үтә җитдиләнеп китүенә Хәлилә хәтта гаҗәпләнеп тә куйды.

– Гел тыныч, имин генә яшәүчеләр бар микән ул? – диде Мәликә, авыр сулап. – Ә менә мин үзем әти белән әни аерылышканга сөендем. – Хәлилә артык сораулар биреп тормады, кыз үзе сәбәбен әйтте: – Әтием авыр, каты холыклы кеше булгангадыр инде. Ләкин, ничек кенә булмасын, әтиемне барыбер яратам, сагынам.

Әтисендә рак булуы ихтимал икәнне, Рәмискә бу хакта әйткәнен һәм, кирәк булса, операцияне үзе ясаячагын тыңлагач, Хәлилә:

– Алла рәхмәтеннән ташламасын берүк, – диде. – Операция кирәк булса, аны, әлбәттә, Рәмис ясарга тиеш.

Кәефләр сүрелә башлаган мәлдә ишек ачылганы ишетелде. Бу Рәмис иде.

– Ничек, уртак тел табып буламы? – диде Рәмис кергән уңайга, елмаеп.

– И-и-и, мондый затлы кыз белән ничек уртак тел табылмасын, – диде Хәлилә шат тавыш белән, күңел халәтенең очрашкан минутлардагы хәленә кинәт күтәрелгәненә куанып. – Хәзер табынны җыештырам да, рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз.

– Мин булышам, – дип, Мәликә җәһәт кенә урыныннан торды.

Алар икәүләшеп табын җыештырып, аннары табак-савыт юарга киткәч, Рәмис үзен дөньяда иң бәхетле кешедәй хис итте. Өйләнешкәч, алар гел бергә булачаклар бит. Кухня тарафыннан ана белән булачак киленнең тонык кына ишетелгән сөйләшкәне, табак-савыт шалтыравы, нидәндер кызык табып көлеп куюлары – моннан да күңеллерәк, якынрак җылы авазларның булуы мөмкинме хәзергесе вакытта!

Мәхәббәт бар икәнне кеше белә, ләкин мәхәббәтнең нәрсә икәненә беркемнең дә әле төшенгәне юк. Илһам, күтәренкелек, тибеп тимер өзәрдәй көч – болар барысы да хас Рәмискә дә. Соңгы вакытта аның күңеленең бер өлеше гел Мәликә янында. Башта кайнаган бихисап уйларның очы аңа барып тоташа. Әмма мәхәббәт вак-төяк проблемалардан арындырса да, бу

якты хис игътибарны көн саен үзенә тартып, вакытны күп ала, төп эшкә кайчак хилафлык та китерә. Кайвакыт профессия белән мәхәббәте арасыннан кайсысын сайларсың дип, үзенә-үзе сорау бирә дә, җавапның Мәликә ягына авышканын тоеп, бераз шүрләп тә куя. Мәликәдән башка киләчәген күз алдына да китерә алмый ул хәзер. Аны югалтудан курку, көнләшү кебек хисләр дә еш калка. Юк кына сәбәпләр аркасында аралар бозылып куйган чаклар да булмады түгел. Мәхәббәт көчлерәк булган саен, бер-береңә каты бәрелү – ниндидер сәер закончалык ул. Мәхәббәт газапсыз яши алмый. Элек-электән мәхәббәт турында язылган әдәби әсәрләрдә газап, кайгы, күз яше, кан зур урын алып тора. Әсәрнең азагы уңай булган сурәттә дә, башта бәла-казалар, төрле михнәтләр аша үтәргә туры килә. Кыскасы, мәхәббәт түп-түгәрәк бәхет түгел, мәхәббәт – бер төргәккә ныклап төрелгән газап белән бәхет ул.

Ни гаҗәп, Мәликәне ул тумыштан ук белә кебек. Әйтерсең лә алар бу Әбелхәят кочагында мәңге булганнар һәм бер-берсен белгәннәр. Алай гына да түгел, гүя алар бер-берсе өчен туганнар, күз-акыл белән тотып күреп булмаган могҗизалы бер яссылыкта хәтта бербөтен булып яралганнар. Кешеләр яртышар-яртышар килә дөньяга, диләр. Бер-берсе өчен яралгач, ничек яртышар булсын инде алар! Алар – бербөтен, ул проекцияне күрер өчен күзәтү ноктасын гына табарга кирәк.

Барча кешеләр өчен бер үк табигать законнары, инсаниятнең уртак кануннары хөкем сөрә. Күңел сизә: алда сынаулар, киртәләр, газаплар булмый калмас. Тормыш тигез генә бармый, яшәешнең якты көннәре – караңгы көннәрдән арынган мизгелләр генә ул.

Нишләп әле уйлар кинәт кояшсыз, болытлы тарафларга таба әйди? Җирдәге яшәешнең асыл-нигезендә фаҗига яткангадыр, күрәсең. Рәмис хирург хезмәтендә әле озак эшләмәде, әмма шул дәвердә ул инде кешеләрнең дөньяга шатлык-бәхет өчен генә килмәгәненә инанды.

Бала чакта, үсмер вакытта кеше театр пәрдәсе ачылганны көтеп утыручы тамашачыны хәтерләтә – шатлык белән, илһамлы киеренкелек кичереп, сәхнәдә кайнаячак тамашаларны, кызык вакыйгаларны көтә ул. Ярый әле нәрсәләр буласын алдан белми. Киләчәкне белмәү – үзе бәхеттер, мөгаен.

Язмыш бөтенләй көтмәгән яктан китереп суга ала. Кешеләр арасындагы элемтәләрнең дә кай төшендә иң нечкә урыннары барын алдан ничек беләсең? Бер-береңне югалтуны да алдан күрү мөмкин түгел. Хыянәт тә ерак йөрми бит әле. Мәхәббәт булган җирдә хыянәт тә ач шакал кебек шул тирәдә иснәнеп йөри. Нишлисең бит, фәрештәләр булган җирдә иблисләр дә оя кора.

Шуңа күрә илһамлы минутларда да караңгы уйлар кара кошлар сыман аң күгендә уйнаклап очалар. Ә яшәү дәвам итә. Син фәкать шул агымда йөзәсең. Яшәеш дәрьясында агымга каршы йөзү мөмкин түгел. Үткән көнне дә фәкать анализлый гына аласың, аны үзгәртә дә алмыйсың һәм аңа кире кайту юлы да ябык. Хыяллар, өметләр киләсе көнгә әйди, күңел шунда талпына. Ә бүгенге көн, хәзерге мәл кичәге белән иртәгәсеннән башка була алмый. Бүгенге көннең ике төп нигезе бар – кичәге көн һәм иртәгәсе көн. Хәзерге мизгел үткән мизгелләрнең дәвамы, бу мизгелдән соң шундук киләчәк башлана.

Бу ямьле кичтә мондый уйларның башта чуалуы һич тә гаҗәп түгел.

Әйе, бәхетле кич бу, ләкин... Әгәр дә тормышта кайгылы көннәр булмаса, бу бәхетле мизгелләр насыйп булыр идемени, ягъни бу мизгелләрнең бәхетле икәнен, чагыштырмыйча, аңлар, тояр идеңмени?

Мәликәне озата китәр алдыннан Рәмис әнисенә: «Мин кайтканчы йокларга ятма», – диде.

Хәлилә инде машина күздән югалгач та, шактый вакыт тәрәзә яныннан китмәде. Ул, шкафның тартмасын ачып, саргая төшкән фоторәсем алды. «Менә, улыбыз өйләнә», – диде ул, күз яшен яулык почмагы белән сөртеп.

Ишек ачылып, Мәҗитнең корык-корык йөткергәнен ишеткәч, Хәлилә фоторәсемне урынына куярга җитешә алмады, тиз генә шкаф өстендәге япма астына тыгып куйды.

Мәҗит кергәч, бер сүз дәшми, диванга сеңде дә шактый вакыт үз уйларына чумып торганнан соң гына, ниһаять:

– Яшьләр кая? – дип сорады.

– Рәмис Мәликәне илтә китте, Навил йоклый. Күрдеңме ректорны?

– Өендә булдым, – дип чыраен сытты Мәҗит. – Шулхәтле читен, уңайсыз. Бу малай миңа инфаркт ясый инде.

Йокы бүлмәсеннән тагын Навил килеп чыкты – хәмерне күп кабул иткән булган, күрәсең, сусавын баса алмый интегә – бу юлысы суны стаканга салып тормады, графиннан гына эчте.

– Малай, иртәгә сәгать тугызда ректорга кер, – диде Мәҗит, аңа карамыйча гына.

– Ярар, – диде Навил илтифатсыз кыяфәт белән.

– Тагын укуыңны калдырсаң, синең өчен йөрмәячәкмен. «Травка» тартуыңны ташламасаң, үзем полициягә тапшырам сине.

– Рәхмәт. Логичное продолжение – әни белән мине ташлап киттең, атасыз үстем, хәзер үз кулың белән төрмәгә утыртырга чирканмыйсыңмы?

– Телеңә салынма, мөртәт! – дип кыҗрады Мәҗит. – Киләчәгең турында уйла! Сиңа яхшылык кына телибез барыбыз да!

– Әйе, телисез... – дип мыгырдады Навил һәм йокы бүлмәсенә кереп китәргә ашыкты.

Хәлилә Мәликә белән танышу шатлыгыннан арынмаган иде әле. Күңелендәге бәйрәм төсен Мәҗиткә дә иңдерәсе килде аның.

– Ярар, тынычлан инде, – диде Хәлилә, янәшә утырып.

– Нишләргә инде моның белән, белгән юк, – дип башын чайкады Мәҗит.

Шуннан соң ул торып шкафтан шешә алды, рюмкага салып шундук эчеп тә куйды. Хәлилә тиз генә кухнядан тәлинкә белән салат алып килде. Ничек булса да, иренең кәефен күтәрәсе килде аның. Мәликә турында кат-кат сүз башлап карады, әмма Мәҗитнең исе китмәде, пүтсез малаеның проблемалары белән башы каткан иде.

– Болай булмый... – дип, кат-кат кабатлады ул, салат ашый-ашый.

– Ярым ятим булгач, анасы нык иркәләгән аны, – диде Хәлилә һәм шундук сорап куйды: – Мәликә ошадымы сиңа?

Мәҗит тиз генә җавап бирмәде, кашларын җыерып уйланып торды.

– Болай ипле, тәрбияле кызга охшаган, – диде ул, ниһаять. – Аспирантурада укыймы әле ул?

– Әйе. Киләсе елда тәмамлый инде. Кандидат биологических наук булачак, – диде Хәлилә үз баласы өчен горурланган сыман илһамлы тавыш белән. – Укый да, эшли дә инде – көллияттә укыта. Миңа бик ошады бу кыз.

Мәҗитнең исә үз фикере бар иде:

– Дөресен әйткәндә, Рәмискә гадирәк кыз кирәк, – диде ул. – Рәмис үзе акыллы, югары интеллектлы кеше. Аңа күзенә генә карап торучы иптәш кирәк, минемчә.

Хәлилә дәшмәде. Иренең сүзе белән килешмәвен белдереп торудан мәгънә юк. Ул инде үзе өчен төгәл фикер билгеләгән иде – ике укымышлы кеше бер-берсен яхшырак аңлаячак. Рәмис сайлаган кыз, күренеп тора – инсафлы, әдәпле. Бәхетле генә булсыннар!

Мәҗит тагын бер рюмка эчкәч:

– Ятабызмы? – дип, шешәне шкафка куйды.

– Син ят, мин Рәмиснең кайтканын көтәм.

Хәлилә улының кайтуын түземсезлек белән көтте. Соңгы вакытта рәхәтләнеп күзгә-күз карашып сөйләшкәннәре дә юк ана белән улның. Көн саен күз алдында булса да, газиз улына ниндидер бик әһәмиятле һәм кирәкле сүзләрне әйтү ихтыяҗы бар ана күңелендә. Нинди сүзләр – үзе дә анык кына аңлата алмый. Әмма бар һәм бик күп әйтер сүзләре. Алар иксез-чиксез, гомер буена әйтеп бетерерлек түгел.

Рәмис озакламый әйләнеп кайтты. Бер сүз катмаган килеш, әнисенең җылы карашыннан аңлады – Мәликә ананың күңеленә хуш килгән, бик ошаткан ул аны, үз иткән. Хәтта яратырга да өлгергән – йөзенә чыккан бит инде!

Шулай да, кем әйтмешли, «фурмы» өчен генә:

– Нәрсә әйтерсең, әни? – дип сораган булды.

– Бик инсафлы икән Мәликәң. Пар килгәнсез, улым, – дип җавап бирде Хәлилә.

Башка фикерне көтмәгән дә иде Рәмис.

– Синнән дә яхшы кеше юк, әни, – диде ул, ягымлы итеп. – Сиңа ошаячагын мин алдан ук белдем.

– Нык ошагач, күз тию дә бар. Ходай рәхмәтеннән ташламасын. Әтиең белән бер-беребезне яратуыбыз бик күпләрне көнләштерде. Кеше бәхетен гафу итә алмаучы кешеләр һәрвакыт була. – Ул әлеге дә баягы саргылт фоторәсемне япма астыннан алып, улына сузды. – Әтиең белән мине бергә күргән һәр кеше таң кала торган иде – нинди матур пар дип. Күз тидергәннәрдер.

Рәмис әнисеннән фотоны алып, мөгаен, әллә ничә меңенче мәртәбәдер, текәлеп карап торды.

– Минем буй-сыным әтинеке шикелле... – дип куйды ул.

– Күбрәк миңа ошасаң да, дикъкать белән карасаң, әтиеңнең чалымнары бик күп синдә. Атлап йөрүләрең, хәрәкәтләрең – аныкы. Чәчең – нәкъ аныкы. Чәнти бармакларың да аныкы шикелле чак кына кәкрәеп тора.

Рәмис әнкәсенә карап елмайды.

Әйе, Хәлиләнең туры борыны, гел елмаеп торган кебек кысыграк күзләре, йөзнең чак кына кара-сарылыгы Рәмискә күчкән булса, Хәлилә әйтүе буенча гәүдә, атлап йөрүләре – әтисеннән.

Хәлиләнең кайчандыр коңгырт чәче инде агарып килә. Зифа буй-сыны да фоторәсемнәрдә генә саклана, соңгы вакытта бигрәк тә тазарыбрак китте.

Барыбер Рәмис өчен иң матур, иң гүзәл зат, иң кадерле, иң нык яраткан кеше – әнкәсе!

Мәликәнең әтисе турында да сөйләштеләр. Аны монда алып килүне әнисенең хуплавын да Рәмис алдан белеп торды, башкача мөмкин түгел иде.

– Андый авыр диагноз булгач, янына бәлки Мәликәнең әнкәсе дә килер, – диде Хәлилә. – Аерылган булсалар да, кайчандыр бер гаилә булганнар бит.

– Мәликә хәбәр итсә, бәлки, килер дә.

– Улым, соңгы вакытта эшең турында бик сөйләшмисең.

– Ул бөтенләй башка дөнья, әни. Микроскоптан күргәннәрне физик-галим

гади кешеләргә ничек сөйләп аңлата алсын? Ул микроскоп астындагы дөньяны үз коллегаларына гына фәнни-гыйльми телдә аңлатып язарга мөмкин. Минем эшем турында да шулай дияргә була.

– Коллегаларың турында элегрәк еш сүз ката идең.

– Мөнәсәбәтләр бик катлаулы бездә. Күбрәк эшләгән саен, кешеләрне якыннанрак беләсең. Кайберләре турында фикер әйтү дә кыен, кайсыларын телгә дә аласы килми. Күңелгә хуш килгәннәре хакында сөйләсәң, мактарга кирәк, ә мактау, син әйтмешли, күз тидерергә мөмкин...

Ә шулай да эштәге бер кеше турында аның сөйләшәсе бик килә.

– Әни, Илзирәне хәтерлисеңме? – диде ул, сынаулы караш белән әнисенә текәлеп.

Хәлиләнең йөзе тагы да яктырыбрак китте:

– Балачак дустыңнымы?

– Нәкъ шуны.

– Ничек инде хәтерләмәскә! Сез бит гел бергә идегез. Очраттыңмы әллә аны?

– Очраттым гына түгел, мин аны үзебезгә эшкә керергә күндердем. Ул поликлиникада эшли иде. Андагы хәлләрдән туйган. Ул да бит гаделлек өчен көрәшә торган зат – минем сыман. Җитәкчеләр белән сүзгә килгән. Ни өчен икәнен әйтмәде, мин дә төпченмәдем. Үзебезгә чакырдым, урнашырга булыштым. Читтән торып медицина университетын тәмамлый, киләсе елда диплом алачак.

– Заочный бүлек медицина университетында юк түгелме соң?

– «Социальная работа» дигән бүлек бар, анда читтән торып укырга мөмкин. Илзирә шуны тәмамлый.

– Бик әйбәт кыз иде. Үзгәргәнме?

– Юк, шул килеш. Андый гүзәл кеше тора-бара үзгәргән сурәттә дә затлылыгын җуймый. Күзләренә генә тирән сагыш кунган.

– Кияүгә чыккандыр?

– Чыкмаган.

Кайчандыр Илзирәнең кем беләндер гаилә корырга маташканын ишеткәне булса да, Рәмис бу турыда әнисенә әйтеп тормады. Тиз аерылышканнар алар. Илзирәнең кияүгә чыгарга җыенганын ишеткәч, Рәмиснең эче пошкан иде. Соңгы вакытта элемтәләре булмаса да, Илзирә аның уеннан чыкмады, иң якын кешеләрнең берсе булып кала бирде.

Илзирә күрше йорт кызы иде. Алар бер балалар бакчасына йөрделәр, аннары бер мәктәптә, бер класста укыдылар. Бала чактан ук бер-берсенә тартылу көчәйде. Яшерен-батырын түгел, алар яратыштылар. Әмма өлкән классларда Рәмискә романтика кирәк иде. Илзирәгә ул, гашыйк икәнен аңласа да, «җирдә» яшәүче гади кыз итеп карады. Мәхәббәт өчен башка төрле, хыялларда гына очрый торган «күктән иңгән» гүзәл зат кирәк иде аңа ул вакытта. Хәзер генә ул чакларның кадерен, үсмер чактагы саф хисләрнең кыйммәтен аңлый башлады Рәмис.

Ә бит Илзирәнең әбисе янына авылга кунакка кайткач, Рәмис үзенә карар кабул иткән иде – алар гомергә бергә булачак. Бу хакта авыз тутырып әйтмәсә дә, Илзирә аның хисләрен аңлаган иде. Рәмис үзе дә Илзирәнең мәхәббәтен җаны белән тойган иде югыйсә.

Алар икесе дә медицина юлын сайладылар. Рәмис: «Университетка документларны бергә бирик, бергә укырбыз», – дип өндәп карады, ләкин ул вакытта Илзирә югары уку йортына кереп карарга җөрьәт итмәде,

имтиханнарны бирә алмам дип курыкты. Шулай итеп, Рәмис университет студенты булды, ә Илзирә медсестралар әзерли торган көллияткә керде.

– Ата-анасы да бик ипле кешеләр иде, – дип Хәлилә улын уйларыннан арындырды. – Алар башка районга күчкәннән соң, бер тапкыр да очраганнары юк.

– Һаман да Оргсинтезда эшлиләр, диде Илзирә. Энесе дә шунда хәзер. Егерме дүрт яшь кенә булса да, цех нәчәлнигенең урынбасары икән инде.

– Малайлары да бик акыллы иде шул. Илзирә, диплом алгач, сездән китәр инде ул.

– Җибәрмим мин аны, – дип елмайды Рәмис.

– Егерме сигезгә кадәр нишләп кияүгә чыкмады икән – үзе чибәр, үзе акыллы, үзе тыйнак. Сайлана микән?..

– Үз тиңен табалмыйдыр.

– Табар, Алла боерса. Менә син дә, ниһаять, үз тиңеңне таптың инде. Ычкындыра күрмә Мәликәңне. Тигез гомер итәргә язсын берүк, ярабби. Бәхетле була күрегез. Миңа оныкларымны сөяргә насыйп булсын. Менә шушы якты халәттә кереп ятыйм мин, – диде Хәлилә һәм, улын аркасыннан сөеп, йокы бүлмәсенә кереп китте.

**5**

Казанга килгән көнне үк Рәмис Котдус агайны стационарга яткырды һәм бер ай эчендә тулы диагностика узарга ярдәм итте.

Аденокарцинома простаты. Гади тел белән әйткәндә – «рак простаты». Беренче стадия. Капсуладан чыкмаган. Метастазалар күренмәде. Димәк, радикаль операция ясарга ярый. Шуннан соң бу яман авыруга нокта куярга мөмкин булачак.

Рак – җаннарны өшетә торган коточкыч сүз. Дәвалап булмый торган чир, чишелмәгән сер. Иң төп сәбәбе билгеле түгел, асылына һаман төшенә алмадылар әле. Дучар ителгәнлек, котыла алмау – бер уйлаганда, моннан да куркынычрак тагын нәрсә булырга мөмкин? Әлегәчә аңардан һаман дәва табылмады. Бу яман чиргә каршы көрәш дәвам итә, әмма чарасызлык дигән төшенчә табиб белән пациент арасында һәрвакыт уяу тора.

Дөрес, аның механизмы аңлашыла шикелле – әйбәт күзәнәкләр зәгыйфьләре һәм комсызлары белән алмашына. Бу агрессив клеткалар бернинди кирәкле хезмәт күрсәтмиләр, әмма тиз үрчиләр, таралалар һәм организмны дөрес яшәүдән мәхрүм итәләр. Шул агрессив күзәнәкләр аркасында, эчке әгъзалар, тамырлар, нерв юллары урынына мәгънәсез, кирәксез тукымалар барлыкка килә. Организм үзенчә көрәшә. Лимфалар системасы рак күзәнәкләрен үтерергә тотына, бавыр аларны, үзе аша үткәреп, эшкәртергә маташа, бөерләр фильтрация ясый, тир аларны тышка чыгарып ташлый. Әмма рак күзәнәкләре нормаль күзәнәкләр белән чагыштырганда, бик гади вә әшәке. Андый гарип күзәнәкләрне, әйбәтләренә караганда, «ясау» бик җиңел. Рак күзәнәген тудыру өчен көч бик аз сарыф ителә. Ә бит туклану организмга тигез бирелә – әйбәте дә, примитивы да бертигез ала ризыкны. Нәтиҗәдә, яман күзәнәк тизрәк үсә – аны бары тик үз массасын үстерү генә кызыксындыра. Үзенә тиешле размерга үскәч тә, аңа һаман туклану кирә тора – димәк, аңа үрчисе генә кала.

Сәламәт организм ул хәшәрәтне тиз генә чыгарып атарга да мөмкин. Ә карт, хәлсез организм моны булдыра алмый.

Шунысы да бар: рак күзәнәкләрен төзү җиңелрәк, моның өчен азрак хезмәт

кирәк. Шуңа күрә, организм ялкаулыкка сабыша һәм кирәк нәрсәне түгел, ясарга җиңелне үрчетә башлый.

Дәвалау ысуллары соңгы вакытта шактый төрлеләнде, яңа дарулар чыгып тора, җиһазларның яңалары кайта. Ә шулай да төп ысул бердәнбер – организмның гомуми куәтен кинәт күтәрү – көрәшә алсын өчен. Чит-ят күзәнәкләрне «ашау», бетерү зарур, шулай гына җиңәргә мөмкин.

Ә бит үз көчләре белән бу яман чирдән котылу мисаллары шактый. Әнә, бер агай, яман шеш барлыгын белгәч, берүзе ялгыз корабта Җир тирәли сәяхәткә чыга. Җир шарын океаннар аша әйләнеп чыккач, табиблар шаккатканнар – ракның эзе дә калмаган бу агайда.

Рус язучысы Солженицынны кара син. Аңа да бит яман диагноз куелган булган. Ә ул үзенә мистика дәрәҗәсендә карар кабул иткән – үләргә ярамый, яшәргә кирәк, чөнки башка кеше ерып чыгалмаслык зур эшне башкару миссиясе бар аның!

Әйе, бөек эшләр кыласы бар дигән кискен максат кирәк, шул чагында кеше җиңә – башкаларны да, үзен дә, хәвеф-хәтәрне дә, иң яман чирне дә.

Табиблар, хирурглар кешегә ярдәм итүчеләр генә, коткаручылар түгел.

Котдусның халәте операция көткәндә ничек булырга тиеш – шундый иде. Куркыта, куркыта! Куркыта!!! Әмма ясатырга кирәк!

Илзирәнең елмаюыннан палата яктырып киткәндәй булды.

– Ничек хәлләр, Котдус абый?

Котдус әкрен генә торып утырды һәм аягына башмакларын киеп:

– Хәл шул бер көе, – диде. – Мине шушылай зурлап, монда алып килеп, аерым палатага яткырып, әйбәтләп караганыгыз өчен рәхмәт инде.

– Рәмис Василовичка рәхмәт. Сөйгәненең этисен ничек зурламасын инде ул. Операцияне үзе ясаячак.

– Ул бик яшь кеше, мондый операцияләрне ясаганы бармы соң аның?

– Яшь булса да, ул – тәҗрибәле, абруйлы хирург. Аның һәр операциясе уңышлы тәмамлана. Күз тимәсен. Аны хирургиябезнең өмете һәм киләчәге, диләр.

Котдус кинәт кашларын җыерып, уйга калды:

– Рәмис Василович... Рәмиснең этисе Васил исемле икән... Фамилиясе ничек әле аның?

– Исламхузин.

Котдус үзалдына мыгырдавын дәвам итте:

– Теге Василның фамилиясе Гыйльметдинов иде...

– Кем ул?

Әйтерсең лә, Котдус бу сорауны көткән иде. Аңарда курку катыш сәер илһамлану сизелде. Киеренке күтәренкелек иде бу, илһам да түгел...

– Әй Илзирә, кызым... Мин бу арада егерме тугыз ел элек булган вакыйганы төшләремдә күреп саташам, – диде Котдус, чыраеннан газап саркытып. – Операция алдыннан башка әллә нинди уйлар килә... – Ул кинәт пышылдап өстәп куйды. – Кылган гөнаһым тынгы бирми.

– Гөнаһсыз кеше юктыр инде ул, Котдус абый, – диде Илзирә, пациентлардан әллә нинди хатирәләр ишеткәнгә күрә, агайның мондый халәттә булуына бик исе китмичә. – Менә бу ике таблетканы йотыгыз әле.

Ул чыгып китмәкче иде, әмма Котдус аны беләгеннән тотып туктатты:

– Тукта. Тыңла әле мине. Мин бик куркам. Операциянең үзеннән курку гына түгел бу... Мин бер яман эш кылдым... Кылдым дип... дөресрәге, күзләремне

йомдым, күрмәмешкә, белмәмешкә салындым. Сиксән сигезенче елны Васил исемле егет белән кооперативта эшләдек, йөк машинасы белән икәүләп, сату-алу оешмасына Мәскәүдән чүпрәк-чапрак, кием-салым ташыдык. Васил «Жигули» машинасы алган иде, шуның белән бәрелеп үлде. Чуйков урамыннан Ибраһимов проспектына борылганда. Минем аркада харап булды ул, мин гаепле.

Илзирә агайның йөзе агарганны һәм кулларының калтырануын күреп, аны тынычландырырга ашыкты:

– Котдус абый, хәзер аны уйлап ятма инде. Операциядән соң уйларсың. Хәзер тынычланырга кирәк, – диде һәм чыгып китте.

Котдус караватка чалкан ятып, түшәмгә текәлде.

Ә Илзирә сестралар бүлмәсенә керде дә, өстәлгә терсәкләре белән таянып, уйга калды.

Хәзер Рәмис керергә тиеш, Илзирә аны түземсезлек белән көтте. Болай туры килү мөмкин микән?..

Киң итеп ишек ачылды һәм бүлмәгә йөзеннән шатлык сирпеп, язгы җилдәй, Рәмис килеп керде. Илзирә хәтта сискәнеп куйды. Һәм ул чак кына: «Болай булырга мөмкинме?» – дип сорап ташламады.

– Исәнме, Илзирә!

– Исәнме, – дип җавап бирде Илзирә, һаман уйларыннан арына алмыйча.

– Син килгәч, бу бүлмә яктырды. Белсәң иде, ничекләр шатмын синең монда эшләвеңә, – диде Рәмис ихластан.

Аның бу сүзләре Илзирәнең, әлбәттә, күңеленә хуш килде.

– Чын әйтәсеңме? – диде ул, чын икәнен белсә дә.

– Чын-чын, чын әйтәм, чын әйтәмен, аппагым, – диде Рәмис чак кына артистларча кыланып. – Дөресен әйткәндә, бер яктан мин чиксез шат синең янәшә булуыңа, икенче яктан, мәктәп еллары, үсмер чак синең белән бәйле, шуңадыр инде – күңел әллә нишләпләр куя. Нинди бәхетле чор булган ул!

Илзирәнең йөзенә моңсулык йөгерде:

– Мин дә ул вакытларны гел сагынып йөрим.

Аларның икесе дә: «Нишләп без гомер юлыннан кулга-кул тотышып китмәдек соң?» – дип уйлыйлар. Нәкъ менә хәзер дә аларның һәр икесендә андый уй бар – сүз белән әйтелмәсә дә, күз карашыннан барыбер күренә бит ул. Балачак дуслыгы гына түгел, үсмер еллардагы якынлык кына да түгел, ә бәлки, araларында тиз генә өзелмәстәй җепләр барлыгын икесе дә аңлый бит.

– Хәтерлисеңме, чыгарылыш кичәсеннән соң, икенче көнне әбиебез авылына сине кунакка алып кайткан идем?

– Ничек хәтерләмәскә инде. Авылыгызның ямьлелеген, әбиеңнең җылы күңелен, ул пешергән бәлешне онытырлыкмыни? Исәнме әле ул?

– Аллага шөкер, исән-сау. Синең турыда кайткан саен сораштыра: Рәмис ничек икән, шалтыратмыймы, үзең шалтыратмыйсыңмы, өйләнде микән, дип.

– Нишләп син поликлиникада проблемалар туа башлау белән мине тапмадың, яисә шалтыратмадың?

– Читенсендем. Беренчедән, син инде һаваларга күтәрелгәнсеңдер, дип уйладым. Миңа өстән карарсың кебек тоелды.

– Нинди һавалар, ди ул?! Ничек инде өстән?! Башта укуга чумарга туры килде, аннары профессиягә кереп китү авырлыгы дөньядан ваз кичәргә мәҗбүр итте. Яшь хирург буларак, каушый-каушый эшкә керештем, аякка басарга кирәк булды. Ә күңелемнән син беркайчан китмәдең. Ярар, менә, очраштык бит. Барысы да тәртиптә бит хәзер. Минем янда сиңа җил-яңгыр тимәс.

Илзирә – чын татар кызы. Коңгырт күзле, борын очы чак кына өскә нәфисләнеп калкып тора. Кара куе чәчен толымлап, бәләкәй чакта да озын иттереп үстерә иде ул. Елмайганда, яңакларындагы ике чокырчык килеп чыга да, шул урыннарыннан үбәсе килә. Урта буйлы, тулган ай кебек түгәрәк йөзле бу җылы кешенең тирәннән куе тембр белән матур тавыш чыгарып сөйләшүенә игътибар итми калган кеше юктыр, мөгаен.

Илзирә моңсу елмайды.

– Синең монда урнашуыңа мин чиксез шат, – дип, инде әллә ничәнче тапкыр кабатлады Рәмис. – Ярар, лириканы башка вакытта дәвам итәрбез. Котдус абый ничек анда?

– Курка.

– Куркыр инде. Әле курыкмаган кешене күргән юк.

– Ул яшь чагындагы бер вакыйганы уйлап кайгырып ята. Имеш, аның аркасында машинасы белән авариягә эләгеп, бергә эшләгән дусты һәлак булган. Чуйков урамыннан Ибраһимов проспектына борылганда. – Ул сынаулы караш белән Рәмискә текәлде. – Синең әтиең дә шунда бәрелгән бит...

Рәмиснең йөзе кинәт караңгыланды:

– Әйе. Анда күп кеше авариягә эләкте, – дип бер ноктага карап торды ул. – Урыны шундыйдыр, күрәсең. – Ул сәгатенә карап алды. – Ярый, мин аның янына кереп чыгыйм әле.

– Бар, бар, булачак бабаң янына ничек инде кермисең...

Рәмиснең чыгып китүе булды, Илзирәнең ике як битеннән күз яшьләре тәгәрәп төште.

**6**

Рәмис Котдус агай яткан палатага барганда, моңарчы булмаган дулкынлану кичерде. Мәликәнең әтисе бит ул. Әллә язмыш сынап карыймы? Бөтенләй көтмәгәндә, үзенчәлекле «имтихан» бирергә кирәкме? Мәликәнең әтисенә яман диагноз куелып, монда килеп, Рәмис кулына эләгүендә нindидер тирән сер бардыр, бәлкем. Дөньяда бер нәрсә дә очраклы түгел, һәр әйбер үз урынында хасил була, һәр хәрәкәт үз вакытында башкарыла. Булачак кияү чын хирургмы, яки ошбу хирург чын кияү булырлыкмы – шушы көннәрдә хәл ителә инде дигән шаян уйдан Рәмис палата ишегенә җиткәч, хәтта көлеп куйды.

– Хәерле көн, Котдус әфәнде! – дип сәламләде Рәмис, палатага кергән уңайга.

Котдус, гадәттәгечә, әкрен генә торып утырды:

– Исәнмесез, Рәмис Василович, – диде Котдус каушаудан бераз калтыраган тавыш белән.

Рәмис Котдусның салкынча кулын кысты һәм кергән мәлдән үк пациентның чыраен, кыяфәтен профессиональ күзлектән карап «өйрәнә» башлады.

– Ничек хәлләр? – диде ул көр тавыш белән.

– Мондый диагнозлы кешенең хәлен үзегез дә чамалыйсыздыр инде.

– Әлегә бернинди фаҗига күрмим. Канның оюы яхшы, йөрәк начар түгел. Анестезиолог та организмыңа уңай бәя бирде. Иң мөһиме: метастазалар табылмады. Простатаны алып ташлыйбыз да, ракны тәгаен онытырга мөмкин булачак. Әмма риск бар. Риск һәрвакыт була. Диагностика вакытында метастазалар юклыгын ачыкласак та, ракның аерым күзәнәкләрен безнең күрмәвебез ихтимал. Шуңа күрә, тулы ремиссия турында берничә ел узгач кына әйтергә мөмкин булачак. Син аңла: 100 процент гарантия беркем дә

бирә алмый. Медицина математика түгел ул. Әмма синең очракта шулай да тулы ремиссиягә ышанам, ягъни прогноз яхшы... гәрчә рискка бер процент калдырсам да. Аңлыйсыңмы – прогноз яхшы. Сөенергә кирәк! Прог-ноз ях-шы!

– Мәликә дә шулай, диде.

– Ул әйткәч һичшиксез шулай булачак! – диде Рәмис, елмаеп.

Чынлап та Мәликә әтисенә аз гына да охшамаган икән. Котдус – озын гәүдәле, тар җилкәле, әмма гәүдәсенең аскы өлеше киң – «төптән юан», диләр андый кеше турында. Пеләш, арттагы чәче агарган. Яшькелт олы күзле, күзләрендә гел сагаю саклана. Олы колаклы, тукмаграк борынлы, иягендә миңе бар. Бөкрәебрәк йөри. Әнисенә охшаган икән Мәликә, әнисенә. Шушы агайның Мәликә кебек чибәр, затлы кызы бардыр дип, чит кеше һич уйламас.

Котдус та хирургны җентекләп күзәтте һәм кыюлыгын җыеп әйтеп куйды:

– Мин бик шат кызымның шушындый егете булуына. Йөзегез ничектер таныш шикелле. Кемнедер хәтерләтәсез кебек. Әллә сезне нык якын иткәнемә шулай тоеламы?

– Бәлки. Дөресен әйткәндә, миңа еш шулай, диләр. Күрәсең, минем чырай шундый универсальныйдыр инде, мине кемнәргә генә охшатмыйлар, – диде Рәмис, көлемсерәп. – Котдус абый, бер-беребезгә «сез» дип түгел, «син» дип эндәшик инде, яме.

Агайның йөзе яктырыбрак китте:

– Ярар.

– Аннары... Караңгы уйларны башыңнан алып ат. Гомереңнең якты мизгелләрен уйларга тырыш. Кешенең башындагы уйлары организмга бик каты йогынты ясый.

– Уйлар чакырып кына килми бит алар, – диде агай, авыр сулап. – Ниндиенең килергә теләге бар, шундые килеп бимазалый.

– Кайгырып ятарга урын юк. Кайчандыр булган гаеп-хаталарны уйларга кирәкми. Хәер, үкенү, тәүбә итү, икенче яктан караганда, җиңеллек тә китерә инде ул. Әмма үзеңне бөтенләй бөгү, таптау, изү дәрәҗәсендә түгел.

Котдус беравык карап торганнан соң:

– Илзирә әйтте мәллә? – диде.

– Без бит аның белән бергә эшлибез, шуңа күрә безнең арада бер сер дә булырга тиеш түгел, һәр пациентның кәефен, күңел халәтен бер-беребез белән уртаклашып, анализ ясарга тырышабыз. Шушындый җитди операция алдыннан да уйлап ятарлык нинди гаебең бар соң синең?

– Васил исемле Чаллы егете белән бер кооперативта эшләгәниек. Минем Волжскидан Казанга яңа гына килгән чагым иде. Бик булдыклы егет иде ул. Берничә эштә эшләргә җитеште, машина алды, өйләнергә җыенып йөрде. «Шеф»ның туган көнен бәйрәм иткәндә, мине кибеткә аракыга җибәрделәр. Кибеттән кайтканда ышпана малайлар Василның йорт янында торган машинасының алгы тәгәрмәчен салдырырга маташалар иде. Мине күргәч, качтылар. Мин тәгәрмәчнең биш болтыннан инде дүртесе борып алынганны, берсе генә урынында калганны күрдем. Моны мин Василга әйтмәдем. Сөйгән кызы кичке тугызлар тирәсендә шалтыратты да, ул ашыгып чыгып китте. Караңгыда тәгәрмәченең дүрт болты юклыгын абайламаган. Шулай итеп, бер болтта гына эләгеп торган тәгәрмәчле машинасы белән чапты. Икенче көнне аның авариягә эләгүен ишеттек. Алгы тәгәрмәче ычкыну сәбәпле, машинасы мәтәлгән, диделәр.

Рәмиснең тәне буйлап эсселе-суыклы дулкын йөгерде.

– Шул чакны тәгәрмәч турында әйтсәм, исән булыр иде, өйләнер иде, балалары туар иде... – дип дәвам итте Котдус.

– Ник әйтмәдең соң? – диде Рәмис, палатадан атылып чыгудан үзен чак кына тыеп.

– Әллә тагы... Уңышлы иде ул, аңа бөтен нәрсә җиңел биреләдер шикелле тоела иде. Ә мин көнләштем... – дип мыгырдады Котдус.

Рәмис, үзен кулга алып, тирән итеп сулап куйды һәм:

– Котдус абый, хәзер ул вакытка кире кайтып булмый, тынычланырга тырыш, – дип әйтергә кирәк тапты. – Дүшәмбе көнне операция ясыйбыз.

Коридордан атлаганда, Рәмис үзенең кая барганын аңламады. Берничә кеше үтеп барышлый исәнләште, ә ул җавап бирмәде. Аяклары аны сестралар бүлмәсенә алып керде. Тизрәк Илзирәне күрәсе килде аның.

Юктыр, юктыр, ул түгелдер. Җир түгәрәк, әмма болай ук туры килергә мөмкин микәнни? Ул түгелдер. Нишләп соң Котдусның бәяныннан соң, палатада ук, Рәмиснең вөҗүде буйлап эсселе-суыклы дулкын йөгереп үтте? Нигә күңел күптән ачыклыйсы нәрсәгә тап булгандай, әллә нишләп китте? Рәмистә интуиция көчле, палатадан сәер бер көч аны этеп диярлек тикмәгә чыгармады коридорга.

Бүлмәдә Илзирә белән тагын ике медсестра бар иде. Кызлар, хирургның тартылып киткән йөзен күреп, чыгып китәргә ашыктылар.

Икесе генә калгач, Рәмис белән Илзирә шактый вакыт дәшми утырдылар. Илзирә аның караңгылыгын эшенә бәйледер дип уйлады.

– Кәефең кырылган, ахрысы, – диде ул.

– Ардырды бу арада, – диде Рәмис, авыр сулап.

Илзирә Котдус белән булган әңгәмәдән соң, күңелен тырнап торган сорауларын бирергә батырчылык итте:

– Син бит әниеңнең фамилиясе белән йөрисең бугай?

– Әйе, Исламхузин булып, әнием буенча йөрим мин.

– Әтиеңнеке Гыйльметдинов идеме?

– Ә син каян беләсең әтиемнең фамилиясен?

– Котдус абый әйтте.

Рәмис Илзирәгә карап катты. Икесе дә сүзсез калды. Шактый вакыт тып-тын утырганнан соң, Рәмис:

– Илзирә, пациентның бу вакыйгасын беркемгә дә сөйли күрмә, яме, – диде.

– Ярар, – диде Илзирә, шомраеп. – Кисәтмәсәң дә була иде. Нәрсә дип, кемгә сөйлим инде мин аны? Хакым юк.

Тетрәнү Рәмиснең бөтен кыяфәтенә чыкты. Илзирә хәтта курка башлады. Рәмис авыр сулап куйды да бер ноктага текәлгән килеш:

– Дөрес түгел бу, – диде.

Илзирә нәрсә дөрес түгел дип сорап тормады һәм:

– Мин палаталарны йөреп чыгыйм әле, – диде.

Ишек катына җиткәч, хирургка нинди дә булса тынычландыра торган сүз әйтергә теләде. Әмма андый сүзләр табылмады.

– Мин монда калсам ярыймы? Монда җылы, рәхәт, – диде Рәмис үзенә һич кенә дә хас булмаган басынкы тавыш белән.

– Син монда кергәнгә җылына бу бүлмә, – диде Илзирә, моңсу елмаеп һәм әкрен генә чыгып китте.

Рәмис өстәлгә терсәкләре белән таянып, куллары белән башын кысып, уйга калды.

Җирдәге хәят үзе тәмуг түгелме соң? Кешеләр, бер яктан караганда, гомер буе җәзалананалар, икенче яктан карасаң, алар – үзләре иблис. Дөрес яшәми кеше. Каян башларга соң төзекләндерүне? Бу сораулар нигә кирәк инде?! Гади хирург нишли ала? Фәкать үз эшен башкара гына ала.

Кешелек дөньясының төпкелендә, ягъни кешенең үзәгендә нindидер яман чыганак ята. Анда син скальпель белән керә алмыйсың. Алып ташларга мөмкин түгел, чөнки син аны күрмисең, тота алмыйсың. Бернинди УЗИ, МРТ, компьютер томографиясе күрсәтми аны. Җирдәге барлык михнәтләр, фаҗигаләр шул яман чыганактан саркый. Аң җитмәслек киң, чиксез Җиһанда, могҗиза өстенә могҗиза кайнаган галәмнәрдә без укымышлы кешеләр зур ачышлар, техник казанышлар белән мактана-мактана горурланабыз, ә үзебезнең асылыбызга һаман төшенә алмыйбыз. Без генә микән бу Әбелхәят кочагында интегүчеләр? Кайлардадыр безнең кебек планеталар, башка төрле кешеләр бар микән? Бәлки алар без чишә алмаган мәсьәләләрне күптән чишкәннәрдер, үзәкләрендәге яман бер шешне күптән инде алып ташлаганнардыр?

Хәер, алай микән? Чит планетада яшәү булган сурәттә дә, алар барыбер бездән дә алгарак китмәгәннәрдер. Чөнки, галимнәр әйтүе буенча, Җиһан бер зур, бөек шартлаудан яралган. Димәк, без бер үк вакытта барлыкка килгәнбез. Вакыт төшенчәсе бер үк, дисәк, бездән тәҗрибәлерәк булулары икеле.

Чит илгә барганчы, анда әллә нинди башка затлы тормыштыр дип уйлыйбыз башта. Ә барып күргәч, анда да шундый ук кайгы, шундый ук шатлык, шундый ук хисләр, шундый ук кешеләр икәнне аңлыйбыз. Анда да елгалар бездәгечә ага, тормыш та бездәгедәй авыр һәм катлаулы. Кайбер әйберләр ялтыравыклы булып күренер, кайбер ризык тәмлерәк тоелыр, әмма кайсы илгә генә барма, анда да шулай ук кайгыдан елыйлар, хатыннар да бала тапканда интегәләр һәм кычкыралар.

Кайвакыт шулкадәр ярдәмсез һәм чарасыз каласың – җаваплылык та үз өстеңә төшә, мөмкинлекләрең дә чамалы була, үткәннәрнең тәэсиреннән дә беркая китә алмыйсың, бүгенге көндә нинди адым ясарга тиешлегеңне дә төгәл аңламыйсың, ә иртәгә нәрсә көткәнен һәм бүгенге гамәлең өчен иртәгә нинди бәяләмә язган – бөтенләй белмисең.

Киләчәк куркыта, чөнки анда билгесезлек. Ничек кенә мин-минлеге зур булмасын, билгесезлек каршында кешедә үз-үзенә ышану кими. Ни гаҗәп, үткән еллар да куркыта, чөнки хәтер тынгы бирми һәм кайвакыт җанны өшетердәй хатирәләр калка. Шулай итеп, киләчәктән курку кешенең үзенә ышанып җитмәүдән башлана, үткәннәрдән исә кеше үзенең элек кылган гамәлләрен искә алып котсыз кала.

Ә хәзерге вакыт? Бүгенге көн? Менә шушы мәл? Куркытмый бит. Әмма бүгенге көн узган көннәр белән киләчәкне тоташтыра. Узган гомер куркытырмы, киләчәк куркынычракмы – нәкъ менә хәзер хәл ителергә мөмкин.

## 7

Көннәр бер-бер артлы үтә торды. «Вакыт дәвалый» дигән булалар. Ай-һай, дәвалыймы ул? Яши-яши синең хәтереңдә башка вакыйгалар урын ала, фәкать шул гына. Вакыт – хәрәкәттәге Мәңгелекнең охшашы. Димәк, элеккеге вакыйга иртәгәсе вакыт өчен бернинди әһәмияткә ия булмаска мөмкин, чөнки иртәгә яңа фаҗиганең, яңа чирнең тууы ихтимал.

Котдус өчен теге вакыйгадан соң, вакыт бөтенләй узмагандыр шикелле тоела башлады. Син ясаган адымнар, син кылган гамәлләр беркая китми

икән бит, гомумән, синең узган гомерең мәңгелек мөлкәте булып кала бирә. Дөресрәге, мәңгелектә синең тарафтан уелган билге-тамгалар булып саклана.

Котдус кызына инде әллә ничәнче мәртәбә бер үк сорауны бирде:

– Әнкәң килер микән?

Мәликә әнкәсенең киләсенә ышанмаса да, әтисенә алай дип әйтәсе килмәде.

– Мин аңа шалтыратып синең турыда сөйләдем, – диде ул, пакетындагы ризыкларны, сокларны тумбочкага тутырып. – Волжскидан ара ерак түгел, бәлки, килер. Ә хатының килер микән?

– Килермен, дигән иде. Күренми әле, – диде Котдус зарлы тавыш белән. – Шалтыратып, хәлне дә белми.

– Эше күптер. Борчылма. Мин бар бит.

Котдусның чырае яктырып китте:

– Әйе, кызым, ярый син бар әле. Шунысы тагын куаныч: язмышыңны минә дигән егет белән бәйләргә җыенасың икән. Егетең шәп. Яшь булуына карамастан, бик абруйлы, төпле егет икән.

Мәликә теләмәсә дә, әтисе никахлашу турында сүз башлады. Булачак туй, торак мәсьәләсе хакында да сөйләштеләр. Котдус, күңеле тулып, бераз елап та алды. Операция билгеләнгән дүшәмбе көнне курку катыш өмет белән көтте ул. Мәликә инде тынычландырыр өчен барлык сүз запасын сарыф итте шикелле.

– Операция ясарга соң түгел, вакытында килеп җитештек – шунысы яхшы, – дип, кат-кат кабатлады Мәликә. – Рәмиснең үзе алынуына сөенеп туя алмыйм.

– Менә бу даруны биргәннәрие, кайчан эчәргә икәнне оныттым, – диде Котдус, тумбочка өстендәге даруга ишарәләп.

Мәликә:

– Рәмискә шалтыратып сорыйм хәзер, – дип, телефонын алган иде, Котдус аңа:

– Кирәкми, – диде. – Эшләре тыгыз аның. Илзирәне күргәнең бардыр бит? Сестраны. Аңардан сора. Ул барысын да белә – бик акыллы кыз.

– Хәзер табам мин аны, – дип, Мәликә палатадан чыгып китте.

Илзирәләр бүлмәсендә Рәмисне күреп, Мәликә башта аптырап калды, аннары шундук шатлыгы йөзенә чыкты.

– Рәмис! Син мондамыни?!

– Әтиеңнең авыру тарихын карап утырдым менә, – диде Рәмис басынкы тавыш белән.

– Даруын кайчан эчәргә икәнне исендә калдырмаган.

– Көн саен иртән ашар алдыннан эчсен.

– Син нишләп болай кәефсез?

– Эшем авыр бит минем.

– Әти дә елап яткан анда.

– Елап ятасы юк. Операцияне барыбер ясарга кирәк.

– Син миннән нәрсәдер яшерәсең шикелле, – диде Мәликә, сагаеп. – Чынлап та, куркырлык бернәрсә дә юкмы?

Рәмис әкрен генә торып, Мәликәне битеннән үбеп алды:

– Әйттем бит инде. Борчылмагыз.

– Хәле начармы әллә әтинең? Анализлары...

– Ник паникага биреләсез – ул да, син дә?! Табибларга ышанырга кирәк. Барысы да яхшы булачак, Мәликә. Уңышка ышанмасам, тотынмас идем бит. Болай нык курыксагыз, операцияне, бәлки, башка кеше ясар? – дип сынаулы караш ташлады ул.

Мәликәнең эчке киеренкелеге тышка бәреп чыкты:

– Син миңа дөресен әйтмисең, – диде ул, еламсырап.

Рәмис, җылы сүзләр әйтеп юатасы урынга кинәт:

– Дөресен мин әлегә үзем дә белмим! – дип ташлады. – Бар, кереп әтиеңне тагын бер тапкыр тынычландыр. Прогноз яхшы! Мин сине монда көтәм. Эш вакытым тәмамланып килә. Озак булма, яме.

Мәликә чыгып киткәч: «Әйе, дөресен мин әлегә үзем дә белмим», – дип үзалдына кат-кат кабатлады Рәмис.

Ышанасы килми... Нәрсәгә? Кемгә? Чынбарлыкның үзенәме? Дөньяның тарлыгынамы? Очраклылык ышандырмыймы? Ә синең ышануың яки ышанмавың нәрсәне үзгәртә ала?

Яман чыганак аерым кешенең төпкелендә генә түгел... Кешелек дөньясында ята яман чыганак... Тормышның төпкелендә кара, акыл ирешә алмый торган коточкыч мәкерле оетккы булып кайный ул. Шуннан чыга тирән фаҗигаләр.

Бу турыда Рәмис еш уйлана. Бу кечкенә Җир шарында үзен-үзе бетерү чирләренең барлыгы гаҗәп хәлмени?! Арыныр, котылыр өчен, каядыр китү мәслихәт. Кая китә аласың моннан? Кая котыла аласың тәкъдиреңә язылганнан? Җир шары үзе дә Кояш тирәли әйләнә дә әйләнә, һич кенә дә ычкына алмый.

Һәрбер сызык кайчандыр боҗра булып тоташа. Ә боҗра, ничек кенә әйләндереп карасаң да, боҗра булып кала. Беркая китеп, качып, тайпылып котыла алмыйсың. Юллар да кайдадыр бер-берсенә барып тоташа, чөнки кешеләр үзләре сала ул юлларны. Шулай булгач, кешеләрнең көтмәгәндә очрашулары гаҗәпмени?

Күк гөмбәзе дә түгәрәк, планеталар да йомры, атомнар, электроннар – барысы да түгәрәк. Кеше психикасы да читкә чыгып озак очып йөрми, әйләнеп үзенә кайта. Бәлки, гомумтүгәрәклектә фаҗига ятадыр? Бәлки шуңа күрә кеше яшәү мәгънәсенә төшенә алмыйдыр? Әгәр дә планетабыз бер үк орбитада йөрмичә, каядыр күз күрмәс тарафларга очып барса, яшәвебезнең мәгънәсе – билгесезлеккә томырылуыбызда дип әйтер идек.

Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә соң? Галимнәр бихисап күп ачышлар ясады, акыл ияләренең тирән фикерләре хәттин ашкан, ә кеше әллә ничә мең элек нинди булган, барыбер шундый булып калган. Эйнштейн теориясе аңлаттымы Җиһанның бөек серен? «Пуанкаре проблемасы»ның хәл ителүе нәрсә бирде кешегә? Барыбер кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр гади, примитив, китап укымыйча да аңлашыла торган булып калды.

Бу дөньяда бәхетнең дә, газапның да чиге юк. Яшәү мәгънәсен эзләгәндә, бу ике капма-каршылыкның бербөтен икәне сизелә. Тулаем алган гомернең мәгънәсе юктыр дигән шомлы уй туа. Ләкин кеше аны үзе өчен көн саен, сәгать саен мәгънәле итәргә тырыша. Шуны эзли ул. Аның яшәү мәгънәсе дә аны эзләүдәдер, күрәсең. Кеше үзенең тулаем гомеренең мәгънәсен аңлаудан мәхрүм. Әгәр дә ул ахыр чиктәге бөек бер мәгънәгә төшенсә, яшәвенең кызыгы булмас иде. Яшәү мәгънәсен эзләү аны яшәтә, тормыш тәмен татырга мөмкинлек бирә.

Шул ук вакытта көн саен, үзе дә аңламастан, мәгънә эзләү адашып йөрүгә тиң бит. Мөгаен, иң акыллы фикер ияләре дә бу дөньядан берни аңламыйча китеп барганнардыр. Барыбер бу чынбарлыкның асылына төшенә алу мөмкин түгел. Матди нәрсәләр, күз күргән күренешләр – фәкать рухи чынбарлыкның символик чагылышлары, күз күрерлек билгеләре генә. Тышкы якта хасил булган нәрсә – рухи чынбарлыкның төрлечә

гәүдәләнеше генә. Кешенең эчке дөньясы нинди – аның гамәлгә ашкан эшләрендә аермачык чагыла. Кешелекнең эчке рухы ни дәрәҗәдә һәм нинди сыйфатта икәнен тарих әле тегендә, әле монда кайнап торган вакыйгалар буенча бәяли. Күзгә күренгән дөнья – аң белән тотып булмый торган эчке халәтнең символларыннан тора. Хәтта илләр арасындагы сугыш та – шул төбәктәге халыкларның рухият торышының символы. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр – ни дәрәҗәдә рухи үсеш кичергәнне (яки рухи түбәнлекне) күрсәтә торган күренеш.

Рәмис күптән түгел үзе өчен ачыш сыман бер фикергә килде: тирәнрәк уйлап баксаң, тормыш-көнкүреш үзе дә, кешеләрнең үрчүе, кешенең чынбарлыкта кыбырсуы, бизнес, дөнья куу, акча эшләү – гомумән, кешелек яшәеше – барысы да ракны хәтерләтә. Гүя бу яшәеш – котылгысыз бер яман чир. Үсү өчен үсү, бернинди фәтвасыз үрчү – рак күзәнәгенең идеологиясе бит!

Уйларның рәте-чираты юк. Һич кенә дә бер мантыйкка тезеп булмый аларны.

**8**

Ул көнне Рәмис эштән иртәрәк китте. Гадәттә, эш вакыты тәмамлангач та вак-төяк кәгазьләрне карап тоткарлана иде ул. Бу юлы операциядән соң ук кайтып китәргә булды.

Хәлилә дә улының бүген иртәрәк кайтуына гаҗәпләнде.

– Көн бигүк тыгыз булмады, – диде Рәмис. – Үзең генәме өйдә?

– Навил эт типкесендә йөргәннән соң кайтып йокларга ятты. Әтисе тагын нindидер укытучысы белән сөйләшергә китте. Хәзер ашатам мин сине, улым.

– Әни, ашау качмас.

Хәлилә улының гадәттән тыш җитдилеген күреп, шундук әллә ниләр уйлап бетерде – эштә берәр күңелсезлек килеп чыкканмы, Мәликә белән аралары бозылганмы, аварияга эләккәнме?.. Ул җитешмәде, Рәмис үзе сорау бирде:

– Әтинең кооперативта бергә эшләгән дусты Казанга кайдан килгән иде, хәтерләмисеңме?

– Волжскидан, дигәние.

– Бир әле алар бергә төшкән фотосурәтне. – Рәмис әнисеннән фотоны алып, озак кына карап торды. – Охшаган, нык охшаган.

– Әйтәм бит, син әтиеңә нык охшагансың.

– Әти белән янәшә басып торучы кеше турында әйтәм мин. Бездә бер пациент ята – бу шуның яшь чагын хәтерләтә.

– Һи, кешеләрдә охшашлык табып була инде ул, – диде Хәлилә, исе китмичә генә.

Рәмис фоторәсемне өстәлгә куеп, диванга утырды.

– Мин аңа операция ясаячакмын. Дустының һәлак булуында үзен гаепле санап кайгырып ята ул. Чуйков – Ибраһимов борылышында аварияга эләкте, исеме Васил, фамилиясе Гыйльметдинов иде, диде. Бергә кием-салым ташу кооперативында эшләдек, Васил өйләнергә җыена иде, дип сөйләде.

Өйдә бер мәлгә колакны «тондырырлык» тынлык урнашты.

– Ул микән соң? – дип пышылдады Хәлилә.

Рәмис тагын шактый вакыт фотога карап торды.

– Охшаган, әни, бик охшаган. Иягендә миңе бар, колаклары зур. Шул инде бу, шул.

– Волжскиданмы?

– Волжскидан.

– Мәликәнең якташы икән... – дип уйга калды Хәлилә. – Ничек гаепле икән соң ул этиеңнең һәлак булуында?

– Мин Василның машинасыннан каракларның тәгәрмәч урларга маташканнарын күрдем, диде ул. Аны күргәч, караклар качканнар. Машинаның алгы тәгәрмәче бер болтта гына калган. Мин аны Василга әйтмәдем, сөйгән кызы шалтыратып чакыргач, ашыгып китеп барды, диде. Тәгәрмәче ычкынып мәтәлгән, диде. Әтине харап иткән булып чыга бит. Мин шуңа операция ясарга тиеш... – Рәмис әйтергәме, юкмы дип уйланып торганнан соң: – Ул гади пациент кына түгел әле... – диде. – Мәликәнең этисе ул.

Хәлилә өнсез калды.

– Мәликәнең этисе?! – дип, пышылдап кына әйтә алды ул.

– Әйе. Сиңа әйтмәм дигән идем дә... Уртаклашасым килде. Әни, зинһар, Мәҗит Нәҗиповичка әйтмә бу турыда, яме. Сер булсын... әлегә.

– Әйтмәм, улым, әйтмәм.

Йокы бүлмәсеннән Навил килеп чыккач, Хәлилә сискәнеп куйды. Аның өйдә икәнен онытканнар лабаса. «Син генә җитмәгәниең монда!» – дип уйлап куйды Рәмис.

– Әти өйдә түгелмени? – диде Навил, берсенә дә туры карарга кыймаган булып кыланып.

– Сине укуыңнан кумасыннар өчен тагын кемгәдер баш иярга китте, – диде Хәлилә, җитди әңгәмә вакытында бу шалапайның монда булуына ачуы килеп.

Навил «уку» сүзеннән чыраен сытып, Рәмискә карады:

– Акча биреп тор әле.

– Әтиеңнән сора, – диде Рәмис һәм кинәт бу имгәкне фатирдан тышка чыгарып атасы килде.

– Мин сиңа аннары бирәм, – диде малай, тыңкышланып. – Әҗәткә сорыйм бит.

– Нәрсә аласың бар? – дип җикерде Рәмис. – Кирәкле әйбер булса, әйт, үзем алып бирәм. Акчалата бирмим!

– Нинди саран кешеләр соң сез! – диде Навил һәм Рәмискә сынаулы караш ташлады: – Нәрсә, этиеңне үтергән кешенең кызына өйләнәчәксеңме инде хәзер?

Хәлиләнең коты очты, Рәмис үзе дә эчке сискәнү тойды:

– Аңламадым? – дигән булды.

– Ә мин барысын да аңладым. Сөйләшкәнегезне тыңлап тордым, – диде Навил битараф кыяфәт белән.

Рәмис аны беләгеннән кысып тотты:

– Менә нәрсә... Ишеткәнсең икән, ярар... Беркемгә дә бу хакта әйтмә, яме.

– Кемгә әйтим мин аны? – диде Навил, беләге авыртудан чыраен сытып.

– Әтиеңә дә ычкындыра күрмә.

– Ярар. Акча биреп тор миңа.

– Күпме?

– Дүрт мең. Бер кызның туган көне, барып котларга кирәк.

Рәмис акча биргәч, «йөгәнсез» малай ямьсез итеп көлемсерәп куйды һәм, кроссовкаларын баулары бәйләнгән килеш киеп, курткасын иңенә элде дә ниндидер көй шыңшый-шыңшый чыгып китте.

Рәмиснең эченә коткы керде:

– Тыңлап торган, зараза!

Хәлиләнең ул малайда хәбәре юк иде.

– Улым, бәлки ул түгелдер... – диде ул, ышанып җиталмыйча.

– Шул инде, шул, әни. Барысы да туры килә бит.

Аяз көнне яшен суктымыни – өнсез калырлык яңалык бит бу. Моны акыл белән аңларлык түгел, монда кайсыдыр чит-ят кешенең явыз нияте бардыр сыман тоелды. Язмыш мондый «бүләк» тә китереп бирергә мөмкин микәнни? Махсус оештырылган нәрсәгә дә охшаган.

Әле тегеләй, әле болай уйлап караганнан соң, икесенә уртак бер сорау тырпаеп калды: нишләргә???

Мәҗит кайтып керде. Чишенгәнче үк, беравык әле Хәлиләгә, әле Рәмискә карап торды. Үзалдына мыр-мыр сөйләнеп, пәлтәсен, эшләпәсен салгач, килде дә Рәмискә туп-туры карап:

– Димәк, шундый хәлләр... – дип куйды.

– Навил бер кызның туган көненә китте, – дияргә ашыкты Хәлилә, Рәмис алып кайткан хәбәр тәэсиреннән тизрәк котылырга теләп.

– Беләм, очрады ул миңа, – диде Мәҗит илтифатсыз гына. – Тагын берәр атнага югалыр микән инде. – Әмма аның башка темага сөйләшәсе килгәне күренеп тора иде. – Ну, Рәмис, нишләргә уйлыйсың инде? – дип сорады ул, көтмәгәндә.

– Нинди мәгънәдә? – диде Рәмис, сагаеп.

Мәҗит, диванга утырып, аягын аякка атландырды:

– Барыбер минем киңәшем дә сиңа комачауламас, дип уйлыйм.

– Аңлатып сөйләш.

– Син операция ясыйсы пациент турында әйтәсем килә. Әгәр дә әтиеңне үлемгә этәрүче – шул кеше икән, операциядән баш тарт. Башка хирург ясасын.

Рәмис йодрыгын төйнәде:

– Вәт, шакал, серне саклармын дигән иде бит. Навил әйттеме?! Беркемгә дә әйтмә дип, акча да бирдем бит әле мин аңа.

– Бер серне ачам дип, башта миннән дә акча алды әле ул, – диде Мәҗит, иреннәрен юкартып.

– Тәки йөгәнли алмадың инде малаеңны, – диде Хәлилә, хафаланып.

– Бәреп үтерәсе генә бар аны, – диде Мәҗит, кыҗрап.

Хәлилә ике кулын селтәп җикерде:

– Әстәгъфирулла, андый сүз әйтмә!

Мәҗит тагын әле берсенә, әле икенчесенә сынаулы караш ташлап:

– Миннән яшермәкче идегезмени? – диде.

– Вакыты җиткәч белер идең әле, – диде Рәмис коры гына.

Һәркем үз уйларына чумып, шактый вакыт дәшми утырдылар, һәркем үзенекен уйлады.

– Синең урында мин отказ бирер идем, – дип аваз салды Мәҗит. – Ул кешегә операцияне син ясарга тиеш түгел.

Рәмис үги әтисеннән шушы фикерне көткән иде дә инде. Әмма бу мәсьәләдә аның фикере бернинди әһәмияткә ия түгел иде.

– Мин инде үзем ясыйм дип, сүз бирдем, – диде ул катгый тавыш белән.

– Кемгә сүз бирдең?

– Мәликәгә. Дөресен әйткәндә, риск шактый зур. Операциядән соң, осложнение булырга мөмкин. Һәм гомергә инвалид булып калуы да ихтимал. Иң яхшы вариант – радикаль простатэкотмияне робот Да Винчи белән ясау. Әмма бездә юк ул. Чит илләрдә ракның беренче стадиясендә робот Да Винчи

белән простатаны бөтенләй алып ташлыйлар да тулы ремиссиягә ирешәләр, ягъни рак турында бөтенләй онытырга мөмкин.

– Ник, Мәликәгә дә, этисенә дә шулай дип аңлат, – диде Мәҗит.

– Германиядә робот белән операция ясатыр өчен 25 мең доллар акча кирәк. Каян алсыннар алар ул хәтле акча?

– Аларның акчасы юк дип, син рисковать итәргә тиешме?

Рәмис кинәт кызып китте:

– Туктале, анда синең ни эшең бар?!

Мәҗитнең дә соңгы вакытта пүтсез малае аркасында нервылары нык какшаган иде, ул да шундук кабынып китте:

– Ничек инде, ни эшем бар?! Ни дигән сүз бу?! Нишләп минем эшем булмасын?! Әгәр дә этиеңнең харап булуында чыннан да ул гаепле икән, син киләчәгеңне Мәликә белән бәйләмәячәксең, шулаймы?..

Рәмис аның сүзен кырт кисеп бүлде:

– Нишләп әле син минем өчен киләчәгемне хәл итеп утырасың?

– Чөнки мин, үги булсам да, синең этиең булып саналам, – диде Мәҗит, үзен кулга алырга тырышып. – Һәм дөрес саналам, чөнки сине тәрбияләп үстерүдә катнашкан кеше мин.

– Мәликәнең ни гаебе бар? – дип арага керде Хәлилә. – Алар бер-берсен яраткач, өйләнешергә җыенгач, этисенең яшь чактагы кабахәтлеге нишләп әле хәзер комачауларга тиеш?

Инде тынычланам дигәндә генә, Мәҗит тагын кыза башлады:

– Ярар, Мәликә синең күңелеңә хуш килде, аны киленең итеп күрәсең килә. Ярар. Ә газиз улыңның аның этисенә операция ясавын телисеңме?

– Белмим, – диде Хәлилә, тәмам боегып.– Ничек кенә булмасын, бу Рәмиснең үзеннән генә тора инде.

– Мәликә дә, аның этисе дә берни белмәячәкләр, – диде Рәмис, катгый итеп. – Һәм операцияне үзем ясаячакмын.

Мәҗитнең кайнарлануы чынлап та Рәмис өчен борчылудан – моны Хәлилә дә, Рәмис үзе дә аңлый. Әмма хәзер мондый бәхәснең беркемгә дә фәтвасы юк. Рәмиснең хәтта чыгып китәсе килде, чөнки сизелеп тора – озакка сузылачак бу хакта сөйләшү.

– Димәк, аларга авария турында әйтмәячәксең? – дип бәйләнде Мәҗит.

– Әйтмәячәкмен.

– Ә ул кеше синең кем улы икәнеңне үзе белсә?

– Каян белсен ул аны. Белсә дә, күпмедер вакыт узгач кына белүе ихтимал.

– Менә, менә! Операциядән соң сидеге тотмый торган булып калса яки башка төрле дефектлар белән бимазаланса һәм операцияне аның аркасында һәлак булган кешенең улы ясаганы мәгълүм булса, сине юри шулай эшләгәнсең дип гаепләячәкләр. Һи, Мәликәгә сүз биргәнсең... Анысы аңлашыла. Ә бит пациентың – сине ярым ятим иткән адәм актыгы!

– Әмма ул бит әле Мәликәнең этисе дә.

– Этисе Чикотило булса да, ул бит – Мәликәнең этисе, дияр идеңме?

Рәмис түземлеген җуеп:

– Телеңне тый! – дип кычкырып җибәрде. – Мин сиңа унике-унөч яшьлек малай түгел!

Мәҗитнең моңа нык ачуы килде:

– Миңа да егерме сигез генә түгел инде! – диде ул кыҗрап. – Үз фикеремне әйткәнем өчен акырасың миңа.

Бәхәс кызганнан-кыза барды.

– Мин үзем дә хәзер аптырашта калдым, – диде Рәмис, әрле-бирле йөреп. – Монда син тагын күңелне болгатасың. Бу ситуациядә эшең булмасын. Әнә, үз улың белән дә проблемаларың хәттин ашкан – шуларны хәл итү турында уйла.

Мәҗит Рәмискә текәлеп карады:

– Син минем белән алай сөйләшмә, – диде ул чак кына ишетелерлек, әмма яман усал тавыш белән. – Проблемаларымны чишү минем хәлемнән килер. Мин улымны ничек тә авызлыклый алырмын. Ә синең болай дорфа сөйләшергә хакың юк минем белән.

– Туктагыз әле, сезнең талашуыгыз гына җитми иде монда, – дип тыгылып карады Хәлилә, әмма Мәҗит әле тынычланырга уйламады, ул Рәмиснең битенә терәлеп диярлек, еш кабатлый торган сүзләрен әйтте:

– Канса да кансов, синең тәрбияңә зур өлеш керткән кеше мин. Әле билгеле түгел, мин булмасам, нинди юлдан китәр идең дә, кем булыр идең. Үсмер чагыңда синең проблемаларны да хәл иткәләдем. Мине начар ата дияргә беркемнең дә теле әйләнмәс.

– Менә боларын әйтеп тормасаң да була иде, – диде Рәмис, читкә китеп.

– Мәҗбүр иттең, – диде Мәҗит.

Бер мәлгә тынлык урнашты, Хәлилә татулаштырыр өчен ниләр әйтим икән дип уйланып торганда, Рәмис:

– Мәҗит Нәҗипович, гафу ит, – диде.

Хәлилә җиңел, иркен сулап куйды. Ә Мәҗит, шуны гына көткән диярсең, барып шкафны ачты:

– Әйдә, алайса, берәр рюмка тотып куйыйк.

Коньяк йотып куйгач, алар шактый вакыт дәшми утырдылар. Хәлилә дә үз уйлары белән диванда тып-тын гына утырды.

– Нишләргә дә белгән юк инде, – диде Рәмис, авыр сулап. – Мин операциянең уңышлы булуына 95 процент ышанам.

– Ә теге биш процентка эләксә, бик яман хәлләр булуы ихтимал, – дип барыбер үз фикерен алга сөрде Мәҗит. – Мин бит синең өчен борчылып әйтәм.

Болай да тынгысызлык хөкем сөргән өйгә тагын да төкселек өстәп, бусагада Навил пәйда булды. Рәмиснең усал кыяфәтен күреп, Навил ялагай елмаю белән:

– Телефонымны онытып калдырганмын, – диде һәм, аяк киемен салып тормыйча гына, телевизор янында яткан телефонын барып алды. Ишек катына җиткәч исә кинәт кыюланып: – Операция кайчанга билгеләнгән? – дип кызыксынды.

– Анда синең ни эшең бар! – диде Рәмис һәм барып, яңагына чабарга да теләге бар иде, аны Мәҗит беләгеннән тотып туктатты.

Навил сискәнеп куйды, әмма чыгып китәргә ашыкмады, авызын чак кына чалшайтып:

– Мин хирург булсам, операция ясаганда аны, махсус укол кадап, үтерер идем, – диде һәм мыскыллы елмайды.

– Хәзер тотып ярам мин сине! – дип, әтисе үзе килә башлагач, Навил:

– Сүз әйтергә дә ярамый, – дип көлемсерәде дә тиз генә чыгып китте.

– Тинтәк! – дип кычкырып калды Мәҗит аның артыннан. Аннары, беркавым башын аска иеп уйланып торганнан соң, әйтеп куйды: – Болай булмый. Уфага илтеп ташлыйм мин моны.

Өйнең яме китте. Сәбәпләре билгеле, әмма җайлы гына хәл итеlә торган түгел.

– Операция уңышсыз тәмамланса, сине гаепләячәкләр, – дип, һаман үзенекен кабатлады Мәҗит. – Әтисе өчен үч алу ниятеннән дөрес ясамаган, диячәкләр.

– Әтине ул харап иткәнне кем белсен?

– Һи, андый нәрсә ишетелми калмый ул, – диде Мәҗит.

– Аны беркем белмәячәк, – диде Рәмис кырыс тавыш белән. Ул җан тынгысызлыгыннан сулыгып киткән әнкәсенә карап елмайды. – Ә операция уңышлы узасына минем иманым камил.

– Тыңла сүземне! – диде Мәҗит, өзгәләнеп. – Башка хирург ясасын!

**9**

Мәликә өстәлендәге бер өем китапларга карап, авыр сулап куйды. Кыска гына конспект өчен күпме чыганак! Бу арада бөтенләй баш эшләми. Автомат рәвешендә генә укый, әмма бернәрсә аңлашылмый, истә калмый. Күңел булачак операциядән курка. Нindидер аңлатып булмый торган тагын бер төрле шом бар.

Берүк уңышлы гына узсын инде. Рәмис ясаячак аны, димәк, куркырга кирәкми. Нишләп соң ул соңгы көннәрдә сәерләнде? Ясыйсы операция турында да сөйләшәсе килми. Әллә минем әтием булганга җаваплылыкны кирәгеннән артык тоямы? Әллә операция нәтиҗәсе икеләндерәме? Әллә әтиемнең хәле мөшкел һәм моны миңа әйтмичә, Рәмис үзе генә кайгырып йөриме?.. Әллә этине монда китергәнгә үкенәме?

Мәликә бу сораулардан, бу уйлардан арыныр өчен кул астындагы китапны ачты. Шул вакытны ишек кыңгыравы зеңгелдәде.

Ишекне ачса, анда, авызын ерып, Навил басып тора. Мәликә аптырап китте. Теге көнне, Рәмисләрдә кунакта берничә минут эчендә генә дә бу шалапайдан җаны бизгән иде аның. Ни калган икән аңа монда?..

– Исәнмесез, – диде Навил ясалма ягымлылык белән.

Мәликә бу тәмам тугарылган, ямьсез малайга ягымлылык бөтенләй килешмәгәнне абайлады.

– Сезгә кем кирәк? – диде.

– Сез кирәк. Мин – Навил, хәтерлисездер?

– Шуннан?

Навил аяк киемен дә салмады, курткасының замогын чыжлатып аска төшерде дә, рөхсәт сорап-нитеп тормыйча, түргә узды, Мәликә каршы килергә базмады.

– Обстановка ярыйсы монда, – диде Навил, фатир эченә күз йөгертеп. – Ничек яшәп ятасыз? Тынычмы бу район?

– Зарланырлык түгел. Миңа нindидер йомышың бармы?

– Без бит тиздән туганлашасы кешеләр. Менә, кереп, хәлегезне белергә уйладым.

– Берәрсе куштымы әллә? – диде Мәликә, көтелмәгән кунакның йөзеннән нәрсә дә булса аңларга тырышып.

– Кушмады, үз теләгем белән килдем. Минем сезгә бер үтенечем бар.

– Нинди?

– Акча биреп тора алмыйсызмы?

– Акча?

– Мин бер атнадан кайтарырмын.

– Хәзер бирә алмыйм. Хезмәт хакы алгач кына биреп тора алам.

Навил якынрак килде:

– Мин сиңа бер серне ачсам, хәзер үк бирәсеңме?

– Нинди серне? – диде Мәликә, шомланып.

– Рәмис абыйның әтисе турында. Әйтсәм, бирәсеңме хәзер үк?

– Үги әтисе турындамы?

– Юк, чын әтисе турында, родной әтисе хакында.

– Аның әтисе ул туганчы ук һәлак булган.

– Менә шул турыда дөресен әйтә алам мин. Бер атнадан китереп бирәм акчаны. Биреп тор инде. Сиңа ул серне белү бик мөһим дип уйлыйм. Аннары соң булмагае.

Бу чынлап та җитди хәбәр әйтергә җыена шикелле, Мәликәнең тизрәк ишетеп, моңардан котыласы килде.

– Күпме кирәк соң? – диде ул.

– Биш мең.

– Өч мең биреп тора алам, биш мең үк биралмыйм.

– Ярар инде алайса, өч мең тек өч мең.

– Нәрсә әйтергә телисең? – диде Мәликә, өстәл тартмасын ачып.

– Акчаны бир инде башта.

Акчаны куртка кесәсенә тыгып куйгач, Навил беравык елмаеп торганнан соң:

– Аның әтисе белән синең әтиең моннан егерме тугыз ел элек бер кооперативта эшләгәннәр, – диде. – Синең әтиең аркасында һәлак булган ул.

– Кем?

– Рәмис абыйның әтисе.

Мәликәнең коты очты:

– Ни сөйлисең син?! Тилерденңме әллә?

Бу малайның психикасы чалшайган, гарип фантазияләр белән яши, дип уйлады Мәликә, акчаны биргәненә үкенеп.

Навил исә куен кесәсеннән фоторәсем чыгарды:

– Бу фотода алар икесе бергә төшкәннәр. Менә Рәмис абыйның әтисе. Ә менә монысы синең әтиеңме?

Мәликә фотоны алып, җентекләп карады.

– Әйе, мондый фото бездә дә бар иде... Волжскида. Әйе, монысы минем әтием. Нишләп минем әтием аркасында һәлак булсын, ди ул? Кем әйтте сиңа монысы Рәмиснең әтисе дип?

– Мин Рәмис абыйның әнисенә сөйләгәнен шыпырт кына тыңлап тордым, – диде Навил һәм фотоны тартып алды да курткасының эчке кесәсенә тыгып куйды. – Машинасының тәгәрмәче бер болтта гына эләгеп торганын әтиең күргән, әмма Рәмиснең әтисенә шуны әйтмәгән. Менә шул аның гаебе.

Мәликә пошаманга калды:

– Нишләп миңа Рәмис бу турыда әйтми соң?

– Әйтәсе килмидер.

– Рәмис каян белгән?

– Рәмис абыйның кем малае икәнен белмичә, әтиең үзе аңа сөйләп ташлаган. Аңлап була – операция алдыннан гөнаһларын барлап ятадыр, үкенәдер.

– Фотоны миңа калдыр, – диде Мәликә.

– Мин аны яшертен генә алдым, Хәлилә апа өчен бик кадерле фото ул.

– Аннары кире кайтарырмын.

– Акчаны биш мең итеп бирсәң, фотоны калдырам.

Мәликә тагын ике мең өстәп биргәннән соң, Навил фоторәсемне кесәсеннән алып өстәлгә куйды да:

– Менә хәзер уйла инде – әтиеңә операцияне кем ясарга җыена... – диде.

Навил артыннан ишек ябылгач, Мәликә бик озак һушына килә алмый торды. Бу хәбәргә ышанасы килми. Әмма күңел сизә – Навил алдамый. Ышандырырлык итеп әйтте. Мәликә телефон номерын кат-кат җыеп карады, ләкин җавап бирмәделәр.

Кая барасын да уйламыйча, пәлтәсен киде дә яланбаш көе генә чыгып китте. Томырылып йөгерәсе килде аның. Әле яңа гына ишеткән яман хәбәрдән шулай котылу мөмкиндер сыман тоелды.

Өлгермәде, подъезддан чыгу белән каршында Рәмис пәйда булды. Бу юлысы аның кулында чәчәк бәйләме юк иде, әмма Мәликә моңа игътибар итмәде.

– Нишләп телефоныңны алмыйсың? – диде ул калтыравык тавыш белән. – Әллә ничә тапкыр шалтыраттым.

– Телефонымның тавышын басып куйган идем – ишетмәгәнмендер... Нәрсә булды сиңа? Йөзеңнең төсе качкан.

– Шалтыратам, шалтыратам, җавап бирмисең, – диде Мәликә, еламсырап. – Үзең дә озак шалтыратмадың. Борчыла башладым.

– Борчылма, әле генә әтиең янына кереп чыктым, кәефе яхшы. Әйдә, берәр кафега кереп утырыйк, кофе эчик...

– Миңа саф һава кирәк, – диде Мәликә, борсалануын яшерә алмавына җаны әрнеп һәм үзендә гаеп тоеп. – Урамда гына йөрик. – Шундук кинәт Рәмискә текәлеп: – Операцияне син ясыйсыңмы? – дип, инде әллә ничәнче кат сорады.

– Мин икәнне беләсең бит, күпме кабатларга була инде?!

Күренеп тора, Мәликә соңгы вакытта сулыгып китте, күзләре нык моңсуланды, нервлары киеренке. Юк сораулар биреп төпченә, шикчел. Менә хәзер дә Рәмискә туры карап, аның ниндидер тирәнтен серен белергә теләгәндәй сорады:

– Нишләп йөзең болай караңгы? Кырыс дип әйтимме...

– Бик авыр көн булды бүген.

– Синең ниндидер серең бар – минем белән уртаклашырга теләмисең шикелле.

– Синнән яшерерлек нинди серем булырга мөмкин минем?

– Әтигә операция ясарга алынганыңа үкенәсең бугай...

– Ни сөйлисең инде син! – Рәмис аны кочагына алды. – Син мондый шикчел түгел идең бит, Мәликә.

Егетенең кочагында Мәликә кинәт җебеде, мөлдерәмә тулы күз яшьләре ташып чыкты.

Мәликәнең егерме тугыз ел элек булган вакыйга турында сөйләшәсе килде, әмма тыелып калды. Ул хәзер курка – Рәмиснең уй-ниятләрен ничек белергә? Ясасын микән Рәмис операцияне? Хәзер инде әтисен аның пычагы астына яткыру дөрес булырмы? Соңгы минутларда гына да әллә ниләр уйлап бетерде ул.

Рәмис үзе дә аптырашта. Аның да Мәликә белән ачыктан-ачык сөйләшәсе килә, ләкин хәзер инде барысын да уртага салып актарудан ни файда? Шулай итеп, һәр икесенә мәгълүм нәрсәне бер-берсеннән сер итеп яшерәм дип, ачыктан-ачык сөйләшүдән мәхрүм кала бирделәр.

Алар урам буйлап дәшми генә атладылар. Әмма озак сөйләшмичә тору мөмкин түгел. Ә сүз, телисеңме-юкмы, әтисенең диагнозына бәйле килеп чыга. Мәликә, саклык белән генә, булачак операциягә карата Рәмиснең оптимизмы сүрелгәнне сизүен әйткәч, күңелдәге шомны көчәйтерлек җавап ишетте:

– Оптимизм беркая да китмәде китүен. Әмма шунысы бар – операция бик катлаулы булачак. Риск зур.

Мәликәнең йөрәге жу итеп куйды:

– Башта алай димәгән идең түгелме?.. – диде ул хафалы тавыш белән.

– Әйтсәм дә, әйтмәсәм дә, риск һәрвакыт бар. Европада робот Да Винчи аппараты белән ясыйлар аны. Һәм алар йөз процент гарантия бирә алалар. Бездә ул аппарат юк. Бездә шул аппарат урынына – мин.

Германиядә ясатыр өчен 25 мең доллар кирәк икәнен Рәмис әйтеп тормады. Барыбер ул хәтле акчаны табып булмаячак. Эзли торгач, бәлки, бурычка җыярга да мөмкиндер, әмма вакыт бара, ә операцияне кичектерергә ярамый.

Мәликәнең тамагына төер тыгылды. Ул туктап, Рәмискә текәлеп карады:

– Әйт дөресен, алынасың киләме операциягә, юкмы?

– Белмим, – диде Рәмис, шулай ук туры карап. – Ә син телисеңме минем алынуымны?

– Белмим, – диде Мәликә чак кына ишетелерлек итеп.

Рәмис елмаеп, Мәликәне иңеннән кочты:

– Ике «минус» нәтиҗәдә «плюс» биргән кебек, ике «белмим» бер «беләм»гә тиң дип кабул итик.

Мәликәнең эчендәге коткыны тиз генә таратырлык түгел иде инде.

– Син бит башта бернинди икеләнүсез үзем ясыйм дигән идең.

– Мин хәзер дә әзер. – Рәмиснең тавышында арыганлык сизелде. Әмма сөйләшүдәнме, әллә теманың үзеннәнме – аңлашылмады.

– Ни сәбәпле икеләнә башладың?

Рәмис гәүдәсен турайтып, күккә карап алды, аннары җитди кыяфәт белән Мәликәгә текәлеп:

– Җаваплылык артык зур, – диде. – Әмма мин ясарга тиеш. Чөнки минем мондый операцияләр буенча тәҗрибәм бар.

Мәликә инде үзе өчен карар кабул итте: барысын да үз агымына җибәрергә. Башкача нәрсә эшләп була инде? Рәмис белән ачыктан-ачык сөйләшеп, этиләре арасында булган хәлләр турында икесенә дә мәгълүм икәнне уртага салып, бергәләп уртак карарга килү яхшырак булмасмы? Ләкин Рәмис яшерергә тырыша бит, бернинди сер юк дигән була. Сер түгел бит инде ул, Рәмис, мин барысын да беләм дип, ярып саласы килде аның, әмма тыелып кала алды. Белмәмешкә салыша икән, димәк, шулай тели. Димәк, шулай кирәк. Ул бит инде Рәмисне күптән белә – астыртын гына үч ала торган, яман эш кыла торган кеше түгел ул. Шулай да Мәликәнең ярты «мин»е операцияне Рәмис ясау яклы булса, икенче яртысы – башка хирург тотынсынмы икән әллә дип бимазаланды. Әйе, әйе, моны үз агымына җибәрергә кирәк. Рәмис – иң ышанычлы хирургларның берсе. Рәмис аны ярата. Аннан шикләнеп инде...

– Соңгы берничә көндә кинәт нык үзгәрдең син, – диде Мәликә, Рәмискә елышып.

– Үзгәрерсең дә, – дип елмайды Рәмис. – Синең этиеңә операция ясаячакмын бит.

– Куркам! – дип пышылдады Мәликә.

– Куркырлык бернәрсә дә юк, – диде Рәмис һәм кызны ике битеннән үпте.

– Сине югалтудан да куркам.

– Кая югалыйм мин? – диде Рәмис һәм уйга калып өстәп куйды: – Дөресен әйткәндә, бу вәхши дөньяда югалу да гаҗәп хәл түгел. Кешенең үзеннән генә тормый шул...

Рәмиснең телефоны зеңгелдәде. Кайчандыр университетта бергә укыган курсташы бер пациентының диагнозлары буенча киңәшләшергә иде дип шалтыратты. Рәмис, Мәликәдән гафу үтенеп, шунда китте.

Мәликәнең үзәге аша ниндидер үткен бер тимер әйбер сызып үтте. Бәгырь урталай ярылгандай, йөрәк икегә бүленгәндәй булды. Эчтә нәрсәдер ике өлешкә киселде һәм аны инде ялгап булмас кебек тоелды.

Өйгә кергәч, бүлмә уртасында тораташ булып басып торды ул. Инде күптән җаны бизгән фатирның һәр почмагы, стеналары, җиһазлары чит-ят булып күренде. Һавасы да авыр, начар исле икән. Аның күз карашы тәрәзә төбендәге орхидея чәчәгендә тукталды. Эчтә җылы дулкын йөгереп узды. Мәликә тирән сулыш алып куйды.

«Юк, ялгыштыр бу, болай булырга мөмкин түгел, төзәтелмәслек берни дә юк!» – дигән мең шифалы уй йөрәк белән бер көйгә сулкылдады. Өметне әллә нинди кара кайгылар да җиңә алмый. Ә мәхәббәтне җиңеп буламы? Рәмистән дә ышанычлырак кешене моңарчы Мәликәнең очратканы юк иде. Иң авыр, иң бормалы хәлләрдән чыгар өчен дә дөрес юл табачак Рәмис. Без бит инде ир белән хатын буласы кешеләр. Без бит бер гаилә булачакбыз, балаларыбыз туар... Шундый киләчәкне бозарга, юк итәргә нинди бәланең көче җитәр икән?!

Мәликә, күз яшьләре аша елмаеп, орхидеяга бик озак карап торды.

**10**

Егерме тугыз ел элек булган фаҗигале вакыйга тынгылык бирми, әтисенә куелган яман диагноз тәүлек әйләнәсе истән чыкмый, Рәмиснең беренче мәхәббәте Илзирә көн саен диярлек очрап тора – боларның барысы бергә туры килүдән күңел төшенкелеккә нык биреште. Мәликә инде хәтта «Әллә әти белән киңәшләшим микән?» дип тә уйлап куя. Әмма, юк, юк, ди ул үзенә, әтигә әйтергә ярамый, үземә дә белмәмешкә салынып йөрисе генә кала.

Хәзер Рәмистән генә тора инде. Барысы да чын мәгънәсендә аның кулында. Ул да белә теге вакыйганы... Үзем ясыйм, дигәне куркыта... Әтием – дошман бит аның өчен! Дошман!

Бу хакта Рәмис белән ачыктан-ачык сөйләшсә, аралар өзелер сыман. Туктале! Чын-чынлап ярата икән, нишләп өзелергә тиеш соң? Юк! Үз агымына җибәрәм, дидем бит инде.

Шушы уйлар белән Мәликә әтисе янына кергәч, Котдус, палатада әллә кайчаннан бирле кулдан кулга йөреп таушалган юка китапны тумбочка өстенә куеп, торып утырды.

Аның:

– О-о-о, минем кызым килгән, – дип җанлануына җавап итеп, Мәликә бары тик:

– Хәлең ничек? – диде һәм саклык белән генә карават кырына утырды.

– Бер көе, – дип, Котдус кызының йөзеннән төс качканга аптырап калды.

– Әти, миңа әйтер сүзең юкмы? – диде Мәликә, туры карамаска тырышып. – Миннән яшергән берәр серең юкмы дип сорамакчы идем...

– Синнән нинди серем булсын инде, кызым, – диде Котдус, сагаеп.

– Врачлар белән ничек сөйләшәсең, минем белән дә шулай ачыктан-ачык сөйләш, – диде Мәликә кинәт кырыс тавыш белән. – Мин бит синең кызың.

Котдус пошаманга калды:

– Мин әле аларга сөйләргә ярамаган кайбер нәрсәләрне дә ачам сиңа. Син үзең миңа нидер әйтергә телисең, ләкин кыймыйсың кебек.

Мәликә шундук кискен сөйләшкәненә үкенеп куйды.

– Юк, юк, әти, мин болай гына... Бүген көне шундый, ахрысы...

Котдусны процедуралар бүлмәсенә кан бирергә алып киттеләр. Мәликә

тәрәзә янына барып, тышка күз салды. Машиналар чаба, кешеләр тыз-быз үтеп тора. Шул ыгы-зыгыга кереп югаласы иде дип уйлап куйды ул. Хәер, урамдагы кешеләрдә проблемалар юкмыни? Кемгә җиңел, рәхәт икән яшәве? Берничә көн элек Илзирә белән көтмәгәндә килеп чыккан әңгәмә искә төште. Мәликә әтисе яныннан чыгып килә иде, диспансер каршында Илзирә очрады. Илзирәнең лабораториядән анализлар язылган бер папка кәгазь алып кайтып килеше иде.

– Исәнмесез, Илзирә! Миңа бер-ике минутыгызны сарыф итмәссез микән? – диде ул, медсестраның юлына аркылы төшеп.

Илзирә башта аптырап китте, аннары кулындагы сәгатькә карап алды:

– Минем биш минут вакытым бар. Тыңлыйм сезне.

Мәликә сүзне ничек башларга белми аптырап торганнан соң:

– Эшегез авыр сезнең... – дип куйды.

– Минекеме?

Мәликәнең эчке киеренкелеге кыяфәтенә чыккан иде. Ул хәтта бераз тотлыгып та алды:

– Гомумән... мед... ицина хез... мәткәрләренә.

– Сезнең дә эш җиңел түгелдер, – диде Илзирә, әңгәмәнең мәгънәсенә төшенә алмыйча. – Җиңел яшәү – үзе дә кызык, рәхәт булмас иде. Эшкә килгәндә, сезнең укытучы хезмәте дә авыр бит. Җаваплылык медицинада да, педагогикада да гаять зур. – Ул көлемсерәп куйды. – Бездән дә, укытучылардан да кешеләр һәрвакыт могҗиза көтә, ә могҗиза килеп чыкса, һич кенә дә гаҗәпләнмиләр.

– Дөрес әйттегез, – диде Мәликә, Илзирәне дикъкать белән күзәтеп.

– Миңа ниндидер җитдирәк соравыгыз бармы әллә?

– Гафу итегез... Сез Рәмиснең беренче мәхәббәте булгансыз икән, шулаймы?

Илзирә бер мәлгә сүзсез калды.

– Беренчесе һәм бердәнбер мәхәббәтем, – диде ул турыдан-туры. – Аннан башка мин беркемне дә ярата алмадым.

– Хәзер дә яратасызмы? – дип, мәнсез сорау биргәнен Мәликә үзе дә сизми калды.

Илзирә көлемсерәп карап торды да:

– Сез аның белән тиздән никахлашачаксыз. Көнләшерлек сәбәп юк сезгә, – диде һәм әңгәмәне дәвам итүнең мәгънәсезлеген аңлап, диспансерга кереп китте.

Мәликә беравык нишләргә белми торды да йөгереп, диспансерга керде һәм Илзирәгә ияреп, янәшә атлады:

– Ә сез көнләшмисезме? – диде ул никтер ачулы тавыш белән.

Илзирә аңардагы эчке агрессияне абайлады һәм шундый ук тонда катгый итеп җавап бирде:

– Көнләшәм. Яхшы көнләшү белән көнләшәм. – Ул тиз-тиз атлап икенче катка менеп китте, Мәликә аңардан калышмады.

– Көнләшү яхшы була аламыни? – диде ул еш-еш сулап.

Икенче катта туктап, Илзирә:

– Хөрмәт иткән кешенең бәхетле булуына ничек сөенмисең инде, – диде. – Мин Рәмис өчен шат – үз кешесен тапкан. Аңа бәхет кенә телисе кала. Сездән көнләшәм – шундый кешенең хатыны булачаксыз. Ләкин мин сезнең өчен дә шат. Рәмис сайлаган бит сезне.

– Сез аңа идеаль кешегә караган кебек карыйсыз бугай.

– Идеаль кеше була алмый дөньяда. Кешеләрнең йөрәк тибешләре дә унисонда була алмый. Ике йөрәкнең нәкъ бертөрле типкәнен әлегәчә ишеткәнем юк. Күңел аваздашлыгы гына булырга мөмкин.

Илзирә әңгәмәне, ниһаять, тәмамлар өчен, тагын сәгатенә карап алды һәм икенче катның коридоры буйлап китте.

– Табиблар, хирурглар да идеаль була алмыйлармы? – диде Мәликә, ияреп.

Илзирә бу бәйләнчектән тәмам туйды.

– Табиб та, хирург та – җирдә яши торган кешеләр инде. Фәкать кешеләр генә, – диде ул, кереп китәсе кабинет ишеге янында туктап.

Мәликә үҗәтләнеп, кабинет ишегенә аркылы басты:

– Әйтегез әле, операция өстәлендә хирургның якын кешесе ятса, ул бар көчен дә куеп башкара бит инде эшен, шулаймы?

Мәликәнең эчендә ниләр кайнаганны Илзирә аңлый, хәтта кызганып куйды ул аны. Кереп-чыгып йөрүчеләргә комачауламас өчен ул ишек төбеннән читкәрәк барып басты.

– Өстәлендә кем ятса да, минемчә, чын хирург бар көчен куеп эшли, – диде Илзирә ихластан.

– Дөнья катлаулы бит ул... – диде Мәликә, калтыранган кулларын кая куярга белмичә. – Мәсәлән, операция өстәлендә дошманы ятса... хирургтан зыян көтәргә мөмкинме?

– Бу очракта операцияне башка кеше ясыйдыр дип уйлыйм. Нишләп сез мондый сораулар бирәсез? Әтиегезгә операцияне булачак ирегез ясаячак. Рәмис – яхшы хирург, ул хирургиябезнең өмете булып санала. Төче сүзләр әйтәсем килми... Шулай да кеше, кем булып эшләсә дә, иң элек үзе алдында җавап тота инде ул. Башкалар алдындагы җаваплылык кына аны игелекле итә алмыйдыр.

– Әтинең борчылганын күргәч, башка әллә нинди уйлар килә шул. Гафу итегез... – диде Мәликә, елмаерга тырышып һәм, үзе дә сизмәстән, кинәт сорап куйды: – Ә сезнең аралар ни сәбәпле өзелде?

– Безнең аралар өзелмәде. Бер гаилә булырга гына язмаган. Аны болай гына сүз белән аңлату мөмкин түгел инде. Тормыш-көнкүреш болганчык агым кебек бит ул. Бер үк яшәеш, бер үк мохит югыйсә... Кешеләр якыная да, ерагая да... Яшь чактагы кыйммәтләргә мөнәсәбәт үзгәрә, хисләрнең кайсысы саега, тора-бара яңалары туа... Аннары, Рәмис – хирург, кайвакыт ул кырт итеп кисә дә куя. Хирургта андый катылык булырга тиештер инде. Аңлата алмыйм... Мәхәббәтнең үзен дә аңлатып булмый бит – ни өчен нәкъ менә шушы ике кеше бер-берсен яраталар? Сезгә нәрсәгә кемнәрнеңдер кайчандыр булган үзара мөнәсәбәтләре? Сез бәхетле кешеләр, Мәликә. Алла боерса, барысы да тәртиптә булачак, менә күрерсез. Кайгырмагыз, тынычланыгыз.

Илзирә, Мәликәнең үз уйларына чумып дәшми торуыннан файдаланып, тиз генә китеп барды, ә Мәликә, кая атларга белмичә, баскан урынында катып калды. Кресло-каталканы этеп баручы апа юл бирүне сорап эндәшкәч тә кузгалмады ул.

Апа якын килеп:

– Хәлегез начар мәллә? – дип сорагач кына, ул:

– Әйе, апа, хәлем шулхәтле начар, хәтта яшисем килми, – дип, коридорның икенче башына таба йөгерде.

Апа бер мәл аның артыннан карап торды.

– Димәк, хәлең бигүк авыр түгел икән әле, – дип мыгырдады ул. – Яшисем килми дип, авыз тутырып әйткәч, үләсең дә килми әле синең. Әҗәл якынайгач, яшисе килә ул... – дип үзалдына сөйләнеп, апа каталканы этеп китте.

## 11

Рәмис биш минут кына буш вакыты булса да, Илзирә янына чәй эчәргә керә.

– Нихәл, Илзирә? – диде ул, гадәттәгечә, көненә инде әллә ничәнче мәртәбә.

– Аллага шөкер, – диде Илзирә, эчтән генә чиксез куанып, әмма йөзенә ясалма корылык чыгарып.

– Берәр чынаяк чәй эчертмисеңме миңа?

– Минем чәемне эчәргә лаеклы дип саныйсыңмы соң үзеңне? – диде Илзирә, шаярып.

Бу шаяру Рәмиснең күңеленә хуш килде. Аның кәефе күтәрелеп китте.

– Бер чынаяк чәйгә генә тартадыр инде минем абруем, – дип җавап бирде ул.

– Хирургия бүлегегездә чәй эчертмиләрмени, гел миңа керәсең? – диде Илзирә, чәй ясаганда.

– Син ясаган чәй һәрвакыт тәмлерәк була.

– Бәлки мин, сиңа күрсәтмичә генә, чәйгә бер-бер ярамаган нәрсә саламдыр, – дип көлеп җибәрде Илзирә.

– Синең кулдан агу эчәргә дә риза, – дип, Рәмис шаяруга шаяру белән җавап бирде.

– Тиз тәмамладыгыз бүген.

– Җиңел операция булды. Чак кына иркенрәк суларга мөмкинлек бар. Бераз иркенлек тә кирәк шул. Тиздән отпуск алам. Диңгезгә барып кайтырга кирәк.

Илзирә сүзсез калды. Шулай да, кыенсынып кына, сорыйсы итте:

– Булачак хәләл җефетең белән барасыңмы?

Рәмис тиз генә җавап бирмәде.

– Эшеннән җибәрсәләр, бергә барырбыз инде, – дип, уйга калды ул.

– Диңгездә бик еракка йөзеп кермә, бата күрмә.

Илзирәнең бу шаярып әйтелгән сүзе бөтенләй шаяруга охшамады.

– Батсам, нык кайгырырсыңмы? – диде Рәмис, бераз кыланыбрак.

Әмма Рәмиснең бу сүзе дә кызык яңгырамады.

– Тьфү, җүләр, авызыңнан җил алсын, алай димә! – диде Илзирә, ачуланып.

– Синең отпуск кайчан?

– Әй, белмим әле, – диде Илзирә һәм Рәмискә текәлеп карады.

– Синең күз карашың мине тишеп чыга хәзер, – диде Рәмис, елмаеп.

– Куркасыңмы әллә?

– Бераз бар.

– Күңелеңне ачып актарып карыйсым килә.

– Кешенең күңелен актарсаң, аннан әллә ниләр чыгарга мөмкин. Җаның бизүе бар. Операция ясаганда, пациентның күңелен дә, җанын да күргәнем юк әле – шунысы куаныч. – Ул гәүдәсен чак кына алгарак сузып пышылдады. – Илзирә, ә менә синең күңелең, җаның кайда икәнне беләм шикелле. Нindидер сәер уй бу, ләкин мин аны гел тоям, хәтта күрәм сыман. – Кулын күкрәк турысына куеп, өстәде: – Менә ул, аның бер өлеше минем үземә күчкәндер кебек... Аңлата алмыйм...

Беркавым тып-тын утырганнан соң, Илзирә:

– Туеңа чакырасыңмы мине? – дип сорады.

– Әлбәттә.

– Ә мин килмим, – диде Илзирә, кинәт кырысланып.

– Нишләп? – диде Рәмис, гаҗәпкә калып.

– Ул вакытта отпуск алам да, берәр кая китәм – диде Илзирә, торып. – Тагын эчәсең килсә, чәйне үзең ясап эч. Минем эшем күп.

Илзирә чыгып киткәч, Рәмис йөрәк әрнүен тойды.

Нәрсәдер дөрес бармый. Кайда, нинди хата китте, ничек ялгышты, кайсы вакытта? Туктале, нигә үземдә гаеп эзләп, казынып утырам һаман? Ә кайда, кемдә казынырга тагын? Сәбәпләрне фәкать үзеңнән эзләргә кирәк. Шулай булгач, нигә башымны салындырып утырам соң әле мин? Барысы да үз кулымда түгелме? Дөресме, юкмы – анысын да үзем өчен үзем хәл итәм ләбаса.

Һәрбер кешедә булырга тиеш түгел нindидер бозыклык, гөнаһ бар.

Ахрысы, шуңадыр инде гел ялгышабыз, гел яхшы белән начарны бутыйбыз. Хәтта аерым кешенең нindидер камиллеге дә аның кайсыдыр җитешсезлегенә тугандаш булганны тиз арада чамалый алмыйбыз. Шулай ук, кешенең һәр кимчелеге аерым бер камиллегенә тиң икәнне дә дөрес күрмибез. Шуңа күрә бит инде дорфалык кайчак – туры сүзлелек һәм ихласлык буларак кабул ителә. Сак кешене кайберәүләр куркаклыкта гаепли. Акчасын пыран-зыран китерүчене юмарт кешегә санаучылар бар. Адымнарын уйлап ясаучыны куркак дип мыскыл итәләр...

Мәликәне дә ашыгып, югары пьедесталга менгереп кую дөрес булды микән? Әле күптән түгел генә мондый сорау хәтта саташкан сурәттә дә тумас иде. Нindидер зур, какшамас нәрсәнең нигезе чалшайды, үзәктә кинәт нәрсәдер үзгәрде.

Мәликәнең әтисе операция көтә...

Аны кем ясарга тиеш – улмы, башка хирургмы?..

Рәмиснең укыганы бар – үлем җәзасы алдыннан корбан үзенең палачын ярата башлый икән.

Беренчедән, үлемгә дучар ителүче инде бернәрсәне үзгәртә алмаганлыктан, гомеренең соңгы минутларында үзенең мөнәсәбәтен үзгәртә, үзенчә йомшарта.

Икенчедән, ул сизә – палач аның чарасызлыгын күрә һәм дошман итми, корбан аңа өмет белән, ихтирам белән карый. Палач бит моны күрә һәм соңгы минутта кире уйлар да, бәлки, үтермәс дигән өмет калка.

Өченчедән, корбан инде беркем түгел, менә-менә аны үтерәчәкләр һәм аның бердәнбер чарасы кала – буйсынып, баш иеп, палачка мәхәббәт белән карап, аның дәрәҗәсенә «менү».

Дүртенчедән, палачка берсүзсез буйсынып, үлемгә эчке әзерлек тоеп, корбан үзен үтерүдә үзе дә катнаша кебек хис итә.

Бишенчедән, коточкыч авыр халәтне булдыра алганча җиңел рәхәт халәткә әверелдерергә тырышу. Хайвани куркуны мәхәббәткә әверелдерү. Яшәвенең актык мизгелләрендә шуннан да артыгын булдыра алмый корбан. Рәмис булачак операциядә үзен палач итеп күз алдына китерде. Әмма Котдусның үлем җәзасы алдыннан кичерәсе хисләре Рәмискә нигә? Шулай да, корбан кичерешләрен татысын иде әтисен харап иткән кеше, дигән уй тынгылык бирми бимазалады. Югыйсә Рәмис белә – бу кара уйлар күп тә үтми таралачаклар, ләкин алар теге төпкелдәге яман чыганактан калкалар, өстенлек алырга телиләр. Рәмис аларга, әлбәттә, бирешмәячәк.

Мөмкинлекләр күп, әмма һәрвакыт кеше шулар арасыннан бердәнбер мөмкинлекне сайлый һәм куллана. Сайлавы җиңел түгел.

Вакыт басымы астында сайлау йөге кеше өстенә төшә һәм ул мөмкинлекләрне бутый, ясалырга тиеш хак адым урынына хәзерге мизгелдә мөмкин булган шартларны куллана. Бу вакытта яман чыганактан нинди импульс чыга,

җанының миһербанлы тарафыннан нинди импульс калка – шунысы мөһим бит.

Ярар, тагын уйлар берсен-берсе узышып чабалар. Шуннан? Эчке көрәш кенә түгелме соң бу? Әгәр дә көрәш икән, димәк, тикмәгә түгел. Ә йомгаклау фикереӊ нинди? Актык фикерме? Ул гап-гади ләбаса.

Кеше үз теләге белән килми бу дөньяга. Шуӊа күрә беркем беркемне гаепләргә тиеш түгел. Димәк, гаепле кешеләр юк. Әмма бу кадәре вәхши дөньяда гаеплеләр юк икән, димәк, барыбыз да гаепле. Менә бит, монда да бозра тоташты!

Кайсыдыр акыл иясенеӊ фикере искә төште: «Гафу итү бер генә тапкыр була, ә нәфрәт, куралмау көн саен, тәүлек әйләнәсе яши...» Шәп әйткән!

Рәмис чәйнектән чынаягын тутырып, чәй салды да берничә йотымда аны эчеп куйды һәм елмаеп үзенә-үзе: «Алга, Рәмис, алга!» – дип боерды.

**12**

Операция уӊышлы узды. Пациентныӊ кем икәнен, нинди кеше икәнен уйламады Рәмис. Аныӊ бурычы – үз эшен камил дәрәҗәдә башкару иде. Һәм ул аны дөрес һәм иӊ профессиональ дәрәҗәдә үтәде.

Котдус анестезияне җиӊел кичерде. Операциядән соӊ, айныгач, бераз авырту-сызлаулар тойса да, бигүк аһ-зарлары булмады. Бернинди катлаулылык килеп чыкмады. Простата алынды, нервларга, орлык куыкларына зыян килмәде. Сидек юлыннан катетерны да тиз алдылар, Котдус бер атнадан инде үзе бәдрәфкә йөри башлады. Өч айдан анализлары яхшырса, алга таба прогноз йөз процентка уӊай дияргә була. Әлбәттә, гел тикшерелеп, күзәтелеп торырга кирәк булачак.

Вакытында куелды аӊа дөрес диагноз, вакытында аӊа операция ясалды һәм вакытында язмыш аны Рәмис белән очраштырды.

Бер айдан аны стационардан чыгардылар һәм өенә кайтып китәргә рөхсәт бирделәр.

Котдусныӊ кәефе күтәренке бүген. Бердәнбер кызы янында ул. Иртәгә Можгага кайтып китә. Хәтта утырып торасы да килми, бүлмә буйлап әрле-бирле йөри. Мәликәнеӊ диссертация язып утыруын онытып, җырлап та ала. Торымнан-торымга алтын куллы хирургка – булачак кияве Рәмискә көр тавыш белән рәхмәтләр укый. Авыртулар бетте диярлек, чөнки махсус даруларны көн саен кабул итеп тора. Рактан арынасына баштарак икеләнгән иде, хәзер исә инде нык-ныклап ышана – котылды ул, котылды.

– Мин бүлнистән чыгуга җәй дә җитте, – диде ул, тәрәзәдән тышка карап. – Ничек инде яшисеӊ килмәсен бу якты дөньяда! Әниеӊ генә килмәде, – дип көрсенеп куйды ул аннары, Мәликә китаплардан арынган мәлне туры китереп.

Мәликә китапны читкә куеп:

– Хатыныӊ да килмәде бит, – диде. – Ярар, операция уӊышлы узды, шунысы иӊ мөһиме.

Озакламый Рәмис килергә тиеш. Мәликә бүген моӊарчы булмаган дулкынлану кичерә. Киләсе вакытын гына әйтмәде, җан тынгысызлыгын шунысы да арттыра. Әтисе кат-кат кабатлый: «Бик шәп кешегә чыгасыӊ, кызым...» Әйе, Рәмис – алтын кеше... Әмма киләчәк куе күгелҗем томанга төренде. Эч поша. Барысы да уӊай бара иде бит. Менә дигән эше бар, аспирантура тиздән тәмамлана. Тормыш гел уӊай гына барырга охшамаган шул. Котдус та, кызыныӊ кәефсезлеген күреп, торымнан-торымга пошаманга

кала, «Арагыз суынмагандыр бит?» – дип сорый. «Юк, барысы да тәртиптә. Әти, сиңа дулкынланырга ярамый», – дип кенә җавап бирә. Тагын нәрсә дисен инде ул?

Әтисе исә, кәпрәеп:

– Ярый, нишләп ярамасын, – дип елмая. – Врачлар хәтта бераз сухой кызыл аракы кабарга да ярый, диделәр әле.

Әтисе берни сизми... Бәлки, әйтер вакыт җиткәндер?..

Мәликә шактый вакыт икеле-микеле уйлар белән утырганнан соң, дипломатыннан фоторәсемне барып алды. Шуннан соң да әле ул әтисенә күрсәтергәме-юкмы дип уйланып торды.

Ниһаять, тәвәккәлләде ул:

– Менә бу фотога карап нәрсә әйтә аласың?

Котдус фотоны алып карады һәм аның йөзен сәер төстәге елмаю биләп алды:

– Минем яшь чак... Бу бит Волжскида, сездә калган фото.

– Әйе, шул ук фото, ләкин монысы башка кешеләрдә саклана. Кем белән син монда?

– Васил белән, – диде Котдус кысынкы тавыш белән. – Сиксәненче еллар азагында бергә кооперативта эшләгән идек. – Аның йөзе тартылып китте, кыяфәте үтә җитдиләнде. – Авариягә эләгеп, һәлак булды ул. Каян алдың син бу фотоны?

– Рәмисләргә кунакка баргач бирделәр.

– Ә аларга каян килгән ул? – диде Котдус, гаҗәпләнеп.

– Васил исемле бу егет – Рәмиснең әтисе.

Котдусны ток суккандай булды.

– Кит аннан?! – диде ул һәм чак кына фотоны кулыннан төшереп җибәрмәде.

– Менә шундый хәлләр, әти, – диде Мәликә, авыр сулап һәм шул ук вакытта иңеннән авыр капчыкны алып ташлагандай.

Котдус шактый вакыт шок хәлендә утырды. Аның әле моңа һаман тәгаен ышанасы килмәде.

– Ничек болай булырга мөмкин инде? Ничек шушылай туры килә ала? – дип кат-кат кабатлады ул. – Әйе шул, яшьли харап булды Васил... – Ул кинәт тагын да катырак эчке сискәнү тойды. – Рәмис бу фотода мине танымады микән?

– Нишләп танымасын, таныган! – дип, еламсырап тавышын күтәрде Мәликә.

– Үзе әйттеме?

– Юк, аның бу хакта бер сүз дә кузгатканы юк. Рәмис әнисенә синең турыда сөйләгәндә, үги энесе яшертен генә тыңлап торган. Фотоны да шул малай алып килде. Кыска гына итеп әйткәндә, әтисенең һәлак булуында син гаепле икәнне Рәмис белә.

– Ничек инде мин гаепле?! – диде Котдус кинәт кайнарланып. – Нинди сүз бу?! Син нәрсә! Ничек мин гаепле булыйм, ди?!

– Туктале, кызма. Син бит операция алдыннан үзең сөйләгәнсең.

– Әйе... сөйләдем... – диде Котдус, калтыранып. – Ничек бар, шулай сөйләдем... Ләкин... мин үтермәдем бит аны.

Ишек кыңгыравы зеңгелдәгәч, икесе дә сискәнеп куйдылар. Мәликә җәһәт кенә фоторәсемне алып сумкасына тыгып куйды. Бу Рәмис иде. Өстендәге ак сәдәпле куе зәңгәр күлмәк шулхәтле килешеп тора үзенә. Мәликәнең соңгы вакытта куырылган үзәгенә бераз җылы йөгерде – ул бүләк итте бит Рәмискә бу күлмәкне.

– Исәнмесез! – дип сәламләде Рәмис ата белән кызны. – Нәрсә, балтагыз

суга төшкән шикелле каңгыраеп утырасыз?! Хәлең ничек, Котдус абый? Авыртулар кимегәндер?

Котдус көчкә каушавын җиңеп:

– Кими бара, – дип әйтә алды.

– Мәликә, мин килгәнгә шат түгелме әллә син?

– Киресенчә, сине әллә кайчаннан бирле көтәбез инде, – дип, Мәликә елмаерга тырышты.

– Котдус абый, кайткач, үзегезнең бүлнисегездә күренгәләп торырсың. Өч айдан ПСА сдавать итәсең. Нәтиҗәсе нинди булуга карамастан, анализларың белән монда килерсең. Мин язган даруларның барысын да кабул ит. Бернинди проблема булмаска тиеш. Вакытында алып ташладык.

– Рәхмәт яусын сиңа, Рәмис улым! Миңа, завсклад булып эшләүчегә, сәламәтлек бик кирәк. Эшем бик абруйлы минем, – дип, үзенең ни сөйләгәнен дә аңламыйча мыгырдады Котдус.

– Бездә завскладлар гомергә абруйлы булды инде алар, – диде Рәмис, көлемсерәп. – Мәликә, чәй куй әле.

Чәйнекне плитәгә куйгач, Мәликә, чәй янына тәм-том алырга дип, кибеткә чыгып китте.

Икесе генә калгач, Котдус бөтенләй бөреште. Ул шактый вакыт Рәмискә туры карарга куркып торды.

– Менә шулай, Котдус абый... – диде Рәмис, урындыкка утырып.

Котдус, үзен көчкә кулга алып һәм бар көчен җыеп, сүз башлады:

– Мин сиңа яшьлектәге дустым Васил турында сөйләгән идем... Мин куркудан арттырып җибәрдем... Операция алдыннан, үзең беләсең... Мин тәгәрмәч бер болтта гына икәнне аңа әйтергә өлгермәдем. Шефның туган көне бит... Ыгы-зыгы, шау-шу, музыка... Мин аңа әбизәтелне әйткән булыр идем. Мин бәдрәфкә барып килгәнче, ул чыгып киткән иде инде... Операция алдыннан, үзең беләсең... Гөнаһларны барлап ятучы бер мин генә түгелдер... Мин аңа әбизәтелне әйткән булыр идем. Мин туалетка барып килгәнче, ул чыгып киткән, аңлыйсыңмы?..

Танышканнан бирле беренче тапкыр Рәмиснең тавышы усал яңгырады:

– Операциягә кадәр үзеңне гаепле санап, үкенеп-уфтанып яткан идең. Хәзер үкенми башладыңмы әллә?

– Алай түгел! – диде Котдус өзгәләнеп. – Үкенерлек нәрсәләр җитәрлек минем... Дөнья тар ул... Әллә кайларда, әллә кемнәр очрашып куялар... Әллә кайчан булган хәлләр дә беркая китеп югалмый, үзең белән йөри... – Ул башын калкытып Рәмискә туры карады. – Ул синең әтиең икән бит. Син – Василның улы икәнсең. Шуңа күрә генә хәзер акланырга тотынды дип уйлый күрмә...

– Юк, юк, алай уйламыйм. Операция уңышлы тәмамланды да, хәзер син курыкмыйсың, тәүбә итәргә дә җыенмыйсың дип уйлап куйдым. Хәзер бит кешеләрнең күбесе Аллага үзләренә кирәк чакта гына ышаналар. Кайбер кеше яман эш кылдым дип түгел, шуның өчен җәза алырмын дип курыкканга күрә тәүбә итә бит.

– Нигә син миңа тәүбә турында әйтәсең? Мин борып алмадым бит аның тәгәрмәчендәге болтларны.

Рәмис сынаулы күз карашын бөрешеп калган пациентына «кадады»:

– Карале, ә бәлки, син үзең борып алгансыңдыр болтларны?

– Юк, юк, юк! – дип кулларын селтәде Котдус. – Мин Василга әйтергә өлгермәдем – шул гына минем гаебем. Бу җинаять түгел бит инде. Гаепле

булсам, Ходай синең белән Мәликәне дә, мине дә очраштырмас иде. Кызым сиңа кияүгә чыгарга җыена... Син миңа операция ясадың... Димәк, минем гаебем юк, Ходай безне туганлаштырырга җыена икән...

Рәмис Котдуска якын килеп, текәлеп карады:

– Бәлки, ул сынап карыйдыр – мине дә, сине дә.

Котдус ни әйтергә белми торды. Бу авыр, баса, сыта торган тынлыктан котылу мөмкин түгелдер сыман тоелды.

– Син минем кем икәнемне операциягә кадәр үк белдеңме? – дип сорады Котдус, башын аска иеп.

– Әйе, белдем.

– Ә ничек син операцияне үзең ясарга булдың?

– Сине мин монда китерттем. Мәликәгә үзем ясыйм дип, сүз бирдем.

Котдусның тыны кысыла башлады.

– Мин саф һава сулап керим әле, – диде ул һәм ишеккә таба юнәлде.

– Озак йөрмә, хәзер бергәләп чәй эчәбез, – диде аңа Рәмис.

Котдус чыгып киткәч, Рәмис тәрәзәне киереп ачты һәм, җәйге һава тәнгә сарылгач, күзләрен йомып, тирән сулыш алды. Ике олы пакет күтәреп, Мәликә кайтып кергәч тә, тәрәзә яныннан китмәде ул. Җиңел, рәхәт иде аңа бүген никтер... Мәликә янәшә басты. Көн матур... Әмма бу гүзәллектә тибрәлер дулкында түгел Мәликәнең күңеле. Йорт каршында әтисе әрле-бирле йөри. Тизрәк кайтып китсен иде инде ул Можгасына. Хәле яхшы бит инде... Рәмис иңеннән кочкач, Мәликәнең тәне буйлап җылы йөгерде.

– Рәхмәт сиңа, – дип пышылдады ул.

– Сиңа да рәхмәт, – диде Рәмис, еракка карап.

– Миңа ни өчен рәхмәт?

– Мәхәббәт өчен.

– Син мине яратасыңмы?

– Яратам, Мәликә. Син минем якын кешем.

– Куркам мин...

– Нәрсәдән?

– Белмим, – дигән сыктанулы тавыш чыкты Мәликәнең салкынаеп киткән иреннәре арасыннан.

– Курыкма, – дип елмайды аңа Рәмис. – Куркуның үзеннән дә куркынычрак нәрсә юк.

Мәликә кухня тарафына колак салды, суы кайнап беткән чәйнекне йөгереп барып, плитәдән алып куйды. Рәмис янына кире килергә базмыйча торды ул. Хәзер үк уртага салып, ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк!

– Нишләп язмыш болай тупас уйный икән кешеләр белән?! – диде ул, әкрен генә тәрәзә янына килеп.

Рәмис дәшмәде. Мәликә кинәт аның беләгенә ике куллап ябышты.

– Рәмис! Мин беләм! – дип ярып салды ул.

– Нәрсә беләсең? – диде Рәмис тыныч кына.

– Барысын да беләм! Әтиләребез турында.

Ул сумкасыннан теге фоторәсемне алып, Рәмискә сузды. Рәмис моны бөтенләй көтмәгән иде.

– Кем сөйләде? Бу фотоны кем бирде? – диде ул, гаҗәпләнеп. – Әни аны югалтты, өйнең астын өскә китереп эзли.

– Навил килеп сөйләде, фотоны да ул алып килде.

– Вәт, шакал! – дип кенә әйтә алды Рәмис, тешләрен кысып.

Менә, ниһаять, беркемнән берни яшерәсе калмады. Бернинди сер булмаган икән бит ләбаса.

Мәликәнең бите буйлап күз яше тәгәрәп төште:

– Соңгы вакытта миңа карата суынуыңның сәбәбен аңлыйм хәзер.

– Мин сине ничек яратканмын, һаман да шулай ук яратам, – диде Рәмис, аның сүзенә Мәликәнең ышанмаячагын белсә дә.

– Чын әйтәсеңме?

Рәмис моңсу елмаеп:

– Чын, чын, чын әйтәм, чын әйтәмен, аппагым, – диде дә сәгатенә карап алды. – Минем бүген барасы җирләрем күп. Мин сиңа шалтыратырмын.

Мәликә котылгысызлыкны аңлады булса кирәк:

– Салкынайды безнең ара, салкынайды.

– Минемчә, бер үзгәреш тә юк, – диде Рәмис ишеккә таба юнәлеп. – Беребез дә беркая югалырга җыенмый бит.

– Ә никах? – диде Мәликә, кыюлыгын җыеп.

– Син акыллы кыз... Аңларга тиешсең...

– Ташлыйсыңмы мине?

– Нинди сүз инде бу – «ташлыйсыңмы»! Без синең белән гел очрашып торачакбыз... син теләсәң... Ә никахка килгәндә...

– Мин аңлыйм. Мин сине яхшы беләм... Мин инде бу көннәрдә күп уйладым... Бер тапкыр да күрмәгән әтиең алдында гаепле булудан куркасың.

– Дөрес аңлыйсың. Әмма курку түгел бу. Бала чакта да, хәзер дә әти мине гел күктән күзәтеп торадыр шикелле. Нәселебездә Котдус әфәнденең каны булуын тели микән ул?

Мәликәнең йөзе ап-ак булды. Ул беркавым һушсыз торганнан соң, үзендә көч табып:

– Ә синең аңа операция ясаганыңны гафу итә микән әтиең?

Рәмис ишек катына җиткәч:

– Гаҗәеп хәл – мин әтине төшемдә күрдем, – диде. Аның йөзе яктырып китте. – Беренче тапкыр керде төшемә. Беләсеңме, кайчан? Котдус абыйга операция ясаган көнне. Елмаеп, каршыма килде, ике куллап күрештек. Димәк, ул моны хуплый, алай гына да түгел, моның өчен әтием минем белән горурланадыр.

– Әйе, син чын хирург, кырт кисә беләсең.

– Кырт кисү түгел бу. Тиешле адым ясау гына. Бернинди хирург кисә алмый торган җепселләр бар.

Аның күз карашы тәрәзә төбендәге орхидеяга төбәлгәнне абайлап, Мәликә боек тавыш белән:

– Соңгы берничә көн эчендә чәчәкләре шиңеп коелды, – диде.

– Ял итеп, хәл алгач, тагын чәчәк атар.

– Юктыр. Монысы соңгы тапкырыдыр.

– Мин сиңа иртәгә шалтыратырмын. – Ул беравык уйланып торды. – Юк, Котдус абый киткәч, үзең шалтырат, яме.

Ул чыгып китте. Мәңгегә, бүтән әйләнеп кермәскә чыгып киткәндер кебек тоелды Мәликәгә. Аның хәтта еларлык та хәле юк иде. Тәрәзәдән карады – Рәмиснең китеп барганын күрермен дип уйлаган иде. Әмма Рәмис машинасын бу юлы йортның икенче ягында калдырганны белми иде ул. «Беркайчан болай күздән тиз югалганы юк иде», – дигән уй чагылып алды. Тәрәзә төбендәге орхидея икесенең бердәнбер уртак нәрсәсе кебек боегып тора. Мәликәнең,

тәрәзәне киереп ачып, кычкырасы килде. Кемгә? Юкка чыккан Рәмискәме? Подъезд янында кукраеп басып торган әтисенәме? Рәмиснең тормышыннан һич кенә дә алып ташлап булмый торган Илзирәгәме? Тавышыңны ишетерләр ишетүен, әмма беркем хәлеңә кермәс, беркемнән иганә килмәс. Ул ыңгырашып, диванга йөзтүбән капланды.

Шимбә көнне Мәликә Илзирәгә шалтыратты һәм аны кафега чакырды. Ник чакырганын үзе дә белмичә. Ләкин аны күрәсе һәм сөйләшәсе килде. Ник, ни турында, нинди максат белән – үзе дә аңламады. Килмәс, баш тартыр дип уйлаган иде ул, әмма ни гаҗәп, Илзирә шундук очрашырга ризалык бирде.

Официант кофе китергән арада, алар шактый вакыт дәшми утырдылар.

– Инде диңгез буенда ял итәсездер дип уйлаган идем, – дип сүз башлады Илзирә, әңгәмәдән тизрәк котылыр өчен.

– Нинди диңгездә? – дип сорады Мәликә. Бу кылану түгел иде, ул чынлап та Рәмиснең диңгез буена барырга җыенуын хәтереннән чыгарган иде.

– Рәмис белән киткәнсездер дип уйлаган идем.

– Киттемени ул? – дип гаҗәпләнде Мәликә.

– Отпускысын диңгез буенда уздырырга җыенган иде.

– Отпускыда икәнен беләм... Диңгезгә киткәнен белмәгән идем.

– Әтиегезнең хәле ничек?

– Әйбәт. Кайтып китте ул.

– Нәрсә булды сезгә?

Нинди җавап бирим икән дип, Илзирәгә беравык карап торганнан соң, Мәликә:

– Аңлата алмыйм, – диде. – Бәхетле кеше сез. Сәер теләк туды – сезнең урында эшлисем килә.

– Һәркем үз урынында эшләргә тиеш. Сезнең ниндидер йомышыгыз бармы миңа?

– Сезне күрәсем килде.

– Тыңлыйм.

– Әтиемне караган өчен мин сезгә бик рәхмәтле. – Аның күз карашы кинәт усалланды. – Шул ук вакытта мин сезне күралмыйм, – дип өстәде ул көтмәгәндә.

– Аңлыйм, – диде Илзирә, бер дә исе китмичә.

– Нәрсә аңлыйсыз?

– Нәфрәтегезнең сәбәбен. Сез болай да миннән көнләштегез, хәзер инде, Рәмисне югалткач, көнләшүегез көчәйде. Кара көнчелек кабынды сездә, бик куркыныч, әллә нинди фаҗигаләргә китерә торган көнләшү. Көнләшүнең чем-кара төскә буялганы була – мәхәббәттә дә, башкаларның уңышына, бәхетенә карата да.

Мәликә ямьсез итеп көлемсерәде:

– Гиппократ антын биргән кешеләр дә бик рәхимсез була ала икән.

– Сезнең ситуациянең дә, безнең әңгәмәбезнең дә медицинага катнашы юк. Минем вакытым тар. Мөһимрәк сорауларыгыз булмаса, китим инде мин.

– Туктагыз әле... – Мәликә әңгәмәнең рәте булмаячагын сизенеп, тагын да зуррак нәфрәт кичерде. – Каты бәгырьле кеше сез...

Илзирә, аның халәтен дөрес аңлап, каршы сүз әйтеп бәхәсләшүнең кирәксезлеген тоеп, тыныч кына үз фикерен әйтте:

– Гиппократ дигәннән... Аның мондый сүзе бар: кешенең күңеле, җаны актык сулышына кадәр үсәргә һәм камилләшергә мөмкин. Олыгайган саен

тән таушала. Ә кешенең җаны яши-яши савыгырга, хәтта яшәрергә мөмкин – рухы дөрес юнәлеш алса.

Мәликәнең соңгы вакытта кәефе капма-каршылыклы төстә үзгәрә торганга әйләнде. Хәзер дә ул кинәт йомшарып китте, әле генә кабынып алган нәфрәт каядыр юкка чыкты.

– Сез миңа башта шундый инсафлы, якты күңелле булып күренгән идегез, – диде ул, сыктанып.

– Мин сезгә нинди начарлык эшләдем, сезнең алда нинди гаебем бар? – диде Илзирә, аптырап.

– Ә минем нинди гаебем бар? – диде Мәликә, чак кына еламыйча.

– Сезнең дә бер гаебегез юк. Шулай булгач, мине күралмавыгызның сәбәбе нәрсәдә?

Мәликә башын салындырды:

– Чынлап та... әллә нишләдем мин, – диде ул. – Гафу итегез!

Һәм көтмәгәндә, кискен хәрәкәтләр белән урыныннан торды да, тиз-тиз атлап, кафедан чыгып китте.

Илзирә динамиклардан талгын гына саркыган моңлы музыканы ахырына кадәр тыңлады да урыныннан кузгалды. Өстәлдә бер йотым да эчелмәгән ике чокыр кофе калды.

**13**

Эш вакыты тәмамлангач, Илзирә ак халатны үзенең чәчәкле күлмәгенә алыштырып, ашыкмыйча гына диспансердан чыкты. Июньнең бер көне кичкә авышып, озакламый мәңгелекнең үткән бер мизгеленә әверелергә тора. Рәхәт тә, ямансу да. Автобус тукталышына илтә торган сукмак чиксез озын булсын иде, шуның буенча атларга да атларга. Кәеф шундыйрак бүген. «Бу дөньяда һәрбер сызык, хәтта турысы да, кайчандыр бер түгәрәкләнә һәм әйләнеп, боҗра булып тоташа. Кеше йөргән сукмакларның, юлларның бер очы икенчесе белән ялганмый калмый. Шулай булмаса, кеше юллар салмас иде, таптап сукмаклар ясамас иде». Моны Рәмис еш кабатлый.

Якты сагыш, июнь җиле булып күңелне айкый, андагы хис-тойгыларның нәзберек тирәкләрен чайкалдыра.

– Илзирә!

Илзирә туктап борылды.

Төшме бу, өнме? Рәмис! Кулында зур чәчәк бәйләме. Өр-яңа кәчтүмнән, затлы галстук таккан.

– Исәнме, Илзирә!

Илзирәнең тыны капты. Бу күренешне аңлау һәм тиз генә кабул итү мөмкин түгел иде. Гаҗәпләнү хисен юдырып, бөтен җаны-тәне буенча шатлык дулкыны йөгереп узды.

– Исәнме! Син беркая да китмәдеңмени?

– Беркая да китмәдем. Бүген – синең туган көнеңдә, ничек мин чит тарафларда була алыйм, Илзирә?!

Илзирәнең күңеле тулды, елыйсы да, көләсе дә, Рәмисне кочып үбәсе дә, хәтта томырылып йөгерәсе дә килде аның.

– Онытмаган, – диде ул чак кына ишетелерлек итеп.

Рәмис чәчәк бәйләмен биреп:

– Туган көнең белән котлыйм сине! – диде. – Ә хәзер, әйдә, тизрәк, машинамны юл кырыенда гына калдырган идем, туктарга ярамый дигән билге тора анда.

Машинага кереп утыргач, Рәмис кечкенә тартмадан беләзек алып, кызның каушаудан калтыраган кулына кидереп куйды:

– Туган көнеңә бүләк.

– Алтын бит бу! – диде Илзирә, сокланып һәм читенсенеп.

– Алтында түгел хикмәт. Син ярата торган төстә ул – кояш төсендә. Туган көнең белән! Гел шушындый чибәр, якты күңелле бул. Сәламәтлек телим сиңа.

– Рәхмәт, Рәмис. – Ул әйтергә микән, әйтмәскә микән дип уйлап торганнан соң: – Мәликә килгән иде, – диде.

– Шулаймы... – диде Рәмис басынкы тавыш белән.

– Әтисе чынлап та шул кеше булып чыктымы?

– Юк, ул түгел! – диде Рәмис, катгый итеп.

– Шул, шул. Мин моны аңладым инде.

– Язмышны алдан күрү мөмкин түгел. Менә Ходай сине эшкә безнең диспансерга китерде – без бергә булсын өчен. Мәликәнең әтисен монда алып килде – дөресе ачыклансын өчен...

Илзирәнең хисләрен аңлатырлык түгел. Аларны аңлау хәтта үзенең хәленнән дә килми. Балачак, яшьлек дусты Рәмис үз эшендә инде югары үрләрне яулаган кеше. Соңгы вакытта «Мин Рәмискә лаеклы түгел» дигән имәнгеч уй-фикер үзәктә инде ныклы тамыр җәйгән иде.

Ә Рәмиснең фикере бөтенләй башка бүген. Илзирәнең киләчәктә нинди урында кем булып эшләячәге дә бернинди роль уйнамый аның өчен. Илзирә аңа бик кадерле һәм бик кирәк кеше! Аның моңарчы нинди романнары булган, кем белән гаилә корырга маташкан – Рәмисне болары да кызыксындырмый һәм бернинди мәгънәгә ия түгел.

Аңа хәзер (хәзер һәм алга таба да) нәкъ менә Илзирә кебек җылы, матур күңелле иптәш кирәк!

Утызга җиткәндә, бигрәк тә кирәк була башлый икән андый кеше.

– Хәзер туп-туры безгә кайтабыз, – диде ул, машинаны кабызгач.

Илзирәнең йөрәге дерт итеп куйды:

– Ничек инде?

– Менә шулай. Анда әни мәш килеп өстәл әзерли. Туган көнеңне бездә үткәрәбез.

– Әй, Рәмис, юк, алай булмый, – диде Илзирә, пошаманга калып.

– Нәрсә алай булмый? – дип көлеп куйды Рәмис.

– Яхшы түгел.

– Әни әзерләнеп көтеп тора, ә син барырга теләмисең – менә бу чынлап та яхшы түгел. Әни өйдә үзе генә. Мәҗит Нәҗипович малаен Уфага илтә китте. Навил укый да алмады, Казанда үзенә урын да тапмады. Бүген бәйрәм – синең туган көнең! Минем өчен бүген икеләтә бәйрәм – тагын әтине төштә күрдем. Икенче тапкыр. Күлгә кармак салып, тын гына утырдык. Мин зур балык тоттым. Ул елмаеп аркамнан сөйде.

Машина җәйге Казан буйлап китте.

**14**

Рәмис боларны миңа ник сөйләде икән?

Бу сорауга төгәл җавабым юк. Һәрхәлдә, бу турыда әсәр язсын дип түгелдер инде. Кем беләндер иркенләп уртаклашасы, бушанасы килгәндер.

Акыллы кеше артык икеләнүчән һәм уфтанучан да була бит ул. Бәлки, Мәликәне күңеленнән алып ташлау хәленнән килмидер. Бәлки, теге мөртәт

Навил аркасында кем улы икәнен сер итеп саклап кала алмаганга эче пошканнандыр. Бәлки, Мәликәнең әтисен яман чирдән коткарган сөенечтәндер... Ә ул моңа, иманым камил, ихластан сөенәдер һәм горурланадыр. Чөнки ул – олы җанлы, акыллы, үз җиреннән игелекле сутлар алып, аягында нык басып торучы ЧЫН ХИРУРГ һәм ни өчен яшәгәнен аңлаучы, яшәвенең мәгънәсен тапкан ЧЫН КЕШЕ!

Кешегә, әгәр дә ул сәламәт булып туган икән, байлык инде өеп бирелгән дигән сүз. Аның капчык-капчык алтын төялгән гомер арбасы бар. Әмма ул күз тондырып, атын куалый – киләчәкнең офыгында ялтыраган утларга, ерактан ишетелгән матур авазларга алданып, шул тарафларга омтыла. Бәхет, рәхәт тормыш, байлык шундадыр дип уйлый ул. Хәтта яшәү мәгънәсе дә шунда табылыр сыман тоела. Шулай күз тондырып чапканда, арбасыннан алтын тулы капчыкларның төшеп, коелып калганын да сизми. Алда ялтыраган утлар исә һаман да шул ук ераклыкта кала бирә. Бара-бара, гомер юлының як-ягындагы күз явын алырдай шау чәчәкле якты болынны күреп хозурлана алмый кала. Күккә омтылып сайраган кошлар җырын ишетүдән мәхрүм була. Иңнәреннән кочып иркәләгән җылы җилнең назын тоймый. Еллар узгач, олы юл үткәч кенә, офыкка барыбер барып җитә алмаячагына төшенә башлый кеше. Яшәү бәхете гомер арбасына утырып әбелхәят кочагында аллы-гөлле болын аша барган чакта булган икән бит дигән ачышны да бик соң ясый кеше. Болын да артта кала, арба да буш... Кире кайту да мөмкин түгел.

Моны яшьтән үк аңлаучы зирәк акыллы кешеләр була.

Күрше подъездда шундый бер танышым (дустым дисәм дә ярыйдыр) яши хәзер.

Якшәмбе көнне кичкырын мин, гадәттәгечә, саф һава суларга чыккан идем. Йортның ишегалдына таныш машина кереп туктады. Рәмис машинасыннан чыгуга ук мине сәламләде һәм, уң як ишекне ачып, хатынына чыгарга ярдәм итте.

– Минем хатыным Илзирә шушы инде, – диде Рәмис шат тавыш белән.

Илзирә матур итеп елмайды:

– Исәнмесез.

– Авыл һавасы ничек? – дигән булдым мин, авыл һавасының әйбәт икәнен белсәм дә.

Илзирәнең җавабы үзенең елмаюы кебек үк ягымлы булып чыкты:

– Авылда рәхәт, әмма Рәмис янәшә булганда гына сулавы иркен.

Алар җитәкләшеп подъездга кереп киттеләр. Ә миңа шушы кыска гына очрашу һәм әйтелгән берничә сүз күңелгә рәхәтлек бирде.

Кайвакыт бәхетле кешеләрне очрату үзеңне дә күпмедер вакытка бәхетле итә.

Мин күтәренке кәефтә, илһамланып, өемә кердем дә шушы повестьны язарга утырдым.

*2019 ел,*
*Казан – Хельсинки – Казан.*



Флёра
Гыйззәтуллина

# ГАСЫРЛАРГА ЕЛЛАР ҮРЕЛГӘН...

## И милләтем

Җил сафлыгын кемнәр илдә кире каксын,
Яшәүләрдән уйсу-уйсу җил искәндә?!
И милләтем, күз алдымда син торасың,
Уйларымның сафлыгына ирешкәндә.

Исеп туймас җилләр булсам, милләтемә
Бәхет юллап, мин дөньялар гизәр идем,
Ана телем гөлләр белән бизәр идем,
Һәр сүземне сәйлән итеп тезәр идем.

Әйтер идем: шушы пакьлек, шушы сүз, дип,
Бәлзәм булып, илнең йөрәгенә ятсын.
Бу сафлыкка кем мылтыктан төбәп атсын,
Ак йөзенә кара яксын, яла яксын?

Яшәүләрдән уйсу-уйсу җил искәндә,
Мин тынгысыз уйларыма дәвам алдым.
Әйтер сүзем әйталмадым, шуңамы соң
Адым саен кабаландым, яраландым?..

***

Туган телем!..
Шундый моңлы бит син –
Җир шарын бит җырлап әйләнәсең.
Бөдрә таллар бөреләнгән чакта
Талга ефәк булып бәйләнәсең.

---

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА (1931) – *шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова, Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Йөрәгемдә шаулый карурман», «Күз нурларым», «Башкаемда дөнья исәпләре» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Туган җирем!
Шундый шәфкатьле син –
Бөтен гөнаһымны кичергәнсең.
Миллиард еллар аккан таң суына
Татлы ширбәт кушып эчергәнсең.

Туган көнем!
Шундый якты бит син –
Сихри алкышларга күмелгәнсең.
Саф күңелле халкым йөрәгенә
Үрмә гөлләр булып үрелгәнсең.

Сөйгән ярым!
Күккә чөйгән ярым!
Син дә мине кичерерсең әле...
Ак күлмәкле айлы кичләреңне
Исләреңә төшерерсең әле...

## Күкеле паровозлар*

Сезнең дә арка-күкрәктә
Төзәлмәс ярагыз бар –
Яшьлектә авыр йөк тарткан
Күкеле паровозлар!

Сезне дә безнең яшьлекнең
Дәрманы чорнап алган:
Ургыттың утлы гудоклар
Ялкынлы торбалардан.

«Уф-уф!» дип авыр сулауның
Бездә дә дәвамы бар, –
Кешегә сансызлар безне
Күкегә санадылар.

Әнә шул «күке»леккә дә
Төшермәс өчен таплар,
Булды бит, булды, кәккүктәй,
Үксеп кычкырган чаклар.

...Юк, үзем өчен оялып,
Башымны имәм түбән.
Эшелоннарга йөк төяп,
Күкләргә тиде түбәм.

Йөк тарткан саен озайды
Шалуннар** озынлыгы.
Озайды сансыз телендә
Күпсенү бозгынлыгы.

– Булмый ул, булмый! – димәгез, –
Тел белән этлек корып...
Күп вакыт күке – ялгызы,
Этлекнең эте – кырык!

Кырыгы бердәм тотынса,
Һау-һаулап чабышуга,
Ишетелми башлый колакка
Гудоклар тавышы да.

Ялкыны сүнгән торбадан
Бары тик корым сара.
Ник сызлый корым астында
Ачылмый калган яра?!

Кәккүккә хезмәт халкыннан
Булса да хөрмәт олы,
Сыйдырмый башлый, йончыгач,
Локомативлар юлы.

Шул үзем төзегән юлдан
Йөртсәләр мине җайга.
Китерер идем тормышка
Тагын никадәр файда!

Үземне талатмас өчен
Ач язмыш этләренә,
Ярамны тотып капланам
Төялгән йөкләремә.

* Күкеле паровозлар – тимер юл эшчеләрен эшкә йөрткән иске, кечкенә паровозлар.

** Шалун – эшелон.

Хәтер гудогым янәдән
Очкынын чәчкән мәлдә:
– Кәк-күк! – дип җавап бирермен,
«Күке!» дип дәшкәннәргә.

Хезмәт күкесен җанымда
Өйрәтеп кышлатырга,
Тереләм әле...
Торам мин
Йөгемне бушатырга!..

## Тарих сөйли

**1**

Шигъри болын! –
Тормыш толым-толым:
Гасырларга еллар үрелгән.
Таң атканда, һәркөн кояш чыккан,
Гөлләр шыткан хәтер көленнән.

Хәтер калса, әмма бик еш кына
Телгә килгән ут та, кылыч та.
Кылычлылар утны һич бервакыт
Алып тормый чордан бурычка.

Тарих сөйли хагын: мәкер колы
Кабат илдә кылыч җилгәрә –
Ап-ак кашкарыйлар арасында
Кара канәферләр тибрәлә.

Кара канәфер ул – кайгы гөле! –
Яуда ауганнардан истәлек.
Шигърияткә мондый истәлекләр
Минут саен тора өстәлеп.

**2**

Шигъри болын! –
Алда соңгы юлым:
Каргап карамагыз күземә...
Чәчәкләрнең агын сезгә бирәм,
Караларын алам үземә.

Утларын да баш очыма чөям,
Илгә капкан туксан тәмугның.
Юк, аксөяк түгел, шигърияткә
Эшче халыктан мин калыктым.

Ут биетер өчен түшәдек без
Тәмугка да имән идәннәр.
Ут хәтерен күрә белмәгәннәр
Шүрәледәй кара көйгәннәр.

Көек исе, шөкатьсезлек төсе
Били җанның үрен, гүрен дә.
Милли талир тәңкә чыңлар чакта
Бүре улый күкрәк түремдә.

Ирегенә киек чыгар иде
Чыгар юлын нәфрәт буаган.
Ничә еллар инде шушы хәлдә
Йокылардан тетрәп уянам.

**3**

Шигъри болын.
– Китәм, хушыгыз! – дип,
Сузам сезгә ике кулымны.
Үр өстенә яңа үрләр үсә,
Карурманнар кисә юлымны.

Карурманга кереп, аваз салам:
– Качып ята монда кайсыгы-ы-з?
Шигъри ялкын сулап җылынсыннар –
Учак ягыйк, утын ташыгыз!

Карурманда ауган агач азмы,
Яраксызлык гаме янаган?!
Болыны да, карурманнары да
Ядкяр безгә ата-бабадан!

## Егет күлгә кармак төшерә

Балык тота халык боз өстендә...
Март кояшы балкый боз ашап.
Балкысаң да, үксеп еласаң да,
Узачак ул гомер, узачак.

Ястык кебек калын бозны тишеп,
Егет күлгә кармак төшерә.
Март аенда туган ир-егетнең
Алтын балык керә төшенә.

Күл өстендә бозлар тиз эреми:
Дулкын бозны төпкә кагачак.
Күлләреңне күккә күчерсәң дә,
Яначак ул йөрәк, яначак.

Балык тотып, егет илһам ала,
Мин дә шул ук күлдән су алам.
...Газиз халкым!
Бигрәк назлы инде
Март аенда туган бу балаң!

Балык тота халык...
Бу халыкны
Еллар әле уйга салачак.
Алтыннарга тиңләп яратсаң да,
Калачак бу дөнья, калачак...

## Еланнар оясында

*(Баллада)*

Сөмбелә – иҗат йолдызы,
Сөмбелә – хәтер, ваем.
Ул минем үгет үзәнем,
Ул минем туган аем.

Алтын йолдызлы алтын көз
Аемнан даулый корбан.
Алтынга ялкын уя да
Яфрагын коя урман.

Карурман томалый илнең
Аен да, кояшын да.
– Ирек! – дип каңгыра халкым
Еланнар арасында.

Бу оя – тарихи оя! –
Коллыкка яра юлын?
Илемне чаккан еланнар
Иңемдә толым-толым.

Мыж килә тирә-ягымда
Аклары-каралары.
Ничәсе инде, ничәсе
Куенымда балалады...

Килсәләр, хәлем белсәләр,
Дусларым, танышларым –
Бер генә тыңлатыр идем
Ысылдау тавышларын.

Һәм көйләр идем догамда
Ирекнең гомерлеген, –
Чагылып елаучыларның
Хәтерсез түгеллеген...

## Йөрәгемдә – туксан тәмуг учагы

Ачыласы күк капусын балкытып,
Барлык сынау сиратларын калкытып,
Якынлашып килә Кадер кичәсе.
Каударланып дөнья малын җыйганда,
Алладан да үзен өстен куйганда,
Меңнәр дөрләп янган тәмуг утына
Берәүнең дә килми сикереп төшәсе.

Иблис белән байлык бүлешкәне дә,
Кәүсәр чишмәсеннән нур эчкәне дә,
Сөю-сәгадәткә ирешкәне дә
Җиде җәннәт тирәсендә капшана.
Муенына элеп дарлы күләгә,
Җәһәннәмгә әмма килеп эләгә.
Тормыш җиле кай яклардан какса да.

Мәхәббәткә чәчеп сөю чәчәген,
Туксан еллык гомер мин дә яшәдем.
Йөрәгемдә – туксан тәмуг учагы,
Мәхәббәтнең һәлакәткә дучары.
Ил иңендә иңридер моң чары,
Күз яшемдә мөлдеридер Җир шары...



Зиннур
Хөснияр

# КАНАТСЫЗ ФӘРЕШТӘЛӘР

ХИКӘЯ

Аны шәһәр читендә ташлап калдырдылар бугай. Чүплек исе, ачы төтен исе килә. Төтен булуы аны сөендерде: димәк ул, каядыр җәһәннәм астында түгел, теләгәндә, кайтыр юлны табарга мөмкин булыр.

Кабыргалары шыгыр-шыгыр килә. Ләкин курку, караңгы төн авыртусызлануны басып тора әлегә. Менә этләр өргәне ишетелде. Авыл этләре кебек кенә түгел болар, шыңшыйлар, бер-берсе белән тешләшеп чинашалар.

Әүвәл җил сыбызгысын хәтерләткән өзек-өзек тавышлар ишетелгәндәй булды. Менә берзаман әлеге аһәң нindидер көйгә салынды кебек: бу килешендә ошбу өннәр алай ук өркетми, шомландырмый; ул тоеп алган көй, киресенчә, аңа дәрман өсти, котыласына өмет бирә; әлеге шомлы, куркыныч мохиттә капылт туган көй янәшәдәге урман тавышын аның тарафына алып килә; урман шавы белән бергә кушылып, шактый түбән ноталардагы күңел көен куаклыктагы сандугач оясы биеклегенә күтәрә дә шуннан соң әле һаман тыпырчынган җанын өмет хисе биләп ала; ул бер дә тукталып тормый, урмандагы төнге кошлар тавышы җаена агач ботакларын тирбәтә, яфракларны шыбырдата, әлеге тирбәнешнең дулкыны тиздән аның хыялында туачак көйнең тәүге ноталарын ишеттерә.

Ул оркестрдагы контрабас тавышын аермачык ишеткән кебек булды.

Төтен исе бик ачы, күзләрне кисә. Димәк, чүп өеме өстендә ята. Бәлки, янындадыр? Хуҗасыз этләр тавышы куркуын арттырып, авыртуны бөтенләй басты.

Ул чүплектән читкәрәк тәгәрәде. Якында урман кебек агачлык шәйләнә. Күзләре караңгыга ияләшә башлагач кына күрде ул аны. Шул рәвешле үрмәлитәгәри агачларга якынлашырга тырышты. Менә куш каенны узып китте. Бер нарат төбенә килеп җиткәч, туктап калды.

Нарат янында ул беркавымга тынычланды, күзләре караңгыга ияләшә башлады, күтәрелеп, төнге аяз күккә карады. Йолдызлар аңа таба чекрәйгән, тын гына күзәтәләр. Аяз булса да, җиле бар, нарат ботаклары төрле тавышка шыгыр-шыгыр килә. Төнге урман оркестрының яңгырашы күңелендә туачак яңа көй белән бергә кушыла. Бу гамәл-фигыль аны бөтенләй тынычландырды. Тагын кесәләрен

Зиннур ХӨСНИЯР (1961) – *прозаик, шагыйрь, драматург; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил исемендәге республика, Фатих Хөсни премияләре лауреаты. «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар», «Терсәк сугышы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

капшады. Берсеннән хатынының лифчигын тартып чыгарды, борынына төртеп алды да кесәсенә кире тыкты. Бу юлы трусигын салып җибәрмәгәннәр икән...

Нарат кәүсәсе коп-коры. Ул аны башта учы белән капшап карады, аннары сыпырды. Тавыш чыкты. Тагын да катырак ышкыды, тавыш көчәйде. Юан нарат скрипка таягы булмаса да, әлеге тавыш аны тынычландырды гына түгел, күңелен кымырҗытты, хәлен җиңеләйтте. Ул йолдызларга төбәлде һәм үзенең языла башлаган көенә төнге күктән тагын яңа ноталар эзләде. Көй эзләде. Ул көйнең шактый өлеше язылып, хәтер киштәсендә урын алган иде инде. Күңеле хәтерендә алар. Тик әлегә башы да, ахыры да юк. Ничек тәмамланасы да билгесез. Кыл уртадан башланды шикелле әлеге көй.

Теге йолдызлар, шыбырдашып, урман өстенә яварга кереште. Алан яктырып китте. Төнге ут бөҗәкләре яктысы икәнлеген белсә дә, ул аның өчен җиргә төшкән йолдызлар иде. Бары аның гына колагы тоя алырлык аһәң ишетелде, шуның аркасында караңгы төн тагын да җылына төште.

Бу тәравих укый торган вакыт булырга тиеш. Аңа кадәр ястү. Һәр намаз алдыннан фарыз укыла. Ошбу намаз вакытында һава чак кына җылынып алгандай була. Мәрхүмә әнисе шулай ди торган иде. Әнисе үзе исән чагында малаен намазга утыртырга бик теләсә дә, Бәхти карышты, «соңыннан!» дип аклана килде. Тик хәтерли, әнисе намаз укыган чакта (андый вакытта намаз укыган кешенең алдына, каршысына чыгарга ярамый, мөгаен, ул читтәрәк, ян ягында булгандыр) өй эче дә яктырып, әнисе ягыннан ниндидер дулкын-дулкын җылылык сирпелә кебек иде. Ул чакта аның әлеге дулкын тирбәнешен көйгә саласы бик килсә дә, өлгерми калды, әнисе вафатыннан соң, өйдә намазлар укылмый башлагач, көй дә, теге җылылык та суынып, яктылыгы да сүрелде. Бәхти күптән түгел «Гарасат» дигән бер романнан Мөхәммәд пәйгамбәр турында гыйбрәтле фикер укыган иде. Ул шул урынга килеп төртелгәч, аптырап калды: яшь чакта әнисе сөйләгән бер риваять бит бу?! Укый башлауга исенә төште: Мөхәммәд пәйгамбәрнең дус шагыйре булган һәм пәйгамбәр шуңа һәрчак: «Син, кичәге, бүгенге турында язасың. Без ни булганын үзебез дә беләбез. Син язучы бит, яз әле иртәгесе көн хакында, киләчәк турында!» – ди икән. Тегесе аңа каршы: «Ә мин аны кайдан белим?!» – дип сорый. Мөхәммәд пәйгамбәр иреннәрен кыймылдатып, акрын гына: «Сиңа аны Җәбраил фәрештә әйтеп торыр, – дигән. – Тавышын ишетмәсәң дә, дулкын-дулкын булып килгән җылысын тоярсың!» – дигән.

Электән калган гадәте буенча намаз вакытларын хәзер дә гел карап бара, яхшы белә иде.

Хатыны Зәмирә дә тәрәзәдән йолдызларны күзәтә торгандыр. Тик ул аларның җиргә коелганын күрә алмый. Шул... берән-сәрән атылганнары чалынса гына инде күзенә. Ул йолдыз яңгырын күрмәгән яшь, матур хатынны кызганып, җәлләп тә куйды. Тәрәзәне ачмасын инде, өйдә бригадир булгач, киенмәгәндер дә, күкрәкләре ялангачтыр... Салкын тияр. Трусигы да юктыр. Бәлки, бригадир күптән китеп баргандыр? Хәзер хатыны аның кайтканын көтеп утыра торгандыр?..

Аландагы җиләк исе килеп торган үләннәр арасыннан көй ургыла да ургыла. Әлеге көйдә ялгыз хатынның моңсу рәвештә тәрәзәдән йолдызларны күзәтүе дә, ирен сагыну хиссияте дә бар. Ул хиссияттә хатынның ике битендәге уймакланып торган чокырлары, көлгәндә, шул чокырларның тирәнәеп алулары да чагыла. Аның күзләре генә түгел, бар йөзе көлә, бу көлү һәр ир-атны аяктан егып, гашыйк итәрлек. Күрәсең, бригадир да ярата аның көлүен. Болар үзләре үк көйнең яңа өлешен яза: әнә ул хатыны күзендәге дымны үз җиле белән

киптерә; тик белеп булмый: бригадир белән булган мизгелләр турында сөйлисе киләме аның, әллә инде ул үзенең аянычлы хәленнән күңел яше белән тын гына елыймы соң? Хатынының көен урык-сурык кына тоя, аны һаман бер тәртипкә сала алганы юк. Моның шулай икәнен белү урман караңгылыгына караганда да шомлырак, куркынычрак иде.

Көй хатирәләрне бер тәртипкә сала. Бригадир элегрәк тә шәһәрчеккә кайтып килгән булган. Айгизәне эзләп тапкан ул, хәтта күрешкәннәр дә. Бу хакта Бәхтигә Айгизә үзе түгел, мәдәният йортында ул укыткан пианино дәресләренә йөргән Зәмирә чиште. Үзе күз атып йөргән Бәхти белән Айгизәнең мөнәсәбәтләреннән көнләшә иде ул. Тик кызның буйдак музыка укытучысына «күз атуы»ның сәбәбе генә аңлашылып җитми иде әлегә. Зәмирәнең Бәхтидән үзенә багышлап җыр яздырасы килә, йә яңа берәр көен үз исеме белән аталуын тели. Кыз һәркайда күз өстендәге каш кебек булырга омтыла, башкалар янында ялтырап күренергә тели. Пианино дәресләренә йөрүе дә музыкага гашыйк булуыннан түгел, хәтта Бәхтигә карата гыйшык та сәбәп түгел моңа; бары тик игътибар үзәгендә гел ул гына булырга тиеш! Нишләтәсең, холкы шундый, җирдә яшәргә түгел, күкләрдә очарга яратылган җан бугай ул. Бәхти аңа ошаса да, ул аңа кияүгә чыгу турында хыялланмый, чөнки егетнең иске пианиносыннан башка берние дә юк икәнлеген күреп тора. Зәмирә кебек чибәрләр бай ирнең йә сөяркәсе, бәхет елмайса, иркә хатыны булырга хыяллана...

Дусты Айгизә сер итеп кенә аңа каладан кайткан түрәнең, бригадир үзе була инде ул, сүз кушуы турында сөйләгәч, көнләшепләр үлә язды. Ни кылганын да аңлап җитмичә, Бәхтигә «яшерен серне» әләкләргә чапты.

Бертуктаусыз колак төбендә яңгыраган көй кинәт атылган йолдыз кебек бистә ягына очты, бригадирның ачык форточкасыннан аның өенә барып керде, анда Айгизәнең маңгай чәчләренә кагылып үтте, кыеклап бәйләгән алсу косынкасы чугы белән уйнап алды һәм яшьле күзләреннән үпте.

Алардан киткәч, төнката үз өенә кайтып кергән бригадирны хатыны Айгизә каршы алгандыр. Әй, юк ла, Айгизә бригадирдан качкан дип сөйлиләр бит. Кайларда каңгырап йөри икән соң ул? Табасы, күрәсе иде элеккеге күрше кызын... Җаныннан саркыган көй капылт борылышлар ясады, күңел оркестрында барабан дөбердәп алды, флейта салкын тавышын ишеттерде. Аннары ул җан оркестрындагы скрипканы эшкә җикте. Скрипка, гадәттә, җырчы тавышына охшаган була.

Көй дәвам итте. Ул хәзер Айгизә турында иде. Бригадир шәһәрчеккә бөтенләй күченеп кайткач, беренче эше итеп Айгизәгә өйләнде. Моңа бар да шаккатты, Бәхти исә бөтенләй акылдан язгандай йөрде. Югыйсә теге чакта аңлашканнар иде бит инде, ул гына да түгел, алар тиздән өйләнешергә сүз куешканнар иде бит кана! Халык өчен тәмләп сөйләрлек гайбәт булса, Бәхтигә бу табышмак, нык төенләнгән бер сер иде. Ул бик хисле егет, кайчак ул хисләре аңын да томалап китә, ниндидер дәһшәтле көчкә әверелеп, җанын актарып ташлый; мондый очракта дошманыңнан йә үч аласы килә, яисә инде соңгы чиктә бауга менәсеме соң?! Бик озак исерек кебек йөрде ул. Бу хәл тагын бер кешегә, ул да булса, Зәмирәгә бик каты тәэсир иткән иде. Көнчелек уты кызны көйдереп бетерә язды шул чакта: тиктомалдан гына Айгизә нинди бәхеткә юлыкты! Бригадир кадәр бригадирның хатыны булды. Бригадир исә аны алдады! Бәхти янында чуалып, Айгизәне аннан биздерсәң, мин сиңа өйләнәм, дип вәгъдә иткән иде ләбаса! Шул чакта:

– Монда Айгизәнең ни катнашы бар? – дип, аптырап сораганын да ачык хәтерли.

– Айгизә – Бәхтинең илһамчысы! Күрәсеңме, ул нинди шәп көйләр яза. Барысы да шул Айгизә аркасында. Ә монда бары мин генә беренче булырга тиеш! Халык монда бары мине генә Алла итеп күрергә тиеш! Бар игътибар миндә, бар сүзләр бары минем хакта гына булырга тиеш!

Бригадирның җавабы кызны ышандырды. Чөнки аның: «Кара аны, син дә ул Бәхти янында бик чуалма. Көнләшеп куюым бар!» – диюе баягы сүзләренә ныклы дәлил кебек иде.

Шушы урында көй туктап торды. Бәхти аны онытмаячак, хәтер киштәсеннән җуймаячак. Оркестрның тулы яңгырашына (tutti) әле ерак. Ләкин күңелдә партитура сурәте бар инде. Ул әлегә фабула рәвешендә генә.

Аның үтереп эчәсе килә башлады. Чү! Нигә нәкъ менә бу нарат төбенә килде соң әле ул? Югыйсә аланның алдына ук чыгып торган куш каен янында туктый ала иде. Аны узып, наратка таба ук шуышты. Аның сизгер колагы төнге күбәләкнең әрекмән яфрагы өстендәге чык тамчыларыннан җыелган суда коенганын ишеткәч, ары үрмәләде бугай. Әрекмәнле урынны эзләп тапты. Тик монда дым гына. Ул теле белән әрекмәнне ялады. Монысын белмәгән булган икән: бераз арырак кырмыска оясы да бар. Учын кырмыска оясына терәде һәм кире тартып алып, кырмыскаларын сыпырып төшергәннән соң, аны иреннәренә китерде. Ачы тәм авызын киптерде генә, аның каравы, башы ачылып, зиһене аязды. Скрипка тавышы яхшырак ишетелә башлады – бу бригадир җыры иде. Тавышы гөбедән чыккандай булса да, моңы юк, көе юк икән бригадирның. Ул аны кызганып куйды. Көе булмаган килеш ничек яши икән соң бу адәм? Көйсез яшәп булмый лабаса! Бик кыен көең булмаган килеш хәят итүләре… Бәлки, ул көе юклыктан бригадир булгандыр да. Рәсми рәвештә «директор» дип аталса да, халык аны «бригадир» дип йөртергә гадәтләнгән. Үги атасы җәбрәй Сәми дә әүвәл бригадир булып торды. Туксанынчы еллар башында килде әлеге гаилә алар бистәсенә. Әллә сиксәндә үк микән? Бистә дигәне хәзер яңа шәһәрчек инде. Директор анда иң зур хуҗа.

Булачак бригадир яшьли ата-анасыз калып, монда – элеккеге бистәдә ятимнәр йортында тәрбияләнде. Ятимнәр йорты ябылгач, ул башкалар белән күченеп китмәде, урманга качып калды. Көзгә таба гына пәйда булды бистәдә. Аны башкаладагы ятимнәр йортына җибәрергә кызгандылар, дөресрәге, үзенең китәсе килмәде, елады, ялварды, үтенде, мине анда җибәрмәгез дип, күз яшьләрен түгә-түгә гозерләнде үсмер; тора-бара малай кемдә туры килсә, шунда яши башлады. Ләкин әйбер урлап халыкның үзәгенә үтте. Аны барыбер милициягә тотып бирүче булмады, кызгандылар, җәлләделәр. Бүреккә салып диярлек тәрбия кылырга тырыштылар. Буй җиткергәч, көннәрнең берендә эскерттәге энә кебек югалды ул. Шактый гомерләрдән соң, хәзер инде шәһәрчеккә әйләнгән бистәгә янә әйләнеп кайтты. Үзе генә түгел иде, башкаладан яхшы машинага утырып килде. Шома йөзле ташкала кешесе аны монда хуҗа-түрә итеп билгеләде.

Аннан соң ул үзенә аерым йорт, дөресрәге, өч катлы коттедж булдырды, Айгизәгә өйләнде, тик әлегә балалары гына юк.

Бригадир эшкә ныклап кереште. Әүвәл бушап калган ятимнәр йортын үзенеке итте, хакым бар, бу минем өем, диде. Аның янәшәсендә эштән туктап калган кирпеч заводы, май заводы бар иде. Аларны да үзенә яздырды. Ваучер кәгазьләре бер уч иде. Бистә читендәге элеккеге совхоз да аның исеменә күчте. Тик бер төн эчендә мең башка якын башмак тана, шулкадәр үк сыер малы гына каядыр юкка чыкты. Бушап калган абзарларга чит илдән чучкалар алып

кайтып тутырдылар. Хөкүмәт ит планын үтәүне бурыч итеп куйган иде, бу эшкә алынган фермерларга миллионлаган субсидияләр бүленде. Бригадирга шуннан зур өлеш чыкты.

Хәзер шәһәрчеккә әйләнгән бистәдә аның нәселен дә, яшь чагын да белүчеләр калмаган диярлек иде, кем кая күченеп китеп бетте. Хәер, барыбер танымаслар иде. Үзгәргән ул. Әллә парик та киеп куйган инде? Калын кара кысалы күзлеге дә аны башка кеше итә.

Бәхти таныды. «Фәрештә» дигән кушаматы да исенә төште. Анысы консерватория тәмамлагач, туган бистәсенә кайтып эшли башлагач иде. Бригадирның яшь чагын белү генә түгел, алар бер өйдә диярлек үстеләр: аның әти-әнисе ятимне кызганып, еш кына үзләренә ала иде.

Кырмыска кислотасы, чынлап та, зиһенен ачты, исенә төшерде: бригадирның атасы бистәдә атаклы көмешкә куучы иде бит. Үзенекен итте ул чакта Сәми: әүвәл «Горбач» указы чагында «шинкар» даны алып, итәк астыннан шәраб сатты. Аракы-шәраб ише эчемлекләр кибетләрдә күренә башлагач та, аптырап калмады, яңа эшкуарлык җәелдереп җибәрде: көмешкә кайната башлады. Алар шул чагында – көмешкә ясаганда, ут чыгып, янып үлделәр. Гаиләдән бер малай исән калды. Аның көе әлеге вакыйгадан башланган иде түгелме соң: янган йорт, ятим калган малайдан идеме?

Юк, башы ул түгел иде бу көйнең! Бу бары «оркестрдагы» скрипка тавышы гына. Башы әле һаман табылмаган.

Исенә килгән һәр хәл-вакыйгадан гына түгел, үзе белгән, аралашкан бар кешедән дә, хәтта нинди явыз бригадирның үзеннән дә бер бөртек кенә булса да, игелек-яхшылык, мәрхәмәт орлыгы табасы килә. Яза башлаган көйне табасы килә һәм аны симфоник оркестр өчен ноталарга салачак.

Замана шундый: тормыштагы һәртөрле кабахәтлектән гаҗиз булган күңел күзенең гүзәл манзара күрәсе килә. Җан да шуңа күрә гел матурлыкка омтыла. Гомер буе мәхәббәт, матурлык эзли кеше. Җирдә начарлык, явызлык күп булгангамы, кабалана-кабалана, тырыша-тырыша эзли аны адәми зат…

Аның күңел көе бригадирның кабахәт гамәлен акларга азаплана. Бүгенге явыз адәмнең түгел, моннан дистә ел элек аларның ишегеннән керә алмыйча салкын болдырда туңып, катып торган бәләкәй малайны исенә төшерә дә үзенең шул чактагы кыланышын акларга тырыша... Бригадир – ул чакта аны яшь язуындагыча «Абрам» дип тормыйча «Абрар» дип йөртәләр иде, кайчандыр монда читтән килеп йортка кергән атасының исеме дә «Самуил»дан Сәмигә әйләнгән – ялан тәпиенә калош эләктереп пес итәргә чыга да бозланып каткан ишекне ачарга көче җитми. Ул – хуҗа малае Бәхти – өйдәшенең туңып торганын белсә дә, ишекне юри барып ачмый, кертәсе килми. Кемгә, нигә керәге бар аның, катып үлсен шунда дип уйлый. Чөнки Абрарның ата-анасы аркасында ярты бистәнең йортлары янып, кара күмергә әйләнде. Ул гаиләне яратмыйлар. Ут чыгарганчы да аларның башкалар кебек мондагы заводларда эшләп азапланганы булмады, атасы башта бригадир исәбендә йөрде, аны ташлагач, сату итте, дигән идек. Аларны бары каргыйлар гына. Бәхти моны ишетеп белә. Ләкин бүген Абрардан аның өчен үч алуы түгел. Конфет өчен көралмавы, өйдә ике малай булгач, өлкәннәр игътибарны да, конфетны да икегә бүлә. Әтисенең кесәсенә ияреп кайткан суыра торган конфетның да берсе Абрарга эләгә. Элек конфетлар икәү, өчәү булса да, бары аңа гына тия иде. Үз бәхетен беркемнең дә башкалар белән, бигрәк тә читләр белән уртаклашасы килми. Көйнең ошбу өлеше әнә шул турыда.

Бригадир көенең башын эзләп тапты сыман ул, ниһаять! Бер дә көйсез адәм

түгелдер бит инде. Тагын эзләячәк әле... Һәркем бәхет эзли. Моның бер дә гаебе юк. Иң әһәмиятлесе: бәхетле булырга омтылган кешегә этлек кылырга, аяк чалырга берәүнең дә хакы юк! Андыйларга Аллаһның каргышы төшә, диләр. Без моны белмибез генә. Каргыш – бик авыр нәрсә... Дошманыңа да күрсәтмәсен андый бәлане, дип уйлый Бәхти, һәм аның чираттагы көй-нотасы нәкъ шул хакта. Тора-бара әлеге көй күкләр белән тоташа. Аллаһ ризалыгын ала ул анда...

Көй акылга буйсынмый, ул бары күңел ихтыярында.

Берәрсенә ияреп, җылы өйгә керү бәхетенә ирешкән малайның табан асты бозланып ката. Бәхти аны, ишек катындагы агач караваткa төртеп егып, шул бозга кайнар сулышын өрә, туңган урынга үзенең җылы кулларын куя, авыртудан шыңшыса, сиздермичә генә бөеренә төртә. Аягы җылынып бетә. Малайның күзләрендә яшь. Ул моңлы күзләрдә яшәү чаткысы. Тегесенең рәхмәт йөзеннән хуҗа малаен кочаклыйсы килә. Бәхти дә йомшара. Кесәсендәге соңгы конфетны алып, аңа суза, үзенең авыз суы корый. Аннары алар пыр тузып уйнарга керешә.

Көйнең бу өлеше җиңел язылды. Симфоник оркестр өчен барысы дүрт өлештән булыр дип уйлаган иде. Малай чак хатирәләре, мөгаен, виолончель белән башкарылыр. Аның тавышы тыгыз, куе. Һәм скрипка. Нечкә, якты, җылы хиссиятне скрипка яхшы бирә.

Кырмыска оясы янында җылырак, әлбәттә, ләкин хуҗалары кием астыннан кереп, гел бимазалап тора. Бер караганда, бу яхшы да, аңа хәзер йокларга ярамый. Көенә кискен борылыш кирәк.

Бер кат кырмыскаларны сыпырып төшергәч, көйнең икенче өлеше башланды. Салмак иде ул. Әнә, бригадир аның өендә, аның газиз хатыны янында. Бәхтинең хатыны бик чибәр, алай гына да түгел, дөньяда атаклы бер матур иде. Бәхти Айгизәгә үч итеп өйләнде аңа.

...Бригадир башка чакта бик кыю, әрсез һәм оятсыз иде дә, хәзер шул матурлык каршында ничектер юашланып калган. Яшь хатынга якынлашкан саен гәүдәсе калтырый.

– Син мине чәнчеп үтермәкче мәллә?! – ди ул калтыранган тавыш белән. – Теге чакта сине тыңламаган өчен үч алырга уйлыйсыңмы?! – Хатын бу сүздән үзе дә дерт итеп куя. – Хәзер, хәзер, чишенәм, – ди һәм халат төймәләрен ычкындыра башлый.

– Тукта! – дип кычкыра бригадир. – Тукта, дидем мин сиңа!

– Син монда шуның өчен килмәдеңмени? Минем Бетховенны шуның өчен өйдән типкәләп чыгармадыңмыни?!

Хатынның куркынган күзләре бригадирга төбәлгән.

– Син бик матур! Менә дигән мисс!

– Синең үз хатының да курчак кебек.

– Юк! Син матур!

– Синең хатының тагын да...

– Ул башка!

– Кысыр, димәкче буласыңмы? Үзең гаепле, диләр түгелме соң?!

– Молчать, дура! Ул көмәнле!

– Ха! Кемнән?! Синнәнме әллә?!

– Тагын кемнән булсын, тиле хатын?!

– Базыңдагы каймак чүлмәгенә ата мәче төшкән!

– Молчать, дура!

– Дурасы дурадыр да... Минем Бетховенны юкка гына типкәләп чыгармадың бит! Менә, үчеңне ала аласың аннан хәзер, бригадир!

Хатынның чишелгән төймәле изүләре ачылып, аннан шалкан кебек шәрә матур күкрәкләре тышка бәреп чыга. Бригадир тораташ булып каткан. Ул бер адым хатынга таба атлый... Скрипка ачыргаланып еларга керешә.

– Дөнья кабахәт. Ә син гүзәл. Монда кайтканнан бирле мине сиңа тарта. Айгизәгә дә. Сезнең икегезнең берегез дә Бәхтигә булырга тиеш түгел иде!

– Бетховеннан үч алуың инде, беләм...

– Сез мине икегез дә малай чактан ук санга сукмадыгыз. Ятимгә күрә.

– Без барыбыз да ятим, без барыбыз да – адашкан җаннар...

– Ә сез ник ятим әле?

– Күкләр бездән күптән йөз чөергәндер инде... Карале, бригадир... кем... Абрар, теге чакта син икебезгә дә берьюлы гашыйк булган идеңме әллә?!.

Бригадир дәшми. Тынлык. Әлеге тынлыкны оркестрдагы альт тавышы дәвам итә. Ул йомшак, иркә тавыш.

Күптән түгел шәһәрчектә гомуми җыелыш булды. Бригадир анда зур доклад белән чыгыш ясады. Без коммунизмдагы кебек яшәргә тиеш, диде. Мисаллар китерде. Хезмәт хакларының ун тапкыр арттырылачагын вәгъдә итте. Бер мәртәбә «коммунизмда яшәп алган» халык акрын гына, тын гына кул чапкандай итте.Үрле-кырлы сикерүче күренмәде.

Бригадирның яшь чагын хәтерләгән элеккеге бистә кешеләре аның бу сүзләренә бөтенләй ышанмады. Аракы сатып һәм көмешкә коеп, мал тупларга хыялланган нәселнең язмышы аянычлы тәмамланды ласа. Тормышлары көйләнә алмады. Урлап яки әшнәлек аркасында капылт баеп, бүген затлы чит ил машинасына кунакласаң да, ни хәл итмәк кирәк, йөргән юлларыңда бабаңнарның чабата эзе ярылып ята...

Теге чакта Абрар бистәдән калага китеп югалса да, чынлыкта исә, ул бер дә «югалып» калмады. Балачактан яклаучысы, сыеныр кешеләре булмау, малайда бары үз көчеңә генә таянырга кирәк дигән эчке инстинкт тәрбияләгән, моны кечкенәдән канына ук салган. Үсеп җиткәч, әнә шул кан күзәнәкләре акылына тынгылык бирмәде. «Үз көчең» дигән нәрсә аны әрсез итте, кыюлык өстәде. Дәүләт малын аерым төркемнәр, хосусыйлаштырабыз дигән булып, үз кесәләренә шудырып яткан чакта ул да нәкъ әлеге «базар»ның уртасында кайнап алды; кирәкле урында кирәкле чакта туры килде. Халык нишләтергә дә белмәгән ваучер кәгазьләрен күпләп кулга төшереп, алар берничә шома егет белән берләштеләр, араларында шактый гыйлемлеләре, акны карадан аера белгәннәре дә бар иде. Вахит Алиевич дигән бик шома кавказлы белән дуслашты, шуның белән дә шактый эшләрне әйләндереп куйдылар: харам малны күпләп кулга төшерергә җай чыккан иркен вакыт иде ул. Вахит Алиевич дигәне берничә шәһәрдә казинолар да тота, Кавказ аша монда тоташкан наркотрафик та аның күзәтчелегендә иде, дип сөйләделәр. Ул чынлап та башкисәр, юлындагы көндәшләрен ике дә уйламыйча юкка чыгарып бара иде. Бу кырын гамәлләрдән Абрар да читтә калмады. Элекке башкисәр төркемнәре замана үзгәрә барган саен малларын канунлаштырып, берзаман хөрмәтле әфәнделәргә әверелеп киттеләр, депутат кәнәфиләрен сатып алдылар. Шуның белән урланган малны сакларга да, арттырырга да җай чыкты.

Харам мал холыкларын да үзгәртте: алар гүя дөнья тоткасы, алар, имеш, иң акыллы, иң башлы, иң гыйлемле һәм үткен зиһенле, алар, имеш, «Алла» иде, алар, җилпер канатлары булмаса да, изге фәрештәләр иде. Мал ничек ансат килсә, күп вакыт шулай җиңел генә шуып та чыга иде. «Атай малы җәл түгел, үземнеке мал түгел!» – дигән гыйбарә дә бу дәвергә карамый, чөнки аларның

аталары малсыз, ягъни чабаталы, дүрт сыйныф белемле булган. Менә шул малайлар бер кәлимә дога белмәсәләр дә, зур мәчетләр, алтын түбәле чиркәүләр салдырдылар, шуның белән исемнәрен мәңгеләштерергә тырыштылар. «Алла йортлары» төзеткәч, үзләрен имам-руханилардан да гыйлемлерәк, белеклерәк итеп хис иттеләр.

Кесәсе шактый калынайган Абрар барыбер тыныч түгел, ятимлек, ялгызлык хисе аны һаман куркыта иде. Шуңа күрә ул башкалада калырга теләмәде, аулаграк урын сайлады. Нәкъ шул вакытта үзе туып үскән һәм инде шәһәрчеккә әверелеп барган туган бистәсе исенә төште. Хәер, ул аны беркайчан да онытмаган иде, нindидер көч магнит кебек аны гел шунда тартып торды. Аларның гаиләсен өнәмәгән, янгын чыгарган өчен үги атасын каргаган күршеләр, әмма шул ук вакытта аны өй саен үзләренә алып, киендереп, тамагын туйдырып, тәрбияләп тә ятим икәнлеген гел исенә төшереп торган ул кешеләр алдында башка сурәттә күренәсе килә иде. Чөнки анда бәхетсез балачагы ирешмәгән максат-хыяллары, теге чакта аны санга сукмаган гүзәл Айгизә, Зәмирә калган иде...

...Бригадир чыгышыннан соң, җыелышның концерт өлеше булырга тиеш. Бәхтине игълан иттеләр. Ул рояль артына утырды һәм башын кыңгыр салып уйный башлады, аннары скрипка алып сыздырырга кереште. Бу әсәр Бәхти-Бетховенның (хатыны кайчак шаяртып үзара гына шулай дип атый аны) мәхәббәт турындагы яңа көе, беренче әсәре иде. Айгизәгә багышланган көй. Уйнап бетергәч, көчле алкышлардан мәдәният йортының түбәсе күккә күтәрелгәндәй булды. Халык аягүрә басып, кул чапты. Бригадирның «коммунизм» хакындагы буш сүзләре шундук җилгә очты. Бистә бары Бәхти турында, аның таланты хакында гына гөжләде ул көннәрдә.

Хатыны Зәмирә исә үпкәләп, үзенчә фикер йөрте: «Нишләп әле ул нindидер Айгизәгә багышланган! Нишләп миңа түгел?! Әәә... Беренче мәхәббәте, диделәр бит?»

Ә үзенең беренче гыйшкы кем иде соң әле? Биюче малай Абрармы? Шул ятим малаймы?.. Ул кинәт кенә юкка чыккан иде бит?! Бригадир сурәтендә яңадан әйләнеп кайтса да, теге чактагы малай күптән югалган, онытылган иде инде...

Бригадир йодрык белән сугып, мәдәният йорты директорының язу өстәлен урталай сындырды. Бик ачулы иде. Хөсетлеге яман иде бригадирның, ул, «авызлыгын» чәни-чәйни, клубтан урамга атылды һәм атнага якын кеше күзенә күренмичә йөргәннән соң, төнката Бәхтинең такта ишеген тибеп аударып кына, йортына бәреп керде. Ярдәмче-бурзайлары Бәхтине типкәләп тышка чыгарып аттылар.

Монысы булган хәл турындагы көйнең бер өлеше.

Бәхти чираттагы кырмыска көтүе һөҗүменнән котылды да күңел кылларын «Фәрештәләр» дигән исем астында яңа көйгә салырга кереште. Моң булып күкрәктән агылды ул...

– Син мине кеше юклыктан файдаланып, пычак белән чәнчемә тагы, яме?!

Хатын бригадирның әлеге сүзләрен шундук аңлады һәм кухня өстәлендәге зур пычакны тартмага шудырып төшерде. Өстәл өсте бушап калды.

Бригадир капылт икенче кеше булып үзгәрде.

– Мин спирт заводын эшләтеп җибәрәм. Главный технолог булып киләсеңме? – диде. – Син КХТИ бетергән бит. Мин беләм, – дип куйды.

Хатын халатның соңгы төймәсен ычкындырды.

– Син монда шуны әйтергә килмәдең бит. Йә?!!

Бригадир, алпан-тилпән атлап, ишек ягына борылды.

– Матурлык чәчәкләрен кыргыйларча коясым килми. Ә инде минем хатыным булырга ризалык бирсәң? Бу хәерче Бетховенның белән ачтан интегеп ятканчы! Кара син бу өегезне!.. Эт оясымыни?! Үзен хөрмәт иткән кеше мондый куышта яшимени? Бер атнадан киләм. Җавабыңны әйтерсең, – диде ул һәм каты басып чыгып китте. Ярдәмче бурзайларның берсе ишегалды ягына очкан ишекне урнаштырып маташа иде.

Бригадирны инде киткәндер дип уйлаган иде, тегесе бераздан тагын әйләнеп керде. «Нәрсә эзләп кергән идем әле мин монда?»

Хатын инде тынычланган, шулай да кычкырып сөйләшергә базмый, курка. Әмма бригадирның зыян салмаячагын аңлагач, беркадәр кыюлык иңгән инде. Ул тавышын көчәйтеп: «Матурлык эзләп йөри идең», – диде. «Ә, ие шул», – дип җаваплады бригадир моңарчы ул гомер ишетмәгән йомшак, назлы тавыш белән. «Син матурлык конкурсында мисс булган кыз идең! Хәерче композитор алачыгында шиңәчәксең бит болай!» Артына чәчәк гөлләмәсе яшергән, сары розалар көлтәсе. Ул аларны өстәл өстенә куйды да, шыгырдый торган идән тактасына салмак басып, бу юлы бөтенләйгә чыгып китте. Бригадир басканда, идән әллә нинди тавыш чыгара икән, дип уйлап куйды хатын, халат төймәләрен каптырганда.

Бригадир аның тәненә орынмаса да, шәрә гәүдәсенә ниндидер пычракмы, тузанмы йогып калган шикелле иде. Ул өйдәге утларны сүндерде дә шәм кабызды, аннары халатын салды, шәп-шәрә килеш душка керде. Өй эчендәге караңгылык матур хатынның ачык күкрәкләрен, тәнен шашып-шашып үбәргә кереште. Ул әүвәл кытыкланды, аннары рәхәт караңгылык дулкыны аны иркәләргә кереште. Тик бу иркә дулкынның «тавышын» ишеткәч кенә, ул аның Бәхтинең күптән язган көе икәнлеген хәтеренә төшереп, сискәнеп китте. Су кранын борды. Боз кебек салкын су куырып алды. Кайнар суны кушты. Беркавымнан соң җылынды, хуш исле сыек сабынны учына алып күкрәкләрен, тыгыз ботларын ышкырга кереште. Зур сөлгегә уранып, душтан чыкканда, өй эче йолдызлар яктысыннан гөлт иткән. Шул яктылык белән ачык форточка аша тагын ниндидер бер таныш көй ургылып керә. Әлеге көйне алар икесе дә – урман кырыендагы нарат төбендә яткан Бетховен да, өй уртасында шәп-шәрә басып торган яшь гүзәл хатын да ишетә, тоя иде.

Көй әнә шулар хакында сөйләде...

Бригадир мәгълүм указдан соң эшсез торган спирт заводын да үзенеке иткән иде. Бер цехны ул көмешкә коя торган итеп, махсус көйләргә уйлады. Дөресрәге, виски ясыйсы килә иде аның. Виски белән көмешкәдән бер үк тәм килә, исләре дә шул ук. Ата-анасы бала чакта өйдә кайнаткан көмешкә пары, күрәсең, аның кайсыдыр күзәнәкләрендә җуелмаслык булып сеңеп калган һәм шул әледән-әле үзен искә төшерә, тынгылык бирми. Бәхетсез балачагы төшләренә кереп йөдәтә, куркытып уята. Ләкин ул алардан һич качып котыла алмый. Ошбу истәлекләр ут тирәсендә әйләнгән күбәләкләр кебек. Бәлки, аны тормышка чынлап ашырсаң, юньсез хатирәләр битәрләүдән туктар дип уйлый ул. Хәер, хәзер көмешкә үзе дә модада. Шул ук көмешкә – виски кыйммәт, белгән кеше куганны эчә. Үги этисе, карт яһүд, көмешкәгә тавык тизәге салырга куша. Әнисе карыша, үтерә бит ул, ди. «Үтерми, башны гына аңгырайта. Тагын сорап килә андый кеше!» – ди атасы.

Әүвәл яңа куганны үзләре сынап карый. Абрар әнисенә килеп асылына

да: «Син эчмә, яме, әнием-бәгырем!» – дип ялвара. Атасы аны этеп җибәрә. «Йөрмә, көчек!» – ди. Ана кеше малаен якламакчы була: «Үзеңнеке булмагач та!» – ди ул. Сүзен әйтеп бетерә алмый, атасы аның башыннан каптырып ала да, авызын каерып, көмешкә агыза. Әни кеше беркавымнан үзгәрә.

Малай елап, урамга чыгып йөгерә. Күршедә Галиулла исемле әйбәт абый яши. Яклау эзләп аларга керә. Галиулла хатыны малайны кочаклап юата. Галиулла абый үзалдына мыгырдана: «Эчеп йөргән яһүдне күргән юк иде әле моңарчы!» – ди. Бу турыда Сәминең үзенә ишетелгәндә, ул авызын ямьсез чалшайтып: «Минем әни марҗа бит!» – дип горурланып, күкрәген суга.

Бәхти Абрарның башка кеше малае икәнлеген өлкәннәрдән ишетте. Әнисе көмәнле чакта үз этисен урман басып үтергән, Абрар туарга өлгермәгән дә булган әле, Сәми – йортка кергән үги эти. Бәхти моны Абрарга малайлар янында әйтте. Тегесе аны тотып ашардай булып карап торды да: «Үзең син! Үзең!» – дип чыгып йөгерде. Ни дип әйтүе булгандыр инде: «Үзең син!» Абрарның зур моңлы күзләрендә Бәхтигә карата кара нәфрәт уты кабынганын берәү дә күрмәде. Абрар моны ул чакта үзе дә белми иде әле.

Хатирәләр хиссиятенең бу өлешен флейта башкарырга тиеш. Сыбызгыны хәтерләткән, әмма салкын көй...

Сызылып таң ата башлады. Кошлар уянды. Кошлар сайравы аның күңеленнән ургылган көйне бутый, саташтыра иде. Ул көч-хәл белән аягына торып басты. Җирдән таяк сыман бер юан ботак алды, шуңа таянып бистәгә таба китте. Көй шул урында әлегә тукталып торды. Ул дөрес якка китмәгән иде, чөнки урман караңгыланганнан-караңгылана барды. Күзләре күрмәс булды. Колагы яхшы ишетә. Ул еракта, караңгылык эчендә кемнеңдер сулыш алганын тойды, шунда таба атлады. Әлеге сулыш аннан ерагайганнан-ерагая бара, ул аның саен адымнарын кызулатып, калмаска тырыша. Шулай куыша торгач, Бәхти урман аланына, бистә ягына килеп чыкканын абайламый да калды. Теге тавыш хуҗасы ак сакаллы карт кыяфәтендә күзенә чалынып кына алды да каядыр эреп югалды. Дәшмәсә дә, ул аның сулышын аермачык тойды лабаса! Бу бернинди саташу да, акылдан язу да түгел, ул сулыш нindидер илаһи җылы дулкын, һава дулкыннары иде бугай. Бәхтинең күңелендәге «оркестрны» алар хәрәкәткә китерде.

Якты көннең үз көе башланды.

Аны арттан җигүле ат куып җитте. Арба кырыенда аякларын салындырып, алдына дилбегәсен салган агай утыра, уртада, тезләренә таянып, бер яшь кыз чүмәшкән. Туктап аны утырттылар. Агай сорау да бирмәде, кузгалып та китмәде. Кулы белән тыгылып, арбадагы кожан астыннан шешә тартып чыгарды, бөкесен тешләре белән каерып ачып, аны юлчыга сузды.

– Мә, җиңеләеп китәрсең. Әйбәт нәрсә.

Ул сусаган иде, нәрсә бу дип сорап тормады, борын очына ипи исе килеп бәрелде, эчемлекне йотып куйды. Шундук гәүдәсе җылына башлады, тагын йотты, тагын берне. Агай шешәне кире тартып алды:

– Җитәр, ату ике таякка калуың бар! – диде. – Болай бергә генә таянгансың әле.

Болар урман артындагы ерак болыннан кайтып килүчеләр икән. Иртүк барып агай печән чапкан, кызы аңа булышкан, күрәсең. Агай шул хакта әйтте дә аның каян килүен, кем булуын да сорап тормыйча, үзенекен сөйләргә кереште.

– Элек печәнне бистә кырыендагы урман аланыннан чаба идек. Бригадирның чучкалары таптап бетерде көтүлекне, – дип көрсенде ул. – Үзе начар кешегә дә охшамаган инде карап торышка. Бер җене кузгалса, күзенә ак-кара күренми түлке.

– Әйбәт ул, – дип куйды, аны җөпләп Бәхти.

– Хатынына әйбәттер! – диде аңа каршы агай, тавышын күтәреп. – Менә безгә юк. Печәнлек кырыенда ун баш умартам да бар минем. Шуны алырга куша. Кортлар чага, имеш. Хатынында корт агуыннан аллергия, имеш. Чуртым булсынмы хатын-кызга корт чагудан?! Файдага гына ул. Бәлкем, үзе бала табар корт чакканнан соң.

– Бригадирның балалары бар бит! – диде Бәхти, аның сүзен бүлдереп. – Икәү. Малай белән кыз!

– Булса ни! Үзенекеләр түгел бит. Детдомнан икесе дә. Икенче хатыны Айгизәне кысыр, диләр.

Моңарчы сүзгә кушылмыйча тын гына барган кыз:

– Бабай, инде! – дип куйды.

– Нәрсә, бабай! Дөрес әйтмимме әллә?! Байлык белән генә булмый шул әле ул! Ходай берсен бирсә, икенчесен бирмәскә дә может!

– Бабай, инде!

– Йә, ярар, бетте, бетте.

Кыз, кулын Бәхтинең җилкәсенә салып, аны үз ягынарак тартты:

– Син Бетховен түгелме соң? Абау, чынлап та шул бит! Бабай, карале!

– Бетховен! Кем тәпәләде болай?! Таң тишегеннән нишләп йөрисең урманда ялгыз башың?

Бәхти дә үзенә музыка түгәрәгенә йөргән бу Фагыйлә атлы кызны танып алды. Скрипкада бик матур уйный иде ул. Ләкин беркөнне Фагыйлә кинәт кенә дәресләргә йөрүдән туктады. Хәтерендә, Бәхти ул талантлы кызны эзләп, өенә дә барды, әмма аны бусагадан кире бордылар:

– Скрипка аңа «Матурлык конкурсы»нда катнашу өчен генә кирәк. Юкка акча әрәм итеп йөрисе юк! – диде анасы. Әлеге сүзләрдән аптырап, каушап калган Бәхти:

– Бушка йөрсен. Миңа сездән бер тиен кирәкми! – дип тә карады.

– Бушка?! Һе, беләм мин бушка дигәннең нәрсә икәнен! Йөрмә монда, бар, кем әле? Ә Бетховен иптәш! Вахит Алиевич безне болай да ярдәменнән ташламый!

– Аю! – диде Бәхти Фагыйләнең соравына каршы, башка ни дип әйтергә белмәгәннән.

– Аю белән сугыштың мәллә?!

– Синең умартаңа килгән булгандыр инде. Миңа очрады да бәргәләп атты менә!

– Әәә, әйтәм аны. Беркөн умартага килгән булган шул ул ләгънәт, этләр куркытты, ди каравылчы. Кырмыска аюы. Менә рәхмәт, алайса син җибәрмәгән инде аны умарта ягына.

– Күсәк белән тондырдым мин аңа! – дип куйды Бәхти, кыюланып. Инде кәефе дә күтәрелгән. Сызланулары да басылган иде. Ә болай мактанып алу аның кәефен күтәрү өчен кирәк иде. Аюга күсәк белән тондырган, имеш! Нинди кыю, нинди көчле ул!..

– Иртүк урманга кошлар җырын отып алырга баргансыңдыр инде, име? – диде кыз бер шаярусыз.

– Ие, – диде Бәхти. – Симфония язам.

– Симфония?! Нинди темага, исеме ничек була?

Агай кызының сүзләрен куәтләде:

– Музыкант булырга укый безнең Фагыйлә, – дип куйды.

Кыз шундук аны бүлдерде:

– Мин биергә яратам!

– Анаң да күбәләк иде. Ни булды! Канатын утка яндырды да хәзер әнә! Син бит скрипкада шәп уйныйсың! Шул дәресләреңне генә дәвам итсәңче канә!..

– Бабай, инде!

Аларның сүзләре Бәхтинең эчен пошыра башлады. Тизрәк сүзгә кушылды:

– Исемеме? Исеме «Фәрештәләр» булыр, бәлки.

– Абау, кызык! Тыңларга мөмкинме? Мин ноталар да укый беләм!

Бәхти ризалашкандай башын какты.

– Син бию көе уйный беләсеңме?

– Белмим!

– Композитор була торыпмы?

Сүзгә агай кушылды:

– Безнең Бетховенның кәҗәләре килгән. Хәер, Фагыйлә, борчыма син аны. Күрәсең бит, аю кулларын да җәрәхәтләгән.

Фагыйлә көлеп куйды.

– Колагына да баскандыр аю аның алайса!

– Котыртып утырма! Аюга каршы чыгу – зур батырлык ул.

– Каяле, Бәхти абый... Бәхти дип кенә әйтсәм, ярыймы? Кулларыңны карыйм әле! Бабай, аптечка!

Агай кожан астыннан бәләкәй тартма чыгарды. Ат арбасында машина аптечкасы йөртә икән! Фагыйлә бабасыннан шешәле су да сорап алды. Шуның белән бармакларын, кулын юды. Кызның куллары кечкенә, бармаклары озын. Аның кул җылысын тою Бәхтигә рәхәтлек бирде. Җае килгәндә, ул аның бер кулын учына салып иркәләмәкче дә булган иде, тегесе Бәхтинең кул аркасына йомшак кына итеп сугып алды да дәвалавын дәвам иттерде. Яраларны юып чистарткач, кечкенә шешәдән ниндиер сыекча салды. Бәхти ачытуга түзә алмыйча чыраен җимерде, кулын тартып алмакчы булды. Ләкин Фагыйлә аны ычкындырмады. Күңелең булсын дигәндәй, башын ия төшеп, авырткан урынга кайнар сулышын өрде, тагын рәхәт булып китте. Бармак-кулларны бәйләп куйгач, авырту басыла төште, тик сулкылдау басылмады. Бәхти кызның йомшак нәни кулын тагын учына әләктерде һәм йөрәк турысына куйды. Кыз бу юлы карышмады.

– Бәйлисе бар йөрәкнеме?

– Бар шул.

– Хатының бәйләр анысын, өеңә кайткач.

Бәхти кызның кул аркасын үбәргә дип башын иде. Кыз бу юлы да карышмады, шаян күзләре көлә, хәзер ул үзгәргән кебек, кырыс түгел. Әнә, Бәхтине кочаклап диярлек, арбадагы кожанны аның өстенә бөркәде, шул чакта аңа орынып та алган сыман булды. Бәхти эреде.

– Мин яза башлаган көйнең бер өлеше син булырсың.

Кыз чыркылдап көлеп җибәрде.

– Безнең профессор әйтә, көйнең әүвәл умырткасы булырга тиеш, ди.

– Ул синең теоретиктыр?

– Вахит Алиевич аны зур акчалар түләп, Италиядән кайтартты! Мине укытырга!

– Ооо! Шулай укмы?

– Ул мине Италиягә чакыра. Монда харап буласың син, ди.

– Китәсеңме?

– Бик китәр идем. Вахит Алиевич каршы.

Агай аларның сүзләрен тагын тыңлый башлаган иде.

– Нинди китү! Үзебездәге пестивалларда кем катнашыр? Ни җитмәгән сиңа?!

Бригадир монда кайтып, беркавым вакыт үтүгә, бистәдә музыкаль фестивальләр оештыра башлаган иде. Кемдер аны музыка ярата, диде. Хәтерләгән кеше: «Әнисе музыка укытучысы иде бит!» – дип җөпләде. Кайсыдыр тагы: «Шул җәбрәйне йортка кертеп кенә харап булды ул», – дип кызганып та ала иде.

Айгыр бүре барын сизгән кебек колакларын шомрайтып, башын чайкап куйды, пошкырды, барган көйгә тибенеп алды. Юкка түгел икән, алар каршысына кара джип килеп туктады да, аннан ике ярдәмче-бурзай төшеп, арбага таба килә башладылар. Бәхти бригадирның тән сакчыларын күреп, башын кожан астына тыкты. Шул арада сакчы бурзайларның берсе Фагыйләне шәле-ние белән күтәреп алып, машинага таба алып китте. Бабай да дәшмәде. Кыз үзе дә чәбәләнмәде, әйтерсең, шулай тиеш иде. Икенче ярдәмче «бульдог» агайга нининдидер кәгазь сузды булса кирәк. Ул: «Вәт сиңа мә! Аргы басудан! Бер гектар җир! Рәхмәт төшкере бу бригадирга! Болай булгач, умарталарны йөз баш итәм!»

Шул арада арба янына машинаның ишеген ачык калдырып, Фагыйлә йөгереп килде һәм кожанны күтәрде дә, Бәхтигә төртте. Тегесе башын калкытуга фәрештә канатыдай куллары белән битеннән сыпырды һәм маңгаеннан үбеп алды да кире йөгерде. Машина кузгалып китте. Ат тынычланды. Бәхти ут булып янган битенә учын куйды. Кулы аша кайнар дулкын йөгереп узып, гәүдәсенә таралды, каны кайнарга күрешүе, шул кайнар кан, тамырлары буенча шаулап, баш миенә ыргылды. Ул кожанны читкә этәрде, арба артыннан баягы көйнең дәвамы ияргән иде...

Агай һаман мөһерле кәгазе белән маташа. Соңында ул аны бик пөхтәләп бөкләде дә куен кесәсенә яшерде.

– Менә бәхет!

– Нинди бәхет?! Кызыңны алып киттеләр бит, күзле бүкән!

– Вахит Алиечның ярәшкән кызы минем онык!

– ...?!

– Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына. Спиртзавод артындагы болынлыкта өч катлы коттедж хуҗасын белмисеңме әллә син? Бар шәһәр шул турыда гына сөйли. И Бетховен, Бетховен...

Вахит Алиевич дигәне бригадирның шәһәрдә бергә «кайнашкан» дусты иде. Бригадир аны үз янына тартты, фазенда салу өчен гектарлап җир бирде. Дөрес, Вахит Алиеч атлы ул «әзәри»нең бизнесы шәһәрдә иде, аны офисына вертолётта йөри, дип сөйлиләр.

Бетховен бистә кырыенда арбадан төшеп калды. Аның белән бергә арба тәгәрмәчләренең ышкылган, шыгырдаган тавышлары урынына скрипка өчен бер яңа көй дә калды. Ул бәхетсез бер кызчык турындагы көй иде. Җиңел, уенчак көй. Кыз бала бәхетсезлеге турында. Әлеге көй китеп барган кызчыкның маңгай чәчләрен йолкый, алар белән уйный, аның йөзенә бәреләә, колак яфракларын чеметә. Тегесенең кытыгы килеп, чыркылдап көлеп куя, шул ук вакытта бу кинәт барабан тавышы белән алышына да олы юл буйлап китеп барган арбаны туктатмакчы була, атның алдына чыга, ялына ябыша, йөгәненнән тарта. Атның чыгымчылавын күргән карт, тез өстендәге дилбегәсен кулына ала, аны каты итеп тартып куя, чөңгереп җибәрә. Тегесе күндәм генә алга таба атлавын дәвам итә.

Көй Бәхти янында кала. «Кыз бала бәхетсез булыр өчен яратылмый!Чөнки ул дәвамчы, тереклекнең бердәнбер дәвамчысы!.. Гамәл дәфтәренә дә шулай дип язылгандыр... Кайчан да булса, аңа барыбер бәхет елмаячак.

Башына капылт килгән әлеге уйлар баягы көйне өзде, бераздан ул юл кырыендагы тигәнәк, билчән, алабуталар арасына кереп югалды; басу уртасында шайтан өермәсе кубарып, аннары тоташ баганага әверелде дә басу тирәли әйләнеп-чабып йөри башлады. Талгын, моңлы көйне шашкын бию көе алыштырды. Туй башланды. Шайтан туе...

***

Бригадирның нәселен хәтерләүче тагын бер кеше бар икән әле бистәдә. Чыннан да, аның әнисе Аня апа әүвәлрәк мәктәптә музыка дәресләре укытты. Ире, көмәнле хатынын калдырып, ГЭС төзергә дип киткән урыс агае Матвей Петрович гаиләсенә кире әйләнеп кайта алмады. Берара төзелештә трактор астында калган дигән хәбәр йөрде дә онытылды. Абрар атасыз туды, яңа әти аңа шул ике-өч яшьләр тирәсе булганда гына, каяндыр пәйда булды.

Бәхти белән Абрар бер сыйныфта укыдылар. Аня апа (Матвей Петрович Ания апага шулай дип дәшә иде) музыкага сәләте булган Бәхтине аеруча якын итте, уку елы башлангач, ул аларны – Абрар белән икесен – бер парта артына утыртты. Өстәмә дәресләр алу өчен Бәхти аларның өйләренә дә барып йөрде. Ул чакта мәктәпләрдә махсус музыка укытучысы булу сирәк хәл, Бәхтинең бәхетенә югары музыка белемле укытучы туры килүе – шатлыклы күренеш иде. Тик бу бәхет озак бармады, Аня апаны алып, музыка укытырга бистә башлыгының эшсез йөргән бер туганын куйдылар. Анысы гармунда бию көе генә уйный белә. Дәрестә балаларны гел биетә генә иде ул. Бәхти белән махсус шөгыльләнүче булмады. Биергә дә хирыслыгы юк иде. Аның каравы Абрар шәп бии. Исенә төшкән саен укытучы аны чыгарып биетә иде. Кайвакыт Абрарның бию түгел, ул уйнаган көйгә селкенәсе дә килми, әмма мәҗбүр иткәч, карыша да алмый. Туйды бер көн малай музыка дәресләреннән, биюләрдән кача башлады. Бәхетеме, бәхетсезлегеме, бер көнне укытучы аңа парта өстенә басып биергә кушты. Менми хәле юк Абрарның. Биергә тотынган иде – юри катырак сикерде бугай – парта тактасы сынып, ул аска мәтәлде. Шуннан соң аны биетүче булмады, Укытучы юк дип, музыка дәресен бөтенләй укытмый башладылар.

Көй, үткәннәрнең шушы хатирәләрен үз хиссиятенә салды да башка дулкынга күчте, болары да хатирәләр белән бәйле бүгенге халәт-хиссият иде. Ни гаҗәп, иртән урманда отып алган кошлар тавышы һаман тынгылык бирмәсә дә, күңел тагын башка көй эзли, җанның кылларына әлеге дә баягы һаман үткән көннәр, хатирәләр дулкыны сугыла, көйне дә шулар чыгара, яза иде.

Үткәне кешене һәрдаим эзәрлекләп торыр, диләр.

Бәхтине үткәне гел эзәрлекли. Ул аларны математик хисаплаулар буенча түгел, күңел көе аша гәүдәләндерә. Дөресрәге, алар аннан сорап та тормыйлар. Агылган моңны туктатырлык түгел.

Аларның күрше подъездларында чәчәк кебек игезәк кызлар яши иде. Бер мәктәптә укысалар да, көндезләрен аралашмыйлар, ә кич ишегалдына бер-бер артлы тезелешеп чыга иде ул кызлар. Алардан зуррак апалары бар, анысы, китап алып, мәйданчыкның иң читендәге берәр эскәмиягә барып чүмәшә дә әледән-әле сеңелләренә күз ташлый-ташлый, китап дөньясына чума. Кызларның икесе – игезәкләр, берсе – алардан ике яшькә генә кечерәк. Алар өчесе дә бертөсле киенеп чыга: чәчләрендә һәрчак ал бантик булыр, ак кыска оек, ул тез астына

кадәр генә. Таганда атынырга бик яраталар. Ара-тирә баудан да үрмәлиләр, асфальтка ясалган шакмаклар буенча да чыпчыклар кебек сикерешәләр иде. Бәхти аларны таганда атындыра. Подъезд ишегеннән ул күренүгә кызлар чәукәләр кебек «Бәхти! Бәхти!» дип черкелдәшергә керешә. Бәхти яннарына бара да өчесе берьюлы утырган таганны тирбәтә. Алар тагын да күңеллерәк «сайраша» башлый, көләләр, чыркылдашлар. Абрарның да аларны таганда атындырасы килә, бик килә. Кайвакыт Бәхтидән алданрак чыгып, таган янына да килеп баса. Тик кызлар нигәдер аның атындыруын теләмиләр. Абрарның моңа эче поша, кызлар янында батырлык кыласы килә. Җәһәт кенә мәйданчыктагы каен башына үрмәли, иң очына менеп җитә. Анда кадәр күршеләрнең сары мәчесе дә менә алмый, ә Абрар куркак түгел, батыр малай, ул бернәрсәдән дә шүрләми. Апа кеше, китабыннан аерылып, агач башында утырган малайны әрли, төшергә куша. Ә тегеләре, бармакларын чигәләренә куеп боралар да, агач башындагы малайны онытып, уеннарын дәвам иттерәләр. Менә Бәхти чыга ишегалдына. Кызлар тагын куанычлы тавышлар чыгарып сайраша-гөрләшә. Бәхти теләр-теләмәс кенә барып, таганны этә, атындыра. Беркавымнан Бәхтине аларның апалары үз янына дәшеп ала. Аның кесәсендә сыбызгыга охшаган уен коралы бар. Ул аны Бәхтигә тоттырып, уйнавын үтенә. Бәхти шул гади генә сыбызгыга өреп, әллә нинди тавыш-көйләр чыгара. Кызлар, таганнарын ташлап, аның янына килеп баса.

Төпчек кыз Айгизәнең күрше малае Бәхтидән колагын тешләттергәннәр иде. Күкләр ярәштергән иде аларны.

Бәхти кызларның кыланышын белеп, күреп тора. Абрарны кызгана ул. Аңа ярдәм итәргә теләп, биюнекенә охшаган көй чыгара. Әлеге көй башта салмак кына башлана, аннан кызулана. Биюгә оста булган Абрар, мәйданчыкта сикерә-сикерә биергә керешә. Кызлар беркавым карап торалар да тагын үз уеннарына чумалар. Апа кеше Бәхтигә башка көй уйнарга куша...

Хатирәләр. Балачакның беркатлы хатирәләре. Алар бүген Бәхти күңелендә көй-моң булып агыла. Абрарның көе юк иде, ул хатирәләр бүгенге «бригадир»ның көе булып агылмый, көе юк бригадирның...

Бригадир монда әйләнеп кайтуга Айгизәгә өйләнде. Бәхтинең яшьтән ярәшкән кызы икәнлеген белә торып өйләнде. Бәхти хәзер Айгизәгә сүз кушарга да кыймый, хәзер инде ишегалдында теге таган да юк, булса да, җиләк кебек пешеп, өлгереп җиткән бу гүзәл аңа утырмас иде. Айгизә атлы әлеге «җиләк» хәзер бригадирның ялтырап торган кап-кара чит ил машинасына утыра. Машинаның карасу тәрәзәсеннән Бәхти аны күрми, ләкин кыз күрә. Күрсә, Бәхти турында ни уйлый икән ул?

Бәхти шул турыда көй язды. Исемен «Таганнар» дип атады. Бер кичәдә уйнады ул аны. Мәдәният йорты шыгрым тулы иде. Көйне башкарыр алдыннан алып баручы аның язылу тарихын, кемнәргә багышланганлыгын сөйләде. Ал бантиклы кызлар таганда атына. Аларны күрше малае атындыра. Кызлар бәхетле. Күрше малаена рәхәт. Ул малай кызларның игезәк сыңарына үлеп гашыйк.

Ул көнне Бәхти мәдәният йортына иртәрәк килгән иде. Җыештыручы хатын, аңа ачкычны калдырып кайтып китте, каравылчы әле күренми. Бүген ял көне, ял кичәләре буласы түгел. Бәхти рояль каршысына утырды да языла башлаган яңа көен уйнарга керешә. Ишек ачылганны да, аяк тавышларын да ишетмәде. Менә уйный торган көе капылт кына өзелде, бармаклары клавишлар өстеннән бер кат йөгереп узды да «Таганнар»ны уйнарга керешә. Ул муенына, аркасына җылы дулкын бәрелгәнен тойды. Дулкын булып аның янына бүген Айгизә

килгән иде. Бәхти, башын борып, аңа карашын ташлады да күз кысып алды һәм бераздан уйнавыннан кинәт туктап калды.

– Уйна, – диде Айгизә тын гына. Аларның бригадир белән балалары юк. Моның өчен бригадир аны каһәрләп-кыерсытып тора. Бу турыда ишетеп белә иде Бәхти. Ләкин хәзер аның Айгизә язмышына бернинди катнашы юк. Үзе сайлаган тәкъдир. Тик яшьлек хатирәләре һаман тынгылык бирми. Гел эзәрлекли. «Таганнар» көе дә юкка гына тумагандыр.

– Уйна инде! – дип ялварды тораташ кебек катып калган Бәхтигә Айгизә. Бәхти көйне башыннан уйнарга keреште. Айгизә аннан башка көйләр уйнавын да үтенде. Кич җитү генә түгел, күптән караңгы төшкән инде. Бригадир ташкалага киткән иде, Айгизә һаман кайтып китәргә ашыкмады. Ләкин Бәхти ашыга, кабалана. Ул моны күңеленең ярсуыннан тойды. Кайларга ашыга аның моңлы җаны?!

Айгизә музыкага хирыс. Аның көе бар. Әйе, Айгизәнең дә, Бәхтинең дә көйләре бар. Көйсез адәм булмый, дигән идек. Бригадирның да көе бардыр. Бәхти аны әлегә таба гына алмый.

Төн пәрдәсе клуб тәрәзәләрен каплый. Клубта эңгер-меңгер. Шул ярым караңгылык эчендә ике көй бергә кушылмакчы була. Күз күрми, ләкин йөрәк һәрнәрсәне тоя торган ярым караңгылыкта аларның иң яшерен көйләре бергә кушылды...

Бу хәлгә бер ел була түгелме соң иде? Бәлки, азрактыр. Хисабын белми Бәхти, күңелнең сәгате юк, вакытны гына сәгать белән исәплиләр.

***

...Шәһәргә җитәрәк, Бәхти аттан төшеп калды. Бистә кырыенда ук аның яшьлеге үткән ике катлы кирпеч йорт бар. Анда әле һаман кешеләр яши. Бәхтинең элеккеге күршеләре күптән юк, бригадир аны ремонтлап, тулай торак ясады. Ләкин бер өлешендә фатирлар сакланып калган иде әле. Бәхти яшәгән фатир да исән. Күрше подъездда да тулай торак түгел, аерым фатирларда карт-коры яши.

Бәхти, бу кыяфәтендә кеше күзенә күренәсе килмичә, йорт ишегалдына керде. Берәр элеккеге танышын очратып, кыяфәтен рәткә китереп алырга ниятләде. Чөнки аның хәзер яши торган йорты шәһәрчекнең икенче ягында ук, Мәдәният сарае артында.

Аларның фатирында күптән читләр инде, ишетеп белүенчә, Айгизәнең олы апасы монда яшәргә тиеш. Игезәк сыңары түгел, Айзирәк исемлесе. Ул балачак ишегалды буенча икенче подъездга таба атлады. Аларның таганы күптән юк инде, синең балачагыңны яхшы хәтерлим әле дигәндәй, искән җилдә ябалдашларын җилфердәтеп, ялгыз каен гына утыра. Каен төбендә теге чакта ук әтисе ясап куйган эскәмия исән! Монда күптән килгәне юк инде! Шуны уйлагач, Бәхтигә бик тә уңайсыз булып китте, сулышы кысылды, йөрәге каен башына очып кунарга омтылган кошчыктай ярсып тибәргә кереште.

Балачак – ул өеңдәге песи синнән олырак булганда гына. Адәми затның үткәннәре һәрдаим аны эзәрлекли. Ләкин аның бөтенләй башка нәрсә икәнлеген Бәхти монда гына аңлады. Балачак истәлекләре җанны сафландырса, үткән тормыштагы гамәлләр вак-зур адымнары белән үкчәңә басып килә, баш миенең яшерен күзәнәкләренә кереп урнашкан ниндидер тылсым-хатирәләр әледән-әле үзләрен сиздереп ала, алар кешенең язмышында яңадан кабатлана; читкә тайпылырга ирек бирми, син үзең дә моны сизмичә, аңламыйча, алар ихтыярына буйсынасың. Үткәне булмаса, композитор Бәхти-Бетховен симфония кадәр симфония тудыра алмас иде. Адәм баласының җанындагы көе аны үткәне белән

тоташтырып торучы күпер сыман... Шул күпере җимерелгән кешедән бернинди көй чыга алмый; туа алмый ул, моң булып агылмый; башкаларның йөрәгенә үтеп кереп хисләндерә, моңландыра, күңелендәге «җан» хиссиятен иркәли алмый.

Көй ул адәм күңелендә бүген генә тумаган, ерак тарихтан, үткәннәр авазы булып милләт, халык һәм нәсел-буын хәтере аша килә... Милләтеннән язган кешенең көе сыңар нотадан гына тора торгандыр, сыбызгы тавышы кебек кенәдер ул, мөгаен...

Композиторның күңелендә симфониясенең яңа өлеше бөреләнеп килә, ул инде «күңеленең тулгак тота» башлаганын тоя, бар җанын шул көйне кабул итәргә яңадан әзерли.

...Бәхти таныш фатирның кыңгыравына басты. Эчке яктан хәтта гадәттәгечә «кем бар?» дигән сорау да ишетелмәде. Аның килүен күптән көтеп торгандай, бик тиз ачтылар, Айзирәк апа ишекнең теге ягыннан ук: «Скорыймы?!» – дип сорады да йозакка бикләнмәгән ишекне эчке яктан төртеп кенә җибәрде. Өй эчендә ачыргаланып кычкырган, ухылдаган, уфылдаган, хәтта ыңгырашкан тавыш килә. Бәхти ярдәмгә ташлангандай эчкә атылды. Ләкин аны ярты юлда туктаттылар.

Айгизәне тулгак тота башлаган! Бригадир йортын ташлап киткән Айгизә апасы янында бәби табарга әзерләнеп ята. Аста шулчак ашыгыч ярдәм машинасының сиренасы ишетелде. Чүп түгүче йөк машинасы, күрәсең, юлын бикләп куйган, тегесе подъезд янына үтеп керә алмый.

Бәхти ачыргаланып илергән тавыш һәм шуның артыннан ук яшь сабыйның беренче мәртәбә кычкырып елаганын ишетеп, имәнеп китте.

Инде бер ел буе диярлек азапланып та, ләззәтләнеп тә эзләгән көенең баштагы ноталары ишетелгәндәй булды. Алар ачык калган ишектән ургылып-ургылып чыктылар, җылы дулкын булып бәрелде ул аңа һәм берара колаклары бары шуны гына ишетте, моң булып агылган җылы дулкын капылт көчәеп, хәтта бермәлгә башын да чыңлатып алды, аннары тигез бер ритм бар гәүдәсе буйлап таралды.

Айгизәне бәбие белән бергә кул күтәрмәсендә машинага алып чыгып киттеләр. Подъезд мәйданчыгында Бәхти аларга юл бирде, аны күргән Айгизә, ни ара кулын сузып, кәчтүм итәген эләктерде, ни ара каты итеп тартып куйды. Ул хәзер бәхетле, газаплану эзләре җуелып бетмәгән аксыл йөзендә бәхетле елмаю. Бер елмаю композитор өчен яңа көй язарга сәбәпче булырга мөмкин, Айгизәнең әлеге елмаюы симфониягә башлангыч булыр, бәлки!

Ул Айгизәнең аңа ни әйтергә теләгәнен шундук аңлады... Дөньяга композитор Бәхти-Бетховенның иң талантлы, иң бөек көе – баласы туган минутлар иде бу!..

Айзирәк «ашыгыч ярдәм»не озаткач кына, Бәхтинең нинди кыяфәттә икәнлеген күрде. Күрде дә әле генә бер шоктан айный башлаган хатын тагын сискәнеп куйды: «Ни булды!? Кем эше бу?!» – дип сорады. Ул бик акыллы, ушлы хатын иде, сорауларына җавап көтеп тормастан, шундук аны фатир ишегеннән эчкә төртеп кертте дә ваннага су җыеп бирде, кулына эскәтер чаклы хуш исле зур сөлге, иренең киемнәрен тоттырды. Ул барысын да белә иде, күрәсең, артык сораулар биреп маташмады; Бәхти сизә бит: Айгизәнең апасы бригадирга караганда, әлбәттә, Бәхтине якын күрә, сеңлесенең аның белән булуын тели кебек күңеленнән. Хәер, хатын-кызның күңелендә ни барын кайлардан белеп бетермәк кирәк, төпсез упкын хатын-кыз күңеле, «күзле бүкән»нәр бик тиз адаша, башын югалта ул упкында.

Киемнәр Бәхтигә таман иде. Ул ишегалдына чыкты һәм, гөнаһ шомлыгына каршы, каенанасына юлыкты. Инде өченче ир алыштырып та гаиләдә хатыны-кыз бәхетен таба алмаган һәм беренче көннән үк киявенә кырын

караган каенана ярты ел чамасы инвалид бишегендә. Яше кырыктан узса да, матурлыгын югалтмаган хатынның, үзе әйтүенчә, ирдән бәхете булмады. Өченчесендә бай эшмәкәргә юлыгып, ниһаять, бәхеткә тиендем, мул тормышка ирешәм дигәндә генә, алар ире белән икесе дә вертолётта һәлакәткә юлыктылар. Ире үлде, ул исән калды, тик гарипләнеп, хәзер инвалид бишегендә.

Каенана белән салкын гына бер-ике сүз алыштылар да, Бәхти тизрәк моннан китү ягын карады. Каенана Бәхтинең киемнәренә баштук игътибар иткән иде, ул бишектәге җәймә астыннан кесә телефонын алып, кызына шалтыратты. Әйе, булдыксыз киявен өнәми, беренче көннәрдә үк аның сүзен тыңламаганы өчен яратмый иде аны каенана. Югыйсә тәмле телләре белән әйтте, җырлар яз, җыр язган кеше акчаны күп эшли, маташма шул симфония-минфонияләрең белән, диде. Тыңламады тегесе. Үҗәт, кире. Кызын бәхетсез итмәкче була! Итми торсын әле менә, каенана моңа юл куячак түгел!

Бәхти ерак ара китмәде. Йорт читендәге чәчәк кибетенә керде. Аннан каенанасының иң яраткан чәчәкләрен – кызыл розалар сатып алды, унбиш данә! – Һәм мәйданчыкта утырган гарип ханымның алдына салды, җилкәсеннән җиңелчә генә кочаклагандай итте. Хатын алдында таралып яткан чәчәкләр өстенә берничә тамчы кайнар күз яшьләре төште. Ләкин берсе дә башлап сүз катмады, тынлык хөкем сөрде мәйданчыкта. «Ә тынлыкның үз көе бар бит!» – дип уйлап куйды Бәхти үзалдына һәм, кызу-кызу атлап, китеп барды. Бите буйлап агарга керешкән күз яшьләрен, Аллаһ рәхмәте, җәйге җил киптерде...

Хатыны өйдә иде. Ишектән керүгә ул иренә сарылды.

– Син әйткәч, мин полициягә шалтыратмадым инде, – диде ул, аклангандай.

– Полициянең катнашы юк монда, – диде Бәхти, хатынны сак кына читкә этәреп.

– Мин спирт заводына эшкә керәм! Бер айда еллык зарплата анда! – диде.

Бәхти җавап кайтармады. Аның дәшмәвен үзенчә аңлаган Зәмирә акланырга кереште:

– Бу эт оясы кебек фатирда күпме яшәп була! Синең зарплатаң юк! Әни дә ярдәм итә алмый хәзер! Үз хәле хәл.

Бәхти дәшмәде.

Өйләнешеп, күпмедер яшәгәч, гаиләдә мәхәббәтне акча алыштыра. Хәер, дөрес тә инде, суган суы суырып утырып булмый бит «эт оясы»нда. Һәр кешенең мул тормышта яшисе килә. Ләкин ир-ат шуны да белергә тиеш: күктә күпме йолдыз бар, хатын-кызның күңелендә шулчаклы яшерен сер яши. Бәхти шул серләрнең берсен чишәргә теләгәндәй, кухняда нидер эшләп маташкан хатыны янына килде дә аны арттан кочаклап алды һәм каерып үпте. Хатынның кулындагы пычагы идәнгә төшеп китте. Нindидер яшерен, ләкин бик көчле бер дулкын аларны почмактан залга этеп чыгарды, аннары әле җыелмаган агач караватка төртеп аударды.

Ул дулкынга берәү дә каршы тора алмый... Кешелек дөньясы дистә мең еллар яшәсә дә, ир-белән хатын арасында әлегә яңа, ягъни башка төрле якынаюның булганы юк. Бүген дә нәкъ шулай иде. Гадәттәгечә булды...

Әмма тәннәре берләшсә дә, өйләнешкәннән бирле көйләре һаман кушылып бетә алмый. Икесен дә әнә шул шомландыра. Бәхти моңа үзен гаепле саный, югыйсә композитор буларак, иң беренче итеп уртак көйне ул табарга тиеш иде.

Әллә?.. Әллә инде... Кем әйтмешли, ул чын композитор түгелме? Элек көйне талантлар тудырса, хәзер тыңлаучылар үзләре дә яза һәм аларда, гадәттә, шырдый-бырдый була... Ул көйләргә сөяккә дип барган эт тә сөртенеп егылырлык...

Зәмирәне иренең мәхәббәте йомшартты, дөресрәге, күңелен нечкәрткән иде.

– Бармак белән дә орындырмадым мин аңа, – дип куйды ул, aклангандай.

– Син кирәкмисең аңа!

– Синме әллә?

Бәхти хатынга күтәрелеп карады.

– Мин.

– Китче, Бәхти?! Алай булса, сине бурзайларыннан талаттырмас иде?

– Нинди беркатлы син, Зәмирә, нинди наив!

– Миңа багышлап, бер көй дә язганың юк, җыр да...

– Көеңне таба алмыйм әлегә.

– Башкаларга тапкансың! Теге көнне күршең Айгизә клуб түшәменә чаклы сикерә язды. Бригадир бәреп үтерә әле аны!

– Бригадирны ташлап киткән ул.

– Бригадир эшкә мине чакыра, дидем. Каяндыр Казанда укып кайтканны да ишеткән.

– Эшкә генә чакырамы икән ул сине?

– Билләһи, валлаһи, бармак белән дә орындырмадым мин аңа!

– Мә! – Бәхти кесәсеннән хатынының лифчигын алып, үзенә сузды.

Тегесе моны күргәч, торaташ булып катты да калды. Беркавымнан һушын җыеп:

– Ә син... Ә син үзең!

– Мин синең көеңне таба алмыйм, Зәмирә.

Хатын караватка ауды һәм, мендәргә капланып, тын гына еларга кереште. Бәхти башка чактагы кебек аны юатып тормады, булган кием-салымын, нота кәгазьләрен бер капчыкка салды да ишектән чыгып китте. Идән такталары бер көйгә шыгырдап калды. Артыннан ишекне япмады.

Ире турындагы гайбәт, димәк, Зәмирәгә чаклы килеп ирешкән. Әгәр кеше артыннан гайбәт сөйлиләр икән, начар инде ул, ә менә сөйләмәсәләр, тагын да яманрак.

Урман ачыклыгында күзенә күренгән аксакаллы карт аңа һаман тынгылык бирми, анисыннан да бигрәк төнге сулыш тынычлыгын алган иде. Теге чакта, әнисе намазын тәмам кылгач, малай аңа җылы дулкын турында сөйләгән иде шул. Дөресрәге, нәрсә ул, дип сорады бугай. Абрар белән икесе иде алар. Намаз беткәнне тын гына көтеп утырдылар.

Әнисе ул чакта гаҗәпләнеп, улына карады, дәшмәде. Шулчак икесен дә шаккатырып, Абрар: «Фәрештә канатларын җилпи, шуның җиле ул!» – дип әйтеп куймасынмы! Әнисе тагын телсез калды. Беркавымнан Абрарны кочагына алып, аркасыннан сыйпады. Аннары үз малаен кочты, авыз эченнән нидер пышылдап, башыннан сыпырды.

«Мин дә тояммы аның сулышын?» – дип куйды Абрар, нигәдер капылт күңелсезләнеп. Аннары кинәт сикереп торды да: «Тоям! Тоям бит менә! Ул миңа бию көе уйный! Юк! Мин үзем – фәрештә! Мин – фәрештә!» Малай тиктомалдан җуләр нәрсә кебек котырып биергә кереште. Ә Бәхтинең колагына башта барабан каккан тавышы ишетелеп торды, аннары аны виолончель, аннан соң скрипка, альт, башка коралларның талгын яки ярсу көе алыштырды. Бәхти кинәт аңын югалтып егылды. Сикерә-сикерә биегән Абрар аңа сөртенеп, маңгае белән шапылдап, идәнгә ауды. Бәхтине әнисе аңына тиз кайтарды, тик Абрарның егылганда, тагын тез капкачы ярылган иде, ул аягына баса алмады. Аны хастаханәгә озаттылар. Шуннан соң ул аларда яшәмәде. Савыгып чыккан малайны үзләренә спирт заводы директоры Афанасий дәдәй гаиләсе алды. Ә «фәрештә» кушаматы малайга ныклап ябышып калды.

***

Янгын төнлә чыкты. Бәхти йокысызлыктан интегеп, караватында аунап ята иде, кинәт аны кемдер төртеп уяткан кебек булды. Ул шыбыр тиргә батып, сикереп торды. Өйдә ялгызы иде. Хатыны күптән спиртзаводта төнге сменада. Төнге сменада булмаса да, кунарга кайтмаган булыр иде, бригадир аңа аерым фатир юнәтте.

Ул, кранны ачып, башын салкын суга тыкты. Пошкыра-пошкыра юынды, элгечтәге сөлгене тартып алды, элгеч урыныннан кубып, шалтырап, идәнгә төште. Бәхти аны аягы белән эштереп кенә җибәрде дә сөлгесен ванна кырыена ташлап, бүлмәгә чыкты, пианино янына утырды.

Бу вакытта кара төтенле янгын көчәйгәннән-көчәя бара, урамда ыгы-зыгы купкан иде. Тик төнге караңгылыкта төтен түгел, кызыл янгын телләре генә күренә. Бәхти тиктомалдан яңа көй уйнарга кереште. Ниһаять, тапты ул аны. Ачык форточкадан өйгә әллә янгын кызуы, әллә Җәбраил фәрештә сулышы ургыла иде – аңламады. Ярсып-ярсып уйнавын дәвам иттерде, онытылды, берара юкка чыгып торды. Янгын сүндерүче машиналарның берсе каты чабып килгән шәпкә аларның йортына бәрелмәсә, бик озак шулай уйнаячак иде әле. Өйнең урам як дивары авыр шыгырдап, аның өстенә таба килә башлады. Бәхти тиз һушына килде, эшнең нидә икәнлеген аңлады һәм ишеккә ташланды. Аның артыннан уйный башлаган көй дә ургылып тышка чыкты.

Машина-техника, кешеләр тавышы, ачы төтен исе, янгыннан шарт-шорт килгән шифер тавышлары бөтен урамны тутырган иде.

Завод эчендә кешеләр калган, диделәр. Аларны коткарып булмады, диделәр.

Кешеләр беркайчан да чын дөреслекне белеп бетермиләр яки белеп тә сөйләмиләр, нәрсәнедер әйтмичә калдыралар: янгын эчендәгеләрнең берсе – япь-яшь хатын-кыз, диләр – котыла алган, аны бригадир үзе күтәреп чыккан да, башкаларны коткарырга тагын эчкә ташланган. Шуннан соң бригадирның кире чыкканын күрмәгәннәр...

Бәхти әле һаман дөрләп янган янгын телләренә шаклар катып, аптырап карап торды да, капылт уянып киткәндәй шунда таба ыргылды... «Зәмирә!» – дип, ачыргаланып кычкырып, янгын эченә ташланды, әмма аны шул вакытта кемдер тотып калды, читкә өстерәде. Кулларын каерып бәйләп салдылар. Кулларын бәйләсәләр дә, янгын телләре белән аллы-гөлле һәм кып-кызыл чәчәкләр өстендә уйнаган күбәләкләр кебек әйләнә-әйләнә, бөтерелә-бөтерелә агылган көйне – күптән башланган төнге симфония агышын – бәйли, туктата алмадылар. Гүелдәгән, ыжгырып шаулаган янгын тавышына кушылып ишетелә иде ул, аннары янгыннан котлары алынган кешеләрнең күз алмаларында үзгә бер яктылык булып чагыла, күмергә әйләнгән такта-бүрәнәләрне шартлатып вата, шифер кисәкләрен сындырып, читкә ата да, кара төтен баганасы булып, төнге күк катына күтәрелә; күзгә күренми, ләкин тавышы ишетелә, гүелдәгән авазлар төнге күк куенында изрәп йокымсыраган болытларны тузгыта, ул болытлар аша шулай тәңре катына омтыла, анда бригадирның үги атасының, газиз әнкәсенең ничәмә-ничә дистә еллар элек янгында эрегән гәүдәләрен ташлап чыгып, илаһ катына ашкан рухлары белән тоташа. Янгынның ялкын телләре бар, янгынның кызыл утлы, кара төтенле хәтере бар. Ул хәтер эчендә бүген яңа язмышлар пыскый, дөрли-дөрли, ялкынланып тузгый-тузгый яна алар. Шуңа күрә дә бик эссе, кайнар, якты кызу утлы, кара төтенле иде ул көй. Ялкынны кара төтен урап алганлыктан кешеләр аның эчендәге яктылыкны күрмәделәр. Бәхти исә

күрмәсә дә, тойды, аһәңен ишетте. Ул аһәңнәр арасында бригадир көенең ахыры да, хатыны Зәмирә рухы булып төнге күк авазы белән бергә кушылган тагын бер үзгә көй дә бар иде. Йөрәкләрне ачыттыра торган көй иде монысы...

Исән калган бер хатын-кыз белән Бәхтине «ашыгыч ярдәм» машинасында хастаханәгә алып чаптылар.

Күккә сузылган янгын телләре өскә күтәрелгән саен нindидер үзгә кыяфәткә керә бара, караңгы төн куенындагы ут шәүләләре арлы-бирле чабышып йөргән колыннарны, әле усал ырылдаган юлбарысны, әле очып барган кошларны хәтерләтте. Тик ул кошларның барысы да канатсыз икән һәм менә, үзләренең кош сурәтен югалтып, фәрештә кыяфәтенә керделәр, аннан соң ачы сызгырган тавышлар чыгарып, күкләр тарафына атылдылар. Бәхти кайнар, утлы сызгыру авазлары арасыннан бары бер көйне генә аерып алырга өлгерде, аермачык ишетте ул аны; ишетте дә шаккатты: «Фәрештәләр» көенең ахыры аның үз күңеленнән агыла иде. Бу аның үз җаныннан ургылган көй икән ләбаса! Ул көй әнә – Бәхтинең күкрәк читлеген ташлап чыкты да яшьтәше Абрарның, көндәше бригадирның өч катлы коттеджын ураган биек койма аша җиңел генә ишегалдына сикереп төште; пожардагы төтен исенә вольерында әрле-бирле килгән аюның куркудан дымланган күзләрен җиле белән өреп киптерде, юешләнгән борынын сөртеп алды; аннары хуҗасы ябарга онытып калдырган форточка аша өй эченә үтте, анда диварларга, кызыл агачтан эшләнгән затлы мебельләргә, юлбарыс манекены эленгән почмакка, император Наполеонның бутафор киемендә төшкән бригадир портретына, шуннан бераз арырак тагын бер алтын кысалы портретка орынды; монысыннан махсус тектерелгән фәрештәләр киемендә Абрар белән компаньоны Вахит Алиевич карап торалар, ике дус «канатлар»ын бер-берсенең иңенә салганнар, аларны хатын-кыз сурәтендәге шәрә фәрештәләр уратып алган; дөньядагы иң кыйммәтле бокото агачыннан таучык кебек ясалган шкафтагы алтын каймалы савыт-сабаларга кагылып узды; ишеге ярым ачык фарфор ташаяклар белән бизәлгән һәм юынгычы алтыннан коелган ванна бүлмәсендә әкияти Су анасы тарагына охшатып, фил сөягеннән ясалган көмеш каймалы элгечтә Айгизәдән онытылып калган халатның итәген җилфердәтеп уйнады; идәнгә җәелгән ак аю тиресендә мәтәлчек атынгандай итте һәм, монда үзенә башка эш-гамәл тапмаганга эче пошкандай, шул ук форточкадан урамга агылды...

Урамга чыгуга, ут телле көй, Вахит Алиевичның күршедәге шундый ук биек коймалы өч катлы сарай-йортына барып керде. Анда яшь хатын Фагыйләнең бакчадан үзе җыеп алган сары розаларына килеп сарылды һәм караватбелән шуның янәшәсендә үк идәндә сузылып яткан ир-ат белән хатын-кыз гәүдәләренә юлыкты. Аларның берсе – хуҗа үзедер, ахрысы, төтеннән тончыгып җан биргән, ул көйне бөтенләй ишетмәде дә, диванда капланып яткан хатын-кыз исә кыймылдады, ыңгырашты, көйне ишетеп булса кирәк, күзләрен ачты һәм идәнгә тәгәрәп төште дә ишеккә таба шуышты. Көй монда озак юанасы итмәде, тагын тышка ургылып чыкты.

Ул көй, ыңгырашып сызланды да, елаган, сыктаган тавышлар чыгарып, тагын бер мәртәбә кызу утлы янгын тирәли әйләнеп, теге фәрештәләр артыннан төнге күк катына ашты.

Ул фәрештәләр канатсыз иде...



Рифкать
Имаев

# ТАБАСЫ ИДЕ ЧИШЕЛЕШЕН...

## Төрлелек

Күңел икән буш булалмый,
Һәр күңелгә сер сыя.
Җирнең гади кешесе дә
Үзенә бер зур дөнья.

Мин башка шул, яши алмыйм
Тормышның гел җаена,
Минем өчен һәрбер кеше
Укылмаган поэма.

Бар күңеле чисталары,
Бар күңеле керлесе.
Бер булалмый бөтен кеше,
Бар арада төрлесе.

Юлга кара, юллар нинди:
Түбән төшә, үр менә.
Дүрт аяклы атлар да бит
Вакыт-вакыт сөрлегә.

Ычкынып та куябыз шул
(Булмый гел түзеп кенә):
Яхшымы бу, начармы бу –
Әйталмыйм өзеп кенә.

Ялыктыра гел бер төс тә,
Һич туйдырмый төрлелек.
Миңа никтер ошый төшә,
Булса кеше серлерәк.

Рифкать ИМАЕВ (1948) – *шагыйрь; «Гомер агышлары», «Алма балланган вакыт», «Уйламыйм, дим, уйлата» һ.б. китаплар авторы. Түбән Камада яши.*

## Кышкы шигырь

Кыш турында икән шигырь,
Нидән башларга сүзне?
Озаттык кызганмый гына
Йөдәткән елак көзне.

Язып тормыйм кар турында,
Кабатлау булыр тагы.
Куяннарның: «Кыш килде!» – дип,
Ап-ак тун кигән чагы.

Ә җиһанның шундый мәле:
Тирә-як калган бушап.
Тик балан тирбәлә җилдә
Кан тамчысына охшап.

Кышка кердек. Курыккан юк
Бер дә эшсез калудан.
Авылларда көн башлана
Кулга көрәк алудан.

Ап-ак дөньяга сокланып
Туа ал таңнар гына.
...Ник агарып бетә алмый
Безнең бу җаннар гына?!.

## Яңа көн

Таң нурлары үпте җирне,
Тургай атылды күккә.
Көн туасын сизеп микән,
Балыклар ятты төпкә.

Күл камышы кыштырдады –
Таң җиле узды бугай.
Сизелер-сизелмәс кенә
Җанланып алды тугай.

Су буенда җыр башлады
Нинди кoштыр – билгесез.
Сандугачны да аермый,
Диясездер инде сез.

Бигүк ошап бетмәсә дә,
Таң белән йөрү шаулап.
Кинәт әтәч аваз салды,
Бер эт куйды һау-һаулап.

Чәчәкләрен кояш үпте,
Тузаннарын чык юды.
Һәр күңелгә өмет өстәп,
Җиргә яңа көн туды.

## Җәйге яңгыр

Яңгырлар ява коеп,
Бар җиһан тора оеп.
Тыңлый күпләр шушы җырны,
Эшен бер читкә куеп.

Яңгырлар ява коеп,
Хисләрне булмый тыеп.
Шагыйрь кулга каләм ала
Шигырь туасын тоеп.

Яңгырлар ява коеп,
Табигать тора оеп.
Җылы яңгыр – ул бит дәва,
Булмый һич аннан туеп.

## Шигъри мизгел

Авыл өстендә болыт
Тора бер япма булып.
Тамчылый башлады кинәт,
Китте күңеле тулып.

Юып алды тузанны,
Чылатты тар ызанны.
Шатландырды сусыл үлән
Аркандагы бозауны.

Ә казларга барыбер күк –
Казлар күлдә су керә.
Тирләп печән чаба идем,
Шәп булды әле зерә.

Үләннәре баш калкытты,
Сафланып китте һава.
Һәр тамчысы дару сыман –
Менә кайда ул дәва!

Агарып калды читләре,
Ахры, йөгеннән бушый.
Бу болыт безнең авылга
Атап килгәнгә охшый.

## Һич беталмыйм төшенеп

Әллә нинди заман ла бу:
Көн тудымы – үтереш.
Ачлык чоры дияр идең –
Начар түгел көнкүреш.

Дөньясының рәте китте,
Көн тудымы – гел талаш.
Гадиләргә бер хөрмәт юк,
Каян килгән бу караш?

Соңгы сәгатьләрен көтеп,
Урында ятсалар да,
«Җитте!» дип әйтә алмаслар,
Алтынга батсалар да.

Шулай булмый нәрсә булсын,
Байларныкы – замана.
Байлык бүген җанга хуҗа,
Байлык бүген – тамада.

Намус, вөҗдан һәм мәрхәмәт –
Калды барысы сүзлектә.
Эзләсәң дә табалмассың,
Озак йөреп өзлекмә.

Табасы иде чишелешен,
Беталмыйм һич төшенеп.
Борчый әмма гел бер сорау:
«Кая бара кешелек?»

## Гаеп бездә

Нинди сүз ул: «Бу тел, – диләр, –
Безнең илдә тыелган».
Ул бит ана сөте белән
Минем җанга уелган.

Бу – акылга сыймаслык хәл,
Бу – ваз кичү анадан.
Булыр идем аңа тугры,
Тусам да мин яңадан.

Тукай, дибез, татар, дибез,
Еш кабатлыйбыз зерә.
Башкаларның Тукае юк,
Алар ничек көн күрә?

Яраталар китерергә
Тукайның сүзен сүзгә.
Игътибар итсәк икән без
Ешрак үзебезгә.

Заманы да башка инде,
Тукайлар туа сирәк.
Кайсыбызда тибә бүген
Тукайда булган йөрәк?

## Шаһзадә

Туктап, сиңа сокланалар
Яныңнан узган бере.
Нидә соң моның хикмәте,
Нидә соң моның сере?

Синдә генәдер, мөгаен,
Кашның кара кыйгачы.
Син кайсының бердәнбере,
Син кемнең сандугачы?

Синдә генәдер йөзнең дә
Ал таңнардай нурлысы.
Килә сине иркәлисе,
Килә сине зурлыйсы.

Эзләсәң дә, табылмастыр
Сиңа охшаш игезәк.
Син бу җиргә күктән иңгән
Үзенә бер ак бизәк.

Миңа сузган ак кулларың
Карлыгач канатыдай.
Синең кебек башка юктыр
Баш җуеп ягатырдай.



Рүзәл
Мөхәмммәтша

# ХӘЛ БУ КИ*

КЫЙТГАЛАР КЫЙССАСЫ

## Башлам

...Шулай итеп, мин «Идел» журналында эшли башладым.

Басмага нигез салган олпат затларның, өстән куелган баш мөхәррир белән бугазга-бугаз килешеп, барлык күперләрне яндырып китүеннән соң, якынча бер ел узган; алар дөбердәтеп япкан ишекнең кайтавазы тынган; офыкларны чамаламаслык хәлгә җиткереп күтәрелгән җәнҗал тузаны басылган иде инде.

Матбаганың үзгә адрес буенча (Чистай урамы), үзгә җитәкче канаты астында үзгә коллектив туплап, үзгә тормыш башлавы иде бу. Искене җимереп яңаны кору хыялы һәрвакыт тилерткеч, гайрәтле һәм җавапсыз була: шул хистән канатланып, әле мин килгәнче үк, дизайнер Олеся иң беренче эш итеп, редакция компьютерын егерме еллык архивтан (фотолар, портретлар, иллюстрацияләр) тазарткан...

Әүвәл эшем һәр санга шигырьләр шәлкеме әзерләүдән, төрле рухтагы һәм аннан да яманрагы, төрле сыйфаттагы язмаларны эшкәртеп, басмага тапшырудан гыйбарәт иде. Көннәрдән бер көнне Фирая апа (баш мөхәррир урынбасары) җаным теләгән темага мәкалә язып карарга киңәш итте. Язып карадым. Аңа ошады кебек. Һәрхәлдә:

– Әйдә, колонка алып бар, – диде. – Сан саен берәр язма? Булырмы?

Миңа егерме яшь иде. Миндә табун-табун айгырлар кешни – утарына сыешмыйча, билгесез, ләкин билгесезлеге белән дә ымсындыргыч азатлыкка омтылып, күндәм язмышына рәнҗи-рәнҗи авызлыгын чәйнәп, бертуктаусыз тояк бәрә-бәрә җанны ерта иде. Мин куәтле идем. Усал идем. Сүз көче белән Җир шарын туктатып, аны, теләсәм, кире якка әйләндерергә сәләтле идем. Шуңа күрә озак уйламыйча:

– Эшләп карыйк, – дидем.

* Журнал варианты.

Рүзәл МӨХӘММӘТША (1989) – *шагыйрь һәм прозаик; М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты. «Каралама», «Бүре мин» дигән китаплар авторы. Казанда яши.*

Нинди тозакка килеп капканымны соңрак, берничә айдан соң гына аңладым. Аһ, күпме каһәрләгәнмендер авызымнан уңай җавап чыккан ул көнне! Яхшылап сүгенүне дә шулвакыт үзләштердем сыман. Бу сәхифәне алып бару тәмуг газабын кичүгә тиң иде, билләһи! Сан саен, сан саен мәкалә! Ул көн кадагына да туры килергә тиеш, журнал чыкканчы искермәскә дә; газетщинага да төшәргә ярамый, әдәби әсәргә әверелдерергә дә; язма актуаль дә, мәңгелек кыйммәтләрне яктырткан да, тапталмаган да, яңа да булырга тиеш иде. Өстәвенә, аны тавык чүпләп бетермәслек башка эшләр белән берьюлы (редакцияләү, тәрҗемә итү, интервью алу) башкарырга кирәк иде әле.

Озакламый минем мәкалә редакциягә иң ахыргы булып керә башлады. Ай буе, чирле кеше сыман, аның белән авырып, изаланып, ай ахырында гына, ниһаять, кәгазьгә түгә идем. Ә иң куркынычы: материалны баш мөхәррир урынбасарына тапшырган мизгелдән үк бу газаплар, качып котылмаслык дулкын булып, өр-яңадан башка ишелеп төшә иде, чөнки киләсе санга янә язма әзерләргә кирәк...

Үзәгемә үткәнгә һәм еш кына ашык-пошык язарга туры килгәнгә, мин ул мәкаләләрне журналда басылган килеш укымаска тырыштым. Һәрберсен хәтеремнән, тормышымнан сызып ташларга теләдем.

Бу ниятемне куәтләп, берсендә мондый хәл булды.

Ул вакытта мин авылда, отпускада идем. Нәүбәттәге мәкаләмне дә шунда ял арасында язып, почта аша гына редакциягә җибәрдем. Яңа сан мине дөньяны онытып, гөмбә җыйган җирдән эзләп тапты (сеңелкәш белән көн дә урманга йөрергә гадәтләнгән идек). Алдым. Ачтым. Шулвакыт арка миен зәмһәрир салкын өшетте. Язмамның ахыргы юллары бертуктаусыз күз алдымда чәбәләнде: «Эштән керәсең дә башың – сау, херня белән тулмаган»... (Игътибар! Әлеге кәлимә, ямьсез булса да, чагыштырмача цензуралы. «Хер» ул – иске славян телендәге «х» хәрефенең атамасы. Ягъни, иң мәгълүм сүзен гел-гел ялангач көе кулланмас өчен, агайне аңа шулай төпсез ыштан кидергән.)

Язучы Сергей Довлатов совет матбугатында хаталар гына хакыйкатькә туры килә, ди: Сталингад, гавнокомандующий... Ләкин махсус шундый «хата» җибәрер өчен мин ул вакытта Довлатовны белми идем әле. Башка килгән фикерне ашыгып, караламага төрткәндә, сүзләр сайлап изаланмыйм анысы. Иң мөһиме – уй очын, образны югалтмау. Бу мәкаләне эшләгәндә дә, табигый, шулай иттем. Ләкин аннары чистага күчергәндә, төзәттем бит!

Кабаланып, компьютерга чумдым, почтаны актара башладым – ни аяныч, гаеп тулаем миндә иде: язманың азаккы вариантына, ничектер, текстның каралама өлеше «ябышып» калган... Һәм шул килеш Казанга киткән. Редакциягә әлеге койрыкны чабып кына калдырасы иде! Әмма соңрак ачыкланганча, журнал басмага тапшырыласы көннәрдә баш мөхәррир урынбасары Рузия апа (биш ел эчендә кем килә торды «Идел»гә, кем китә торды, билгеле) хастаханә юлын таптап йөргән, бик вакытлыча баш мөхәррир вазифасын башкарган Алексей татарча бөтенләй белми иде, ә корректор Миләүшә апа минем материалга кул тыгарга базмаган...

Йомгаклауга таба борып әйткәндә, кәминә бәндәгез ул мәкаләләргә хәзер, күпме сулар аккач кына, яңадан күз ташларга базды. Арада төрлесе бар икән. Яхшыларына аерым тукталып тормыйм. Ниемә хаҗәт ул? Алар болай да яхшы бит. Әмма оешып бетмәгәннәре арасында да кызыклы, игътибарга лаек урыннар, Тукай заманыча әйтсәк, «кыйтгалар» күзгә чалынды. Башта барысын

бер шәлкемгә җыеп чикләнергә уйласам да, аннары азмы-күпме уйдырма кушылган хикәяләр белән сипләүне дөресрәк күрдем.

Кыскасы, хәзер ул кыйтгалар – сезнең алда.

Аларда минем биш ел гомерем.

Аларда минем пычак йөзедәй шәрә һәм үткен хисләрем: ышаныч-өметем, борчуларым, януым.

Аларда минем мәхәббәтем. Нәфрәтем. Бәлки, беренче чиратта – нәфрәтемдер. Кичәдә калган бүгенем. Бүгенгемә әйләнгән киләчәгем.

Хәл шул ки.

## Тәүге кыйтга

*(Февраль, 2011)*

...Ничәнче сыйныф булгандыр... Солдат хезмәте турында инша яздырдылар. Тугызынчы май уңаеннанмы, егерме өченче февральме? Истә калмаган. Ләкин мин ул биремне бик самими, саф күңелем белән башкарып чыктым. Төп фикерем: хезмәт итү – изге эш, намус эше; һәрбер ир-егет, һичшиксез, сөекле илебезне явыз дошманнардан сакларга тиеш. Иншаны кемнәргәдер җикеренеп тәмамлаганым хәтердә: «Ватаныбыз хакына баш салган каһарманнарыбыз алдында оят түгелме сезгә? Бабаларыгызның күзенә ничек карыйсыз?»

Нишләтәсең...

Беренчедән, ул вакытта үз бабам исән әле. Ветеран! Җиңүче! Горурлыгым! Икенчедән, әтинең дембель альбомы: гаярь фотолар, мактау кәгазьләре. Ниһаять, сугыш турында кинофильмнар. Һәммәсе йогынты ясагандыр. Җитмәсә, чечен кампаниясе барган вакыт: анда да бит, хәтерләсәгез, «бандитлар» «без»гә каршы яу чапты. Телевизор хакыйкатьне түкми-чәчми җиткереп торды: тегендә шартлау, монда янгын һәм – үлем, үлем... Оятсызлар! Бәйсезлек кирәк икән аларга! Боек («о» урынына «ө» басарга телим, басылмый, каһәр) дәүләтнең нигезен какшатмакчы, гайрәтен туздырмакчы булалар! Хәтта имля алышу да үт куыгына китереп суга аның, ә монда – танклар, боргалаклар, исәпсез-сансыз корал...

Нәрсә соң ул Ватан?

Шул сорауга җавап эзлим хәзер.

Минем өчен Ватан – әти-әни, сеңелләрем, сөйгәнем һәм иң якын туганнарым, мөгаен. Бетте! Ярар, күп дигәндә – республикам булсын. Ләкин аны бу исемлеккә гаять зур ташлама ясап кына кертергә мөмкин. Чөнки минем якларлык-сакларлык чын республикам юк.

Бетте!

Нишләп әле мин үземнең аман-имин кайтасымны төгәл белмәгән килеш милләтемне, халкымны буып, җай чыктымы – хач-тәресен күтәреп, өстемә килгән, әледән-әле шакшы кулын авызыма, телемә сузган ватан өчен (гафу итегез, хәзер менә баш «в» хәрефе басылмый башлады) бер ел гомеремне харап итәргә тиеш? Адәм рәтле стипендия түләсен идеме соң... Яшәргә куыш бирсен идеме... Алайса, ачлы-туклы җан асра, җитмәсә, шул җаныңны чыгарып салыр почмагың булмасын, иртә таңнан кичкә кадәр бил бөк, өстәвенә, ике көннең берендә газга-утка-суга бәяләр күтәрелеп торсын – алай да илең алдында нәмәгълүм мифик бурычың калсын икән. Һәм син аны, телисеңме-юкмы, кайтарырга тиешсең. Тарих күрсәткәнчә, еш кына баш бәрабәренә дә.

Минем бүгенге уйлар шул тирәдә бөтерелә.

Инде самими чагым кире кайтып, иншасында яктырткан мәсьәләләрне күтәреп килсә, алай гына да түгел – оялтырга, иманыма күндерергә теләсә, нишләрмен? Аклана башлармынмы? Әллә, киресенчә, булмаган ялкынлы хисләремне бар итеп күрсәтергә омтылырмынмы?

Бер әтәч конфет тоттырырмын да башыннан сыйпап:

– Үс әле, аннары сөйләшербез, – диярмен, мөгаен.

## Икенче кыйтга

*(Март, 2011)*

...Милиция кабыгын алыштырырга җыена. «Полиция» турындагы канун март башыннан гамәлдә. Хезмәткәрләргә яңа форма тегеләчәк, жетон тапшырылачак. Хәзер алар, кемне дә тоткарлаган очракта, бичараның гаебен һәм хокукларын аңлатып узарга тиеш булачак. Сафларны сирәкләндерү дә көтелә. Бусын, кем әйтмешли, бишкуллап хупларлык.

Кыскасы, тышча үзгәрә. Эчтәлеге нишләр?..

Әлегә мин белгән тәртип саклаучыларның төп эше гражданнар артыннан иснәнеп йөрү һәм: «Ярамаган урында пес итте», – дип, штраф чәпүдән артмый иде...

## Лулу

Редакция хатын-кызлары безне бәйрәм уңаеннан котлады.

Без, үз чиратыбызда, ул котлауларны кабул иттек.

Граммнарда.

Аннары мин өйгә кайтырга кузгалдым. Ләкин кайтып җитә алмадым. Ишек төбендә алар очрады. Икесе. Хөрмәткә лаек затлар: Газинур абый, Марат абый.

Безнең арада Ватанны саклаучылар көнен җитди нәрсәгә санаучы юк. Ләкин хөрмәткә лаек затлар белән табын уртаклашырга яратучы бар.

Ул кеше – өчебез дә.

Кыскасы, без әллә ничек кенә яңадан «Лулу»га барып чыктык.

«Лулу» – куркыныч урын. Анда тәбәнәк түшәм. Плитәсе чәрдәкләнеп купкан идән. Андагы диварларны таралып төшүдән кат-кат ябыштырылган обойлар гына саклап тора кебек. Анда караңгы, шомлы, шыксыз. Андагы эрегән сумала һәм май исе күңелне болгата. Анда урыс әчесенең иң арзанлысы сатыла. Аны йотып куюга күзләр чалшая, борыннан төтен чыга. Кабымлык урынына алган томат суына озаграк карап торсаң, ул күз алдында терелә һәм синең белән сөйләшә башлый. Анда өстәл артына урнашып, йомшак келәмгә аягыңны салып ләззәтләнергә өлгермисең, келәм могҗизалы рәвештә исерек бомжга әверелеп ыңгыраша. Дөрес, бер-бер артлы өч чәркәне сугып куйгач, һәрвакыттагыча, бу урынның да сөйкемле сөяге табыла. Күз язылып китә. Шау-шу эчендәге тынлыкны ишетергә өйрәнәсең. Сатучының күз төбендәге «фонаре» бүлмәгә сихри ямь өсти.

«Лулу» – Казанның һәммә нерв җепләре төенләнгән урын.

Барлык юллар «Лулу»га илтә.

Мин бу ышыкны җенем-җаным белән сөймим. Аңа да карамастан, иң авыр көннәр һәрдаим монда тәмамлана.

Хәер, аның истән чыгарырга ярамаган гүзәл бер сыйфаты бар. Нинди хәлгә

җитсәң дә, «Лулу» мәрхәмәтле, ышанычлы: моннан метроның «Кәҗә бистәсе» станциясенә шуып кына төшмәле.

Бераздан безнең утырыш шактый җитди төс алды:

– Нәрсә соң ул ватанпәрвәрлек? Коры гына әйткәндә, ватаныңа мәхәббәт булсын, ди. Ә ватанга мәхәббәт ничек туа?

Газинур абыйның бу сорауларына җавап бирү мәҗбүри түгел иде.

Бездән вакыт-вакыт: «Шулай», – дип хуплау гына таләп ителде.

– Әлбәттә, аның да сине яратуыннан, синең дә аңа кирәклегеңне тоеп торудан туа ул. Ватаныңның изге гамәлләреннән, үз халкына карата ихтирамыннан һәм игътибарыннан туа. Мәхәббәт бер яклы гына була алмый! Булган очракта да, җавапсыз хисләр берәр кайчан барыбер сүреләчәк. Иң яхшы дигәндә. Әмма ул хисләрнең нәфрәткә әверелүе дә бар...

Газинур абый уналтынчы гасырдан башлап әлегәчә алып барылган исәпсез-сансыз орыш-канкоеш өчен империянең иманын киерде. Сөйләгәндә, чырае кызарды, күзләре шарланды, авызы бөреште, күккә кизәнгән уң кулы, бизгәк тоткандай, әледән-әле тартылып куйгалады.

Ул үзе армия хезмәтендә булмаган, хәрби кафедрада ыштан туздырып котылган. Шуңа күрә аңа гаскәрне сүгү гаять җиңел һәм рәхәт, ә сугышчыларны «империя этләре» дип атау берни тормый иде.

Марат абый, «шулай» дип кушылуын санамаганда, аны шыпырт кына, карышмыйча тыңлады. Болай да сагышлы күзләре, чәркә арты чәркә күтәреп куюга карамастан, ныграк сагышлана төште. Күрәсең, Газинур абый әйткән сүзләрнең градусы катырак иде.

Марат абый – «шурави». Ике ел буе әфган җирен уттан уздырган кеше. Унсигез яшьлек егет килеш сугышның ач бугазына кергән ул. Сөяк булып тыгылган, ләкин йотылмаган. Тәмугтан алып кайтканы: янган бэтээрлар, КамАЗлар фонында төшкән өч-дүрт фото, биш-алты хикәя, бер повесть. Калдырганы: ике ел гомер. Хәер, алай түгел. Ике ел – искә алып, тел әрәм итәрлек вакытмыни? Соңыннан тормыш күрсәткәнчә, Марат абый якты киләчәген дә әфган ялкынында яндырып, көлен күккә очырган икән. Җөмләдән, ул кырык яшенә тәмам чаларган иде инде.

Мин, һичшиксез, Газинур абыйны хупладым.

Әмма, ничектер, Марат абый да кызганыч булды. Кыскасы, бик аңлаешсыз, таркау хисләр кичердем.

Бәхеткә, шулчак үрә катып, Газинур абый:

– Нах-хауз! – дип кычкырды.

Бу – таралышырга тәкъдим иде.

Метрога төшкәч, аны алыштырып куйдылармыни – шунда ук басылды, сабырланды, күз ачып йомганчы мулла песиенә әверелде. Арттан шапылдап ябылган ишек җиленнән чайкалмаска тырышып, туп-туры турникет аша чыгып та китте. Мин, кашларны җыерып, аңа иярдем. Юл йөрү картасын пассажирларны үткәрү аппаратының маңгаена чәпеп, һәйбәт кенә эчкә (дөресрәге, аска) уздым. Марат абый исә һич сәбәпсезгә артык озаклый тоелды. Артка борылып карасам, ни күрим: гаярь егетләр аны бөтенләй тоткарлап маташа иде.

«Лулу»да рәнҗү булып оешкан хисләрем кинәт ачу булып кайнап чыкты. Мин нигәдер Марат абый алдында үземне бик җаваплы, хәтта бурычлы итеп сиздем. Шуңа күрә төптән күтәрелгән тавыш белән:

– Җегетләр, – дип сөрән ташладым, – бәйрәм көнне карт әфганчыны ник

борчыйсыз инде? Сез чупылдый-чупылдый ими суырсын өчен заманында кан койган кеше ул! (Чынлыкта мин алай дип уйламый идем, билгеле.)

Полиция колагын тырпайтты. Берсе, күзлеклесе, аптыраганнан баш чүмечен кашып алды. Алар мондый оятсызлыкка әзер түгел иде кебек. Ләкин үзләре дә ярыйсы ук ушлы икән. Игътибарын тулаем миңа күчереп:

– Ник киртә аша сөйләшәсең? Бу якка чык, – диде икенчесе, каракучкыл чырайлысы.

Шунда мин кичермәслек хата эшләдем.

Исем китмичә, яңадан турникетның ары ягына уздым. Егетләр, хәерле юл теләп, Марат абыйны поездга озатты. Мине исә, кулларны артка каерып, станция эчендәге читлеккә ташладылар.

Кыз килеш зөфаф төненә кергән кәләш халәтендә калдым.

Зәңгәрсу тар куыш. Өстәл. Компьютер. Бер-ике папка. Үрелеп ясалган тимер рәшәткәнең ныклыгын тикшергән арада сизгер хуҗалар яңадан бүлмә уртасында үсеп чыкты.

– Бу ни бу? – дидем мин, карадан киенгән пар күгәрченнәргә багып.

– Тәртип бозасыз, – диде каракучкыл чырайлысы. Аның йөзендә иман, күзендә нур юк иде. Тегесе, сыңары, күзлеклесе, минем кебек үк үзенең кая килеп эләккәнен аңламый иде сыман.

– Ничек? – дидем мин, аптыравымны яшермичә.

– Хезмәт бурычын үтәгәндә, каршылык күрсәтәсез...

– Син что, с..., – дип ычкынды ялгыш.

– Һоу-у, – дип сузды каракучкыл чырайлысы.

– Документыңны күрсәт, – дидем мин, һөҗүмгә күчеп.

– Күрсәттем инде, – диде ул.

– Погонлы убырдыр син, бәлки?

Бу сүзләрдән каракучкыл чырайлысын тимгел басты. Тегесе, сыңары, күзлеклесе, куырылып куйды.

– Менә, – дигән сүзгә ияреп, борын төбемә катыргы сузылды.

Урыс имласының утыз хәрефе, цифрлар белән җитәкләшеп, күз алдымда татарча бии башлагач, мин үземнең ярыйсы ук салмыш булуыма төшендем. Шулай да, җил уйнатып юкка чыкканчы, катыргыдагы кайбер хәрефләрне чүпләп алырга һәм алардан саңгыраурак фамилия оештырырга өлгердем.

– Иптәш Ипатов, син татарча беләсеңме? – дидем, астыртын елмаеп.

– Юк, – диде Ипатов. Татарча.

Шулвакыт мин яңадан ялгыштым.

Астыртын елмаюымны бөтен чыраема җәя төшеп, тирән сулыш алдым да:

– Алайса-а... – дип бая гына Газинур абый кузгаткан теманы актарып чыгардым һәм, шуңа үзем аңлаган ачы хакыйкатьне дә кушып, боларның баш чүмечләренә кадак-кадак тезислар сугып кертә башладым. Шулкадәр күңелгә сеңеп калган икән: аерым бер ләззәт белән ике-өч тапкыр «империя этләре» дип ычкындырдым. Дөрес, хәзер бу сүзләр полиция хезмәткәрләренә карата әйтелде.

Мин бүртенә-бүртенә һава ярганда, Ипатов кымшанмады да. Ул ихлас күңелдән бирелеп, хәтта, тирән инануымча, сүзләремә тәмам ышанып, килешеп тыңлады. Аның үз-үзен тотышыннан разыйланып-эреп, төп фикер арасына ничектер: «Агайне, мин сине яратам», – дип тә кыстырдым бугай. Аннан аермалы тегесе, сыңары, күзлеклесе, икенче җөмләдән үк мәет төсенә керде.

Сәгать буе дәвам иткән штурмнан соң мин, рейхстагка әләм кадагач, эше беткән батырдай исәрләнеп, рухланып, бер тында аяктан яздым.

Ипатов бәбәкләрен акайтып, әле миңа, әле тегеңә, сыңарына, күзлеклесенә карап торды да сагышлы көрсенеп:

– Патруль чакыртырга кирәк, – диде.

Ике пүнәтәй каршында сумканың эчен чыгардылар: каләм, куен дәфтәре, «Идел»нең яңа саны, каралама язмалар бүселеп төште... Бер-берсен узып, барлык кәгазьләргә имза сырлаган шаһитләрнең Кафтау артыннан качып килүе күзгә бәрелеп тора иде. Яшь килендәй тел яшергәч, кайсының кем булуын үзем ачыкларга керештем. Аз гына чамалап бетермәгәнмен. Әзәри дигәнем – әрмән, төрек дигәнем – көрд булып чыкты. Алар миңа икесе дә рәнҗеп калды.

Патруль килгән арада Ипатов бертуктаусыз чүбек чәйнәде:

– Бәйрәм алды икәнен аңламыйбызмы? Кешенең атынып-чайпалып торганын күрмибезме? Ник күкрәк төяргә? Ник телеңә салынырга? Артыңны кысып кына йөр югыйсә... Шулаймы? – дип, фамилиямне атап сорагач кына, бу сүзләрнең тәгаен миңа юнәлтелгәнен аңладым. – Иртәгә үзеңә оят булачак бит.

Бераздан метро станциясе каршына чатан бака сыман аксый-туксый «УАЗ» килеп туктады. Полицейскийлар миңа дүртәү булып күренә башлады. Күземне кат-кат уып карагач кына, аларның, чыннан да, кинәт үрчеп китүенә инандым. Үзара чыш-пыш килешеп, макулатура алышканнан соң, яңалары мине машинага алып китте.

Арткы ишекне ачып керәм дигәндә, машинаның тоткасын ваттым.

– Сиңа кем анда тыгылырга кушты әле? – дип җикеренде йомры сержант. Ул маена чыдый алмыйча мыймылдап тора иде. Ачуланып, ристанын багажникка, алмаш тәгәрмәч өстенә томырганнан соң, мырлый-мырлый ватык ишеккә ябышты. Бер дөбердәтте, ике сукты, әмма тимерчыбык белән чорнап куюдан да юньлерәк әмәл тапмады.

Озакламый «УАЗ», чатан бака сыман аксый-туксый, яңадан кузгалды.

Багажникта кысан иде.

– Үзең кебек нечкә билле хулиганнарны ничек йөртәсең? Арба тагып киләсеңме? – дип, бүгенгә соңгы тапкыр теш шыгырдаттым.

Мин бу көннән гарык идем. Кинәт бөтен барлыгымны күңелсезлек, моңсулык басты. Айнуга китте, ахры, дип борчылдым.

Айныгач, мин танымаслык булып үзгәрүчән шул...

Җәһәннәм тишегендәге полиция бүлегенең тимер ишеге авыр ыңгырашып ябылды. Мин башта алып гәүдәле, киң җилкәле ир уртасы белән бергә-бер калдым. Иңендә – әфисәр погоннары. Көл сибелгән тыгыз, куе чәче артка каерып таралган. Уң кашын урталайга ярып, җөй яткан.

– Нәрсә булды?

Мин дөресен сөйләп бирдем.

Тыңлаган чагында ул миннән дә сагышлырак тоелды.

Аннары үзен җир йотты.

Документларым яшь һәм, чамалавымча, тәҗрибәсез егет белән кызга күчте. Алар, намуслы биографларым, елъязмачыларым сыман, һичбер хата-ялгыш җибәрмәскә тырышып, исем-фамилиямне, туган елымны, туган урынымны «дело» папкасына күчереп язды. Аерым пункт итеп нинди гамәлем аркасында тарихта каласымны теркәделәр. Бу шомлы, кургашындай авыр тынлыкны үзем бозарга булдым:

– Энекәш, чыгышың кайдан?

– Теләче, – диде, тартынып кына.

– Әйбәт яклар, – дип хупладым.

Көтмәгәндә, егетнең хезмәттәше телгә килде:

– Мин сезне таныдым, – диде ул, ярчыкланып, теткәләнеп-канап беткән җанымны ефәк тавышы белән сыйпап. – Телевизордан күргәнем бар.

Мин шунда гына бу кичәнең мәгънәсенә төшендем.

Тырышып караганда, гестапо киемен бермә-бер хәтерләткән җитди чүпрәк эчендә оялчан, сылу гәүдәле татар кызы барлыгын абайладым. Күкрәгенә кадәр көдрәләнеп аккан чем-кара чәчләре, карлыгач канатыдай сызылып киткән кашлары, таң нурының салкынча сафлыгын сеңдергән яңаклары... Ул бизәнмәгән иде диярлек. Аңа бизәнергә кирәк тә түгел иде. Чык тамчысы тисә дә, өзелеп төшәрлек чиядәй тулышкан иреннәре генә кып-кызылга буялган.

Шушы бердәнбер күрешүебездән соң күпме вакыт узды, күпме кадерсез гомеремне кичке шәфәкъ утына ташлап яндырдым. Әмма ул туташ тормышым юлында янә очрый калса, мин аны, һичшиксез, кайнар мәхәббәткә манылган иреннәреннән танып алыр идем.

Бу вакыйганы баштан кичерүгә үк мин Боттичелли картинасы белән чын Венера арасында бернинди уртаклык тапмый башладым.

Йә.

Мин бугазга бөялгән чарасызлык авазын кире йоттым һәм, сүземне хисси баетмыйча:

– Хәзер болай да күрдегез инде, – дидем. Аннары дәшми торгач: – Танышып бетәрбез, бәлки? Исемегез ничек соң? – дип өстәдем.

– Луиза.

– Луиза, – дип кабатладым мин. – Лулу...

Ул арада баягы әфисәр яңадан калыкты. Каршыма берничә кәгазь таратып салды:

– Без сине эш көне башланганчы ябып тотарга тиеш. Менә монда, менә монда имза сал да... – Юан бармаклар имза саласы төшне күрсәтер урынга аны каплап, өстенә басып тора иде. – Өеңә кайт, җитәр. Иртәгә штраф түләгәч, квитанцияңне кертеп чыгарсың.

Штраф – якынча ике ярты бәясе...

Тимер ишекләрнең авыр ыңгырашып ябылуын ишетергә әзерләнгәндә, чал әфисәрнең тавышы колак читемә орынды:

– Бүген метрода күренеп йөрмә!

Шәһәрнең чырае тагын да караңгылана төшкән иде. Төнге җил кочагында бераз сафланып алгач, автобуска кереп утырдым. Ул мине үзебезнең якка алып китте. Башта билгесез урамнардан уздык, соры йортлар неон утлардан тагын да ямьсезләнеп, авыру кешедәй саргаеп калгандай күренде.

Тын алырга тукталган автобустан Кәҗә бистәсендә чыктым мин. Һәм... туп-туры метрога юнәлдем. Таш баскычлар буйлап шакы-шокы атлаган адымнарга катлы-катлы булып кайтаваз кушылды. Ул тавышлар бер-берсен бүлдерергә, бер-берсен кабатларга тырышып, һаман саен катырак, куәтлерәк яңгырады. Гүя төнге станциягә мин япа-ялгызым түгел, ә дистәгә якын дус-ишем белән берьюлы төшеп бара идем.

Аста Ипатов күренмәде. Тегесе, сыңары, күзлеклесе исә мине тануга ук очкылык тота башлады. Аякларын гайре табигый рәвештә әле кушып, әле аерып баскангамы, ул миңа төбе төшкән кешене хәтерләтте.

– Ипатов кайда? – дидем, ачуланмаска тырышып.

– Җир өстен урый.

– Аның миңа бурычы калды. Тоткарланганчы, мин юл хакын түләгән идем инде. Нишлибез?

Ул муенына тагылган картасы белән калтырана-калтырана турникет аппаратының маңгаен сыпырды. Ялт итеп яшел ут янды. Тәкәбберлек тозы утырган карашымны полицейскийның күзеннән аермыйча, вәкарь генә эчкә уздым:

– Ипатовка ялкынлы кайнар сәлам. С.., дияргә кушты, диярсең.

Яңадан җир өстенә күтәрелгәч кенә, өшеп киткәнемне сиздем. Капюшонны баш очына шудырдым. Төймәләндем. Тирә-юнем коточкыч караңгылык иде. Кая карама – дивар-дивар булып баскан караңгылык. Яктылыкның әсәре дә, исе дә юк. Бу хәлдә ничек адашмый атларга соң? Ничек абынып башны ярмаска? Ничек яшәргә? Мин күкрәк турысын капшый-капшый, аннары төя-төя, җан авазын чыгарырга тырыштым. Бармы әле ул? Исәнме? Юлдан яздырмыйча кыйблама җиткерәчәкме?

Каяндыр төптән, тамырдан зәгыйфь кенә тавыш килде.

Мин аны ишеттем.

Аннары эчке кесәдән телефонны алып, соңгы җыелган номерлардан күз йөгерттем. Берсендә тукталып «чакыру» төймәсенә бастым:

– Нихәл, Марат абый?

Сүзләре карлыгып чыкты:

– Бер килеш. – Тавышы йокылы-уяулы иде. – Син исәнме?

– Исән.

– Самый главный.

– Тыныч йокы.

– Үһу.

Шундый сабыр, сәмави төндә, аның да шылт иткән аваздан челпәрәмә килерлек бәллүр, садә мизгелендә кем дә кем юк-бар сүз белән борчып, кешенең татлы халәтенә кизәнә инде? Үкенеп туймадым.

## Алтынчы кыйтга

*(Датасыз)*

...Әдәби әсәр тулы канлы булып бары тик бер телдә – оригиналда гына яши ала. Чын җәүһәрләр тәрҗемә ителми. Аңа беркадәр охшаш күчермә (копия) тудырырга мөмкин, билгеле. Әмма һичбер валчыгын, кәеф-халәт төсмерчеген җуймыйча, һәр җөмләнең эчке моңын, тынын саклап, җиген җиккә китерү – мөмкин түгел.

Димәк, һәр иҗат җимеше бары тик шул телне аңлаган халыклар йә аерым кешеләр өчен генә языла.

Юкмыни?

Ә Еникинең сыгылмалы, нәзакәтле җөмләләрен, әйтик, урысча ничек биреп була соң?

Ә Зөлфәт шигърияτен? Зөлфәтнең һәр строфасына мул рәвештә салынган моңны («моң» сүзе дә тәрҗемә ителмәгән килеш) ничек урысча бирәсең?

Ә Дәрдемәндне?

Иҗатындагы борынгы сүзләрне яңарак сыңарларына алыштырсаң да Дәрдемәнд фәкыйрьләнеп кала лабаса! Ничек шундый иҗатны авторның

образларына, чагыштыруларына бөтенләй чит, ят телгә күчерәсең? «Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан, биткәенең иң очында миң яраткан»ны чукынсаң да, нәкъ шундый килеш тәрҗемә итеп булмый, булмый!

Ә Бабичны?

Ә Тукайны?

«И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!»

Ишетәсезме?

Никадәр җылылык, якынлык, мәхәббәт, шул ук вакытта – борчылу да бар әлеге шигырь юлында! Юл башындагы «и» генә дә ни тора бит! Ошбу кечкенә, бәлки, күп вакытта игътибар да бирелми торган кисәкчә нинди бай, гаҗәеп тирән мәгънә белдерә.

Дөнья мәшәкатьләрен онытып, күзләрегезне йомыгыз да яңадан кабатлап карагыз әле: «И туган тел! И матур тел!..» Буыннарыгыз буйлап ләззәтле дулкын үтмимени? Рәхәт булып китмимени?!

Ә Туфан?

«И минем җандай кадерле, и җылы, тере телем!»

Шулай ук күзләрегезне йомып кабатлап карагыз. Әкрен генә, сулышка ияреп кенә. Биредәге өндәү дә – тойгы билгесе. Тукайдагы кебек. Әйтик, урысча ул кычкыру сыман яңгырар иде.

Ә Такташ?

Аны ике төрле тәрҗемә итәргә мөмкин. Беренче очракта – кып-кызыл шагыйрь килеп чыгачак. Икенче очракта – чын Такташка пародия.

Ә бүгенгеләр? Марсель Галиев? Ркаил Зәйдулла? Газинур Морат?

Әлбәттә, бу теория – чын әдәбият, чын әсәрләр һәм чын иҗатчыларга гына карый. Урта кул авторны рәхәтләнеп телдән-телгә күчерсәң була, һәм ул, бәлки, оригиналга караганда яхшырак та чыгар әле...

Кыскасы, милли әдәбият милли укучылар бар чакта гына яши, яшәячәк. Тискәре очракта Һади Такташ түгел, ә Северцевка, Мартыновка охшарга тырышып язган «какой-то» татар шагыйре, Муса Җәлил түгел, ә Моранга яисә Тарковскийга коточкыч ияреп язган «какой-то» татар шагыйре, Хәсән Туфан түгел, ә Штейнберг, Хаустова шигырьләрен хәтерләтеп язган «какой-то»... татар шагыйрьләре генә калачак.

## Җиденче кыйтга

*(Октябрь, 2011)*

...Мин тәрәзәдән вакыт агышын күзәтәм: көн артыннан көн, атна артыннан атна уза...

Сәгать уклары, тилереп, кызулана, кызулана...

Майя календаре ялгышып, дөнья бетми калса, озакламый олуг юбилей җитәчәк. Коллыгыбызның биш йөз еллыгы. Әйе, мескен адәм баласы өчен кырык ел гомер – бик күп вакыт. Ләкин тарих өчен – чүп кенә...

Безнең исә Универсиада дип шашкан көнебез. Бөтен дөньядан кунаклар көтәбез. Һәм уйламыйбыз да: аларны кабул итәргә әзербезме соң? Казанны татар башкаласы итеп күрсәтергә әзербезме? Татарлыгы бармы аның? Без, гомумән, матди һәм рухи көчебезне дөрес эшләргә түгәбезме?

Пайтәхетне, илне яклап шәһит киткән бабаларыбыз да истәлек билгесеннән мәхрүм бит! Башка сыймаслык! Ә мең сыналган хакыйкать бар: үзен хөрмәт итмәгән милләтне башка беркем дә хөрмәт итмәячәк.

Нигә шундый хәлгә тарыдык соң әле?

Ничек мәмләкәтләр тоткан бөек милләттән бүгенге хурлыкка калдык?

Мин бу сорауларга җавап таба алмый изаланам. Җитмәсә, соңгы арада әллә ниләр белән саташа башладым: күз алдымда Болгар терелә, Алтын Урданы, Казан алынуын искә төшерәм, аннан соңгы көрәшләрне... Ахырдан: «Ярый әле саташу гына», – дип юанам. Юкса, Батыршалар якалап: «Сез ничек анда?» – дип сораса? Башны иеп: «Гафу итегез», – диярсеңме?..

Илләр тоткан, яулар чапкан асыл татар халкы исәнме соң әле ул?

Күптән мәрхүм түгелме?

Без – шул бөек милләтнең күләгәсе генә ләбаса.

Болай барса, илле икенче елны да, исән-имин һәм тук килеш, ләкин татарваның урыска үз иреге белән кушылу көне буларак каршыларбыз. Урысча тостлар күтәрелер. Әйбәт бара бит: меңьеллык, туплы хоккей буенча дөнья чемпионаты, су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты... Хәзер Универсиада менә.

Шулай итеп, илле икенче елга да җитәрбез, Аллаһ боерса.

Ә боермаса... җитмәбез дә.

## Сигезенче кыйтга

*(Ноябрь, 2011)*

...Быелгы көзнең искитмәле матур чагында авылга кайттым мин. Отпускага. Беренче вакыт ияләнә алмый йөрдем: һичкем ашыкмый, автобуслар узышмый, машиналар чинашмый. Урам буш. Тыныч. Маңгаена «Вамин» тамгасы сугылган тракторлар гына әллә нигә бер капка төбеннән узып китә. Монда көннәр шундый озы-ын! Монда тормыш конвейерга салынмаган әле.

Мин сеңелкәш йогынтысында гөмбә җыярга ушландым. Алар да кешеләргә охшаган икән. Менә, кәпрәеп тора бәгъзесе, үзе юан, майлы. Әмма орынасың – эче тулы корт. Яисә киресенчә: үзгәсе кәкрәйгән, боеккан була; юан, майлы күршесе янында мескенләнеп башын игән; өстенә, тыйнакланып, чирәм япкан. Әмма орынасың – үзәге чип-чиста.

Әйтеп бетергесез ләззәт: акрын гына (юкса, таба алмаячаксың), аяк астына карап кына (таптап китүең бар), артыңа борыла-борыла (качып калмаганнармы?), сабырлык белән һәр чыршы төбен капшап алга атлыйсың...

Менә бер гөмбә, менә ике, менә янчыгың тулды да...

Бәй, тормышның бөтен асылы шунда түгелме?

Уйлап карасаң, тормышта да, дөнья куучы булудан бигрәк... гөмбә җыючы булырга кирәк икән ләбаса! Тормыш чытырманыннан узганда да, ашыкмыйча гына, артыңа, үткән көннәреңә борыла-борыла атларга кирәк икән! Һәммәсен дә дөрес эшләдеңме, үкенмәячәксеңме аннары? Борыныңны күккә чөймичә, аяк астына карап йөрергә кирәк икән: берәр яхшылыкны (кешене, вакыйганы, сүзне) таптап узмадыңмы?

Күк дигәннән...

Авылда күк беркайчан да кап-кара булмый. Иң караңгы чагы да – куе зәңгәр аның. Һәм шул зәңгәрлек тулы җем-җем йолдызлар! Шәһәрдә йолдызлар юк бит! Ялгыш берәрсен күреп алыр өчен дә күкнең нинди сәмави мизгеленә тарырга кирәктер? Алар шәһәр сулап чыгарган сөремдә тончыга. Димәк, шәһәр мәңге йолдызларсыз яшәргә хөкем ителгән!

Авылны бетерү белән без инде күпме чәйнәлгән милли рухны, телне, гореф-

гадәтләрне генә түгел, йолдызларны да югалтачакбыз икән. Хәер, нәрсәгә кирәк алар, диярсез? Хактан да: хәзер күптән күккә карап сокланмыйлар, мәхәббәт аңлатмыйлар, хыялланмыйлар. Бәлки, берәрсе атылганга куанып, ашык-пошык теләк телиләрдер дә... мал-милек соранудан артамы икән ул?..

## Тугызынчы кыйтга

*(Датасыз)*

...Герберт Уэлсның «Вакыт машинасы» әсәрендә төп герой ерак киләчәктә Җирдәге тормышның бетүенә шаһит була. Тирә-юнь чүл һәм кечкенә бер кулләвектә соңгы җан иясе (краб, дип хәтерлим) кымшана. Соңгы җан иясе! Ул үлсә (ә ул, һичшиксез, үләчәк!) – бетте, тәмам. Инкыйраз. Күз алдына китерү дә куркыныч.

Шул ук вакытта, мондый күрәчәкнең үсентеләрен мин бүген тәрәзәдән күзәтәм: подъезд төпләрендә, балалар мәйданчыгында биле ачык, бер кат челтәрле колготкидан, яланбаш үсмер кызлар тәмләп төтен суыра, сыра эчә... Кешелек дөньясының пыскып сүнгән тәмәкедәй юкка чыга баруы: бу кызлар нәселен дәвам итә алган очракта сау-сәламәт бала табармы?

Аллаһ Тәгалә хатын-кызны яратканда, шулкадәр киң күңелле булган. Ул аны нәфис, чибәр, камил гәүдәле итү белән генә чикләнмәгән; кимсенмичә, кызганмыйча, аңа үз көченең бер өлешен (димәк ки, үзенең дә бер өлешен!) – тормыш тудыра алу сәләтен биргән.

Хатын-кыз – Аллаһның дәвамчысы.

Хатын-кыз «Тормыш мәгънәсе нидә?» дип уйланырга тиеш түгел. Аның өчен ул мәгънә – кайчандыр, бик борынгы заманда яралган Дөньяны саклауда, үстерүдә, яңартуда чөнки.

Хатын-кызның тормыш мәгънәсе – Ана булуда!

Шагыйрь дә шулайрак язып калдырган бит.

Интуитив рәвештә моны кешелек дөньясы аңлый да: ул гомер-бакый Җир-Анага табынган, Табигать-Анадан хәтәр-хәвефсез көннәр сораган, Ватан-Ананы яклап кылыч күтәргән...

Буталды дөнья. Асты-өскә килде җиһанның. Аллаһ Тәгалә Ир-ат белән Хатын-кызны бар иткәч, икесе ике котып, ике башлангыч булсын, дигән. Бүген, Җир шарының да Төньяк һәм Көньяк котыплары калтыраган чорда, Кешелекне тотып торган Ир-ат белән Хатын-кыз котыплары да күчәреннән кузгалды, үзара сыйфатын алмашырга кереште.

Хәер, киресенчә, Хатын-кыз белән Ир-ат котыплары кузгалганга, бүген Җир шарының котыплары шулай калтырыйдыр ул: тетрәүләр, цунами, су басулар, янгыннар, глобаль җылылык...

Хатын-кыз тәүге кат чалбар кигән, тәүге кат сүгенгән, тәүге кат чәчен кыркыган көннән башлангандыр бу тәшвиш.

Хатын-кызның ирдәүкәгә әверелүе гомосексуализмга этәргеч биргәндер. Табигый бушлыкны ничек тә тутырырга кирәк булганга, хатын-кыз характерлы ир-атлар үрчергә тотынгандыр...

Аллаһ дәвамчысының үз кадерен белмичә, үз миссиясенең зурлыгын аңламыйча түбән тәгәрәве, урам чатына чыгып басуы – аяныч. Иң зур сер булырга тиешле могҗиза белән шуның өчен бүләкләнгәнмени син?

Аллаһ дәвамчысының товарга әйләнүе – һәлакәт.

Хатын-кыз – изге, бөек, якты, кояш кебек кешелек дөньясын балкытучы һәм җылытучы зат ул! Һич югы – шулай булырга тиеш!

Хатын-кыз – тормыш чыганагы.

Хатын-кыз – яшәешнең нигезе.

Нигез какшады икән – көт тә тор, күпме еллар буе төзелгән, мәгълүм, мәгърур булган, күпме еллар буе зилзиләләрдә селкенмичә нык торган цивилизация гөрселдәп ишеләчәк... һәм... тузаны да калмаячак.

## Тинтәк

Илнурның буш фәлсәфәсе башка капты. Кулындагы китабын йолкып, чыраена сылыйсы килде хәтта. Бөтен тулай торакны яңгыратырлык итеп! Элгәре матур гына әйтеп карадык. Аннары шул ук фикерне тупас, әмма тыгыз, тирән мәгънәле сүзләр аша җиткердек. Барыбер файдасы тимәде.

Нәтиҗәдә авыр язмышыбызга күндек кенә.

– Ир-ат – аучы, сунарчы, – дип тезде ул үз чиратында. – Җиңүче холкы аңа табигатьтән салынган. Ир-ат корбан яуларга тиеш! Корбанны үзенеке итәргә тиеш! Такташ исә Гөлчирәне...

– Кайсын? – дип кысылдым мин, күлмәкне төймәли-төймәли.

– Беренчесен, – диде Илнур. Канәгатьсез рәвештә тынып торды. Һәм дәвам итте: – Такташ исә Гөлчирәне буйсындыра алмаган!

– Алай ук түгел инде, – дип килешмәде Рәзил, мут елмаеп.

– Тинтәк, – дип ычкындырды Илнур. – Шигырьләрдәге Такташ белән хатлардагы Такташ – икесе ике кеше. Ул дөнья алдында күкрәк төеп яңа чорга дан җырлый, алга, яктылыкка барабыз, дип ышана һәм ышандыра. Куәт иясе! Бунтарь! Ә ак кәгазь алдында үзе генә калгач... елый... Ачыргаланып, ачуланып, хәтта кимсенеп елый!

– Бәлки, хатынын бик нык сөйгәндер? Шул гына?

– Сөйгәндер анысы. Без гомер буе кемнәрне генә сөймибез! Гөлчирәне дә...

– Кайсын? – дип ачыклык кертергә теләдем мин, кәчтүмне җилкәгә шудырып.

– Бу юлы икенчесен, – диде. – Ләкин аңарга ул җаннарны өтәрлек кайнар хатлар багышламаган. Экспрессия юк! Нерв юк! Фәкать дежур сүзләр: яратам, сагынам. Чөнки монда Такташ – җиңүче. Иманым камил, үлем түшәгендә дә Гөлчирәсен...

Ул яшен тизлегендә миңа борылды. Өн чыгармыйча чалбар каптыруымны күргәч, сабыр гына фикерен тәмамлады:

– ...Беренче Гөлчирәсен сагынып, җиңелү ачысыннан әрнеп, дөньядан саташулы хатирәләр кочагында узгандыр.

– Нишләтәсең инде, – дип көрсендем, каеш тагышлый. – Үзгә очракта без эчкерсез хатлардан һәм «Алсу»лардан мәхрүм калыр идек.

– Әлбәттә, – диде, килешеп, Илнур.

Әмма:

– Уралның галстугын бәйлә, – диде, килешмичә, Рәзил.

– Нигә тагы?

– Безнең хакта акыллы кешеләр сиңа карап фикер йөртәчәк. Адәм хурлыгына каласыбыз юк. Кроссовкаңны сал.

– Нигә тагы? – дип, ихлас аптырадым. – Уралның галстугына төстәш бит ул.

– Тинтәк, – дип кабатлады Илнур, бу юлы миңа карап.

– Мә, ботинка ки.

Өстемдә – Илнурның семестр буе сохари кимереп алган кәчтүм-чалбары.

Рәзилнең күн ботинкасы. Уралның галстугы, күлмәге. Кәттә демисезон пәлтәнең каян килгәнен, гомумән, аңламыйча калдым. Ә менә трусик белән оек үземнеке иде.

Рәзил кызлардан ялтыравыклы журнал табып китерде. Аның кайбер сәхифәләренә кыйммәтле хушбуй исе сеңдерелгән. Журналны муеныма ышкыдым.

– Бу көнне календарьга тамгалап куярга кирәк, – диде Илнур, ямьсез көлеп. – Кешене беренче тапкыр махмыр урынына иман сукты.

– Әле күрерсең, җиңеп тә кайтачак, – диде тегесе.

– Юарбыз, – дип шаулаштылар.

– Ул вакытка сезне туфан басып китәчәк, Аллаһ боерса.

Мин, чыннан да, Мәрҗани мәчетенә юл тоттым.

Анда бүген «Таян Аллага» әдәби конкурсына йомгак ясала иде.

Бу ярышта катнашырга һич теләгем булмады. Илнур әйткәндәй, үземне яхшы беләм бит инде. Хәер, беребез дә күктән төшмәгән. Барыбыз бер иш. Шуңа күрә килешеп яшибез дә.

Вакыт күп. Акча аз. Күп кергән чакта да тиз бетә.

Илнур берсендә автомәктәптә укырга ниятләде. Туган ягыннан аңа шактый зур сумма җибәрделәр. Укуының яртысын түләп куярга. Ләкин көтмәгәндә, уку хакы күтәрелде. Авылдан башка акча килмәде. Үзеннән өстәрлеге юк та юк иде инде. Нәтиҗәдә без берәр атна бик рәхәт яшәп алдык.

Рәзилнең бер кызган килеш әйткән сүзләре әле дә колагымда:

– Миңа әни ашау-эчүгә акча кызганмаска куша!

Без эчүгә беркайчан да акча кызганмадык. Ашау дигәнебез, гадәттә, кабымлыкка кайтып кала иде.

Бер елны мин ноутбуклы булдым. Атна саен үзебезнең катта кино күрсәтермен дип, факультеттан проектор сорап алдым. Бирделәр. Башта барысы да сөйләшенгәнчә барды. Кинозал вазифасын кухня үтәде. Чәй кайнаган, аш ташыган вакытта, билгеле, фильмдагы тавыш эффектлары бермә-бер баеп китә иде. Кызларның бәрәңге әрчи-әрчи, Хатиконы кызганып елаулары һаман күз алдымда.

Аннары кинозал үзеннән-үзе безнең бүлмәгә күчте. Бер генә кичкә дигән шарт белән диварга Уралның ап-ак җәймәсе эленде. Һәм бүтән беркайчан да салынмады. Читкә чыгып йөрү сирәгәйде. Хәзер мәдәни программа үз кулыбызда иде. Бүлмәдә кинәт буш шешәләр артты.

Без Кустурицаны тулаем өйрәнеп чыктык. Тарковскийны да.

Рәзил, фон Триерның «Антихрист»ын карагач:

– Мин бүтән эчмим, – диде. – Гомеремдә дә!

Күрәсең, аңарчы барыбызның да күңеле йомшарып өлгергән: ничектер, бертавыштан иптәшебезгә теләктәшлек белдердек.

Ләкин шомлы хәбәр, төнге Казанга таралып, «Субконтинент» кибетенең котын очырган иде. (Ул тулай торакның каршысында гына.) Һәм икенче көнне үк анда акция игълан ителде: дүрт шешә сыра алучыга бишенчесе – бушка...

Шулай итеп, тәртәгә керми калдык. Киресенчә, җитми башлады.

Ә төнгә тулай торак ишекләрен бикләп куялар...

Безнең бүлмә икенче катта. Җайлаштык тагы: җәймәләрне тоташтырып, тәрәзәдән генә аска төшәбез. Аласын алабыз. Аннары берәрсе тартып менгезә.

Артык илһамланып киткән бер кичтә Илнур, партия кушуы буенча шулай кибеткә чыгышлый, җырлап җибәрде:

– Земля в иллюминаторе видна!..

Хәер, шактый читкә салуланды бугай.

Сүзем әдәби ярыш турында иде бит.

Минем, чынлап, катнашырга һич теләгем юк иде.

Барысы да Шигърият бәйрәмендә башланды.

Тукай эргәсендә чыгыш ясаганнан соң, алкышлар тынуын да көтмичә, сәхнәдән төштем. Халык арасына кереп югалмакчы идем. Мине озын чабулы плащ кигән, баш өстенә татар кәләпүше батырган, сакаллы, бик пөхтә кеше туктатты. Борынгыча исәнләште. Үзен Вәлиулла хәзрәт дип таныштырды. Ул татарча беркадәр үзгәрәк сөйләшә иде.

– Вәгаләйкемәссәлам, – дидем мин.

Башта шигырьләремне мактады. Соңыннан Диния нәзарәтенең әдәби конкурс игълан итүен әйтте. Катнашырга кыстады. Әлбәттә, бу тәкъдимне җитдигә алмадым. Мин кайда да дин кайда? Без, кылый күзләр кебек, икебез ике якка карап торабыз.

– Бәлки, – дидем. Һәм ни әйткәнемне шунда ук оныттым.

Көзлектә үзе шалтыратты ул. Җәй көне тәүге җыентыгым чыккан иде. Бик начар җыентык. Исеме генә яхшы. Шуның турында сорашты:

– Бармы әле?

Нәшрият миңа гонорарның яртысын китаплата түләгән иде. Бер өлешен авыл кибетенә кайтарып куйдым. Бер өлешен очрашуларда төрттем. Таныш-белешләргә тараттым. Дошманнардан урлаттым. Болардан соң да карават астында шактый тираж калган иде әле.

– Әлбәттә, бар, – дидем.

Гәрчә төбенә тоз салып карасаң, булмаска да мөмкин иде.

Әйтик, октябрьдә генә Илнур егерме бер яшен тутырды. Ләкин бәйрәм хәстәрен алдан ук күрә башлады: атна уртасы җитүгә берничә тартма сыра юнәтеп, нәкъ минем сыман, карават астына тыгып куйды. Менә ул тираж тиз бетте, мәсәлән. Туган көнне көтмәде дә. Нәтиҗәдә ике тапкыр сыйландык.

– Безгә сатмыйсыңмы соң?

– Ничәне?

Хәзрәт бик күп сорады.

– Ничәдән?

Хәзрәт бик күп тәкъдим итте.

– Кибет куйган бәясе арзанрак ич аның, – дидем, каушап.

– Булсын, – диде хәзрәт.

Мин дөньяны болай да аңлап бетерми идем, шушы мизгелдән бөтенләй аңлаудан өметемне җуйдым.

Рәзил яраткан киноларда кырку герой төргәк-төргәк доллар ташлаган кебек, юл сумкасын китап белән тутырдым. Аннары нәзарәткә киттем. Лобачевский урамы тулай торакка якын булса да, юлда җиде тапкыр туктап ял иттем. Хәзрәт ишек катында каршылады. Без аның бүлмәсенә күтәрелдек – ул китап-кәгазь белән шыплап тулган иде. Алыш-бирешне өзгәннән соң, һич уйламаганда:

– Барыбер шигырьләреңне җибәрмәдең, әйеме? – дип сорады.

Мин дөресен әйттем:

– Калебем конкурс нигезләмәсенә туры килми.

– Синдә Аллаһ бардыр бит?

Кинәт мине диварлар кыса башлады. Учым тирләп чыкты. Үземне этлектә эләккән шпанадай хис иттем.

Нинди җавап кирәк иде аңа?

Нәрсә көтә иде?

– Шигырьләреңдә син гел Аның белән сөйләшәсең...

– Аның исеме кергәннәре дә, асылда, кеше хакын хаклап язылган.

– Ул үзе дә һәрдаим кеше хакын хаклый.

– Без нигә бу турыда сөйләшәбез соң? Сезгә бик иманлы әсәрләр килгәндер. Мәдехләр. Зикерләр. Дөрес яшәү инструкциясе...

– Син, шулай да, шигырьләреңне җибәр әле.

– Нигә соң?

– Катнашучылар исемлеген баетыр өчен. Конкурска абруй өстәр.

Без шулай хушлаштык.

Китап саткан акчага мин тәүге мәртәбә сенсорлы телефон алдым. Үзем белеп түгел инде. Миңа кешенеке шикеллесе дә ярар иде. Ләкин салонда Илнур фикеремне тиз үзгәртте. Артык кыстамады да югыйсә:

– Тинтәк, – дип кенә әйтте.

Сөенечтән шул кичне үк конкурска шигырьләр юлладым.

Ләкин...

Юдыра алмадым мин ул телефонны. Күңелем тартмады нигәдер.

Моны Илнур белән Рәзил бик авыр кичерде.

Өч көн сөйләшмәделәр.

Мәчеткә барып җиткәч тә, эчкә узарга базмыйча, ишегалдында таптандым. Бу юлы да Вәлиулла хәзрәт чыгып алды. Үзе шунда ук эзен суытты.

Бер залда байларча табын корылган иде. Урнаштым. Кайнар аш чыгардылар, тавык ите, пылау... Ач студентның шулпа иснәсә дә, кәефе яхшыра. Ә монда – җәннәт, диярсең: җиләк-җимеш, тәм-том, җитмәсә. Түр почмакта мөнәҗәтләр җырлана, шигырьләр укыла.

– Нинди ямьле кич, – дип уйладым. – Болай да утыру мөмкин икән...

Әмма шулвакыт, иң якын җене кинәт Иблискә әверелеп куйган кебек, сәламәт кешенең һичкайчан башына килә дә, сыя да алмаслык куркыныч, тетрәндергеч хәл булды: миңа Гран-при бирделәр.

Тантанадан соң исәнгерәп урамга чыктым.

Кул ярыннан театр ягына атладым.

Салкынайткан иде. Йолдызлар чекрәеп тора. Көзге җил, назга туенмас җилбәзәк кыздай, изүне чишеп, куенга кермәкче була. Шаяргандай итеп, колакны тешли. Ә күкрәк эчендә – песиләр тырмалана.

Мин Вәлиулла хәзрәтне җыйдым.

– Котлыйм, – диде ул яңа телефоным аша.

Сүзне нидән башларга белмәдем:

– Конвертка бик күп салгансыз, дип шалтырату иде.

– Кая күп булсын инде.

– Нигә мин соң?..

Ахыргы җөмлә тел очында эленеп калды, әйтелмәде. Аннары, сәер хискә әйләнеп, йөрәккә төшеп утырды. Шулай яшәдем. Көннәрдән бер көнне Вәлиулла хәзрәтнең интервьюсына юлыкканчы. Газета аның сүзләрен акка кара белән күчергән иде: «Безнең өчен бу конкурста төп критерий – ихласлык булды»...

Театр мәйданы буш иде. Берән-сәрән ялгыз-ябагадан кала һичкем юк.

Берзаман каршымда хур кызы калыкты. Дөресрәге, ай сукмагы буйлап ашыкмыйча гына җиргә төште. Әллә күземә ялгыш күрендеме? Ул миңа

шулкадәр таныш тоелды. Каян beləm соң үзен? Иңемә терәлеп узганда, сүз катып өлгердем:

– Без Фатих Әмирханның берәр хикәясендә очрашмадыкмы?

– Юк, – диде гүзәл зат. – Мин Әмирхан Еникидән.

– Гел бутыйм шуларны.

Кыз туктап калды. Борылды. Йөзендә ай нурлары балкый иде...

Безнең карашлар очрашты. Сабырсызланып, ялкын дөрләвен көттем. Һай, тәкәбберлегем! Иблис көнләшерлек. Әмма каршымдагы күзләрдә капыл ут сүнде. Шуннан соң...

Шуннан соң ирене читеннән минем исем төшеп китте.

Әллә колагыма ялгыш ишетелдеме?

Аптыравымны яшермичә, текәлебрәк бактым.

Һәм, ниһаять, таныдым аны.

Мин бик матур якларда туып үстем.

Безнең авылның бер ягын зур су юып уза.

Бер ягы – урман. Бер ягы – тау.

Урман – чик. Аннан Мамадыш районы башлана.

Тау да чик. Аннан – Киров өлкәсе.

Без шактый аулакта яшибез. Безне район эчендә дә белеп бетермиләр.

Бездә беренче канал гына күрсәтә. Татарстан радиосы гына сөйли. Почта даталарда бутала. Күрше Нәби абый, мәсәлән, яңа 2000 ел иртәсендә котлау открыткасы алды. Анда Казан Универсиадасы сурәтләнгән иде.

Кукмара юллаган автобусның тау башыннан кире борылып китмәве дә – безнең өчен бик зур вакыйга...

Яңа гасырның тәүге җәендә авылга яшь гаилә кайтып төште. Сапура апаның улы, килене, оныгы. Без аларның барлыгын ишетеп белә идек. Сирәк-мирәк күзгә чалынганнары да булды. Бу юлы озагракка тәвәккәлләгәннәр. Гелгә үк. Идрис абый машина-трактор паркына эшкә керде. Зилбәр апа бухгалтериягә урнашты. Кызлары Лия әбисе белән өйдә калды. Әйе, Лия шул. Танышкан чакта, аңышмыйча:

– Нишләп сиңа исемне яртылаш кына кушканнар? – дигән идем.

Алар түбән очта торды. Без тагын да түбән очтарак. Җәй буе бергә җил кудык. Бик тере иде ул. Малайлар кебек. Кыргый иде. Итәктән килеш агач башына үрмәләвен мин, әйтик, сокланмыйча күзәтә алмадым...

Көзен ул безнең сыйныфка укырга керде. Алтынчыга. Икебезне бер парта артына утырттылар. Гарьләндем, билгеле: кыз-кыркын белән утыргыч бүлеш инде! Укытучы һәммә дус-ишемне шул рәвешле мыскыллап чыккач кына тынычландым.

Башта барысы да ипле барды. Иртән күрешәбез. Көне буе аңа түзәм. Дәрес беткәч таралышабыз. Әмма отыры мәктәпкә шомлы сүзләр үтте:

– Ул физкультурада да Лия янына баса...

– Ул тәнәфестә дә Лиядән калмый...

– Ул, сиңа исем кушканда, мулла тотлыккан, дип, Лияне үчекли...

Мин үземдә һичнинди үзгәреш сизмәдем.

Бары тик шигырьләр яза башладым.

Элгәре алар якты, чиста иде:

Син минем йөрәк ягында –
Бер карыш ара.

Сөйләр сүзләрем күп сиңа!
Тик – дәрес бара.
Тактада – формула, Ньютон.
Китап киштәсе.
Һәм син тырышып-тырышып
Мисал чишәсең.
Ә минем күзләрем – синдә,
Һәм синдә күңел.
Тик мин сиңа классташ кына –
Артыгы түгел.

Тора-бара шигъри юллар арасына куерак төсләр тамды. Лирик герой аңлаешсыз халәт кичерүгә күчте. Янәшәсендәге гүзәл затны сагынудан нишләргә белмәде. Лирик герой аңа авыр караш ташларга да курка иде. Шул ук вакытта тәнәфес саен толымыннан тартты. Ачуланса да, рәхәт булып китә иде...

Ул тереләй утка керде. Ул ут йотты.

Дәреслек тышлыгында сыйныф саннары үзгәрде.

Ул һаман ут йотты.

Һәм, ниһаять, кичергән хисләренең соң чигенә барып җитте:

Без туган көннән алып ук
Китәбез бу дөньядан...
Бәхил бул, яр! –
Мин бүгеннән
Мәңгелеккә югалам.
Күз яшемдә кояш эри,
Ни әйтим шуңа өстәп? –
Каркылдап шәмәхә таңда
Каргалар мине көтә.

Ул көненә өчешәр тапкыр шулай бәхилләшә иде.

Шигырь саен.

Бераздан математика кабинетында сәер мисаллар барлыкка килде: минем исем + Лия = йөрәк. Бу, тәгаен, дәрес программасы буенча түгел иде. Язулар тиз арада башка бүлмәләрдәге парталарга да күчте.

Дус-ишем, мине юатып, йодрыгын уды:

– Табабыз ул этне!..

Без бик үҗәтләнеп, бу үртәгеч гамәлнең иясен эзләргә керештек. Кайбер сыйныфларга дәрес вакытында килеп кердек. Тәнәфестә шикле укучыларны күзәттек. Берничәсе белән ишегалдында егетләрчә сөйләштек тә. Ләкин тырышлыгыбыз барыбер нәтиҗә бирмәде. Дус-иш, сөмсере коелып, ахырдан:

– Булмады, – дип яман сулады.

– Рәхмәт, – дидем кәефсез генә.

Алар, бик тырышса да, ул кешене исәпләп чыгара алмас иде.

Чөнки ул кеше... мин үзем идем.

Озакламый Лиягә унөч яшь тулды. Форсаттан файдаланып, җанымны ачарга җыендым. Каян акча тапканмындыр – шоколад юнәттем. Йөрәк сурәте ябыштырдым. Үзегенә имзамны сырладым. Аңламаслыкмыни? Бүләгемне тәнәфестә Лиянең сумкасына тыгып куйдым. Үзем спортзалга йөгердем.

Мин ул вакытта хатын-кызга карата политтехнологияләр куллану серен белми идем әле. Мин бары тик яраттым гына. Бик каты яраттым. Ихластан. Шул җитә кебек иде.

Кызык бит: нәрсә генә өмет иттем икән?

– Әйдә, өйләнешик! – дигән сүз көтмәдем бит инде.

Белмим. Бер елмаю, бәлки? Рәхмәт сүзе? Иң татлы төшләремдәгечә, битемнән үбүен? Белмим. Минем хыяллар шунда төкәнә иде.

– Моннан соң якын киләсе булма! – дип ысылдады Лия, спортзалдан каршы алышлый. Шоколадны идәнгә атып бәрде. Шоколад шырт итте. Умырткамны сугып сындырдылар гүя. Бу тамашаны күреп өлгергән сыйныфташлар авыз ерды. Башкаларының авызы соңрак, күңелле хәбәр телдән-телгә таралып, мәзәк рәвешенә кергәч ерылачак иде.

Мин бүләгемне җыеп алырга иелдем.

...Яңадан турайсам, каршымда кечке Казан, Кабан күле, театр мәйданы һәм ай нурларын тулаем үзенә күчергән Лия басып тора иде...

Без кочаклашып күрештек. Аһ-ваһ килештек. Көлештек.

Җай табуга ул мине баштанаяк өйрәнеп чыкты.

– Юка киенгәнсең, – дидем, үз чиратымда.

– Болай матур бит, – диде. – Матур бит?

– Сиңа бүрек белән унта да килешер иде.

Аның ирене кысылды – иннегә сыгылып чыкты.

– Матурлыгыңны бернинди чүпрәк тә бозарлык түгел, диюем.

– Син тыйнаграк булып истә калгансың...

Казан төнгә кереп маташа иде. Караңгылык, авыр капкач сыман, шәһәр өстенә төшкән. Алай да якты әле. Монда һәрвакыт якты. Урамның ике ягына тезелгән баганалар муен бөгеп, таңга кадәр күз нуры түгә. Кәефләнеп алган мең тавыш, сыеныр куыш тапмыйча, диварларга бәрелә, йорт саен ишек шакый, тәрәзә кага. Йә машиналар үкерүен, йә күтәренке музыка, йә яшь-җилкенчәкнең кычкырып көлүен хәтерләтә...

Казанның бишек җыры да мажорда башкарыла шул.

Кинәт кесәм тулы акча искә төште.

– Син ашыгасыңмы? – дип сорадым.

– Сәгать ничә соң?

Вакытны карар өчен телефонга үрелдем.

– Тугызынчы ярты.

Ул минем телефонны исем-фамилиясенә кадәр атап бирде.

– Шәп, – диде аннары, соклануын яшермичә. – Ашыкмыйм.

– Әйдә, җылынып чыгабыз?

– Кайда?

– Монда чат саен ресторан лабаса.

Үземнең, әлбәттә, әлегәчә андый җиргә аяк басканым юк иде. Кая ул?! Нинди ресторан?! Дөге боткасын ай буе кайнар суда бутап ашыйбыз. Аш итәбез, янәсе. Дөгесе беткәч, тәлинкәгә коры су гына салына. Ягъни, кысыр шулпага калабыз.

Хәзер миңа консерваториядә укып йөргән бер дустымның сөйләгәннәре ярдәм иде. Ул сөйгәненә бүләк ясар өчен ГУМ бетереп уенчык куян эзләгән. Тырышкан – табар: тапкан. Шул шатлыктан тамак ныгытырга уйлаган. Сәүдә үзәгенең соңгы катына менгән. Тегендә – хозурлык, ди! Күз камаша, ди! Чыдарлык түгел! Менюдагы бәяләрне күргәч кенә, күз аллары, ниһаять, караңгыланып киткән. Нашатырь иснәтеп айныткannар. Аннары табан ялтыратырга кыенсынган инде. Нәтиҗәдә, бер айлык стипендиясенә ике салат яфрагы ашап чыккан.

Һәрхәлдә, үзе шулай сөйләде.

Хәзер минем өчен гаять кулай урын иде бу.

Тукай паркын кичкәндә, Фәрит абый белән очраштык.

– Что-то театрда күренми башладың, – дип шелтә белдерде ул.

– Премьераңа, һичшиксез, киләм, – дидем.

Аңарчы тартынып куярга өлгергән идем: нигә саграк бәрелмәде инде, берьялгызым булмаганны күрде бит... хур итте...

Әмма очрашу Лиягә һич көтелмәгәнчә тәэсир ясады:

– Бу әллә Бикчәнтәевме? – диде ул, гаҗәпләнеп.

– Әйе, – дидем.

– Режиссёр Бикчәнтәевме?

– Әйе.

– Вау!

Ресторан безне җирдән кубарды. Монда түбә итеп күкне генә япканнар. Чын күкне! Берән-сәрән йолдызлар чамалана.

– Кассиопея, – дидем, «дабл ю» хәрефенә төртеп.

Без өстәл янына урнашкан идек инде.

Бу йолдызлык миңа күп тапкыр ярдәм итте. Кызларга романтика кирәк бит. Хәтта иң тупас, коры сыман тоелганнары да, асылда, барыбер, балачакта укыган әкиятләренә ышанып яши. Һәм гомер буе шуларның тормышка ашуын көтә. Байтак егетләр баш очында пар чүмечтән гайре нидер булуын чамаламый да. Ә мин иксез-чиксез, исемле-исемсез төрткеләрне Кассиопея итеп тоташтыра алам...

– Казан бүген синең аяк астыңда, – дидем.

Ул җавап бирмәде. Елмайды гына. Тоташ пыяладан эшләнгән дивар-түшәм буйлап күзен йөгертте. Мин дә тышка бактым: шәһәр, гыйнвар чыршысы кебек, мең утларда җем-җем килеп тора иде.

– Официант!

Биредә җылы һәм хуш иде. Кеше аз. Тыныч. Җиңелчә музыка уйный.

Лия сыр салып пешерелгән креветка ашына заказ бирде. Бөҗәк-мазарны өнәмәсәм дә, ул кыстагач, үземә дә алдым. Тәмен басар өчен кыздырылган ит китерергә куштым. Лия кус-кус сорады. Минем андый ризык турында ишеткәнем дә юк иде. «Нәрсәгә аңа уксус?» – дип уйлап куйдым әле.

Буш өстәл күз алдында натюрмортка әйләнде.

– Аш тәмлеме? – дип кызыксынды Лия, ирен читен сөртеп.

– Тәмле, – дидем мин. – Дөге шулпасы кебек.

Сүз ара сүз ялганып, үземнең «Идел» яшьләр журналына урнашуымны әйттем. Һич мәкерсез гамәл түгел иде бу. Безнең буын Бразилия сериаллары карап үсте. Лия шуларның берсендә уйнаган журналист Шику Мотага гашыйк иде.

Һаман шигырьләр язуымны белгерттем.

– Әле менә конкурста җиңдем, – дип өстәдем.

Мин андагы бүләкләрне күтәреп йөрергә иренгән идем. Бер сугылырмын дип, артыгын Вәлиулла хәзрәттә калдырдым. Түш кесәгә конверт белән үз китабым гына шуды. Ярышта катнашучылар өчен сатып алынган һәм әйләнгеч юллар аша яңадан иясенә кайткан бу китап, ахыр чиктә, Лиягә насыйп булды.

Ул исә медицина училищесын тәмамлаган икән. Хәзер хастаханәдә эшли. Идел буе районында бугай. Шәфкать туташы. Торуы да шунда ук, ди. Берничә иптәше белән фатирга кергән.

– Биибезме?

Сәер тәкъдимнән аптырап калдым.

Ә аның йөзе балкый иде.

Ә үзе гаять чибәр.

– Мин һаман да бии белмим әле, – дидем. – Сиңа ияреп йөрсәм генә.

Урыныбыздан торгач кына, миемне сорау өтте:

– Син болай киенеп-ясанып кая бара идең соң?

– Хәзер мөһим түгел инде, – диде ул.

Иңемнән этте.

Артка чигендем.

Гаҗәп нәрсә бу – хәтер: әллә кайда калган вакыйгаларга кайтып, аларны кабат яшәп, яңадан чынбарлыкта айнып-уянып китәр өчен күз сирпеп алган вакыт җитә...

Лиянең туган көненнән соң мин, кирәксез хисемне сугып чыгарырга теләп, таңгача күкрәгемне төйдем. Ләкин ул йөрәккә шактый тирән тамыр җәйгән булып чыкты: кабырга сөякләрен он итсәң дә, аннан арыну мөмкин түгел иде.

Мин үземдә сөюне буарга тотындым. Мин аны үтерергә теләдем. Әмма аның үләсе килмәде. Ул зар елады. Ул тыпырчынды. Тешләште.

Ул, һичшиксез, көчлерәк иде...

Һәм мин башкача итәргә булдым: аны күрмичә, сизмичә, тоймыйча яшәргә өйрәндем.

Борын астында мыек күренә башлауга без, малайлар, кызларга карата үзгәрдек. Толымнарын тарту һич кызыксыз шөгыльгә әйләнде. Аларның хәзер күз кыздырырлык башка яклары бар иде: түшләре калыкты, билләре нәфисләнде, итәкләре тыгызланды...

Ниһаять, тугызынчыны тәмамладык, зур булдык. Җәй азагында мин ындырга эшкә урнаштым. Төнге сменада ашлык киптердем. Монда Лия дә еш күренгәли иде.

Берсендә икебезне АВМга[1] куйдылар. Бу агрегатта эшләүнең артык мәшәкате юк: машина-тракторлар чалыш бушаткан тонна-тонна арпа-бодайны чокырга этеп төшерәсе генә. Ял иткән арада әллә ничек уйнап киттек. Ул минем өр-яңа бейсболкамны тартып алды. Үзенә киде.

– Сал, – дидем. – Сиңа килешми.

– Миңа һәммә кепка килешә.

Мин аны куып киттем. Ул качты.

Мин аны куып җиттем. Баш киемен кайтаргач кына җибәрдем.

Ләкин АВМ эчендә Нәби абыйга каптым. Ул монда төп кеше иде. Ындырның күз-колагы, диик. Шул менә бейсболкамны йолкып, Лиягә ташлады:

– Солы тутыр! Аңарчы җибәрмим!

Җен кызы үшәннәрдән түгел иде – җебеп тормады.

– Нишләвең бу?! – дип җикерендем. – Күрше башың белән! Сатлыкҗан!

Нәби абый акыллырак иде шул.

– Хәзер аны кыскаларга җитди сылтавың бар!.. – дип пышылдады.

Шулай итеп, мин тәүге мәртәбә хатын-кызга орындым.

Тәүге мәртәбә учымда илаһи камиллекнең калтырануын тойдым.

Хатын-кызны тулаем татып карауга ерак иде әле.

[1] Витаминлы он агрегаты. – Лирик герой искәрмәсе.

Шулай да...

– Аны хет кешечә у идең инде, рәхәт итеп, пешмәгән, – дип сукранды Лия. – Нәрсә бәбәк акайтасың, көрәгеңне ал!

Агу сеңгән сүзләре йөрәккә үтте, билгеле.

Үземне юатыр өчен генә булса да, искәртеп узыйм: бу – капма-каршы җенеснең миннән беренче һәм соңгы кабат ризасыз калуы иде.

Хәер...

Йә.

Ул елны Лиянең әти-әнисе аерылышты. Идрис абый, исерекләр санына зыян-зәүрәт салмыйча, авылда калды. Зилбәр апа Кукмарага китте.

Лия сентябрьдә укырга килмәде.

Һәм мин аны бүтән күрмәдем.

Бүгенгәчә.

Бүген исә тирә-юнь – җемелдәшеп янган якты утлар, баш өстебез – чигүле зәңгәр күк, ә без – меңъеллык Казан эчендә идек.

Башта каушап беттем. Аягына басмаска тырышып, сак кына хәрәкәтләндем. Тиргә баттым. Ләкин, бәхеткә, киеренкелек озакламый үзеннән-үзе язылды.

Ресторанда бездән башка хатирәләр генә биеде.

Лиянең борын очы минем колак яфрагын сыпырып үтте:

– Блю де Шанель?

Соравын аңламаганга күрә:

– Татарча гына сөйләшмибезме? – дидем.

Ул кычкырып көлде.

Мин аны кочакладым. Тән җылысын үз күкрәгемдә тоюга каным кызды. Чигә тамырларым бүртте. Бәхеткә, ул берни сизмәде.

Яңадан өстәлгә якынлашканда гына, күккә моңлы караш ташлап:

– Бигрәк караңгы, шомлы төн, – дип көрсенде. – Җитмәсә, бүген кызлар да өйдә юк әле...

Аны шәфкать туташы киеменнән күзаллауга башым әйләнеп китте.

Мин, бик күп еллар элек яшергән хисемне табарга теләп, ашыга-кабалана җанымда актарындым. Качып калмаганмы, чыкмасмы дип, күкрәгемә суктым. Йөрәгемнең эчен-тышын кактым. Ләкин берни тапмадым.

Мин – буш идем...

Бу хәл бераз уйга салды.

Монда кергәнче, минем алда ике юл бар иде. Алар икесе дә дөрес иде. Берсен сайладым. Шушы мизгелдә генә каршымда янә ике юл барлыкка килде. Ләкин боларның икесе дә ялгыш иде инде. Һәм элеккечә арадан кайсындыр сайларга кирәк иде.

Без исәп-хисапны өздек. Такси чакырттык.

Машина каршыбызга ук килеп туктады.

Шулвакыт мин тилердем.

Лия артыннан ишекне ябарга үрелеп:

– Ачуланма, зинһар, – дидем. – Мин... калыйм әле...

– Сау бул, – диде ул, ишеген үзе ябып.

Аның күзендәге җылылыкны котып җилләре алыштырган иде.

Тулай торакка ничек кайтып җитүемне начар хәтерлим. Бары гомум гүләүдә вакыт-вакыт кайбер авазларның ачыграк ишетелүе истә калган. Машиналар кычкыртуы, мәсәлән. Тагын... фаралар яктысы күз алдымда. Кулларымны янякка җәеп, юл уртасында басып торуым.

Бүлмәгә мине Илнур тартып менгезде:

– Рәхим итегез!

Ул шактый гына «төшереп» алган иде. Бераз тынып торганнан соң:

– Мин үземне Пётр Первый итеп тоям, – диде.

– Нигә?

– Без икебез дә тәрәзә ачучы.

– Рәзил кайда?

– Өстә, кызлар этажында бугай.

– Урал?

Илнурның аңлаешсыз авазлары миңа «белмим» булып ишетелде.

Алардан кала барысы да үз урынында иде: дүрт караватъ, дүрт тумбочка, диварга беркетелгән шыксыз агач шкаф. Көзге. Минем анда карыйсы килмәде. Кальян күмере үтәли тишкән чуар келәм. Буш шешәләр. Бик күп шешәләр.

– Җиңдеңме соң?

– Җиңдем.

– Кайчан юабыз?

– Ат бугы бөреләнеп чәчәк аткач.

– Образ бар, – диде Илнур. – Ә намус юк.

Мин өс-башымны алыштырып, ятакка аудым. Түшәмдәге чуар таплар арасыннан Кассиопеяне эзләдем. Таба да яздым. Ләкин күз җиткән соңгы йолдыз булырга тиешле чебен әллә кая очып китте. Җаным гәүдә эченә сыймый башлады. Аның, баягы чебенгә әверелеп, йолдызлыктагы буш урынга кунасы килде.

Илнур исә, шешә төбен төеп, тамчыдан күл җыймакчы иде.

– Без нигә шулкадәр күп эчәбез ул?

– Без нормально эчәбез, – дигән җавап ишеттем. – Дөньяны бизәп җибәрерлек кенә.

– Берәр кайчан айнырбыз бит?

– Айнырбыз.

– Һәм дөньяның чын йөзен күреп, исебез китәр.

Илнур канәгатьсез рәвештә тамак кырды:

– Миңа бу диалектика ошамый әле, – диде. Аннары сынап бакты: – Син, чыннан да, җиңдеңме?

Бертын онытылып алганнан соң:

– Җиңдем, – дип расладым. Шул сүздә үк ятагымнан сикереп тордым. Тумбочкадагы бүлмә ачкычын учыма себереп төшердем. Телефонны кесәмә шудырып, ярым ачык ишек катына юнәлдем.

– Кая киттең тагы?

– Өскә, җиңеп бетерергә.

– Һай бу татар теленең нечкәлекләре! – дип калды Илнур.

Иртәгәсен яңа көн җитте.

Берсекөнгә – аннан да яңарагы.

Искә төшкәч, мин Вәлиулла хәзрәттән бүләкләрне барып алдым. Алар, нигездә, китаплар иде. Кайткач, Илнурга «Һәфтияк шәриф» тоттырдым. Рәзилгә «Җен вә шайтаннан саклану догалары» эләкте.

Үзем «Тәмуг газабы»на ирештем.

Баштан кичкәнне, нишләптер, егетләрнең берсенә дә сөйләргә базмадым. Кыенсынганмындыр инде. Нидән югыйсә? Шуннан ни? Алар мине нинди хәлдә генә күрмәгән дә нинди хәлдә генә белмәгән.

Ну, күп дигәндә, Илнур, бәлки:
– Тинтәк, – дип куяр иде.
Һәм, бәлки, хаклы булыр иде.
Шулай бит?

## Унынчы кыйтга

*(Ноябрь-декабрь, 2012)*

...Узып баручы ел нәрсәсе белән истә калды?

Иң әүвәл – бик күп илләр парламент яисә илбашы сайлады. Җәен Лондонда Олимпия уеннары үтте. Төньяк Корея үзен атом-төш коралына ия дәүләт итеп таныды.

Көзен АКШта гарасат хөкем сөреп алды.

Индонезия, Мексика, Япония, Чили, Италиядә җир тетрәде.

Сүриядә гражданнар сугышы, Малида чуалышлар башланды, Гвинея-Бисауда – түнтәрелеш, ике Судан уртак чик сызыгында «бугазлашты», Кения белән Сомали территорияләренең бер өлешен «радикаль исламчылардан тазартты», Израиль белән Газа Секторы арасында мартта кабынган бәрелешләр ел азагына кабат яңарды...

Бездә исә беркая да китмәгән Тозкүз кире кайтты. Шуннан соң Төмән янында очкыч мәтәлеп төште, Краснодар краен су басты, Себер һәм Ерак Көнчыгышны ут ялмады.

Ләкин, мөгаен, Татарстан һәм татар халкы өчен иң куркынычы, иң тетрәндергече – июль уртасында, Рамазан-шәриф алдыннан, Илдус хәзрәт Фәизнең машинасын шартлату һәм күренекле Вәлиулла хәзрәт Ягъкупның җанын кыю булгандыр. Күпме гомер чиркәү чаңыннан катырак тавыш ишетмәгән Казанда шулкадәр тыйнак, басынкы дин әһелен атып үтерсеннәр әле! Аһ иттек: нәрсә бу? Кая барабыз?

Аннары китте контртеррористик чаралар: Яшел Үзән юлында ниндидер машинаның көле күккә очты, шунда ук почмагы да көймәгән дини китаплар табылды; Татарстанның нәмәгълүм «Мөхәммәт әмир»е дөньяга килде һәм, июль терактларын үз өстенә алуга, серле рәвештә дөньядан китеп тә барды; Корбан гаете алдыннан Вәлиулла хәзрәтне үтерүчеләр үтерелде...

Кирәк вакытта каты эшлибез дә инде. Йомычкаларны җыеп кына өлгер.

## Унберенче кыйтга

*(Декабрь, 2012)*

...Бу ай азагында, майя календаре ялгышмаса, ахырзаман көтәбез. Димәк, исәпсез афәтләр китергән Аждаһа елы безнең белән гаять югары аккордта бәхилләшмәкче.

Дөресен әйткәндә, дөнья бетү – әйбәт инде ул. Гомумән, һәр бетү – әйбәт. Чөнки аннан соң нәрсәнеңдер башлангычы булырга тиеш. Ә башлангыч – ул яңа өмет, яңа ышанычлар.

Мин аны бик рәхәт күз алдыма китерәм: «шарт!» һәм... караңгылык, бушлык, беркем-бернәрсә дә юк. Аннары Җир шары безнең цивилизация калдырган нәҗестән арынырга тотыначак. Арыначак, арыначак. Ниһаять, матур бер мәлдә җансыз салкын ташларда вак кына куе яшел мүк төрткеләре күренә башлаячак. Әкренләп, дистә еллардан соң, ул мүк ташларны бөтенләй каплап алачак. Тагын бераздан мүкле таш арасыннан кыюсыз гына тәүге

үсенте баш төртеп маташачак. Мескен, көчсез, һич яклаучысыз үзе. Ләкин аңа һични янамый әле. Чөнки ул нинди генә мескен, көчсез, яклаучысыз булмасын – бердәнбер! Ул – бердәнбер! Ул дөньяның хуҗасы! Бераздан алар артачак. Үсемлекләр үпкәсеннән чыккан һава парга әверелеп, садә туфракка коелачак. Бер тамчы, ике тамчы... аһ, нинди зу-ур күл җыелган! Анда берән-сәрән генә, ана карынындагы сабый кебек матур, җанлы, өр-яңа организмнар күренәчәк. Аннан, тагын исәпсез-хисапсыз еллар үткәннән соң, табигатьне тулгак тота башлаячак, ул шабыр тиргә батып көчәнәчәк, һушын җуярдай булып тешләрен кысачак, һәм әлегәчә Җир йөзе күрмәгән, белмәгән җан иясе бар дөньяны яңгыратып: «Әни-и!» – дип аваз салачак...

Борынгы календарь ялгышса да, моңсуланырга кирәкми. Бездән, һич югы, иске ел китә. Искелек китә. Хәере белән китсен, бетсен ул! Һәр бетү – әйбәт, дидек бит. Чөнки аннан соң нәрсәнеңдер башлангычы булырга тиеш, дидек. Ә башлангыч – ул яңа өмет, яңа ышанычлар да әле...

## Уникенче кыйтга

*(Датасыз)*

...Киресенчә булырга тиеш ләбаса.

Әмма телисеңме-юкмы, барлык кануннарга каршы килеп, яшәеш дисбесе иң нечкә, иң нәзек түгел, ә иң нык, иң ышанычлы тоелган урыннан өзелә. Гәрәбәләр чәчелеп китә... Бер тирәгә җыйналган да алар, әмма – ни кызганыч! – берләштереп торучы җеп юк инде...

Барысы да шул ук та кебек, шул ук түгел дә. Әйе, Туфан абый хәзер эшкә йөрми башлады[2]. Коридорда тавышының да күптәннән ишетелгәне юк. Әмма театрда һаман аның спектакльләрен уйныйлар, китап киштәләрендә – аның әсәрләре, интернетта, газета-журналларда, телләрдә – ул элеккечә һәммә җиргә өлгерә ләбаса! Шуңа күрә, бәлки, китмәгәндер дә ул? Бәлки, без алданабыз гынадыр? Чөнки яшәү – аяк-кулларны селкеп, сикереп йөрү дигән сүз генә түгел әле! Алай икән, димәк, Туфан абый һаман исән, мәңге исән! Моңа чын күңелдән ышанырга гына кирәк.

Мин ышанам.

## Унөченче кыйтга

*(Июнь, 2012)*

...Тормыш – гаҗәп нәрсә ул. Искитмәле нәрсә!

Вак-төяк кимчелекләренә карамастан, тормыш – матур ул!

Кешенең табигате шулай корылган инде – тегене яисә моны югалткач кына аны сагына, кадерен белә башлыйбыз. Әмма ни кызганыч, гомеребезне бер-ике тапкыр югалтып карау мөмкинлеге бирелмәгән шул. Киттең икән – мәңгегә киттең. Кире кайтып, һичнәрсәне үзгәртә дә, яхшырта да алмыйсың.

Шуңадырмы, һәрбер үлем-китем әледән-әле күктән җиргә төшәргә, күп әйберләр турында тагын бер кат уйланырга мәҗбүр итә: мин дә берәр кайчан шулай ятачакмын бит, дисең...

Минем иңемдә кемнәрнеңдер рәнҗеше йөрмиме?

Күккә омтылганда, бу рәнҗешләр, авыр йөк булып, мине аска – упкынга тартмаячакмы?

2 Туфан Миңнуллин җитәкләгән «Сәхнә» журналы Чистай урамында «Идел»нең күршесе иде. – Лирик герой искәрмәсе.

Бурычлы калмыйммы? Үкенерлек яшәмимме?

Үлемнән соң мине ни көтә?

...Дисең.

Чын ир-ат йорт салырга, агач утыртырга, ир-угыл үстерергә тиеш. Бу, чыннан да, шулайдыр. Мондый тәгълимат юк урында барлыкка килмәс. Уйлап карасаң, йорт – нәсел-нәсәбеңне яңгырдан-кардан ышыклап тотачак; агач – тир тамчыңны, түккән көчеңне үзенә сеңдереп, синең төсең булып шаулый-шаулый һәр яз саен яфрак ярачак; ә улыңа тапшырган каның әле күп, бик күп оныкларыңның йөрәгендә тибәчәк! Димәк, озак, бик озак яшәячәксең әле син! Офыкта күренмәгән ерак киләчәктә дә кемдәдер, һич югы, бер генә тамчы булса да, синең кан агачак. Димәк, аның тамырлары буйлап син агачаксың! Бу – үлемсезлек ләбаса!

Яшәешнең һәр күзәнәгенә, һәр пәрәвезенә, һәр чәчәгенә гашыйк Хәсән Туфанның сөргеннән кайтыр алдыннан Габдрахман Минскийга язган хатында мондый юллар бар:

«О, матур да соң тормыш! О, нинди бөек эш бу – яшәү! Яратам, үлеп яратам тормышны! Миңа расстрелның ун ел белән алмаштырылганын укыганда... минем аша гүя яшәү-тормыш үзе кычкырды:

– Хет йөз ел! Бары яшим генә!»

Тормыш – гаҗәп нәрсә ул. Искитмәле нәрсә!

Вак-төяк кимчелекләренә карамастан, тормыш – матур ул! Гаҗәп матур! Шуңа күрә мин дә, һичшиксез, аның яклы.

## Автограф

Машина безне башта узып китте. Аннары артка чигеп туктады. Ярар, мин, Аллаһның рәхмәте төшкән чакта гына тукланып-туенып йөрүчән студент, үтә күренмәле булыйм да, ди. Әмма Ркаил абыйны ничек абайламый калырга мөмкин соң? Ул зур. Ул Казанның теләсә кайсы почмагыннан күренеп тора.

Бүген Аксубайда Хәсән Туфанның юбилеен уздыралар.

Без шунда кайтмакчы.

Атна уртасы булганга, баш мөхәррир мине әүвәл җибәрергә теләмәде. Үземнең «Идел»гә урнашкан чагым гына. Артык әрсезләнә алмыйм. Уңайсыз. Аңа Ркаил абый шалтыратты. Нәрсә дип сөйләшкәннәрдер, белмим. Озакламый мине төп кабинетка чакырдылар.

– Синең анда барасың киләме соң?

– Килә.

– Белмим инде...

Мин мәсьәләнең төбенә төштем. Баш мөхәррир минем авыздан Ркаил абыйга «юк» дип әйттерергә тели иде: әнә, үзе бит, янәсе...

– Бик барасың киләме?

Кабинетта авыр тынлык урнашты.

Хәсән Туфан бит ул! Мин бүген шигырь язу серләрен аннан өйрәнәм. Иҗатындагы адәмидән алып галәмигә кадәр үстерелгән фәлсәфәгә төшенергә тырышам. Аның гади дә, шул ук вакытта, яңа да, көтелмәгәнчә тирән дә образларына, тел-сурәтләү чараларына сокланам. Миңа аның әбизмнар[3] белән саташуына кадәр якын! Мин шундый ук абруй казанырга, шундый ук зур

[3] Әбизм – әдәбиятта борынгылыкка иярүче законнар мәктәбе (аббревиатура). Мин аның тәгаен нидән гыйбарәт булуын әлегәчә аңлап бетермим. – Лирик герой искәрмәсе.

шагыйрь, шундый ук ап-ак чәчле, ап-ак җанлы ил карты булырга хыялланам. Уртадагы уналты еллык сөргенен сикертеп кенә, билгеле...

– Ярар, алайса, – диде баш мөхәррир, авыр сулап.

Ркаил абый утыруга тау кадәр машина чүгеп куйды. Бәй, монда миңа урын юк икән бит! Рульдә – Миргалим абый, янәшәсендә – хатыны Роза апа. Артка туфанчы-галим Мәсгуд абый белән ниндидер юлаучы хатын урнашкан.

– Багажникка утырсаң гына инде, – диде йөртүче. – Анда утыргыч бар.

Миңа ул вакытта һич нигезсез тәкәбберлек хас иде. Мин һаман да тәкәббермен, билгеле. Әмма хәзер аның нигезе бар бит.

Багажникка? Үзем теләп? Булачак зур шагыйрь килеш?

– Утыр, – диде Ркаил абый коры гына. – Хәсән Туфан ай буе смертниклар камерасында да утырган әле.

Шулай итеп, күндерде ул мине.

Ул, гомумән, кешене тиз күндерү сәләтенә ия.

Аның белән танышуыбыз да сәер булды.

Казанда тәүге елым иде. «Идел» журналына берничә шигырь китердем. Берәр кайчан бу басмада эшләрмен дигән уем да юк әле! Кая! Монда – зубрлар гына. Якын килерлек түгел. Редакция тулай торактан кул сузымында булганга, һич югы ишекнең кайсы якка ачылганын белеп кайтырмын, дип тәвәккәлләдем.

Җәйгә узмакчы айның җомга киче иде бу.

Мөштәри урамындагы борынгы бинада минем «Исәнмесез!»гә кайтаваз гына җавап бирде. Бүлмә саен шакып киттем. Һәркайда бушлык, тынлык. Мур кырганмыни?! Биек түшәмнәр. Таш идән. Акшарланган дивар буйлап, кан тамырлары сыман зәп-зәңгәр ярыклар сузылган.

Мин үземне бер мәлгә Дию сараенда дип хис иттем. Җир астында. Коридорда кабер салкынлыгы иде. Артымнан шыпырт кына килгән шомлы җил мине ялап узды. Почмактагы бүлмәдә урындык күчкән тавыш ишетелде. Иленнән тартып алынган гүзәл патша кызы шунда качырылса гына...

Гүзәл патша кызы Искәндәр Сираҗи булып чыкты.

Гозеремне аңа аңлаттым. Чалбар кесәсеннән дүрткә бөкләнгән дәфтәр битләрен чыгарып салдым. Ул, күз йөгерткәннән соң:

– Бара бу! – диде. – Икенче юлы машинкада җыеп китер.

Шулай итеп, редакция халкының график дигән нәрсә белән санлашмыйча яшәвен белдем. Алар ял көннәреннән чәршәмбедә генә чыгып китә, ә пәнҗешәмбедән янә ял көннәренә керә башлый икән. Сираҗи, озаграк җыена торгач, бу юлы җомгага гына килеп өлгергән.

Икенче баруымда алар арткан иде инде. Искәндәр абыйның каршысына, кояшны каплап, зур гына, төксе чырайлы, бик тырышып карасаң, таныш чалымнары чамаланган җитди зат урнашкан иде. Аның астындагы кәнәфинең мөшкел хәлен күреп, мин гомеремдә беренче тапкыр җансыз предметны кызганып куйдым.

– Кукмара районыннан, – дидем танышканда. – Безнең авыл Киров өлкәсенә терәлеп тора...

Искәндәр абый минем бая калдырган кәгазьләрне теге затка сонды. Болай да бетәшкән кульязмалар аның симез бармаклары арасында бөтенләй кызганыч иде. Ул кашларын җыера төште. Әле бер күзен, әле икенчесен кысып, шигырьләргә караш ташлаганнан соң:

– Син ритмны ишетмисеңме әллә? – диде.

– Ишетәм.

– Алайса, мин ишетмим инде.

– Махсус шулай... ике төрле үлчәмдә яздым. Строфа саен берсе кабатлана.

– Строфаны беләсең? – диде ул, мине бүлдереп. Аның кашлары, маңгай җыерчыкларын узып, өскә менеп алды. Бу җөмләнең асылына шактый соңрак төшендем әле: ул мыскыллауны да мактау сүзенә охшатып әйтә белә икән.

Билгесез зат икенче битне алды:

– Чәнечкеле чия буламы?

Моңарчы дәшми торган Искәндәр абый түзмәде:

– Чәнечкелесе дә була инде, – диде, мине яклап.

Шикле адәм янә кәгазьгә күз ташлады:

– Һәм шул, кулыңны сузсаң, тәнне ертамы?

– Чәнечкеле булгач, ерта инде, – диде Искәндәр абый.

Теге кеше миңа текәлде. Аның күзенә боз утырган иде. Кәнәфидә урынлашканга, үзе миннән тәбәнәгрәк. Шул килеш тә өстән аска карап сөйләшә. Оятсыз затның шәхесен ачыкларга теләп кенә:

– Абзый, син кем соң? – дип сорадым.

Шулвакыт миңа саңгыраулык сукты гүя: дөнья кинәт телдән язды. Күрше бүлмәдә бертуктаусыз шакы-шокы компьютерга баскалаган корректор апа да тынып калды. Тораташтай каткан кулда минем дәфтәр битләренең тыпырчынуы гына ишетелә иде. Бераздан, түзмичә, кәнәфи ыңгырашты. Искәндәр абый шул мизгелдә үк, тынлыкны төбе-тамырыннан ватышлый, миннән ваз кичте:

– Ркаилне белмәгәч, бу, чыннан да, Киров урманыннан чыккан инде!

Берәр айдан соң мин Изге Болгар җыенына бардым. Анда, барча матур сыйфатларына өстәп, якташым да булган Газинур абый белән таныштым. Бер сәхнәдә чыгыш ясадык. Алкышлар алдык. Шунда ул үсендерергә теләпме:

– Син бу шигырьләреңне Ркаил абыеңа күрсәт, – диде.

– Күрсәттем инде, – дидем мин, авыр көрсенеп.

Дөресен әйткәндә, ул кешене башка һичкайчан күрмәсәм дә, риза идем.

Әмма озакламый бергә «Исхакый укулары»на кайтырга туры килде. Барганда, күрешеп үттем. Яуширмәдә бер-ике сүз алыштык.

Табигатьнең иң ямьле чагында ачык һавада уздырылган чын бәйрәм иде бу. Казаннан килгән кунаклар ат уйнатты. Без, яшьләр, чара тәмамланыр алдыннан гына сәхнәгә мендек. Таралыша башлаган халыкны үзебез язган югары поэзия үрнәкләре укып озаттык. Шигырьнең яртысына җиткәндә, минем микрофонны сүндереп куйдылар. Үзалдыма сөйләнеп бетерәсе булды.

Казанга кайтканда, Ркаил абый автобусны тиз арада иярләп алды. Һичкем аңа каршы әйтергә, аның гегемониясенә дәгъва белдерергә базмады. Без, яшьләр, мохтарият хокукында, арткы утыргычларга – чик сызыгына сыендык. Бераздан Ркаил абый, бөтен биләмәсен сискәндереп, бар куәткә минем исемне кычкырды:

– Кил әле!

Янәшәмдә утырган яшьтиләрне шом басты:

– Барма.

Әмма чакыручының тавышы гайрәтлерәк иде:

– Кил, дим!

Ул һич уйламаганда-көтмәгәндә... иңемнән кочып алды.

– Менә, – диде, – күрегез, өр-яңа шагыйрь... Чын шагыйрь!

– Яшьләрне бозма, – диде аксакалларның берсе.

Ләкин җавап һичнинди бәхәскә урын калдырмады:

– Мактау-сүгүне күтәрмәслек булгач, безгә нигә ул? Димәк, чын шагыйрьлеге шуның кадәр генә. Аяк астында буталып йөргәнче, тизрәк бозылуы яхшы.

Соңыннан белдем: вакытында Туфан Миңнуллин бу сүзләрне аның үзенә карата әйткән икән.

Әллә кайдан гына пластик шешә барлыкка килде.

– Мә, су эч, – диде Ркаил абый. – Син боз ялау яшеннән узган инде.

Әүвәл икеләнеп калдым.

Ул, бер күзен кысып, серле генә елмайды:

– Яуширмә суы!

Аннары уртлап куйдым.

Су җылынган иде. Шуңа күрә авыр китте.

– Әйдә, шигырь сөйлә!

– Сөйләмим, – дип кырт кистем. Һәм үз урыныма барып утырдым.

Шигырь сөйләү теләге һәрвакыт бар миндә югыйсә. Нигә күнмәдем соң? Белмим. Һич сәбәпсезгә бик каты карышасы килгәндер, мөгаен...

Казанда автобустан төшкәндә:

– Беләсеңме, – диде Ркаил абый, зур сер әйткәндәй. – Чәнечкеле чия дә була икән. Ниндие генә әле...

Бу сәфәрдән соң без аның белән башка күрешмәгән идек бугай.

Хәер, бер-ике тапкыр театрда юлыбыз кисеште.

Аларына аерым тукталып тормыйм.

Көз иде ул.

Ә хәзер кыш.

Һәм без, ниһаять, Аксубай районына кайтып җиттек.

Хәсән Туфанның музей-йорты Иске Кармәт авылында урнашкан.

Машина капка төбенә үк килеп туктады. Өстән явып тора иде. Безнең делегацияне зурлап каршы алдылар. Миргалим абый белән Роза апа чәкчәктән житешкәндә, мин, ничек котылырга белмичә, ике запас тәгәрмәч арасында бәргәләндем. Биктә! Берүзем! Утыргычларны этеп тә, төртеп тә карадым: ян ишекләргә буй житәрлек түгел иде. Аптырагач, багажникны каерып кына ачарга туры килде. Якты дөньяга чыктым. Юк җирдән шулай бар булуымны күргәч, урам себерүче картның авызыннан тәмәкесе төшеп китте.

Өстән кар ява иде...

Ркаил абый чуваш хатыннары белән биеде.

Мин кул чабып тордым.

Ә өскә кар ява иде...

Ап-ак кар...

Вак-вак кар...

Бөтерелеп-бөтерелеп. Йөгерә-йөгерә. Күктә качыш уйнаган кебек...

Кар минем маңгайга кунды.

Югалды.

Кар минем битемә яуды, чеметкәләп алды.

Аннары югалды.

Карашымны Тәңре катына күтәрдем. Югарыдан ишелеп-ишелеп аклык иңә иде... Ул ачык тәнемә, ян-якка җәелгән учыма кагылып, миндә югала, юк, алай түгел, миңа сеңеп бара иде. И Тәңрем! Аклыкка шулкадәр мохтаҗмыни мин?

Аклык кирпеч постамент артыннан башын гына күрсәтеп торган Хәсән Туфанга да яуды. Әмма ул бу аклыкны алмады. Аңа үз аклыгы да артыгы белән җитә иде, күрәсең.

Кар минем керфегемә тамды. Эреп, күз алмасы турына җыелды.

Анысын үзем сөртеп төшердем.

Безне эчкә дәштеләр.

Шәхесләргә багышланган музейлар, гадәттә, бер-берсеннән аерылмый. Игезәк фотографияләрдә кешеләрнең йөзе генә алышына. Өч яшь шагыйрь бергә төшкән бу сурәтне, мәсәлән, минем моңарчы Казанда, Җәлилнең музей-фатирында күргән бар иде. Инде Иске Кармәттә очрады. Тәңре язып, Сыркыдыга юлым ятса, иманым камил, анда да бусага катында ук шушы фотография каршы алачак. Ә безнең әдәбиятыбыз бай, әдипләребез күп! Һәркайсының бер-берсе белән төшкән рәсемнәрен җыйган очракта да авыл саен музей ачарлык.

Мин биредә бабамның сурәтенә юлыгырга гына әзер түгел идем...

Алдан төшкән.

Яннан төшкән.

Чәче кыркылган. Яңагы эчкә баткан. Карашында – туфан басып узганнан бирле җыела килгән татар сагышы...

Бу кеше шуңа да якынмы әллә миңа?

Ул монда туган! Монда үскән!..

Ркаил абый куеныннан яшел тышлы китап чыгарды:

– Туфанның сайланма әсәрләре, – диде. – Казанга тәүге килүемдә матур теләкләр язып бүләк иткән иде.

Бу мизгелнең, шулай ук, фотосурәттә сакланган нөсхәсе искә төште: чал Хәсән ага яшь Ркаилгә шигъри әманәтен тапшыра... Араларында яшь Газинур ихлас елмаеп тора... Әйе, бөек шагыйрьгә алмаш берәү генә була алмый.

– Бу җыентыкны мин бүген аның үзенә кайтарам...

Музей җитәкчелеге куанычыннан нишләргә белмичә бибаһә ядкяргә кул сузганда, минем йөрәк бугазыма менеп тыгылды. Туфан китабы! Автографлы! Тере шигырьләрне җансыз музейга олактыралар! Гербарий сыман, пыяла астына тыгып куяргамы? Яңа буынга тапшырсын өчен генә Ак шагыйрь аны Ркаил абыйга биреп тормаганмыни? Бу китап миңа насыйп түгелмени? Ничек соң... остазлык традицияләре? Аксакаллык? Дәвам? Тьфү!

Берничә тапкыр, җай табып, рәнҗүле сүзләремне адресатына ирештерергә омтылдым. Ишетмәде дә. Ул дөньяның кендегенә әверелеп өлгергән иде инде. Җитмәсә, яшьлегендә Иске Татар Адәм Суы дигән сәер исемле авылда нәрсәдер укыткан да икән. Кайсы якка борылма, берәр укучысының аягына басасың.

Төшке ашта аңа бәлешнең иң зур кисәген суздылар. Миңа ямаулык камыры калды. Чәй пакетының да Ркаил абый сыгып биргәне генә эләкте.

Бөтен кеше әдәбиятның бүгенгесе белән мәшгуль.

Киләчәкне уйлау да юк!

Агайларын, авырлыгы азрак булса, күтәреп кенә йөрерләр иде.

Район үзәгендә кичкырын бик матур концерт куелды.

Гадәттә, елыйсы җирдә көлеп, көләсе җирдә елап, бәйрәмнең ямен, бәйрәм итүчеләрнең кәефен җибәрүчән Ркаил абый үзен бу юлы гаять ипле, сабыр, тыйнак тотты. Бер поэмасыннан өзек укып төште. Озаклап алкышладылар. Кәминә бәндәгез дә ымсынып карады, билгеле. Әмма усал кешеләр:

– Син банкетта сөйләрсең, – дип, мине урыныма утыртты.

Сәхнәгә чибәр хатын менде. Залга моңлы халык җыры агылды:

– Мин сагынсам, тәрәз ачам,
Син җил булып исәрсең...

Гаять ипле, сабыр, тыйнак Ркаил абый түзмәде – сынатты. Карашы белән җырчының һәммә калку төшен капшап чыкты да:

– Аннары китә җилдән туган балалар, – дип куйды.

Хәер, аны мин генә ишеттем бугай.

Хәсән Туфаннан да шигырь укыттылар. Ак шагыйрьнең ышанычлы ораны, әллә кай чорларда адашып йөри торгач, ниһаять, Аксубай мәдәният йортын эзләп тапты:

– Җир барыбер әйләнә, инквизитор,
Коммунизм ягына әйләнә!

Мин бу урында концертның тәмамланганын аңладым.

Моңа өстәп нәрсә әйтәсең инде?

Соңрак табын корылды. Галстуклар бушады. Телләр чишелде.

Күпмедер вакыттан мин Ркаил абыйның иңбашына кулымны куйдым. Көне буе җыелган сүзләремне түкми-чәчми әйтеп салырга исәпләдем. Ләкин ул бу юлы да вазгыятьне гел икенче якка борып җибәрә белде:

– Юк сүз сөйләгәнче, шигырь укы.

Минем чигенми чарам калмады. Чөнки бу – һәрвакыт, диярлек, күңелемә хуш килә торган тәкъдим. Урынымнан тордым. Ләззәтле киерелеп алдым. Аннары бик тырышып, бүртенеп бер әсәремдәге бүренең авыр уйларын бәян иттем. Үземчә, искиткеч килеп чыкты. Сыек кына алкышлар да ишетелде хәтта.

Шулвакыт көтелмәгән хәл булды. Моңарчы почмакта шым гына утырган Мәсгуд абый:

– Сиңа классикларны күбрәк укырга кирәк, – дип ташлады. – Бәлки, соң түгелдер әле. Язарга да өйрәнерсең.

Чак артыма авып китмәдем:

– Ничек?

Ул кәчтүменең өске төймәсен ычкындырды. Астагы төймәсе болай да юк иде. Бизәкле свитеры шәрәләнеп калды.

– Менә монда яшьлек тә бар, дәрт тә бар, шигырь дә бар! – диде галим. – Ә синдә һавалану белән агрессия генә. – Һәм, үрнәк итеп, Хәсән аганың егерменче еллар сәламен тапшырды.

Шигырь, чыннан да, шәп иде.

Ләкин чәркәне өч тапкыр үбеп куйганнан соң мине һичничек рәнҗетергә мөмкин түгел. Үзем зәһәрләнәм. Бу юлы да алны-артны, уңны-сулны аерудан яздым. Куллар җил тегермәне сыман бертуктаусыз әйләнергә тотынды. Авыздан кайнар-кайнар сүзләр чәчрәде. Аларны, әдәби калыпка салып гомумиләштерсәң, ихтимал, мондый җөмлә оешыр иде:

– Мәсгуд абый, мин сезнең белән һич килешмим.

Нәтиҗәдә без икәү чәкештермичә эчә башладык.

Озакламый Казанга кайтыр вакыт җитте. Җыелышып урамга чыктык. Баягы юлаучы хатын Иске Кармәттә калганга, миңа машинаның арткы утыргычында урын бушады.

Өстән һаман явып тора иде.

Бистә ап-ак иде...

Җиһан ап-ак иде...

Кайтканда, һәрвакыт тизрәк кайтасың.

Казанда барыбыз бергә Миргалим абыйларга кунакка кердек. Анда да сыйландык. Бер уңайдан йортларын күрдек.

– Ркаил, менә, күз төшерче...

– Ркаил, моңа ни диярсең?..

– Ә бусы, Ркаил?..

Иманым камил: хуҗа бу хансарайны Ркаил абыйга күрсәтер өчен генә төзегән иде.

Алга таба, мөгаен, сәгать уклары кызулангандыр. Кинәт кенә тулай торакка соңаруым ачыклангандыр. Күңеле киң әдип мине үз фатирына кунарга чакыргандыр. Шулайдыр.

Белмим.

Минем зиһенемне тоташ аклык биләп алган иде.

...Тукран чигәне бер чукыды.

Аннары тагын бер.

Аннары аның тукран булмавы аңлашылды.

Чөнки тукранның томшыгы мондый тупас түгел.

Үрдәк бу.

Бик зур үрдәк.

Бик көчле үрдәк.

– Тор, бөек!

Бүлмәдәшем Илнур каяндыр сөйләшә торган үрдәк алып кайткан. Мин «көш» дип карадым.

– Тор!

Бигрәк әрсез үрдәк.

Көч-хәл күземне ачтым. Ркаил абый каршыма баскан көе имән бармагы белән чигәмә төртә иде. Иртәнге җиде. Бу вакытта әле «Время» тапшыруына кадәр ятып йоклаганнар да уянмый.

Торып утырырга туры килде.

Ваннада битемә салкын су сиптем. Пастаны бармакка сылап кына авызымны чистарттым. Баш тонган. Ләкин авыртмый. Ярты бәхет. Ркаил абый, аһ-уһ килеп, кухняда актарына иде.

Мин киендем. Рәхмәт әйтеп, ботинкама үрелдем.

– Кая барасың?

– Эшкә.

– Кит әле... бу вакыттамы?

– Ие.

Ачуым һаман басылмаган иде әле. Шуңа күрә, уңайлы форсат туугa:

– Син нишләп Туфанның китабын миңа бирмәдең? – дидем, үртәлеп.

– Миндә яхшырак бүләк бар...

– Нинди?

– Башта чәй эчик.

Минем, чынлап, эшкә барасым бар иде. Лекцияләрне тозлыйм да тозлыйм инде. Анысы хәерлегә булсын. Ни дисәң дә, карт студентмын. Ләкин редакциягә урнашкан чагым гына лабаса. Һай, уңайсыз!

Кухняда без дөнья әдәбияты турында гәпләштек. Хәер, дөресен әйткәндә, мин күбрәк тыңлап утырдым. Тагын да дөресрәк әйткәндә, гомумән, сыңар сүз кушмадым. Ул Уолт Уитменның шигъриятт҄ә революция ясавы турында сөйләде.

Лопе де Веганың тарихи пьесаларда романсеро традицияләрен саклавына басым ясады. Огюст Макеның, асылда, начар язучы булуын икърар итте:

– Берүзе ул пычагым да кырмас иде...

Аны һушым китеп тыңладым. Болар барысы да шулкадәр тансык, яңа, кызык иде миңа. Кичкә кадәр рәхәтләнеп тыңларга да риза идем. Даими рәвештә, күзен акайтып:

– Шуны да белмисеңме? – димәсә.

Аның алдында беркадәр реабилитацияләнер өчен генә:

– Син Купринга охшагансың, – дидем.

Ркаил абый әдипне һәрьяктан сүтеп җыярга кереште:

– Аның әнисе Колынчакова. Затлы нәсел. Тамырлары – Олуг Олыстан.

Үзем «Гранат беләзеге» белән «Олеся»ны гына укыган!

– Утлап йөрүче колын сурәтле яшел әләме дә булган, диләр...

– Нигә – колын?

– Ничек инде?

– Нигә, мәсәлән, бүре сурәтле әләм түгел?

– Колын-чаков-лар нәселе, дим!

– Ә-ә.

– Шуны да белмисеңме?

– Хуш. Киттем мин.

– Ә бүләгем?

– Бир, алайса.

Ул авырсынып кына табын түреннән торды. Авырсынып кына балконга юнәлде. Башта аптырадым. Аннары аңлашылды: абзый һәр фатирның чүплегеннән гыйбарәт иң шыксыз бүлмәне җылытып-эчләп, эш кабинеты иткән икән. Биредә агач өстәл, агач урындык. Агач диварлар буйлап агач киштәләр сузылган.

Ркаил абый арадан бер китапны тартып чыгарды. Үзенекен. «Мәгарә»не. Монда аның иң яхшы шигырьләре тупланган. Пар канатын ике якка каерып, җыентыкны җиңелчә кагып алды. Бер кәгазь бите очып төште.

– Бу – Туфанның миңа язган автографы, – диде ул, идәнгә үрелеп.

Кан тамырларымнан җылы йөгерде.

– Менә болай эшлик без...

Абзый, кулъязмадагы үз исемен минекенә алыштырып, кәгазь битендәге яшел хәрефләрне берәм-берәм «Мәгарә»нең форзацына күчерергә кереште: «...мин котлаган киләчәгеңә хәерле юллар теләп...»

Туфан «киләчәгеңә» сүзендә ялгышкан иде. «Киләчә...ңә» дип җибәргән. Аннары, мәктәптәгечә ыргап ясап, «ге» иҗеген кире кайтарган. Онытылган иҗек, кануни урынына ничек кысылырга белмичә, иптәшләре арасында тырпаебрак тора иде.

Ркаил абый Хәсән аганың хатасын кабатлый башлагач:

– Дөресләп яз инде, – дидем. Шагыйрь:

– Аның бөтен хикмәте шунда, – дип каршы төште. Һәм оригиналдагыча язып бетерде.

Минем башыма куанычтан кан саугандай булды.

Ркаил абый үзеннән «P.S.» тамгасы өстәде. Беркавым дөньядан китеп торды. Аннары: «Бу постскриптумда ни әйтергә дә белмим», – дип, каләмен куйды.

Күңел чак кына кителеп алды, билгеле.

Ул шунда ук икенче җыентыгына үрелде. Чәчмә әсәрләренә. Анысына: «Менә мине кем алмаштырыр!» – дип язды.

Күңелнең китек урыны яңадан ямалды.

Ләкин Ркаил абый уйда иде. Кашларын җыерган, җитди. «Идел» редакциясендә танышкан чактагы кебек. Башта кәкре-кыек юлларга караш ташлады. Аннары миңа бакты. Өндәүгә иялләнеп тә өлгермәдем, ул, әле бер күзен, әле икенчесен кысып караганнан соң, баягы җөмлә азагына ышанычлы сорау билгесе өстәде: «Менә мине кем алмаштырыр!?» Җитмәсә, акырып көлде дә әле.

Бу вакытта күңелнең нишләгәнен әйтмим.

Тагын берничә тапкыр китәргә омтылыш ясадым. Барып чыкмады.

– Шигырьләр укы, – диде.

Ну... Монда бернишләтеп булмый инде... Укыдым. Хәтта күп укыдым. Яттан белгәннең барысын да. Шуннан соң китмәкче идем.

– Ә мин? – дип еламсырады ул. – Мин укымыйммыни?!

Аны да тыңларга туры килде. Бик озак итеп. Китабы беткәнче.

Кыскасы, котылып урамга чыкканда, караңгы төшкән иде инде. Дөнья үзгәрмәгән. Кичәгечә. Өстәвенә, кичәгечә кар ява...

Ап-ак кар...

Вак-вак кар...

Ниһаять, тулай торакка кайтып аудым. Бүлмә буш. Егетләр биләмдә йөри иде.

«Мәгарә»не ачтым. Автографка күз ташлыйсы килде.

«...Мин котлаган киләчәгеңә...» Ничек? «Киләчәгеңә...» Алай түгел бит... Ишләре өстенә менгән «гә» белән бергә иҗекләп укырга керештем: «ки... лә... ге... ңә...» «Килә... геңә!..»

Киләгеңә!..

Ркаил абый, Туфанның хатасын кабатлаудан тыш, үзе дә тагын бер иҗекне төшереп калдырган иде.

Аннан соң шактый еллар узды. Бүген без бик якын дуслар. Уртак казанда кайнап, уртак Казанда яшәп ятабыз. Мин һаман зирәкләнәм. Ул һаман киңәя. Каламбур: юанлыгы – аның нечкә җире. Шуңа күрә дә кәминә бәндәгез бу хикәя дәвамында, аерым бер ләззәт белән, яраткан персонажының гәүдә төзелешенә басым ясарга тырышты.

Дөрес, соңгы елларда абзый (яисә әзи, диик) сәламәтлеген кайгыртуга күчте. Кем әйтмешли, томау төшсә дә, хастаханәгә чаба. Аны еш кына:

– Аракы эчсәң, үләсең, – дип, кире озаталар.

Шуңа ышанып, ул шау-шулы мәҗлесләрдә катнашмау ягын карый. Кайвакыт кына үзенә кайтып килә. Берничә дустын чакырып...

Ул зур әдип. Ул зур кеше (хәзер конституциясенә ишарәләвем түгел). Аның китаплары чыгып тора. Ул аларны миңа да бүләк итә. Автограф белән, билгеле. Нәүбәттәгесе, мәсәлән: «Шешәдәш! Диндәш!..» – дип башлана.

Соңгысы булмасын.

### Ундүртенче кыйтга

*(Ноябрь, 2013)*

...Һәр язучы, һәр композитор, һәр актёр аерым бер чор өчен туа. Ул үз чорында яшәргә һәм иҗат итәргә бурычлы. Ләкин монда, иманыңны алыштырырга яисә кыен ашарга туры килмәсен өчен вакыт чикләрен бозмавың яхшы. Нәкъ шулай: кирәк вакытта туып, кирәгенчә яшәү генә түгел, кирәк вакытта кирәгенчә үлә дә белергә кирәк әле.

Әйтик, Сибгат Хәким бу мәсьәләдә дә бик төгәл кеше булган. Шәйхи Маннур – шулай ук. Мирсәй Әмир. Хәсән Туфан. Габдрахман Әпсәләмов. Алар совет чынбарлыгында яшәп, ул чынбарлыкның беркайчан да юкка чыкмавына инанып үлгәннәр.

Аңарчы күп ел алдан Габдулла Тукай җиһан ишеген дөбердәтеп ябарга дөрес вакыт сайлаган. Ә Фатих Әмирхан, Дәрдемәндләр – ялгышкан.

Узган гасырның соңгы дистәсендә бакыйлыкка күчкән зыялыларыбыз, мөгаен, бәхетле саналырга хаклыдыр. Алар мөстәкыйль Татарстанның барлыгына, һич югы, булачагына өмет баглап киткәннәр: Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники, Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Рәшит Әхмәтҗан, Кадыйр Сибгат...

Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Нияз Акмал, Роберт Әхмәтҗаннар исә, киресенчә, өметләрнең акланмавыннан ачыргаланып, йөрәк авыртуына түзә алмыйча дөньядан ваз кичкән кебек.

Әлбәттә, күпсенеп әйтүем түгел, ләкин Мостай Кәрим дә беркадәр өлгеррәк булса, «Россиянмын» шигыре өчен яңа чор алдында җавап тотмас иде. Аның бер интервьюсы истә калган.

Журналист:

– Сез һаман да үзегезне русияле дип саныйсызмы?

Шагыйрь:

– Әйе, мин үземне һаман да русияле, россиянмын, дип саныйм. Чөнки туган илеңне яратмас өчен йә шыр надан, йә бик явыз кеше булырга кирәк...

Цитатаны хәтерләгәнчә китердем.

Эш шунда гына: кайсы территорияне туган илең дип саныйсың бит...

## Унбишенче кыйтга

*(Датасыз)*

...Туксанынчы елларда хакимият-милләтчеләр-халык коалициясе көчле иде. Бу төшенчәләр бербөтен, бер сүз, бер күренеш булып яңгырый иде.

«Татар!» булып яңгырый иде...

Бүген мәсьәлә тулысы белән үзгә: хакимият – биектә, еракта; халык – төптә; милләтчеләрнең кая икәнлеген беркем дә тәгаен әйтә алмый.

Җитмәсә, рух та элекке түгел – сынды. Дәрт тә сүнде.

Хәвеф кенә шул ук калды.

Борис Гребенщиков җырлаганча: «И люди, стрелявшие в наших отцов, строят планы на наших детей...»

## Уналтынчы кыйтга

*(Июль, 2013)*

...Куркыныч, соры, салкын бина. Түбәләрендәге шифер соңгы тапкыр кайчан алышынгандыр... Авыр тимер ишекләр аша эчкә үтсәң, идәндәге линолеумда ямау өсте ямау – калайдан, җитмәсә; котсыз таш баскычлар; бүлмә арасындагы ишекләре ничә кат буялып, аннары кубып, аннары яңадан буялып, тәмам ямьсезләнеп, шадраланып беткән. Әлбәттә, буяу аяк астына да тамгалаган (аккалаган хәтта): рам буйлап түзем, тын гына үтәргә тиешле пумала, исерек йөртүче утырган йөк машинасы кебек, шуышып, юл кырыена – пыялага чыккалаган. Беренче каттагы тәрәзәләрдә – тимер рәшәткә.

Мин хәзер бәби табу йортын сурәтләдем.

Минем улым шундый шартларда дөньяга килде.

Баланың биредә кычкырып елап җибәрүе тагын да шөбһәләндерә, барлыюклы, кирәкле-кирәкмәс уйларга этәрә: әллә иң-иң әүвәл күргән тирә-юненең шыксызлыгыннан ризасызланып «кая килеп чыктым мин?» дип ачыргалануы, «нинди котсыз җир!» дип куркып үксүеме бу?..

## Унҗиденче кыйтга

*(Июнь, 2014)*

...Салават күперендәге җете буяулардан тыш, җиһанда тагын меңәрләгән кара-караңгы төсләр һәм төсмерләр булуын чамаламаган нарасый эчпошыргыч, елмая да белмәгән дөньяны сискәндереп көлә-көлә, Җир шарының кыл уртасында чүгәләп, чуар күбәләкне сыйпарга үрелә...

Шулвакыт минем йөрәк, сугып төшерелгән бәллүр ваза сыман, таш диварга оча һәм авыр уй кыйпылчыклары булып, бөтен тирә-юньгә чәчри, җанның һәрбер күзәнәгенә барып кадала. Йа Раббым! Дию пәриләре илендә бу фәрештә валчыгын ни көтәр соң? Кем булыр ул? Нәрсә күреп үсәр? Мохите – пычрак, шыксыз, соры йортлар; әдәпсез, әхлаксыз, намуссыз, ялганчы, оятсыз, вөгъдәсез, ямьсез, куркыныч кешеләр; зәвыксыз, имансыз, буш, ялган «мәдәният», «әдәбият»... Уңыш казанырлык кеше булыйм дигән һәркемгә яңа дәвер нибары бер шарт куя, аңардан бер генә сыйфат таләп итә – шомалык. Шуңа ирешү кирәк.

Бик күңелсез заманаларда яшибез... дип өзәргә тел кычытты да икеләнеп калдым. Үзгә еллар бәйләмендә гомер кичереп, аларны үз чорың белән чагыштырып карадыңмы әллә? Замананың кайчан җиңел булганы бар? Инкыйлабка кадәр, инкыйлабта, инкыйлабтан соң? Сугышка кадәр, сугышта, сугыштан соң? Ләкин... ул еллардан аермалы буларак, безгә (миңа?) хәзер кечкенә, бүгенге көн кыйммәтләре белән янәшә куйганда, тәмам пүчтәк кенә бер нәрсә җитми: өмет. Киләчәккә өмет. Иртәгәгә.

## Эңгер

Бүген минем отпусканың соңгы көне.

Бүген мин тагын бер җәем белән хушлашам.

Кояш, тәкъдиренә карышмыйча, салкын билгесезлеккә тәгәри.

Яшьлегеннән яшьнәп торган ямь-яшел агачка багам. Талгын җилдә аның яфрак-яфрак җетелеге куба. Ул күз алдында фәкыйрьләнә, зәгыйфьләнә. Ул, җәһәннәмнән туфракны ертып чыккан чандыр шәрә кул шикелле, кәкре бармакларын тырпайтып, болай да соң сулуын алган кояшка үрелә, аны йолкымакчы була...

Яшел келәмгә салынган ямаулык сыман брезент өстендә ни-нәрсәләрдер эзләп (һәм, күренгәнчә, тапмыйча), мәш килгәннән соң, хатын-кыз, икәүләшеп:

– Кибетне урап кайт инде, – дип ялварды. Дөньяларын онытып җил куган оланнар, мин җавап биреп өлгергәнче, куанычларыннан чәрелдәп, ике ботыма чат ябышты:

– Мин дә барам, мин дә барам, мин дә барам!

Сабыйлыкка карышып буламы соң? Үземнеке шунда ук машинага сикереп менде. Кечесе, сеңелкәшнеке, аның артыннан калышмаска тырышты.

Озакламый без урманнан чыгу юлына борылдык.

Һичничек тынычлана алмаган оланнар телендә «әти» һәм «абый» сүзләре ешаеп киткәч кенә, аларның баядан бирле минем белән «сөйләшеп баруы» ачыкланды:

– Нигә Җир түгәрәк?

– Су нигә юеш?

– Карурманда кар бармыни?

– Нигә мин күзләремне күрмим?

– Нигә ташбака әкрен йөри, ул әллә бабаймы?

Еларга җыенган җиреңнән елмаерсың.

Футбол буенча дөнья чемпионатын хәерле-имин генә уздырып җибәргән башкала, ниһаять, бушанып, тынычланып, сабырланып калган. Киеренкелек кими төшкән.

Югыйсә бер атна элек сыңар шырпы чыгарып, ике бармак арасына кыстыр – шул мизгелдә үк аңа дөрләп ут кабар төсле иде. Полицейскийлар үз дөньяларына таралышкан. Шуңамы, юл читендәге куаклар да сирәгәеп калган шикелле.

Тавышлар басылган. Төсләр уңа төшкән. Күк гөмбәзе кабаттан үз урынына кайтып утырган.

Бәйрәм тәмам. Күн туптай шыгырдап торган тыгыз фикерләр генә баш эчендә һаман капка таба алмыйча бәргәләнә...

Кибет ишегенә үрелүгә кесә телефоны тамак кырды. Хезмәттәшем Мәскәү депутатларының каникулга җыенуы турында мәкалә җибәргән иде. Ахырдан: «Алар быелга үз эшен эшләде», – дип тә өстәгән.

– Бертавыштан, – дип яздым мин, язганымны телдән дә кабатлап.

– Икәү каршы. Син ни хәлдә?

– Җәй бетте.

– Кыл уртасындамы?

– Иртәгәдән эшкә кадәр һәм эштән соң гына күренеп алачак кысмыр кояшлы көннәр башлана.

– Иртәгәнең нинди булуы синнән генә тора.

Хатын тоттырган исемлеккә ябышып, кая сугылырга, нәрсәгә үрелергә белмичә, Кытай диварыдай озын һәм киң товар киштәләре арасында адашып йөргәндә, оланның олысы җиңемнән тартты:

– Әти, чүпләвек ал әле.

Ул чикләвекне шулай атый. Аның күзаллавында бу сүз чүп, чүпләү мәгънәсеннән ясалган. Дәшми генә бер пакет алып әрҗәгә салдым.

– Әти, зурысын ал инде.

– Безгә кечкенәсе дә җитә, – дидем.

– Ну, безгә зурысы да җитә бит, – диде ул.

Янәшәдә нәрсәнеңдер челпәрәмә килүен ишеттем. Иреккә чыккан тозлы помидор малайлары рәхәтләнеп таш идән буйлап йөгерешә иде...

– Ватылдырдым, – дип, үз гаебен танып, ихлас күңелдән баш иде кече олан.

Авыл ризыклары яныннан үткәндә, абыйлык, өлкәнлек (димәк – гыйлемлелек тә) хисләрен күрсәтергә теләп, мөгаен:

– Тавык йомырка сала, – диде оланның зурысы.

– Ә сыер молоко сала, – диде кечесе. Мин шунда ук аны төзәттем:

– «Сөт», диген. Әллә син урысмы?

Ул бу сүзнең ни аңлатканын белми иде, ахры. Алай да, ачуланып әйткәч:

– Юк, – дип кырт кисте. – Мин әйбәт.

Елмаеп куйдым. Хәер, елмаюым озакка җитмәде.

Шушы нарасыйлар кемгә нинди зыян-зәүрәт салган соң әле? Нигә кара җаннар калтырана-калтырана аларның авызына үрелә?..

Үзләре күрәләтә күзгә төтен җибәрә бит. Кәрт уенындагы кебек, төшенчәләрнең мәгънәсен алыштырып уйный. Һичнинди сайлау мөмкинлеге булмауны иң гадел сайлау мөмкинлеге дип ышандырырга тели. Капкынга салынган бармак очы кадәр сыр кисәгенә ишарәләп:

– Юкса, ачтан үләчәксең, – дип куркыта.

Борылышта катырак каердыммы, күрше утыргычта барган язу-сызулар аяк астына ишелеп төште. Машинаны туктатып, аларны җыештырырга керештем.

Мин биш ел матбугатта эшләдем. Ул арада ярыйсы гына язу язылган – шуларны беркадәр игә китереп, китап итеп чыгарырга җыенам.

Хәзер мин үзгә җирдә эшлим. Бик җитди урын ул. Иҗаттан бик ерак та.

Хәзер миңа уйлаганымны әйтергә, әйткәнемне язарга, ә язганымны бастырырга ярамый. Ләкин мин бу хәлнең вакытлыча булуына өметләнәм... һәм үземне, элеккечә, фәкать язучы итеп күрәм.

Мин бу китапны бик тырышып, вакланып эшлим.

Алай да, күңелдән корт китми: галәм киңлегеннән берәмтекләп сайлаган-чүпләгән сүзләремнең кадер-кыйммәтен тоючы булырмы? Ун елдан? Егерме елдан?

Оланның кечесе йоклап киткән иде. Өлкәне алга үрелеп:

– Әти, ә мин беләм Тукай нишләгән, – диде.

Олан шигъри әкиятләрдән озын-озын өзекләрне яттан сөйли. Бүреләрнең Кәҗә-Сарык белән уртак тел таба алмавына үртәлә: ботка барысына да җитәр иде бит, имеш. Кыскасы, белә ул Тукайны.

– Нишләгән?

– Үлгән, – диде олан.

Мин аны башыннан сөйдем.

Игътибарым кул арасына кергән кәгазьләрнең берсенә төште: «...кайчак тешләреңне кыса-кыса, җаныңны ерткаларга теләгәндәй, күлмәк изүеңне умырган чаклар була: барысы начар, үзең дөм сукыр, ә тирә-юнең дөм караңгы кебек тоела башлый; бүгенгеңдә генә түгел, киләчәгеңдә дә яктылык шәйләнми һәм мәңге шәйләнмәячәк сыман; егыл да үл менә... Ләкин чынлап еласа, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр бит, ә без бүген кызарынып-бүртенгәнче рәхәтләнеп еларга сәләтле әле...»

Бу язманы укып чыккач, җанга беркадәр сабырлык иңде. Китапны тәмамлар өчен яхшы кыйтга икән, дип уйладым. Ул булмаса, әлеге хезмәтемнең дә мәгънәсе булмас иде. Алай гынамы? Ул булмаса, гомумән, яшәгән гомеремнең дә мәгънәсе булмас иде. Төзәтмәләр белән чуарланып беткән кәгазь битен читкәрәк алып куйдым.

Бүген егерме бише.

Үзем теләгәнчә яшәгән соңгы көнем.

Бүген мин җәй белән хушлашам. Хәер, нәрсә ул җәй? Юкә чәчәге исеннән исереп айну арасы гына... Бүген мин тарихымдагы тулы бер чор белән мәңгелеккә хушлашам.

Коры-сары өметләр һәм ышанычлар кебек чатнап-сынып, учак яна. Әле соң түгел. Ләкин шунысы шиксез: тимер тартмада уйнаклаган тыйнак куз дулкыны

озакламый, хәзер менә, якты күздә, офык буйлап йөгерәчәк һәм гамьсезлектән исәнгерәп утырган дөнья тоташ ут эчендә калачак...

Кем белә, бәлки, алай хәерлерәктер дә?

Кем белә, бәлки, ул очракта төн җитмәс?

Без кызган иттән авыз иттек. Хатын-кыз ду килеп мактанышса да, миңа ул коры һәм тәмсез тоелды. Кибеттән җыйган тәм-том да һушымны алмады.

– Әти, морожный тәмлеме?

– Татарча туңдырма була ул.

– Тәмлеме соң?

Анысы һәркемгә берешәр тигән иде. Олан үзенекен юк итеп, хәзер өметле күзләрен минем өлешкә төбәп тора иде.

– Тәмле.

Бу сүзләрдән соң нарасый, эче пошкан кешедәй, әрле-бирле йөренергә тотынды. Үзенә урын тапмады. Аннары йөрәгендәгесен ачты:

– Әти, делиться татарча ничек була әле?

Мин туңдырманы аңа суздым.

Бала рәхмәт йөзеннән иренемә гаять сусыл, татлы йөзем җимеше тигерде. Муеныма сарылып:

– Күзеңне йом, авызыңны ач, – дип башлады ул сүзен. Ризык тел өстенә тәгәрәгәч: – Ә хәзер күзеңне ач, авызыңны йом, – дип тәмамлады.

Ул арада, урман читеннән дөбердәп узган поезд тавышы уятканмы, күз төпләрен уа-уа кече олан торып чыкты:

– Мин йоклап бетердем.

Без ял итә торган урман читенең бер ягында – бүзәргән басу, икенче ягында – бакчалар: яңгырдан соң шыткан төп гөмбәләре сыман, анда-монда калын эшләпәле чуар йортлар таралып ята. Мин еш кына, оланнарны да ияртеп, авылга охшаш шул тарафка юл тотам.

Бүген дә шулай иттем.

Кече олан карга санап барган җиреннән тамырга абынмакчы иде, беләгеннән тотып алырга өлгердем:

– Егыла күрмә.

Бу гамәлем өлкәненә сәер тоелды, ул, энекәшен яклап, әллә аның өчен горурланып хәтта:

– Соң, ул бит егыла белә, – диде. Аннары, иксез-чиксез кырга ишарәләде: – Бу нинди чәчәкләр?

– Карабодай басуы.

Олан әле очсыз-кырыйсыз киңлеккә, әле миңа сынап караганнан соң, барыбер килешмәскә булды:

– Ап-ак бодай басуы бит.

Мин бирегә шактый киң булып кергән юлның кинәт тар сукмакка әверелеп калганын абайладым. Ул тагын да тараеп, аркылы яткан тимер юлдан соң гына янә киңәя төшә һәм, ниһаять, офыкларга барып тоташа иде. Оланның кечесе бер урында таптана-таптана мәгърип белән мәшрикъны барлаганнан соң, ихлас борчылып:

– Адаштык, – диде.

– Юл бар бит әле, – дип, аңа каршы төште өлкән олан. – Димәк, адашмадык.

Мин тынып калдым.

Ишеткән сүзләремне кат-кат күңелемнән кичердем.

– Елмай, әти, – диде олан.

Сабыйлыкка карышып буламы соң? Әллә ничек хәл-халәтем җиңеләеп киткәндәй тоелды. Әйтерсең, күкрәк турыма бертуктаусыз тибеп юанган авыр албасты җилкәмнән төште. Күңел төбенә җыелган терекөмеш хисләр таралды. Мин ерак офыкка төбәлдем.

Без, әлбәттә, шлагбаум каплаган юл аша исән чыгачакбыз.

## Соңгы кыйтга

*(Датасыз)*

...Милләтемә карата беркайчан да ышанычымны җуймадым мин. Хәзер дә җуймыйм. Киләчәктә дә, Аллаһ боерып, зиһенемдә калсам, җуярга җыенмыйм.

Әлбәттә, кайчак тешләреңне кыса-кыса, җаныңны ерткаларга теләгәндәй, күлмәк изүеңне умырган чаклар була: барысы начар, үзең дөм сукыр, ә тирә-юнең дөм караңгы кебек тоела башлый; бүгенгеңдә генә түгел, киләчәгеңдә дә яктылык шәйләнми һәм мәңге шәйләнмәячәк сыман; егыл да үл менә... Ләкин чынлап еласа, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр бит, ә без бүген кызарынып-бүртенгәнче рәхәтләнеп еларга сәләтле әле...

Димәк, барысы да ул кадәр үк начар түгел.

Бетәбез, дип, вакыт-вакыт артыгын хафаланабыз кебек. Безгә кадәр дә шулай килгән. Инде, чираты җитеп, ниһаять, без дә шуны кабатлыйбыз. Инерция буенча. Бу барлык халыклар, һәрбер кеше өчен табигый хис, әлбәттә: курку. Киләчәгең, нәселең өчен курку. Әле дә ярый ул бар. Чөнки моңарчы шул хис безне исән-имин яшәтеп килде, җырларыбызны, әкиятләребезне, бөтен халык авыз иҗатын, гомумән, сәнгатьнең һәр төрен – сөлге чигүдән алып шигырь язуга кадәр – югалттырмыйча, саклап, гасырдан-гасырга тапшырттырды. Безгә аннан һәрьяклап файда гына: курку булганда, күзгә йокы керми, тынгысызланып, борчылып, уйланып ятасың. Алдан баручыга карап үз хәлеңнән елыйсың, артка карап юанасың. Бездә, татарда, бу хиснең әлегәчә сакланып килүе – куаныч! Бу – авызлыгыңны кимереп, өзәргә тырышырга, алга тартылырга, үрелергә, тешең-тырнагың белән тормышка ябышып, өскә күтәрелергә өстәмә стимул, мотиватор бит! Тук кеше ризык турында уйламый ул. Шулай ук иркенле кеше богау турында уйламый. Шулай ук сау кеше, хастадан аермалы буларак, чир турында, бигрәк тә – үлем турында уйламый...

Татарга, кызганычка каршымы, бәхеткәме, рәхәткә омтылу да хас шул. Иртәгә рәхәт чигәр өчен ул бүген тәмугка керергә риза: шахтага да төшә, Себергә дә китә, япан кырда заводлар да кора. Шушы хис харап итә дә инде безне. (Бу хисне икенче төрле тырышлык та, диләр әле.) Тир түгеп, дәүләтләр төзибез, кан-яшь түгеп, аны дошманнардан саклыйбыз, аннары, һәммә теш кайраучының барлык тешләрен бәреп төшергәннән соң, иркен сулап, көбә-шишәкне салып, кулыбызга сука яисә без-шөшле алабаз; тагын бераздан, иген белән читек тә җитәрлек булгач, түшәккә менеп ятабыз. Шулай йокыга китәбез. Уяулык югала. Дошманның коелган тешләре урынына яңалары үсеп чыкканын сизмибез дә. Шулай түгелмени? Ни диярсең, Болгар? Җитмәсә, бер-беребез белән талаша, тарткалаша да башлыйбыз әле. Алтын Урда, аның кыйпылчыклары – Казан, Кырым, Нугай... Ни диярсез?

Ул яктан, мәсәлән, урыс халкы бәхетлерәк: алар беркайчан да рәхәт яшәмәгән.

Безнең соңгы ләззәт кичүдән соң биш гасыр айныган юк инде. Нишләтәсең?

Иң мөһиме – курку хисе югалмасын.
Күңел тынычлыгы һич ярамый безгә!
Күңеле тыныч татар бүген маңкортка әверелә...

Иманым камил: бу милләттән Илаһ йөзен чөермәде әле. Ул торымнан-торымга безгә мөмкинлек биреп кенә тора. Нигә еракка китәргә? Узган йөзнең егерменче, туксанынчы елларын искә төшерик. Бер гасырга – ике, ягъни илле елга бер тапкыр азатлыкка тиенү форсаты туган! Моңарчы ниятебезгә ирешү насыйп булмады. Әйе, кызганыч. Ләкин тарих спираль буенча әйләнә, дибез бит. Димәк, киләчәктә тагын бер мөмкинлек, ә анысыннан да коры калсак, тагын бер мөмкинлек булачак әле! Шуңа әзер торырга һәм... шуңарчы исән калырга гына кирәк.

Шәхсән мине барлык күңелсез уйлардан ныклы ышанычым яклый: һәрвакыт болай бара алмый, барысы да берәр кайчан үзгәрергә, һичшиксез, уңай якка үзгәрергә тиеш! Аллаһ Тәгалә кешене дөньяга яратты икән, тиккә генә яратмагандыр бит? Мин (яки миллионлаган башка берәү) дөньяга татар өммәтеннән булып туганмын икән – юкка түгелдер! Димәк, минем татарлыгым, татарчалылыгым кешелек, дөньялык өчен кирәкле булган. Мин үземнең бөек ханнар, бөек шагыйрьләр, бөек галимнәр телендә аралашуымны, алар телендә – дөньяның иң камил телләренең берсендә! – язуымны беләм. Гәүдәмне ураган тамырларда аларның кан җылысын, җан җылысын тоям. Үткәнемнең шанлылыгын, данлылыгын, мәгърурлыгын исемдә тотам, бүгенгемнең сорылыгын, күңелсезлеген таныйм, ләкин иртәгәмнең бүгенгедән генә түгел, кичәгедән дә төслерәк, матуррак, шанлырак, данлырак, мәгъруррак булачагына ышанам. Ә торыннарым миңа карап төкеренмәсен өчен, алар алдында хурлыкка калмас өчен – тыйнаксыз тоелсам, кичерегез! – бүгенге сорылыгымда гадел һәм дөрес яшәргә, булган егәремне, көчемне халкым, аның әдәбияты, аның мәдәнияте өчен сарыф итәргә тырышам.

Бәгъзеләр хәтерли булыр (хәтерләмәсә дә зарар юк): суверенлык кояшы астында үсеп, шул кояшның баеп барышында буйга җиткән чакта мин әдәбият мәйданына «Ышанам халкыма!» дигән бисмиллам белән аяк бастым. Әлегәчә ул шигыремә дә, үз шигаремә дә хыянәт иткәнем юк. Ышанам! Мәңге ышаначакмын! Сөембикә үле бала табып, үзе вафат булса да, Болгар манарасы ишелеп, Җәгъфәрне таш басса да, минем ышанычым барыбер чеметем дә кимемәячәк. Мин милләтемнең сау калачагына, тернәкләнеп китәчәгенә ышанам. Авыр туфрагының җиңел булуын теләп, каберенә кемсәләрдер йомарлам-йомарлам балчык ыргытканда да, аның, кәфенлеген ертып, «Яшим!» дип оран салачагына ышанам.

Мин шуның белән бәхетле.

Мин ул бәхетне сезгә дә телим.

*2010 – 2019*



Зимфира
Исламова

# ТАПШЫРЫЛА ДӘВЕР ҮТЕНЕЧЕ

## Ах, бу хәтер!

Ах, бу хәтер!..
Иләнәсе иләнгән дә
Калган гыйззәт ятмалары...

Үткәннәрдән күчтәнәчләр килә
Тартмаларда –
Баллы, татлы!
Һаман килә өем-өем
Бер-бер артлы...
Һәр тартмада тәгамнәрнең
Иң тәмлесе;
Сурәтләрнең иң купшысы,
Нәкышлесе;
Көнкүрешнең, яшәешнең
Шат, гамьлесе –
Алып кына өлгер,
Таң атуга далаларга
Таратканчы җилләр...

Нигә шундый татлы икән,
Кәрәздәге балдай
Хәтер күчтәнәче?

Чылбыр булып тапшырыла
Дәвер үтенече
Өтерләрдә...
Өзелмәскә буын бәйләнеше,

Зимфира ИСЛАМОВА (1958) – *шагыйрә; «Бер тамчы җәй», «Язмыш аръягында кем көтә?» һ.б. китаплар авторы. Тукай районы Зур Шилнә авылында яши.*

Үткәннәрме йөри әйләнешеп
Хәтерләрдә?
Бу хәл миндә генә мәллә??

Замандашлар:
«Әллә нинди син», – дип
Әйтерләр дә!..

***

Күз алдыңа китер
Минсезлекне.
Әле синең бер дә
Кичергәнең юк ла...
Ә син көлмә!
Иртә дә мин, кич тә янда,
Әле артта бераз, әле алда...
Булмый торсам тик бер ара,
Син беләсең: кайтып барам
Синең янга
Тутырырга тормышыңны
Моңга... зарга...

Мәгънә эзләп азапланма
Минем сүздән.
Кояш нурын көлә-көлә
Түккән кебек,
Сөйлим генә –
Таш сытарлык тынлык
Китсен бездән.
Ишек ачык – керсен кичке
Җиләс һава.
Син дә сөйлә... болай гына...
Сине тыңлау
Үзе савап, үзе дәва.

Минсезлекме?
Астан упкын булып килер,
Өстән басар тимер гере.
Кайсы якка талпынсаң да,
Мин булмамын.
Ә син тере...
Бушап калган бүлмә эче
Бәллүр савыттай чыңлар,
Ай сузылып, форточкадан
Соңгы сүрәне тыңлар.
Очып йөрер бер күбәләк,
Ышандырып чынга:
Булмас исем... төсем...
Минем җисем...
Күз нурларым сеңгән
Яран калыр саклап
Тәрәз төбен.
Минле чакта борчуларның
Онытырсың инде күбен...
Көйләргә дә кирәк булмас
Күңел сәгатемнең
Ватык телен.
Каш җыерма,
Әллә ниләр язганыма.
Күз алдыңа китер бары
Минсез чакны... азга гына...

## Гүзәл җыр

Бер гүзәл җыр туып ята таң нурында
Зәңгәр күзле язның назлы сүзләреннән.
Һәр юлында, аяз күктән көлгән кояш
Нурын үбеп, иркәләнә чыклы үлән.

Тамчыларның энҗе кебек җемелдәвен
Исе китеп карап тора аксыл болыт:
«Сихриятне яшем белән бозмам микән,
Күңелләрем кинәт, – диеп, – саксыз тулып».

Гүзәл җырга нур өстенә нурлар сирпеп,
Ап-ак чәчәк ата чия, алмагачлар.
«Ишет, – диеп, – Туган җирем, сөюемне!»
Көйгә салды җырны моңлы сандугачлар.

## Сурәт

Кулларымда икәү төшкән
Аклы-каралы сурәт.
Ничек таптым?! Кызым йөри:
«Күрсәт, – дип, – әни, күрсәт».

Елмаеп тора үткәннән
Аклы-каралы бәхет.
Бер-берсенә елышканнар,
Күз карашлары – бәрхет.

Бу карашка сыйган Галәм,
Бар матурлык, гүзәллек!
Сөю җыры ургыладыр,
Үзәкләрне өзәрлек...

Егет башын кыңгыр салган,
Кызы – назлы гөлчәчәк.
...Пар күгәрчен гөрләшкәндәй,
Йөргәнбез шатлык чәчеп.

Икебез дә йөрәктәге
Хис ташкынын тыймадык.
Бер сурәткә сыйганбыз да,
Бер язмышка сыймадык...

## Син, чор, дисең...

*Кышкы чия... Кемерево... 25.03.2018. 16.00.*
*Сәүдә үзәгендә 64 кешенең гомере өзелде.*
*Шуларның кырык бере – балалар, диделәр...*
*Шушы сабыйларның якты рухына багышлыйм.*

Син, чор, дисең, вакыт, дисең...
Ә секундлар?
Секундлары гасырга тиң,
Ут-ялкынга кергән булсаң –
Ялкын телен бер мизгелдә
Чәч бөртегең, һәр керфегең,
Үпкәдәге күзәнәгең,
Тырнак очың белән тойсаң...

Тынны буа төтен өтеп...
Ут эченнән шул вакытта
Оран килә, тетрәндереп:
«Әти, әни, мин яратам!..
Ярата-а-ам сезне... хушыгы-ы-ыз...»
Йә, шуннан соң җаныгызга
Боз булырга кушыгыз?!
Гомерләре өзелгәндә –
Төтеннән аң киселгәндә,
Ачу һәм дә үпкә түгел,

Иң-иң мөһимен бу җирдә –
Яратуны белдерделәр!
Өлгерделәр...
Ә гомерләр... секунд иде...

Шул секундлар Кешелекне
Асылына кайтаралыр.
Кемнәр анда – акча колы:
Байлык, диеп, лаф оралар –
Тукталыгыз! (Адәм икән).
Яшәү – каһәр, сугыш түгел,
Ә мәңгелек СӨЮ икән!
Соңгы секунд – гомер соңы:
«Мин бик тә яратам сезне!..» –
Ишет, Галәм, бала моңын!

Кемнәргәдер гомер буе
Вакыт җитми аңларга.
Ә аларга секунд җитте –
Яшәү серен безгә ачып,
Ягылдылар таңнарга.
Һәм калдылар секунд түгел –
Мәңгелеккә аңнарда...

## Әле минем синле чагым

Әле минем синле чагым –
Көлә-көлә,
Йөзләремдә кояш бии.
Үзем кояш
Нуры булдым – нәрсә диим?!

Әле минем синле чагым:
Очам, гүя,
Аякларым тими җиргә.
Исем китми
Итәгемнән тарткан җилгә.

Әле минем синле чагым.
Кочак-кочак
Бәхет түши эзләремә
Алтын кулы
Мәхәббәтле күзләремнең.

Әле минем синле чагым!
Сукмак буйлап
Китүеңне, кайту диеп,
Белгән чагым.
Нәүмиз итмә, күзләр тиеп...
Әле минем синле чагым...



Нәсих
Таҗиев

# ЧИККӘН КУЛЪЯУЛЫК

хикәя

Яз... Быел ул авылда да, шәһәрдә дә иртәрәк килде. Кышын ишеп яуган кар өемнәре март башында ук ямьсезләнеп, иске бишмәт төсле керләнеп-каралып, бөтен матурлыгын җуйды.

Карлы яңгыр озак яуды. Таң сызылганда гына туктады ул. Авылларны район үзәге белән тоташтыручы асфальт түшәлгән юлның чокырлы-чакырлы урыннарында күлләвекләр җыелган. Иртәнге сәгатьтән үк юлга кузгалган машиналар ул суларны як-якка чәчрәтә-чәчрәтә ашыгалар.

Менә шул машиналарның берсе, яшел төстәге «Жигули», район үзәгендәге бизәкле тимер койма белән әйләндереп алынган ике катлы таш пулатның капка төбенә килеп туктады. Иске булса да, яхшы хуҗа кулында сакланган машинадан олы яшьтәге бер агай төште. Колакчын куян бүреген салмаган, кыска җылы курткасы авыл кешесе икәнен сүзсез дә аңлатып тора. Ул юл сумкасын алды, аннан машинаның ишекләрен бикләп, берәм-берәм тикшереп чыкты һәм түбәсенә зур хәрефләр белән «Сәламәтләндерү үзәге» дип язылган капканы ачып, эчкә узды.

Аны ишек төбендә үк күптән көтелгән кадерле кунак сыман каршы алдылар һәм икенче каттагы олы бер бүлмәгә чаклы озатып, компьютерлы, язу-сызу әсбаплары белән тулы өстәлләр артында утыручы бик мөлаем яшь кенә бер ханым хозурына тапшырдылар.

– Әйдә, абый, түргәрәк узыгыз. Күреп торам: ерак юлдан килгәнсез, арыгансыздыр, утырыгыз. Олы кеше белән аяк өсте сөйләшмиләр бездә, – дип, бик җылы итеп елмайды ул.

«Хуҗаларыдыр инде», – дип уйлады абзый һәм сумкасыннан үзе белән алып килгән юлламаны, паспортын алып, шул сөйкемле ханымга сузды.

– Безгә беренче мәртәбә килүегезме, Искәндәр абый? – Документларын укыгач, аңа бу юлы исеме белән дәштеләр.

– Алтмышка җитеп, читкә алты адым да ясаган кеше түгел дияр идем, дөнья булгач, район үзәгенә еш киленде, әмма шуннан ары чыкканым булмады.

---

Нәсих ТАҖИЕВ (1938) – *журналист һәм шагыйрь; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Баскыч һәм элмәк», «Кояшлы гөл» китаплары авторы. Чаллыда яши.*

Гомерем иген басуында җир сөреп, фермада малларга кыш буе салам ташып узды. Ял йортларына да, санаторий дигәннәренә дә кыстадылар. Бер елны район сабанчылар конкурсында җиңгәч, Кырымга путёвка бирделәр хәтта. Бармадым, хатынны берүзен җибәрдем. Әле сезгә дигәненә дә фельдшерыбыз, Әлфия исемле бик миһербанлы кыз бала үзе районнан юллама алып кайтып бирде. Искәндәр абый, ялгыз башың тәрәзәдән карап моңаеп ятма, бар, кеше күреп, сәламәтлегеңне ныгытып кайт, дип, бик кыстагач кына ризалаштым, балам.

– Ә нишләп берьялгызың, диден, хатының, балаларың юкмыни?

– Хатыным үлгәнгә сигез ай. Егерме елдан артык шикәр чиреннән интекте. Күзе күрмәс, колагы ишетмәс булды, бер аягын бот төбеннән кистеләр бәгырькәйнең. Үлеме дә кинәт кенә, аяк өсте дисәм дә ярый, иртән тәһарәт алып, намазлыгына басты да балта белән чабып аударган агач сыман идәнгә сыгылып төшеп, намазлыгы өстендә җан бирде.

– Урыны оҗмахта булсын, изге җан икән. – Өстәл артындагы ханым, авыр сөйләшүне өзеп, шулай диде.

Тәрәзәсе урам якка караган бу бүлмә ике кешелек иде, караватлар пөхтә итеп җыелган, каз мамыгыннан булмаса да, күпертеп куелган мендәрләр... Шәһәрдәгечә, ваннасы белән бәдрәфенә кадәр бар.

– Абый, куясы ризыкларыгыз булса, коридорда суыткыч та бар. Ашыкмагыз, иркенләп урнашыгыз да бездән кәгазьләрегезне алып, табибка керерсез, – диде дә чибәр ханым чыгып китте.

Искәндәр асылмалы юл сумкасын ачты. Кирәге чыгар дип, бер тавыгын суеп, үзе йолкып-чистартып, пешереп өлгергән иде, шуны төреп алып килде. Пөхтәләп төргән спорт костюмын кияргә ниятләп, караваты өстенә куйды. Ул хатыны исән чакта Чаллы базарына барып алып кайткан, кисә дә бер-ике генә кигән кара төстәге буй-буй сызыклы костюм-чалбарын киеп килгән иде. Элек кая барсалар да, киемен һәм башка кирәк- яракларын хатыны үзе барлап, үзе сайлап ала, Искәндәрне бала киендергән кебек киендерә торган иде. Хәзер уңга караса да, ялгыз, сулга борылса да, сөйләшер, киңәшер кешесе юк. Балалары: бер кызы Казанда, икенчесе Чаллыда, үз тормышлары белән көн күрәләр. Аналарын җирләгәч, баштагы мәлне ешрак кайткалап тордылар Тик: «Әти, ялгыз яши алмассың, күчеп кил безгә», – диючесе булмады. Әйтсәләр дә, бармас иде ул. Кызларың үзеңнеке булса да, кияү бит – чит кеше баласы. Гомер буе олы йортта хуҗа, хатынга – ир, балаларга чын әти булып яшә-яшә дә карт көнеңдә кияү кулына кал: ул тапканны ашарга, ул кушканча яшәргәме? Юк, Искәндәр анысын булдыра алмый инде. Ир кешегә ялгыз яшәү авыр, диләр. Анысы хак, баштарак Искәндәр ашын да пешерде, сыерын да сатмады – үзе сауды, үзе көтүгә куды. Тавыкларын да карарга өлгерде.

Кышны бигрәкләр авыр чыкты ул. Күршегә керми, беркемгә бармый, кар яуса – көрәп, яумаса – диванда аунап, телевизор карап, көн уздырды. Фельдшер Әлфия ишек шакымаса, язы да шулай бертөсле үтәр, җәе дә җитәр иде. Бар, дигәч, карышмады, күрәсең, үзен дә ялгызлык туйдыргандыр. Кичтән җыенды, иртән иртүк торып, юлга чыкты.

Җыенды дигәчтен дә, ул юл сумкасына нәрсә салырга, нәрсәләр алырга белми аптырады. Үз гомерендә түр яктагы шифоньерның ишеген ачканы юк иде. Бүген ул аның ике ишеген дә ачып куйды – аласы, киеп барасы киемнәрен барларга кереште. Шунда ул бик күптән күзенә чалынмаган, барлыгы истән дә чыга башлаган карасу-яшькелт төстәге солдат мундирын чөйдән алып, беренче мәртәбә күргән кеше сыман, бик озак әйләндерә-әйләндерә карады. Иренмәде, өстендәге киемнәрен салып, галифе чалбарын, ялтырап торган җиз

төсле мундирын, элгечләр өстенә ясалган киштәдән йолдызлы фуражкасын киеп, көзге каршына килеп басты. Егет чагында озынча буйлы, шомырт кара куе чәчле, типсә тимер өзәрдәй гәүдәле, солдатта чакта ике потлы герне йөзәр мәртәбә «эһ» тә итмичә һавага чөйгән егет иде ул. Гомер тиз уза икән. Кайчандыр мәһабәт гәүдәсенә сыланып торган кием зурайган бугай, буш капчык сыман салынып тора.

Искәндәр, ыспайланырга маташып, күкрәк турысын сыпырып алды. Бер кесәсе күперебрәк торган шикелле тоелды аңа. Башта ул акча микән әллә, хатыны салып куйгандыр да оныткандыр, дип уйлаган иде. Акча да, солдат хаты да түгел бу – бик тә нәфис ефәк кулъяулык иде! Дүрткә бөкләнгән, кер дә кунмаган, еллар узып та хуш исләре бетмәгән. Зәп-зәңгәр җепләр белән челтәрләп чигелгән әлеге кулъяулык Искәндәр өчен яшьлегендә бик кадерле һәм истәлекле булса, йөрәктә яра калдырган, аның саф мәхәббәтенә хыянәт китергән көннәрнең инде онытылып беткән хатирәсе дә иде. Ул кулъяулыкның бер почмагына җете кызыл җепләр белән чигелгән сүзләрне, күзе начар күргән кеше сыман, әле бер ягын, әле икенче ягын әйләндереп, әллә укыды, әллә уйлар дөньясына чумып, шактый ара онытылып торды.

Искәндәр кулындагы кулъяулыкны пөхтәләп, дүрткә бөкләде дә инде гимнастёрка кесәсенә салмыйча, киеп барасы костюмының кесәсенә тыкты. Ни өчен болай эшләгәнен ул үзе дә бу мизгелдә әйтә алмас иде. Күңеле нишләптер нечкәрде, алда аны нидер көткәндәй билгесез хисләр кайнады.

Ул төнне күзләренә йокы кунмады Искәндәрнең, таң алдыннан гына бераз черем итеп алды. Күп нәрсәләр исенә төште аның, шул кулъяулык яшьлек хатирәләрен язгы ташкын сыман айкады...

Ул урынында микән дигән сыман, түш кесәсенә тыгылып, кулъяулыгын капшап карады. Онытып та җибәргәнмен, врачка керергә кирәк бит әле дип, утырган җиреннән торып, ашыга-ашыга ишеккә атлады.

Врач бүлмәсе шул ук катта икән. Шактый озын чират җыелган. Күбесе дивар кырыйлап куелган урындыкларга утырган, басып торучылары да җитәрлек. Искәндәр шулар янәшәсенә килеп басты.

– Минем арттан булырсыз, – диде аңа алдарак басып торган, күзгә ташланырлык чәчкәле озын күлмәк, кызыл төстәге җылы кофта кигән бер ханым. Ул бу сүзләрне башын бераз гына борып әйтсә дә, Искәндәр аның йөзендә ниндидер таныш төсмерләр күреп өлгерде. Буй-сыны да кемнедер хәтерләтә иде. Әллә берәр таныш кешегә охшаган гынамы?

Була бит шулай, берәрсенә читтән җентекләп карап торсаң, кешедә сиземләү тойгысы көчәя. Менә ул Искәндәргә борылып карады. Сүзсез генә баштан-аяк күздән кичерде дә:

– Сез Яшьлек авылыннан түгелме? – диде.

Искәндәр аны бер карауда танып алды. Илле ел гомер узса да, ул белгән унҗиде яшьлек чая, чибәр кыз бер дә үзгәрмәгән шикелле тоелды аңа. Үзгәрмәгән дип, ул яраткан сылу буйлы, карлыгач койрыгы сыман сызылып торган кара кашлы, кызыл ефәк тасмалар белән үрелгән, биленә чаклы төшеп торган толымлы Өнҗүдә түгел иде аның каршысында... Шул толымнарын кисеп, җилкәсенә җитәр-җитмәс кенә калдырып, коңгырт төскә буяган. Зәп-зәңгәр күзләрендә яшь чактагыча очкын уйнап тормаса да, инде шактый олыгайган, зифалыгын җуйган, шулай да һаман мөлаем Өнҗүдә иде бу.

– Син дә ял итәргә килдеңме, Өнҗүдә? – диде ул, исәнләшеп тә тормыйча. Әйтерсең лә гел очрашып, гел күрешеп торган танышлар.

– Әйе. Син һаман да авылдамы, Яшьлектәме, диюем? Үзең генә килдеңме, әллә хатының да мондамы?

Искәндәр, башта кайсы сорауга җавап бирим икән, дигән сыман уйланып, сүзсез торды. Аннан:

– Үзем генә, Әнҗүдә. Хатыным вафат булды, җәйгә елын үткәрәбез. Ә син кайда яшисең хәзер? Шулкадәр гомер узып, авылга да кайтканың булмады бугай, әллә юлларыбыз гына кисешмәдеме?

– Кайталмадым шул, Искәндәр, – диде ул, ниһаять, аңа исеме белән эндәшеп, – язмышым туган җирләрдән еракта йөртте. Тормышымны көйли алмадым, яшьлегем белән күп ялгыштым. Беренче зур ялгышым – сиңа биргән вәгъдәмне бозуым булды.

Шунда сүзләре өзелде. Әнҗүдәнең чираты җитте, ул врач бүлмәсенә кереп китте. Искәндәр дә бушаган урындыкларның берсенә килеп утырды...

Әнҗүдә бер колхозга, бер үзәккә караган күрше авыл кызы иде. Урта мәктәп тә алар авылында иде. Искәндәр шунда йөреп унны бетерде, ул аттестат алганда, Әнҗүдә сигезне генә тәмамлаган, буйга җиткән һәм классташлары арасында гына түгел, бөтен мәктәптә чибәрләрнең дә чибәре төсле тоела иде аңа. Алар укыганда ук аерылгысыз пар булдылар, качып-посып күрешмәделәр. Дәресләр бетү белән Искәндәр, күрше авыл егете булса да, Әнҗүдәне көн саен өенә чаклы озатып куя иде. Өйләренә кергәләде, әти-әнисе бик тә итагатьлеләр, Искәндәрне яраттылар, чәй эчерми озатмаслар иде. Мәктәпне тәмамлагач та, һәр кичне шул авыл юлын такырайтты ул. Кыз бик матур итеп бии, җиңел гәүдәле, биегәндә, аяклары идәнгә тимәс иде. Ә Искәндәргә Ходай моңлы тавыш биргән, аның җырлавын Әнҗүдәсе генә түгел, бөтен авыл таң калып тыңлый, концертларда катнашсалар, икесенә дә дәррәү кул чабарлар, кат-кат сорап биетер-җырлатырлар иде.

Аттестат алган җәйне үк Искәндәр комбайнга утырып, иген урды, ашлык суктырды. Беренче урагында ук районның яшь комбайнчылары ярышында кыр батыры булды. Шул көзне аңа хәрби комиссариаттан повестка килде. Армиягә китәсе атнаның һәр төнен таң әтәчләре кычкырганчы, бергә утырдылар. Вәгъдәләр куештылар. Иртәгә юлга дигән кичне кыз аңа читләрен үзе каймалап, бер почмагына: «Көтәм сине. Әнҗүдәң» дигән сүзләр чигеп, ефәк кулъяулык бүләк итте. Бүген аның түш кесәсендә шул кулъяулык иде...

– Искәндәр, Искәндәр дим, әллә мәрткә киттеңме? Синең чират, бар, кер врачка.

Ул уйларын кабат яшьлегендә калдырып, башын күтәрде.

Врач бүлмәсеннән тиз чыкты ул. Әнҗүдә китмәгән, урындыкка утырып, аны көтә иде. Урнашып беткәч очрашырга сөйләшеп аерылыштылар.

***

Килгән көннәреннән башлап алар аерылмас пар булды. Ашханәгә дә бергә йөрделәр, бер өстәл артында кара-каршы утырып ашадылар. Дәвалау бүлмәләренә дә икәүләшеп керделәр. Ял итүчеләрнең күбесе бер-берсен беренче мәртәбә күрә, төрле авыллардан, хәтта күрше район-шәһәрләрдән дә килүчеләр күп. Шуңадыр аларны ирле-хатынлы бик матур пар, күз тимәсен үзләренә, дип йөрүчеләр дә бар иде. Үзләре дә язмышларын башкаларга ачып салмадылар.

Кичләр җитте исә, икенче каттагы «кышкы бакча» дип телгә кергән гөлләр арасында сөйләшеп туя алмыйлар. Сорашасы, аңлашасы сүзләре үткән гомер юлында күп җыелган шул. Читлеккә ябылган кенәри белән чибәр тутый кош та, алар керә башлагач, җанланып киткән төсле булды. Ялгыз кенәри читлек эчендәге чыбыкка кунып сайрап ала, тутый кош та, мин берьялгызым дигән сыман, аларга озак кына карап торганнан соң, үз телендә ашыга-ашыга нидер

сөйләргә тотына. Тик Искәндәр белән Әнҗүдәнең генә бу читлек кошларында гамьнәре юк бүген. Алар яшьлек бакчасында Искәндәрне армиягә озатасы кичтә очрашкан сандугачлы беренче мәхәббәтләренең гомерлек шаһиты, авылга исем биргән Яшьлек чишмәсе буенда.

– Ул бәхетле кичтән соң күп гомер узды инде...

– Картаюын картаймадык әле, олыгаябыз гына. Ә менә кадерле әйбер тузмый да, искерми дә, ышанасыңмы шуңа? Син биргән ефәк кулъяулык менә ул, кер дә кунмаган, чигеп язган сүзләреңнең бер хәрефе дә уңмаган.

Искәндәр пөхтәләп дүрткә бөкләнгән кулъяулыкны Әнҗүдәгә күрсәтте.

– Ни гомерләр үтеп, ничек сакладың аны, Искәндәрем? – Болай кинәт кенә үз итеп эндәшүенә Әнҗүдә үзе дә уңайсызланып куйды, сөешеп-яратышып йөргән яшьлек елларында гына ул «син» дип эндәшә торган иде. Искәндәр дә моны онытмаган икән:

– Әнием дә сине нык яраткан иде. Игелекле бала күренә, әллә яучылыйбызмы, дигәне дә хәтердә. Армиягә барасым бар, кайткач туйларбыз, дигән идем. Килен каенана туфрагыннан ярала, дисәләр дә, сиңа безнең нигезгә килен булып төшәргә язмады шул, Әнҗүдә. Көтмәдең. Синең кияүгә чыгып, нефтьчеләр каласына китүеңне ишеткәч, яшәүнең мәгънәсе калмады шикелле тоелды миңа. Үрнәк солдаттан исәр солдатка әвереледем. Май бәйрәме алдыннан полк командиры приказы белән ун көнлек отпуск биргәннәр иде... Синең турыда хәбәр алган кичне, частьнең биек коймасы аша сикереп, самоволкага качтым. Кичке тикшерүдән соң, минем юклыкны белеп, шәһәр урамнарыннан эзләргә патруль чыгарганнар.

Иртәгесен мине ике атнага гауптвахтага яптылар. Отпускам да янды, кадерем дә бетте. Соңгы хезмәт елым иде, командирларымның карашы үзгәрде, наряд өстенә наряд бирделәр, иң авыр эшләргә җибәрделәр. Автомат белән сакта торган көннәремдә, әллә атылыйм микән дигән чакларым да булмады түгел, яшермим, булды, Әнҗүдә! Түш кесәмдәге менә шул яулык саклап калды мине. Кулга ала идем дә сүнеп барган өмет чаткысы кабынган төсле була иде...

Әнҗүдә бер сүз дәшми-нитми аны тыңлап утырды. Искәндәр дә, сөйләвеннән туктап, янәшәсендә утырган Әнҗүдәнең җылы кулларына кыяр-кыймас кына кагылды, каршылык күрмәгәч, шул җылы кулларны сыйпый-сыйпый иркәли башлады. Әнҗүдә, яшьлегенә кайтып, Искәндәр белгәндә, озын толымлы, бүген исә кыска итеп киселгән, коңгырт төскә буялган чәчләреннән тәмле исләр килеп торган башын Искәндәрнең иңбашына куйды. Алар шулай ут алмаган дөм караңгы бүлмәдә икәүдән-икәү шактый гомер утырдылар. Икесендә ике уй дөньясы иде.

***

Беренче көннәрне Искәндәр белән Әнҗүдәне ир белән хатындыр, олыгайгач та пар күгәрченнәр кебек, диючеләр күп булды. Бер авылдан килгән танышлардыр, дип фаразлаучылар да табылды.

Күпләрнең күз уңында булып, күңелләрен кытыклап торган сер ял итүчеләрнең тамашалар залында уздырылган танышу кичәсендә ачылды.

Әйтелгән сәгатьтә зал шыгрым тулы иде. Сәхнәгә баян күтәреп чыккан оештыручы Илгизәне күргәч тә, зал дәррәү кул чапты. Кул чабулар тынганчы ук Илгизә баян күрекләрен тартып, тынычландык, дигәндәй, аккорд биреп алды һәм моңсызларны моңландырырлык, көйсезләрне җырлатырлык, нечкәргән күңелләрне елатырлык моңлы көй уйный башлады.

Алдан репетиция ясап куйганнар диярсең, ярты зал шундук җырга кушылды...

Ах, әгәр мин бер гөл булсам,
Ал чәчкә атар идем.
Атлап түгел, яшьлегемә
Йөгереп кайтыр идем...

Илгизә беркавым зал тынычланганны көтте.

– Залда гыйбрәтле, кызыклы, үкенечле язмышлы кешеләр бар. Танышыйк, таныштырыйк үзләре белән...

Таныштыруны ул атказанган укытучы Клара ханымнан башлады; аннары ирле-хатынлы, Ленин орденлы бригадир Гаяз абый белән картайганчы сыер сауган, хәзер кул-аяклары сызлаудан арынмаган Кафия апалар үз яшьлекләре, үз язмышлары турында бәйнә-бәйнә сөйләделәр, җырлап та күрсәттеләр. Кичәне Җәлил бистәсеннән килгән фольклор ансамбле җырчылары тагын да җанландырып җибәрде.

– Хәзер мин сәхнәгә илле елдан соң, менә шушы безнең үзәккә ял итәргә килгәч, чын мәгънәсендә яшьлекләренә кире кайткан, үкенечле язмышлы бер парны чакырам. Алар – Искәндәр абый белән Әнҗүдә апа. Рәхим итегез зал түренә!

Күпләр өчен чишеп булмастай табышмакка әйләнгән сәер һәм серле парны күргәч, зал йокыдан уянгандай пышылдашып алды.

– Таныштыруыбызны кемнән башлыйбыз, Искәндәр абый, сүзне сиңа бирикме?

– Мин ялан кырда эшләп гомер уздырган кеше, сүзгә осталыгым чамалы. Әнҗүдә сөйләсен башта, дим...

– Алайса, Әнҗүдә апа, син баскан килеш, менә шушы урындыкка утырган Искәндәр абыйның җилкәсенә кулыңны куеп, яшьлектә калган мәхәббәтең белән таныштырасың. Аллага тапшырдык!

– Безнең мәхәббәтебез... Искәндәрне армиягә озаткач та, җанымны кая куярга белми йөрдем. Солдат хатларын көн саен капка төбенә чыгып көтеп ала идем. Искәндәрнең хатлары ике көнгә бер диярлек килә иде башта. Тора-бара, солдат тормышына күнегеп, туган якны сагыну сагышы басыла башлагандыр инде – атнага бер-икене ала идем. Искәндәр күп сүзле, төче телле егет түгел, һәр сүзен сайлап сөйли. Шулай да ул язган хатлардагы күңелгә сары май булып ятарлык ягымлы, җылы сүзләрне, бәхетемдер дип, җылый-җылый укыдым.

Ул киткән җәйне Алабуга укытучылар институтына укырга керәм дип барган идем, конкурстан узмадым.

Искәндәр кайтасы елны, урак өсте башлану белән, авылыбызга янәшәбездәге Чаллы шәһәреннән автоколонна килде. Шофёрларның күбесе солдат хезмәтен тутырып, яңа кайткан япь-яшь егетләр иде. Гадәттә, аларны икешәр-өчәр кешегә бүлеп, бала-чагасыз гаиләләргә фатирга урнаштыралар. Безгә ике яшь егетне керттеләр. Әни аларны җәй көннәрендә безне йоклатып-уйнатып үстергән зур сәкеле ак келәткә урнаштырды. Шунда ашадылар, эштән кайткач, шунда ял иттеләр.

Егетләрнең берсе, сызылып кына үскән кара мыеклысы – Җәмил исемле иде ул – бик тә чая, бигрәкләр юмагай телле булып чыкты.

Җәйге кичләр якты, озын бит ул, кояш соң бата, иртә калка. Элеваторга икмәк илтмәгән көннәрендә кырда суктырылган ашлыкны ындыр табагына ташыйлар. Комбайннар туктау белән өйгә кайталар. Җәмил әни әзерләп куйган кичке ашны ашый да, өс-башын алмаштырып, капка төбендәге озын эскәмиягә мандолинасын тотып чыгып утыра. Тальян гармун моңнарына күнгән кичке авыл урамнарын сихри ят моң сискәндереп җибәрә. Яшь йөрәкләрендә мәхәббәт гөле чәчкәгә

бөреләнергә торган җилкенчәк кызларны кичке уенга чакыра сыман. Шулаен да шулай икән шул. Басуда, ындыр табакларында, җәйләүләрдә көн буена эшләп, арып-талып кайтуларын да онытып, мандолина чакырган тылсым тулы капка төбенә җыела алар. Уйныйлар, җырлыйлар, бииләр, тыючы да, куучы да юк үзләрен. Андый кичләрдә тирә-күршедәге, каршы яктагы урам тәрәзәләре тутырып ачылыр иде дә аларда яшьлекләрен искә төшереп тамаша кылучы әниләребез, апаларыбыз күренер иде.

Яшьләр таралышкач та, без Җәмил белән шул эскәмиядә икәүдән-икәү кала башладык...

...Шул сүзләрдән соң Искәндәрнең тәне тартышып куйган төсле тоелды Әнҗүдәгә. Ул җилкәдәге кулын алды да, сөйлимме, юкмы дигән сыман бер залга, бер Искәндәргә карап алды. Зал тып-тын иде. Илгизә генә шул тынлыкны бозып:

– Шуннан, шуннан ниләр булды, Әнҗүдә апа, Искәндәр абый солдаттан кайтып төштеме әллә?

– Юк, кайтмады, сеңлем, кайтса, үз бәхетемне үз җүләрлегем белән җуймаган булыр идем мин. – Ул, үзе дә сизмәстән, яшьлек йомгагын сүтә башлады. – Кичке сөйләшүләр, иртәгесен рульдәге Җәмил янәшәсенә утырып, ындыр табагына эшкә баруларның мәгънәсе тирәнәйде. Юма теле белән әнине дә үз ягына аударды. Әрҗә төбенә салып, тавык-чебиләренә бер-ике чиләк бодай, арпа алып кайта башлады. Элеватор урнашкан шәһәрдән күчтәнәчләрен әледән-әле әни кулына тоттыра.

– И-и, нинди инсафлы бала, шундый киявем булсын иде, – дип, миңа оеткы сала башлады әни. Соңрак:

– Күктәге торнага ымсынып яшәгәнче, кулыңдагы чыпчыкны ычкындырмыйсыңмы әллә, кызым, ул солдатың кайтса да, сиңа әллә өйләнә, әллә юк, – дип, җае килгән саен кабатлап торды. Күңел исәрләнде, ни уйларга, ни эшләргә белми йөрдем. Үзем Җәмилдән читләшмәдем.

Урак тәмамланып, ташыйсы-тапшырасы ашлыклар азайган бер мәлдә Җәмил кичкә каршы Чаллыга кайтып килде. Үзе белән әтисен-әнисен дә утыртып килгән бу. Мин башта әни кунакка чакыргандыр, дип уйлаган идем. Әни бәлеш салып, таба ашлары пешереп, олы табын әзерләде. Ул көнне Җәмил дә эштән иртә кайтты.

– Элеваторга соңгы ашлыкны илттек, – диде ул. – Атна азакларына табан эшләрне түгәрәкләп китәбез инде.

Әтисе аның соңгы сүзенә кушылып:

– Тик буш кул белән китмәскә иде безнең исәп, – диде, һәр әйткән сүзенә тирән мәгънә салып. – Без бу нигезгә яучы булып аяк бастык бүген, кызыгызның кулын улыбызга сорарга килдек. Без риза, сездән ризалык көтәбез.

Әниемнең җавабы әзер иде: «Риза булмыйча, бик риза без, шулай бит, атасы?» – дип, өчебез өчен дә җавап биреп, минем ризалыгымны сорап та тормыйча ярәште дә куйды. Әти дә, әни сүзеннән чыкмый торган ир, баш кагып кына ризалыгын белдерде. Шул табында алдагы җомгада безнең өйдә никах укытасын һәм кызны озату көнен килешеп куйдылар.

Нәкъ бер атнадан беренче саф мәхәббәтем кабызган ялкынга су сибеп, хатын-кыз язмышына язылган бәхет капкасын үз кулларым белән ябып, өйдән һәм туган авыл капкасыннан, яшьлек җүләрлеге белән алда нинди язмыш көткәнен уйламыйча да чыгып киттем. Мин моны яши-яши, олыгая-олыгая аңладым, тик соң иде. Бәхет кошым башка берәүнең кулында иде. Ике бала белән, шәһәрне калдырып, аерылып, авылыбызга кайткан елны Искәндәр өйләнгән иде...

Әнҗүдә зал ни әйтер дигән сыман аны кызыксынып тыңлаган кешеләргә күз тутырып бер карап алды да Искәндәр янәшәсендәге урындыкка утырды.

– Сезгә сүз, абый, – диде сәхнә читендә басып торган Илгизә. – Хәзер инде сез Әнҗүдә апаның янәшәсенә басып, кулларыгызны җилкәсенә куеп сөйлисез.

– Сөйлисез, дип, сүзгә маһир кеше түгел мин, басу тургаемын. Көннәр буе җир сөреп, иген игеп, тургайларга кушылып җырлап узды минем гомеркәем. Күңелемдәгесен җыр белән әйтергә тырышырмын бүген. – Ул кичә башында Илгизә урындыкка куйган баянны кулларына алды да, каешын иңбашына киеп, берәүгә дә таныш булмаган бик тә моңлы көйне уйнап җибәрде һәм:

– Яңа җыр бу, радиодан яздырып отып алган идем, – диде дә моңлы көчле тавыш белән җыр башлады:

Ник соңладың, ник соңладың, дисең миңа,
Син бит миннән ерак – ары идең.
Очрашсак та, күрми үтәр идек,
Син бүтәннең назлы пары идең.

Тартылган, сузылган баян күрекләреннән ташып чыккан моң, чишмә сулары челтерәгәндәй яңгырап, күңелләргә үтеп кергән матур тавышы бер мизгелгә зал тулы йөрәкләрне җилкендереп сихерләде, моң агылды да агылды...

Соң булса да эзләп таптым сине,
Аерылышу мөмкин түгелдер.
Тәүге сөю тоташ ялкын булса,
Соңгы сөю утлы күмердер.

Искәндәр җырның кушымтасын җырлаганда, яшьлеген, югалткан үкенечле мәхәббәтен искә төшереп нечкәргән күңелләр, чыланган яшьле күзләр белән тулы зал моң дәрьясыннан арынып, дәррәү кул чапты. Искәндәрне сәхнәдән төшермәделәр, кабат җырлатасылары килде. Тик ул мин бит артист түгел дигән сыман баянын урындыкка куйды да сәхнәдән төшеп китте.

***

Вакыты киртләп куелган ял итү көннәре бер-бер артлы үтте. Көндезләрен дәваланып, кичләрен уеннар уйнап, кичәләр оештырып, концерт-кино карап, ике атнаның ничек узганын тоймадылар да алар. Кайтасы көн җиткәч, иртәнге аштан соң, Әнҗүдәне алырга машина белән кызы килде. Искәндәр үзе соңрак китәргә булды, ул Әнҗүдәне озата чыкты. Кызы, буй-сыны белән дә, төскә-биткә дә коеп куйган әнисе иде.

– Исәнме, Искәндәр абый, – дип, үзе кул биреп күреште ул. – Гаҗәпләнмәгез, әни миңа телефоннан сезнең көтмәгәндә-уйламаганда очрашуыгызны сөйләде. Шуңа беләм мин сезне. Минем исемем Гөлфия, Искәндәр абый, кунакка килегез безгә.

Алар кочаклашып та, кул бирешеп тә саубуллашмадылар, Әнҗүдә машина ишеген ачып утырыр алдыннан:

– Адресны, телефонны бирдем, югалта күрмә, – дип кеткелдәп көлеп алды. – Үз җаең белән килерсең, көтәм сине!

«Көтәм сине» – Әнҗүдә яшьлегендә ап-ак ефәк кулъяулыкка чигеп язган шушы тылсымлы ике сүзне белепме, белмичәме, тагын бер мәртәбә әйтте дә кабат күз уңыннан югалды...

Искәндәр кичкә каршы гына кайтыр юлга чыкты. Аңа кайчан кайтса да, барыбер түгелмени?! Өйдә сагынып-саргаеп көтеп торган кешесе юк.

Көтәм сине... йөрәк тибешенә кушылып, әледән-әле күңелендә кабатланып торган, юл буе җанга тынычлык бирмәгән шул ике сүз очына чыга алмаслык уйлар дәрьясында айкалды...

Әнҗүдә белән кушылды да, ди. Балалары ни әйтер? Риза булырлармы чит хатынны туган нигезләренә кертергә? Бәлки, ризалашырлар да. Әниләре үлгәч, үзләренә чакырмадылар түгел, кат-кат чакырдылар. Үз куллары белән ата-баба нигезенә салган шушы йорт-җирне ничек ташлап китсен ул! Юк, ике аягының берсен дә атламаячак. Нигезне туздырып, балалары кулына калып, өйдә асраган этне куып чыгарган сыман урамда калучылар турында да ишеткәне бар Искәндәрнең.

Картлыгында хатыныннан калган ир-ат ялгыз да яши алмый. Өйләнеп тә уңмаганнары үз авылларында да җитәрлек, еректан эзлисе юк. Картлык ишеген ачканда, берәү дә гыйшык утында янарбыз, дип килмәс бит инде. Югары очтагы картайганчы тракторыннан төшмәгән Шәрифҗан абыйсы басуда чирәмгә сузылып ятып, ял итеп алган чакларында:

– Искәндәр, энем, син яшь кеше, тимер тибеп өзәрлек чагың. Мин дә бер дә картаймас кебек идем, хәзер алда ни көтә, дип уйлана башладым. Ходайдан бер генә нәрсә сорыйм мин, энем, хатыннан ялгыз калмасам иде, алдан үлсәм иде, – дигәнен бер генә түгел, берничә мәртәбә тыңлады Искәндәр. Ул чакта бу сүзләрне көлеп кенә уздырган иде, хатыны вафат булгач кына, бөтен нечкәлеге белән аңлады.

Көтәм сине... Көтәсеңдер, анысында шигем юк, Әнҗүдә, тик яшәп китә алырбызмы? Яшьлектә үзең сүндергән учакта чаткы да калмады бит. Тергезеп булырмы шул учакны, пыскып-пыскып янса да, картлыгыбыз үкенечле булмас иде. Искәндәр менә шул уйларны башына чалма итеп урап, атна буе исәр кеше сыман йөрде дә, аек бер фикергә килеп, Әнҗүдә яшәгән шәһәргә сәфәр чыкты.

Иртән китте, кичке эңгер-меңгердә, үз машинасы белән капкасы төбенә кайтып җитте.

Ялгыз китте, парлап кайтып төштеләр. Искәндәр, егетләр җитезлеге белән машинадан алдан чыгып, Әнҗүдә утырган яктан ишекне ачты һәм кулын сузды.

– Әйдә, төкле аягың белән, килен, бәрәкәтең белән кер безнең нигезгә! Аяк астыңа кайры тунны әйләндереп җәюче дә, йомшак мендәргә бастырып, бал белән май каптыручыбыз да юк бүген, – дип, әллә шаяртып, әллә инде күңелендәге ачыктан-ачык әйтеп, тимер капканы барып ачты һәм Әнҗүдәне – яшьлегендә ап-ак туй күлмәкләре кидереп, җигүле пар атларда төшерү турында хыялланган киленне җитәкләп, үз оҗмахына, үз почмагына алып кереп китте. Килен бирнәсе – алыпсатарлар товар йөртә торган аклы-каралы олы сумка иде.

***

Җир өстендәге пычракны ташкын итеп агызган, табигатькә җан өргән, карт йөрәкләрне дә җилкендергән яз үтте... Чәчәкле җәйне, елак кара көз алыштырды... Кыш уртасы да җитте... Ләкин алар әле һаман аерым – Әнҗүдә киң караватта ялгызы ята, Искәндәр икенче бүлмәдәге йомшак диванда йоклый...

Йоклый дип инде, Искәндәрнең айдан артык рәтле-юньле йокы күргәне юк. Уй белән ята, уйларыннан арынып өлгерми, таң белән аякка баса.

Баштагы мәлдә уртак тормышлары матур башланган иде шикелле. Икесен дә ялгызлык туйдырган булдымы, көннәрен дә сөйләшәләр, төннәрен дә серләшер сүзләре җитәрлек иде. Әкрен-әкрен яшьлек хатирәләре белән тулы

күңел сандыклары бушады, гадәти тормыш мәшәкатьләре белән күмелгән авыл тормышы башланды.

Хатыны үлгәч, Искәндәр мал-туардан арынды үзе, тавыклар белән генә калды. Ул аларны да иренмичә карады, җимен бирде, суын куйды, кышын тагаракка кар кертеп салды. Әнҗүдә, авыл кызы булса да, гомерен шәһәрдә үткәргән хатын, крәстиян нужасына чуммасын әле дип, күп эшне үзе эшләргә тырышты. Алсуы ашка-суга бик булган хатын иде, Әнҗүдә ботка пешерсә – боткасы, коймак тугласа – коймагы күп вакыт көйгән була. Авыздан сулар китереп, исе борынны кытыклап торган ит бәлеше, таба ризыкларын Алсу үлгәннән бирле күргәне юк Искәндәрнең. Сирәк булса да, җаны теләгән, күңеле төшкән таба ризыкларын үзе пешергәләде. Алсуы исән булса, хатын-кыз эшенә тыгылып, хатынша булып йөрмә аш-су бүлмәсендә, дияр иде. Әнҗүдә андый сүз әйтмәде, ул пешергән һәр ризыкны, тәмле булган, шәп повар икәнсең, тракторчы булып әрәмгә гомер уздыргансың, дип, кеткелдәп көлә-көлә ашады.

Араларына шайтан кергән көн кышның соңгы аенда булды. Һаман да шул акча сәбәпче булды аңа. Искәндәрнең пенсиясен хат ташучы китереп бирә. Ул аны ала да савыт-саба тезелгән шкаф киштәсендәге олы чәйнек эченә салып куя, кирәк-яракка шуннан үзе алып тота.

Бүген дә хат ташучыны капкага чаклы озатып кергәч, аның пенсиясен санап утырган Әнҗүдә кулыннан акчаны алды һәм үзе белгән урынга илтеп куйды. Әнҗүдә беркавым дәшми утырды да:

– Искәндәр, тормышта ирләр акчаны хатын кулына бирә. Яши башлаганыбызга инде ел тула, минем синең акчаны күргәнем юк әле, – диде.

– Син дә пенсия аласың бугай, минем дә күргәнем юк, әллә сиңа пенсия түләмиләрме? – дип, Искәндәр сүзне шаянга борып, нокта куярга уйлаган иде, барып чыкмады, Әнҗүдәгә аның шаяртуы барып җитмәде, тавышын ачуланган сыман көчәйтә төшеп:

– Нишләп бирмәсеннәр, бирәләр, тик өйгә генә китермиләр, сберкнижкага күчерәләр.

– Бик әйбәт. Күчергәнне алып буладыр бит? Әллә картлык көнеңә җыеп барасыңмы?

– Җыям, ди, әйттем бит инде, кызым ирдән аерылып кайтты, ике баланы берүзе үстерә. Пенсиямне аларга бирәм, бала бит...

– Минем дә ике балам бар. Оныкларымны үстерәләр. Икесе дә «КамАЗ» заводында туктап-туктап, атнага өч-дүрт көн генә эшлибез, диләр. Мин дә аларга бирсәм, газга, утка, суга кем түләр? Мал-туар юк, абзар буш, күп ризыкны кибеттән сатып-алып көн күрәбез, Әнҗүдә. Үзең күрәсең, эчеп-тузып, әрәм-шәрәм итеп йөрмим. Безнең бөтен тапкан малыбыз хөкүмәт биргән шул пенсия бит.

– Абзарым дигән була тагын. Өеңне дә, абзарыңны да – бар мөлкәтеңне балаларыңа бүләк итеп яздыргансың бит. Беркөнне шкафның тузаннарын сөрткәндә, кәгазьләрең арасыннан васыятьнамәңне күреп шаккаттым. Шыр ялангач хәерче икәнсең бит син, Искәндәр. Сиңа ышанып, мин җүләр кияүгә чыктым. Ә син үлсәң, балаларың икенче көнне үк мине куып чыгарачаклар, шулай түгелме?

– Син ни сөйлисең, Әнҗүдә, мин бит әле үләргә җыенмыйм, типсәм, тимер өзәрлек ирмен.

– Алла диген, дөньяныкын бер дә белеп булмый, адәм баласы бүген исән, иртәгә... – Ул җөмләсен нокталап бетермәде, сүзне икенчегә борып, йомшаграк тавыш белән:

– Никах укыткач та әйттем мин сиңа, язылышыйк, никахыбызны

законлаштырыйк, дидем. Бер түгел, ун әйттем. Әле дә соң түгел, язылышсак, васыятеңне дә үзгәртерсең, йорт-җиреңне хосусыйлаштырырбыз да, миңа да өлеш яздырырсың.

– Мин язылышкан законлы хатын белән гомер кичердем, балалар үстердек, бу нигездә аның да хезмәте – уртак мал. Кем беләндер бүлешәсе малым юк. Законлы хатын буласың килгәч, көтәргә идең. Минем эчкерсез яшьлек мәхәббәтемне ташлап, өч иргә җиткәнсең, язылышкансыз, малларын, фатирларын бүлешеп аерылышкансыз бит. Сиңа мин түгел, минем мал, йорт-җирем кирәкме? – Искәндәр аның җавабын да көтмичә, гарьлегенә чыдый алмыйча, әй, дип кул селтәде һәм тиз-тиз генә киенеп, ишегалдына чыгып китте.

Ул анда үз-үзен кая куярга белмичә, тынычлана алмыйча, әрле-бирле йөрде. Кулына лом алып, кар астына су төшеп каткан ышык урындагы бозларны вата башлагач кына бераз тынычланды. Тынычланды дигәч тә, карт йөрәкнең дөп-дөп ярсып тибүе кимеде, тик Искәндәрнең өйгә керәсе килмәде. Бозларны чабып, кардан ачылган кояшлы җир өстенә таратып бетергәч, тавык кетәклегенә керде, андагы кыш буе җыелган тиресне кырып, әрҗәле кул арбасына төяде дә бәрәңге бакчасындагы өемгә чыгарып түкте. Эш белән вакытның узганын сизми дә калды, соңгы арбаны бушатканда, язгы кояш җир читенә тәгәрәп төшеп, күк чабуын алсу нурларга мана-мана баеп бара иде. Көн саен күзәткән шушы кичке манзараны беренче мәртәбә күргән кеше сыман баскан килеш шактый вакыт сокланып торды. Аннары кул арбасын бакча кырыена чыгарып, ихата коймасына терәп куйды һәм көздән ярылмый калып, утыргыч итеп куелган каен бүкәненә барып утырды.

Яшәгәндә, бар нәрсә дә онытыла: кайгы-хәсрәт тә үтә, авыр сүз дә йомшара, аны да кичерәсең, тик менә беренче мәхәббәткә кылынган хыянәт һич кенә дә онытылмый икән. Кушылып, парлы мендәрләрдә йоклый башлагач та, Искәндәр Әнҗүдәгә күнә, үз итә алмый газапланды. Алсуы иреңенә иннек, бит алмаларына кершән якмады, сирәк кенә, кунакка барганда гына, Искәндәр туган көненә бүләк иткән француз хушбуен бармак очына тидереп кенә, колак артларына сөртер иде. Бизәнмәсә дә, Искәндәр өчен чибәрләрнең чибәре, гүзәлләрнең гүзәле иде бит ул. Башны башка куеп ятсалар, чәчләреннән күңелгә якын хуш ис килеп торыр иде. Кышкы суыкларда өй суынган төннәрдә Алсуын кочаклап, аңа сыенып ятса, мич җылысы бер читтә торсын – изрәп йокыга китәр иде.

Әнҗүдә белән алай түгел. Ят иде ул. Авыл кызы булса да, шәһәрдә гомер уздырып, авыл тормышыннан бизгән, кош-корт янына да чыкмый, аш-суга да осталыгы чамалы.

Бер көнне Искәндәр:

– Әнҗүдә, суыткычта Алсудан калган колмак чүпрәсе бар, әйдә әле, баш ясап, кайнар мичтә авыл ипие пешерик, ят ризык бик тәмле була ул, – дип башлаган иде, сүзен төгәлләргә өлгермәде...

– Хәзер, Мамай заманындагы мичеңне ягып, камыр басып, ипи-кабартмалар пешереп ятармын. Пешкәне әнә кибет тулы, кер дә алып чык, акчаңны йомарлап ятма, – дип авызын япты да куйды.

Искәндәр ул көнне каршы дәшмәде. Ямьсезләнәсе-тәмсезләнәсе килмәде инде. Авылга газ кергәнгә дә биш былтыр, утын ягып өй җылытасы, казан астына ягып, аш пешерәсе юк. Авылда миче сүтелмәгән өй бар микән, булса да Искәндәрдә генәдер, шәт. Алсуы сүттермәде. Аларның урам як бакчаларында Искәндәр белгәннән бирле коймага үрелеп колмак үсә. Әнисе җәй урталарыннан соң шул мичтә пешерә торган чәкчәкләргә охшаган чәчәкләрен җыеп киптерә

дә кыш буе шуны кайнатып, оеткы салып, чүпрә ясый һәм шешәләргә тутырып сакларга куя иде. Киленне каенана туфрагыннан яралган, диләр бит, Алсу күп эшкә каенанасыннан өйрәнде. Әни белән кыз сыман бик тату яшәде алар. Урын өстенә калгач та, Алсуы аны үз анасыннан артык тәрбия кылып, соңгы юлга озатты... Искәндәр мич алдына баскан килеш шуларны күңеленнән кичерде дә, чукынып китсәнә, дигән сыман кулын селтәп, тиз-тиз өйдән чыгып китте. Ул чакта да ике көн кырлы-мырлы гына сөйләшеп йөргәннәр иде.

Бүген исә Искәндәр караңгы төшкәч кенә кайтып керде. Әнҗүдә алгы өйдә телевизор карый. Аш бүлмәсендә аны көтеп торучы, ашыйсыңмы, чәй эчәбезме, диюче дә юк. Искәндәр өстендәге курткасын, бүреген салып, чөйгә элде дә, бер сүз дәшми-нитми, балалар үскәндә, алар бүлмәсе булган, алар таралышкач, Искәндәр үзе ял итәргә, беркемгә дә комачауламыйча, шунда телевизор карарга яраткан бүлмәгә кереп китте.

Әмма бу халәттә озак яши алмадылар. Кояшлы бер иртәдә барысы да хәл ителде дә куйды. Искәндәр уянганда, Әнҗүдә аш бүлмәсендә чәйләп утыра иде. Бер ел элек күтәреп килгән олы шакмаклы сумкасы ишек төбенә куелган. Искәндәрнең шул сумкага карап торганын күрептер инде, Әнҗүдә:

– Мин китәм, Искәндәр, безгә бергә яшәргә язмагандыр инде. Әнә, нинди сумка күтәреп килсәм – шуның белән китәм, бер ел яшәдек, арткан бер җирем дә юк. Күрәсем дә юк, чөнки син үзең хаерче. Бу минеке, дияргә нәрсәң бар?! Авызың ачсаң – үпкәң күренә, җанкисәгем.

– Син ни сөйлисең, Әнҗүдә? Уйлангансың, акылыңа килгәнсең дигән идем. Ярар, мин сине кумыйм, китәсең икән – юлыңа ак җәймә. Хәзер машинаны кабызам, чыгарсың, – дип, ишек тоткасына кулын салган иде, Әнҗүдә:

– Кабызма, кызым такси белән килеп җитә хәзер, – дип, аны туктатты.

Ул арада урамда машина кычкырткан тавыш ишетелде. Әнҗүдә чөйдәге җиңел пәлтәсен алып киде дә, авыр сумкасын күтәреп, урамга ашыкты. Искәндәр урындыгында утырган килеш калды.

Озак утырмады, капкасының «дөп» итеп ябылуына сискәнеп, кинәт кенә сикереп торды да шифоньердагы костюм кесәсеннән чиккән кулъяулыкны алып, урамга атылып чыкты. Ул чыкканда, Әнҗүдә утырган такси, авылның югары очындагы күперен узып, баганалы олы юлга борылган иде инде. Искәндәр капка баганасына сөялгән килеш Әнҗүдәне алып киткән шул юлга бик озак карап торды.

Ул, авыр уйларыннан айнып, Әнҗүдәнең үзенә кире бирермен дип алып чыккан кулъяулык белән яшьле күзләрен сөртеп алды. Аннары әрдәнәдән бер кочак каен утыны алып кереп, берәм-берәм мич алдына бушатты. Әле генә капка төбендә җанына тынгылык бирмәгән уй-фикеренең берсен үтәргә җыенуы иде аның. Алсуы үлгәннән бирле кул тимәгән агач саплы озын тимер кисәүне мич астыннан тартып чыгарды. Ботаксыз коры пүлән сайлап, чыра телде дә мич төбенә өйде. Каен тузына ут төртеп утын өстәде. Күптән ут күрмәгән мич эче кинәт дөрләп яктырып китте. Корымлы морҗа да, гүя сөенә-сөенә, ялкынны үзенә тартты. Коры каен утыны бик тиз янып бетте: башта утлы кисәүгә әйләнде, аннан кып-кызыл күмер булып, мич төбенә җәелде. Искәндәр күмерне әледән-әле әйләндергәләп, бер урынга өя торды. Һич икеләнеп тормыйча теге кулъяулыкны кисәүнең очына туздырып салды да утлы күмер өстенә ыргытты. Яулык гөлт итеп бер балкып алды да аклы-каралы көлгә әйләнде.



*Алинә Бикмуллина Балык Бистәсе районы Олы Әшнәк авылында туган. Туган авылында урта мәктәп тәмамлаганнан соң, 2007-2011 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетында укый.*

*Саҗидә Сөләйманова исемендәге стипендия иясе. Бүгенге көндә Казан шәһәре иҗтимагый үзәгендә тәрҗемәче булып эшли.*

Алинә
Бикмуллина

# УЙДА – ТАУЛАР, ЫМСЫНДЫРГЫЧ ҮРЛӘР...

## Юк тынасы бу җилнең

Килде дә бәрде үзәккә –
    аңышмый калдык берни...
Боз кебек салкындыр җиле –
    якадан тотып сөйри...
Сөйләргә генә ирек юк:
    күзәтү хәзер – өстән...
Таулардан ташлар коела
    ...кайтаваз булып өскә:
«Сабыр бул!
Нык тор!
Бирешмә!» –
    ...әйтергә ничек җиңел!
Тамырдан алып өзгәли –
    Юк тынасы бу җилнең...
Чигенеп... бераз көтәйдең –
вакыт аз,
    фикер сыек...
Сыеныр почмак тапмассың –
    бу җилнең тынасы юк...
– Еллар хәрабә хәлендә,
әйт бер сүз,
    нишлик... гасыр?!
– Карыштың, карышмадың ни –
    бу җилнең юк тынасы...

## Чулмансу

Чулмансу...
Ярларында аяк чылатсам да,
уятсам да төнлә таш чиртеп –
Чалкан ятып кочагыма оча,
чал тарихлы башын кече итеп...

Хушлашканда...
Болыткача кизәп ярсуларын,
дуылдата – бәрә яңагыма...
Каешланып беткән акчарлактан
каурый-каурый үпкә ява миңа...

Очрашканда...
Күмелә офык – дулкын йөгерә
Ярын очраткандай яңа гына...
Ак күбекләр сальса бии шашып –
Аяк чылатсам да ярларында...

* * *

*Мин югалмам, мин булырмын тамга –*
*Юл чатында киңәш көткәннәргә...*
Сөләйман

Йөгерәм дә чыгам, йөгерәм дә чыгам –
барган сукмак кына чатнамасын...
Шундый таркау чагым, шундый зәгыйфь чагым –
торсаң идең көтеп... чатта басып...

Чаң сугарга әзер – чарасызлык иңдә,
эзләмим лә юл чатында тамга!
Үзең кирәк, сүзең кирәк, бер киңәшең –
бу мизгелдә, бу минутта җанга...

Шундый читен чагым – җил уйнаклый тагы,
аңа нәрсә?! – чакрымнарга чыдам...
Түзәр чама бетте, олы юлга таңнан –
йөгерәм дә чыгам, йөгерәм дә чыгам...

* * *

Бу – безнең көн:
Дивардагы саргылт календарьның
биттен ертып,
төнәтмәсен ясыйм иртәдән...
Кыл уртасы җәйнең,
кыл уртасы елның –
кышка ерак, көзгә иртәрәк...
Исәр кебек икәү утырырбыз –
иртә таңнан кара төнгә чаклы...
Үткән юлны-хатирәне барлап –
сөенербез ихлас...
һай, ничаклы!

Көлешербез күз яшьләре аша –
онытылыр гайре дөньялар...
(Шаккатырсың!
Календарьның гади бер көнендә
бу күңелгә күпме дәва бар!..)
Төнәтмәсе еллык юшкыннарны
төбе-тамыры белән алып юар...
Ә соңыннан... таң беленер –
календарьда яңа көн туар...

***

Шәһәр-авыл – мәгърип белән мәшрикъ...
Мәш киләбез ике кыйтгада...
Кала – кырыс,
тимер салкын таштан;
ә саланың
җаны-рухы бар...

Пәрдәләргә кояш сеңгән. Шәһәр –
күзен ачты, салмак киерелә...
Авыл күптән
җир җимереп аткан –
...уянгандыр әнкәй
таң белән...

Кала халкы һич тартынып тормый –
ашый, эчә барган хутына.
Әнкәй яңа
гына утыргандыр
«бисмиллалы»
табын артына.

Кызу. Эштәгеләр кондишерлы
бүлмәләргә кереп качкандыр.
Әнкәй шатлыгыннан
өйнең барлык
тәрәзләрен
киереп ачкандыр.

Уйда – таулар, ымсындыргыч үрләр...
Нәфес кошы тынмый – сайрый гел.
Көн куабыз,
ә авылда әнкәй
сәҗдә саен
бәхет сорыйдыр...

Ахшам керә, шәһәр мәңге тынмый –
Тизлек, шау-шу уңда вә сулда...
Гәҗит укып ятам.
Әнкәй анда
шәл бәйлидер
төн уртасында...

# АЛИНӘ БИКМУЛЛИНА ШИГЫРЬЛӘРЕ

Алинә Бикмуллина исеме татар матбугатыннан хәбәрдар кешеләр өчен таныш: шигырьләре әледән-әле газета-журнал битләрендә басыла. Сәләтле кыз, «Казан утлары» журналына тәкъдим ителгән шигырьләрдә дә аның иҗат кануннарыннан хәбәрдарлыгы күренеп тора. Шуңа сүзебез осталыкны арттыру турында булыр.

Шигырьләрне җыйнап торган исем кинаяле, символик: «Уйда – таулар, ымсындыргыч үрләр...». Татар поэзиясе XX гасырда тау символының тотрыклы берничә мәгънәсен танылырлык итеп беркетә: ирешергә омтылган биеклек тә ул; абруйлы, танылган шәхесләр дә шушы атама белән билгеләнә; идеал, өмет эчтәлеге дә актив.

Беренче шигырь шушы гомуми исемгә аеруча ярашып тора. Ул постсимволизм юнәлешендә иҗат ителгән, ягъни эчтәлеге символларның мәгънәсен ачыклауга бәйле булып чыга.

«Юк тынасы бу җилнең» дип исемләнгән шигырьнең үзәгенә татар шигъриятендә еш кына тау символы белән янәшә, парлы кулланыла торган җил символы куелган. Әлеге символның төп мәгънәсе иҗтимагый-сәяси авырлыклар буларак, Һ.Такташ һәм Х.Туфан иҗатларында тәкъдим ителә. XX гасыр буена, бигрәк тә 1960 елларда – эзоп теле алымы белән бергә, гасыр ахырында узган тарихны бәяләү вакытында шушы мәгънә гаять активлаша. А.Бикмуллина шигырендә дә символның шушы эчтәлеге беренче планга чыга. Беренче строфа соңгы еллардагы татар теленә, милли үзаңны саклауга «килеп бәрелгән җилне» күңелгә китерә. Җил белән бергә, тау һәм тамыр образлары да символга әйләнә.

Шигырьнең лирик герое – милли-иҗтимагый хәл-халәткә битараф булмаган кеше. Бу очракта шигырьдәге фикер берничә юнәлеш алырга мөмкин: ситуация хакында хәбәр итү, аңа мөнәсәбәт белдерү; йә булмаса укучыны, халыкны бирешмәскә өндәү – шундыйлар исәбеннән. А.Бикмуллина тарафыннан иҗат ителгән текст башка фикергә юнәлтә. Исемгә – көчле позициягә чыгарылган «Юк тынасы бу җилнең» дигән фраза шигырьнең үзендә дә өч тапкыр кабатлана. Беренче-икенче кат ул лирик герой исеменнән яңгыратылса, өченче тапкыр «гасыр» исеменнән кабат көчле позициягә чыгарыла, текстны йомгаклый. Ягъни әлеге кабатлаулар иҗтимагый-сәяси авырлыкларны җиңүгә бернинди өмет калдырмый, киресенчә, мондый авырлыкларның даими булачагы турындагы фикер кат-кат укучы аңына сеңдерелә. Соңгы ике тезмәдә ул тулысынча әлеге хәл белән килешергә чакыру кебегрәк аңлашыла башлый: «Карыштың, карышмадың ни – / бу җилнең юк тынасы...». Ахыр чиктә, шигырьнең идеясе циклга куелган исем белән дә каршылыкка керә: уйда таулар булганда, бу дәрәҗәдә өметсезлекне шигырь аша әдәби җәмәгатьчелеккә таратырга мөмкинме, кирәкме икән дигән уйга киләсең.

Әлбәттә, беренче шигырь турында шулай озак итеп, вакланып сөйләү юкка түгел: ул каләмгә алынган һәр кешегә адреслана. Чынлыкта, беренче текст – шигырь, ул шигырь булган инде. Әмма аның идеясенә бәйле тәнкыйть каләмгә алынган һәр яшь кешенең үз укучысына, коллектив аңга нинди фикер белән тәэсир итәчәге хакында уйланырга тиешлеге, аның шәхси җаваплылыгы хакында искәртә!

Шигырьнең формасына-эшләнешенә кагылышлы кайбер күзәтүләр белән дә уртаклашыйм. А.Бикмуллинаның башка текстларында да очрый торган сыйфат –

рифмаларның һәрвакытта да уңышлы сайланмавы. Икенче строфадагы «өстән – өскә», өченче строфадагы «җилнең – җиңел» соңгы строфадагы «гасыр – тынасы» шул хакта сөйли. Беренче очракта «кайтаваз булып өскә» фразасында фикер төгәлсезлеге бар; хәтта «кайтаваз килә күктән» дип аз гына үзгәрткәндә дә, ул күпмедер тигезләнер иде. Өченче строфада рифма төгәлсезлеге ритм бозылу белән кушыла. Икенче тезмә 3+2+2 вәзенендә булса, дүртенче тезмә 4+1+2 рәвешен ала! «Юк» сүзенең урынын алыштыру да бу очракта гармонияне-көйне саклый ала.

«Чулмансу» шигырендә һәр строфаны башлап, өстәмә итеп куелган сүз куллану – А.Бикмуллинаның матур табышы. Мондый алымны шагыйрәнең визит карточкасы буларак та кулланырга мөмкин. Бу текстта «чылатсам да», «уятсам да» кебек эчке рифмалар, «каурый-каурый үпкә», «Болыткача кизәп ярсуларын» кебек детальләр матур. Биредә дә вәзен ягыннан төгәлсезлекләр бар. Беренче строфа – 10/9; икенче строфа – 10/10; өченче строфа 10/10 (әмма биредә беренче тезмәдә 9 булып укыла) үлчәме кулланыла. Классик төзелешле текстта мондый күчеш рөхсәт ителми.

Өченче текст – «... Йөгерәм дә чыгам...» – эмоциональ тәэсирле, лирик героиняның борчулы-чарасызлык халәтен тулы тергезүгә белән җәлеп итсә дә, биредә әлеге халәтнең сәбәбе аңлашылмау фикер ачыклыгына комачаулый. Сәбәп шәхсиме, гомумиме – моны укырга ачкыч юк. Шул ук вакытта кабатлауларның урынлы кулланылуы, риторик эндәш – бу очракта Алинәнең осталык билгесенә әйләнә.

«Бу – безнең көн...» шигырендә календарь битеннән төнәтмә ясау – абстракт образлылыкка, модернистик шигъриятькә дәгъва итә. Әмма текстта сурәтләнгән гомуми картина бу юнәлештә түгел (ул классик мәдәният тибы таләпләренә җавап бирә). Яки әлеге образны үзгәртәсе, яки текстны тагын берничә шундый образ белән баетасы килә. Бу очракта, XXI гасыр әдәбияты эклектиканы ярата дисәк тә, иҗат методларын бер текст эчендә янәшә куллануның үз законнары барлыкны искәртергә кирәк.

«Шәһәр-авыл...» шигыре – циклдагы иң уңышлысы, мөгаен. Шәһәр-авыл бинар оппозициясенә корылган текстта хис-кичереш тә, сурәт тә – үз урынында! Шигырь авылда үсеп, шәһәрдә авылын, әнисен уйлап гомер кичерүче бик күпләрнең хис-кичерешләрен чагылдыра. Шушы матур шигырьне фәлсәфи йомгаклап куясы да килә: ул өзелеп калган кебек тәэсир уяна. Соңгы строфада вәзен ягыннан чатаклык бар: ул шунда ук шигырьнең гомуми көен-яңгырашын боза башлый. Моннан тыш, «кыйтгада – җаны-рухы бар», «уңда вә сулда – төн уртасында» рифмаларының уңышсыз булуын күрсәтергә кирәк.

Кыска шигырьләрдә фикри яңалык булырга тиешлеген искәртеп, мондый яңалык бар икән, рифма яки вәзен килешсезлегенең текстны бозуын әйтергә кирәк. Кыска шигырь – камиллеккә иң сизгер форма; сүзләр сайланышында камиллек, көтелмәгән яңа образ яки деталь ярдәмендә тудырылган гадәтилектән ерак дөнья сурәте; сискәндерерлек фикер булганда гына, бу форманы файдаланырга мөмкин.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Гөлзәлифә
Әхмәтгалиева

# СУКМАК

хикәя

Күр әле, бакча почмагындагы алмагач ап-ак бүрек кигән. Ул бүрекнең як-якка салынып төшкән колакчыннары әкияти дәү кошның ак канатлары диярсең... Гөлзифаның күңелен башта шушы кышкы манзарага соклану биләп алды, аннары кисәк кенә әрнүле бер хис чеметеп үтте. Кош? Әллә соң моннан байтак еллар элек шушы алмагач төбендә җирләнгән сыерчыкның җаны мамык кар булып агачка килеп сарылганмы? Булыр да, кошларның гына түгел, кешеләрнең дә җаны адашып йөргән заман...

Ничә яз җырчы кошларны зарыгып көтеп алган, күзләрен сагышланып озатып калган сыерчык оясына ул елны да пар кошлар кайтып кунды. Кундылар да, исән-сау, пар булуларына шатланып, туган якның матурлыгына дан җырлап, өздереп-өздереп сайрарга да тотындылар.

Ә беркөнне әлеге шатлык җыры кырт өзелде. Ял көнне иртән мунчага су салыйм дип ишегалдына чыкса, Гөлзифа имәнеп китте: сыерчык оясы алдында ялгыз кош тилмереп, өзелеп, киселеп сайрый; юк, сайрамый, елый, ачына, бәргәләнә. Ә аста, бәбкә үләне борын төртеп килгән җирдә, аның җан юлдашы ята. Хатын, өйдән алып чыккан сыңар чиләген кая ыргытканын да абайламыйча, тизрәк аңа иелде дә кошчыкны учларына алды. Түшенә сәер сорылык иңгән сыерчыкта җан әсәре юк иде. Ата мәченең явызлыгымы, балачага шукланып таш атканмы, әҗәле җиткәнме...

– Парлашып ни ераклардан кайткан идегез, ни авырлыклар үткән идегез, – дип сөйләнә-сөйләнә, Гөлзифа бакчага юнәлде. Коймага сөяп куелган көрәкне алып, як-ягына каранды. Бу бичараны алмагач төбенә булса да җирләсен инде, җир өстендә калдырып булмас...

Баскычка чыгып, тәмәкесен кабызган ире аның кош белән әвәрә килгәнен карап торган, ахры:

– Нәрсә, әллә хәзер мал духтыры да булыргамы исәп? – дип урынсыз шаяртып куйды.

Гөлзифа аның төртмә сүзенә игътибар итмәскә тырышты.

– Бигрәк кызганыч бит. Икәүләп каян кая кайтсыннар да, – диде дә читкә тәгәрәгән чиләген алып, мунчага таба атлады.

Рафил алай төчеләнеп тормады:

– Кешеләр дип торып чабуың җитмәгән, кош дип тә башымны катырма әле, – диде гадәти кырыслыгы белән.

Гөлзифа дәшми генә мунча ишеген ачты. Иренең соңгы араларда дорфаланганнан-дорфалана баруын үзенчә акларга тырышты. Нишлисең, фельдшер булып эшләгәч, Гөлзифа – өенеке генә түгел шул, бөтен авыл аның күзенә карап тора. Кеше төсле ял да, бәйрәм дә күрә алганы юк: ире белән парлап мәҗлескә барса да, үч иткәндәй, берәрсе йөгереп килеп җитә. Кирәк бит, нәкъ шул мәлдә берәвесе балага авырый башлый. Йә баласы ут янып урынга егыла. Йә булмаса, кемдер киселә, бәрелә, сызлана...

Баштагы мәлләрдә Рафил алай ук күтәрелеп бәрелми иде. Сукранса да, «кирәк булгач барасың инде», диюдән узмады. Төн уртасында ишек кагып уятулар тора-бара аны чыгырыннан чыгара башлады.

– Иртән барырсың, синең эш сәгатең түгел! Бик кирәксә, районга шалтыратсыннар! – дип, хатынының кулыннан пәлтәсен тартып алган чаклары да булгалады.

Андый мәлләрдә Гөлзифа иренең тузынуына игътибар итми, кулына ни эләксә шуны киеп, дару-шприцлары тутырылган чемоданын эләктереп, тизрәк чыгып йөгерә. Белә бит: ире тузына-тузына да аннан сүрелә... Кеше аннан ярдәм көтә, бәлки, гомере кыл өстендәдер. Ә ул монда, минем эш сәгатем түгел дип, икенче якка әйләнеп йоклап ятсынмы?.. Аннан ни йөзе белән авыл халкының, нәни улының, әти-әнисенең күзенә күренер?

Ул чакта да ял көне иде. Язгы кояшның тәрәзә аша үтеп кергән нурларына ияреп, газ өстендә шул кояшның үзенә охшаган кечкенә-кечкенә коймаклар пеште. Керләр юылды, бакча тутырып бауга эленде. Борын очын кытыклап, коймак исенә кушылып, ишегалдына тәмле мунча исе таралды. «Пиннек пешерә тор», – дип, Гөлзифа башта мунчага ирен озатты. Үзе сөлге-тастымалларны күтәреп, өйдән чыккан иде, бакчадан сыерчык тавышын ишетеп, җәлләүдән йөрәге ярылырдай булды. Ялгыз калган кош, алмагачка очып кунган да, үзенең ярын уятырга теләгәндәй, баягыдан да уздырып өзгәләнә иде. Үзе нишләргә белми, елый-сайрый бер ботактан икенчесенә күчеп утыра...

– Исән булса, бу хәтле тилмерүеңне ишетеп, яныңа әллә кайлардан очып килер иде җанашың. Юк бит, мәңгегә киткәч, әйләнеп кайту юк бит, – дип, кош белән сөйләшә-сөйләшә, күз яшен сөртә-сөртә, Гөлзифа мунчага кереп китте.

Ун-унбиш минут үттеме-юкмы, ишекне дөбер-шатыр кагуга атылып мунча алдына чыкты да күнегелгән гадәте буенча өстенә халатын эләргә тотынды.

– Гөлзифа, Гөлзифа, җаныкаем. Әнкәй «эчем, эчем» дип, идәндә бөтерелә, сукыр эчәгесе шартламаса дип куркам, урап кына китәрсең әле, – дип, ишекнең теге ягында такмаклаган хатынны тавышыннан танып өлгерде.

– Хәзер, Рәйсә апа, артыңнан килеп җитәрмен, яме, – дип, инде киенә дә башлады.

– Бөтен өмет синдә инде, рәхмәт яусын, – дип, хатын үзләренә йөгерде.

Рафилнең йөзе кара көяргә өлгергән иде.

– Юынып чыккач барырсың, ут капмаган!

– Кайткач иркенләп керермен. Эче авырта, ди бит, ничек көттерәсең... – Гөлзифа инде киенеп өлгергән иде.

Рафилнең дуамаллыгы куптымы, сүзен сүз итәсе килү булдымы:

– Алайса, сайла, соңгы тапкыр әйтәм: йә гаилә, йә сиксән яшьлек шул карчык. Барасың икән, мин Чаллыга чыгып китәм. Бөтенләйгә. Туйдырды мондый тормыш! – дип давыл куптарды.

«Тормыш түгел бу. Аерылышырга кирәк. Шәһәргә китәм». Рафилнең мондый сүзләре беренче тапкыр гына яңгырамый иде, шактый еш кабатлана башлады. Үч иткәндәй, быел Яңа ел киченнән үк Гөлзифаны шушы рәвешле эзләп килүләр башланган иде, елны ничек каршыласаң, шулай дәвам итәр диюләре әллә дөрес инде – күбесе карт-карчыклар гомер сөргән авылда фельдшерга эш җитәрлек иде. Иң үзәккә үткәне – юлсызлык. Егерме беренче гасырга аяк баскан мәлдә шушындый юллар бар, дисәләр, кемдер ышанмас та. Авыл эчен әйтәсе дә юк, язын-көзен бот төбеннән итек киеп атласаң да, таманга туры килә. Андый чакта машина белән йөрү, районга илтүче юлга машина белән чыгып җитү турында хыялланасы да юк...

Гөлзифа каршы дәшмәде. Иренә күзләрен тутырып карады да чыгып китте.

Рафил да китте. Шул көнне. Рәсми аерылышмасалар да, әлеге көннән алар икесе ике ярда яши башлады. Ай ул чаклар... Алмагачка кунып, ялгыз калган сыерчык түгел, Гөлзифаның җаны өзгәләнгән булган икән бит...

Ярый әле янында улы булды. Эше бар. Ире әйләнеп кайтмасмы дигән өмете, сабырлыгы булды. Шулай елларга еллар ялганды.

***

Быел кышын кар бик мулдан яуды. Басу-кырлар, урам, ишегаллары, Тукай әйтмешли, «юрган ябынды». Тирә-якта аклык кына, күзләр карап камашырлык, сокланырлык ак дөнья. Кар көртләре тарайткан урамнар.

Бүген дә медпункт ишеге ябылып тормады. Кайсының кулы пешкән, кемдер укол ясата – көндәгечә, эше тыгыз булды Гөлзифаның. Көндезге ял җиткәндә, арып-талып өенә җыенды. Улы мәктәптән кайтуга, аш әзерләп өлгерәсе бар, шәңгә пешерергә җитешмәсме әле... Гөлзифа шул уйларына ияреп, ишекне бикләде дә өенә ашыкты. Шул мәлне кесә телефоны зеңгелдәп шалтырарга тотынды, хатынның йөрәге дерт итеп китте. Ни хикмәт, төнлә каты-каты итеп ишек шакуларга күнеккән колак инде ничә еллар шушы телефонның тавышына ияләшә алмый бит!

– Гөлзифа кызым... – Трубканың теге ягында Фатыйма карчыкның хәлсез тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә иде. – Тагын кан басымы бугай...

– Фатыйма апа, аңладым, хәзер киләм, яме! – Гөлзифа аны озын-озак сөйләштереп тормады.

Бу минутта аның башында «төшке аш, Гиппократ анты, эш сәгате түгел» дигән каршылыклы төшенчәләр юк иде. Ул – фельдшер. Вакыт үлчәүләренә кеше гомере салынган. «Көндезге ашны ашап килим», диясеңме андый минутта?..

Гөлзифа өенә түгел, авылның аскы урамында, иң читтәге йортта ялгыз яшәүче карчык янына юл тотты. Фатыйма карчык – үзе дә күпме кешеләрнең гомерен саклап калган, күпме сабыйны якты дөньяга тудырган элекке фельдшер иде. Ә менә хәзер ул үзе ярдәмгә мохтаҗ. Утыз биш ел буе кемнәрне генә дәваламагандыр, авыру җиле үзенә дә килеп кагылды шул, инсульт кичерергә дә өлгерде... Әнә шуларны уйлый-уйлый, Гөлзифа аскы урамга юл тотты. Урамны чистартып торуны кирәксенмәгәннәр, карны эттерүче булмаган – карт-карчыклар өендә генә утырсын дигәннәрме...

Гөлзифа, көч-хәл белән үзенә сукмак ярып, Фатыйма карчык яшәгән йортка якынлашты. Капка төбендә дә, ишегалдында да кеше эзе күренми. «Әби бүген бер дә чыкмаган, үзенә дә керүче булмаган, ахры», – дигән уйлар башыннан йөгереп узды. Капканы ачып керүе мең мәшәкать өстәде: төнге буран кар тавы өеп куйган, ялгыз карчык яши дип кызганып тормаган. «Кайда икән бу мәктәп укучылары, кайда икән без үскәндәге тимурчылар?» – дип, эченнән генә сыкранып алды. Ниһаять, капкадан үтә алу бәхетенә ирешкән Гөлзифа сукмак яра-яра өйгә керде. Кар тулган итекләрен тиз генә салып ташлады да караватта ыңгырашып яткан Фатыйма карчык янына атылды. Әбинең ике бите кып-кызыл булган, үзе дер-дер калтырый, хәле мөшкел икәнлеге сукыр күзгә күренерлек. Гөлзифа үзеннән бер дә калмаган сумкасыннан тонометр алып, кан басымын үлчәде. Саннар әллә кая сикергән иде. Гөлзифа, җылы сүз белән карчыкны тынычландыра-тынычландыра, аңа тиз генә каптоприл таблеткасын каптырды.

– Һай, Фатыйма апа, ять-яшь башыңнан кан басымы дип ятмасаң, – дигән булды, әбинең арык беләген сыйпый-сыйпый. – Мин хәзер районга шалтыратам, «Ашыгыч ярдәм» машинасы җибәрсеннәр, алай ышанычлырак булыр. – Үзе кесә телефоныннан җәһәт кенә җыеп, авылны, йортны әйтте дә сәгатенә карап куйды. Район үзәге артык ерак түгел түгелен, тик менә, җилдереп килеп җитсәләр дә, урамга машина да, җәяүле дә керә алмый бит, арттырып әйтсәң... «Нишләп була соң?» дигән уйдан хатынның чигәсе чатнады.

«Тукта әле, тракторчы Ниязга эндәшеп карасам? Авыл башына чыга торыр идек». Башына килгән уйдан йөзе яктыра төште. Нияз – Фатыйма карчыкның күршесендә генә диярлек яши, ялт кына шуның телефон номерын җыйды.

– Нияз, син өйдәме? «Беларусь»ың белән Фатыйма апа йорты янына килеп тукта, зинһар... Тизрәк, яме...

Егетнең игелекле зат икәнен белгән Гөлзифа бераз тынычланып куйды. Көттермәс, килеп тә җитәр.

Ә үзе карчыкның киемнәрен, документларын әзерләргә кереште.

– Кызым, өйне бикләп, ачкычны үзең белән ал... Алай-болай булсам, соңгы юлга җыеп озатуны да үз өстеңә алырсың. Минем бит беркемем дә юк... Карап торганым син... – диде Фатыйма карчык, көчкә тын алып, җөмләсен өзә-өзә.

– Юкны сөйләмә, Фатыйма апа. Үзең әйтмешли, ак халатлы фәрештәләр бераздан килеп җитә, медицина көчле хәзер, бик тиз терелтеп кайтарырлар.

Фатыйма карчык үзенең һөнәрен дәвам иткән Гөлзифага бик ышана, аны үз кызыдай күреп ярата. Уртак һөнәр, ялгыз тормыш аларны еллар узган саен бер-берсенә ныграк якынайткан, туганнардай иткән иде. Карчык хәлсез кулы белән Гөлзифаның беләгенә кагылды. Чит-читен җыерчыклар сарган күзләрен тутырып, хатынның йөзенә текәлде. Күкрәп, ире белән иңгә-иң куеп яшәр чагы да, нишлисең, сыңар канат тилмерә ять-яшь көе... Зәңгәр күзләрендә моң тирбәлә. Түгәрәк йөзе, бер-берсенә тиеп диярлек торган кашлары, кызу атлауданмы, борчылуданмы алланып торган бит алмалары белән җиләккә, чәчәккә тиң чагы югыйсә...

Карчык үзенең хәлен беразга онытып, Гөлзифа турында уйланып алды.

Шулвакыт урамда трактор тавышы ишетелде. Озак та үтми, җил-җил басып, бүреген баш артына гына чәпәгән Нияз килеп керде.

– Нияз, нишлибез, әбине ничек алып чыгабыз? Авыл башына «Ашыгыч ярдәм» машинасы килә. – Гөлзифаның беренче сүзе шул булды.

– Ничек дип, минем кар эттергеч юк шул... – Егет бүреген салып кулына тотты, уйланып калды. – Тракторга менә алмый инде Фатыйматтәй... Чүмечкә утырта алмыйм бит инде мин аны...

– Нигә утыртмаска? Юрган җәябез дә икебез дә шунда чүмәшәбез... Нияз, безнең һәр минут санаулы... – Гөлзифа, хәлнең җитдилегенә ымлап, пышылдап кына шулай диде, үзе Фатыйма карчык янына иелде. – Фатыйма апа, әйдә, җайлап кына утыртыйм әле. Хәзер пәлтәңне бирәм. Бер дә борчылма, яме, барысы да яхшы булыр.

– Үзең беләсең инде, Гөлзифакаем, син әйткәч, әйбәт булыр, Алла боерса...

– Менә бит, дару капкач, хәлең дә рәтләнеп китте.

Шулай дип сөйләнә-сөйләнә Фатыйма карчыкны киендергәч, кирәкле документларны, әйберләрне сумкасына салгач, Гөлзифа белән Нияз, әбине култыклап, «кәҗә сукмагыннан» трактор янына алып килделәр. Нияз тракторның «чүмеч«ен җиргә чаклы төшерде дә култык астына кыстырып чыккан юрганны җәеп тә куйды. Фатыйма карчыкны шунда җайлап утырткач, Гөлзифа да аның янына бөгәрләнде. Ул арада кесә телефоны зеңгелдәргә тотынды.

– Без авыл башына кердек, монда бит сез әйткән урамга үтә торган түгел...

«Ашыгыч ярдәм»дәге табиб булдымы, шәфкать туташымы – Гөлзифа, аны бүлдереп:

– Беләм, беләм... Без сезнең каршыга барабыз, хәзер килеп җитәбез, – дияргә ашыкты.

...«Ашыгыч ярдәм» машинасы шофёрының «мондый ярдәмне» беренче күрүе иде, ул башта үзләренә таба якынлашкан трактор чүмеченә шаккаткан кыяфәттә карап торды, аннан, кабинасыннан сикереп төште дә тиз генә телефонын чыгарып, чүмечкә утырган әби белән авыл фельдшерын фотога төшереп мәш килде.

– Ну се-е-ез! – дип баш чайкады ул, маҗарага тап булгандай, гаҗәпләнүен яшермичә.

Карчыкны күчереп утырткач, Ниязга рәхмәт әйтеп, Гөлзифа үзе дә «Ашыгыч ярдәм» машинасына кереп чумды. Барсын әле, җаны тынычрак булыр. Улына шалтыратып әйтер, югалтып тормасын тагын....

Гөлзифа карчыкның кулын тотып, пульсын санады, хәлен сорады.

– И кызым, нигә болай газап чигеп йөрисең, өйдә генә үлсәм, яхшырак булыр иде, – дигән җавап ишетте.

– Алай димә, Фатыйма апа, терелеп, үз аякларыңда кайтырга язсын. Әнә, Гөлсем апа бүлнискә бармады, чирен белгертмәде. Мәңгелеккә киткәненә ничә ел, өенең тәрәзәләрендә көндез дә пәрдә тартылмый. Ә син Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сора. Үз эшен белгән, белемле табиб туры килсен иде, дип телә.

Әбине шулай юатып бара торгач, ниһаять, больницага килеп җиттеләр. Карчыкның документларын барлаганчы, авыру тарихын тутырганчы, табиб Марсель Әхәт улының өметләндергеч сүзләрен ишеткәнче, Гөлзифа шунда, Фатыйма апасы янында булды, кайтып китәргә ашыкмады.

– Ярый әле вакытында алып килдегез... – Табиб, күзлеген салып, Гөлзифага җитди дә, рәхмәтле дә караш ташлады. – Аз гына соңарган булсагыз...

Урамга чыккач кына, Гөлзифа үзенең шактый арыганын, ачыкканын тойды. Шулай да күңелен зарлану түгел, «Аллага шөкер, менә тагын бер гомер сакланып калды бит», дигән сөенеч хисе тутырды. Урам тутырып бертуктамый

тыз да быз чапкан машиналарны күргәч кенә, башына: «Ә мин ничек авылга кайтам соң?» – дигән уй йөгерде. «Такси чакыртсам инде»... Тик дару-уколлар белән тулы сумкада акча юк иде, карточкасы да, акча янчыгы да әллә өйдә, әллә эштә калган.

Гөлзифа, берәр игелекле бәндә утыртмый калмас әле, дип тәвәккәлләп, юл чатына чыгарга ниятләде. Телефонның шалтыравы бу юлы да җанын сискәндереп җибәрде. «Улыма шалтыратам, дидем дә, оныттым бит... Балакаем, мәктәптән кайткандыр да, «әни, аш юкмыни» дия торгандыр инде», дип уйлап, кесәсенә үрелде.

– Син нишләп мине бөтен районга, районга гына түгел, республикага хур итеп йөрисең? – дип җикеренгән тавыш иясен берара танымый торды.

Эшне төшенгәч, ак димәде, кара димәде, хатын телефонын сүндерде дә кесәсенә салып куйды. Шалтыратучы – хуҗалык җитәкчесе Рушад иде. «Ашыгыч ярдәм» шофёры үзе төшергән фотоны Интернетка куеп өлгергән дә, аның кайтавазы җитәкчеләргә дә килеп ирешкән икән. Ай бу замананың тизлеге... Гөлзифа әле район үзәгеннән үз авылына да кайтып җитәлмәде, ә Фатыйма карчыкның авырып, бүлнискә китерелүе бөтен дөньяны айкап чыгарга җитешкән... Ни дисен җитәкчегә авыл фельдшеры, «нигә авылны чистарттырмадың соң?» – дип тарткалашсынмы?.. «Кеше гомере сакланып калды», – дип сөенәсе урында, үз абруе өчен кайгырган җитәкчегә ни дип җавап бирсен? Әнисенең кышкы салкын көндә юлда бәбәйләгәнен, нәкъ менә Фатыйма апаның Рушадны машина кабинасында якты дөньяга китергәнен исенә төшерсенме... Фатыйма апаның, пәлтәсен салып, шушы баланы төргәнен, үзенең яланөс туңып барганын тагын бер тапкыр исенә төшерсенме Рушадның...

Кышкы көннең озынлыгы – бер саплам җеп кебек кенә. Юл чатына чыгып җиткәндә, күз дә бәйләнә башлады. Чит ил машиналарына кул күтәрмәде, барыбер туктамыйлар. Шактый озак басып торгач, эченә салкын үтә башлаган иде, янына ак төстәге «Лада калина» килеп туктады. Олы гына яшьтәге агай, хатын кереп утырган арада:

– Сеңлем, нишләп басып торасың? Правага укып, машина алмадыңмыни әле? Ике машинаның берсендә рульдә хатын-кыз бит хәзер, – дип сөйләнеп алды.

«Алырсың, бар... Авылда «халык саны аз» дип, хезмәт хакын 0,75 ставкага калдырдылар. Ул акчаны ничек кенә кысып тотсаң да, җиткерүләре ай-һай шул. Улын да киендерәсе, үзенең дә кеше кебек киенәсе килә. Рафил кулыннан килгәнчә улына дип акча җибәргәләп тора да... Белә Гөлзифа, әлегәчә ялгыз башы шәһәрдә торып, заводта эшләп йөргән элекке иренең дә уч тутырып акча күрәгәне юк...» Бу хактагы уйлары, әлбәттә, Гөлзифаның күңелендә генә калды. Телдән: «Юк шул әле», – дию белән чикләнде.

– Мин бит сине танып туктадым, сеңлем. Үзең, бәлки, оныткансыңдыр да инде. Авырулар күп, ә син – берәү генә, онытсаң да гаҗәп түгел. Күрше авылныкы мин, Әхмәдулла абыең булам. Синең эшли генә башлаган елларың иде әле. Комбайнда эшләгәндә, минем кул бармагым киселде, ярасы тирән генә иде, хәтерләмисеңме?.. Үзебезнең авыл фельдшеры Рәмзия ялда, Алабугасына кайтып киткән иде. Бүлнискә барып тормадык, синең янга килдек. Яшь идең, шулай да тәвәккәл идең. Комбайнчының кулын беләсең инде, майга баткан була. Син тыныч кына, мине сөйләндерә-сөйләндерә, башта май катыш канлы кулымны юдың. Мин синең йөзеңә карап утырдым, авыртуымны шулай

бастым. Аннан ни беләндер эшкәрттең, асылынып торган тирене тектең, бәйләдең. «Бүлнискә барырга кирәк, абый» дигән сүзне уттай эш өстендә, урак өстендә кем яратсын инде, тупас итеп җавап бирдем мин сиңа, һич онытмыйм... «Юк, бармыйм. Мин урасы икмәкне кем урсын», – дип кырт кистем, исеңдә түгелме?... «Бияләй киеп йөр, атна буе салма, пычрак кертмә. Бер атнадан килерсең», – дидең. Кулларың шифалы булды. Эш тә ташламадым. Бармак та исән калды. Районга барсам, йөрер идем әле бүген дүрт бармаклы булып. Мин сиңа, сеңлем, гомерем буена рәхмәтле.

Әхмәдулла агай бик сүзчән булып чыкты, Гөлзифаның ярдәме тигән тагын әллә кемнәрне барлап чыкты. Үткәннәрне искә алып, кайтып җиткәннәрен сизми дә калдылар. Гөлзифа рәхмәт әйтеп машинадан төшкәндә, Әхмәдулла агай саубуллашырга дип аңа кулын сузды. «Игътибар белән кара әле, җөе пачти беленми дә бит», дисә дә, яраның әзме-күпме эзе калган иде. Шулай шул, төзәлмәс дигән яра да төзәлә, тик барыбер сизелер-сизелмәс булса да җөе кала инде аның...

Үз капкасын ачып кергәндә, Гөлзифаның күңелендә хуҗалык җитәкчесенең сүзләре янә баш калкытты, җаны сызланып куйды. «Кулдагы яра эзе нәрсә ул, менә синең җаныңны шулай урынсыз яраласалар, нишләргә? Җандагысы онытылмый бит... Ә анда... яралар болай да байтак»... Ялгыз хатынның күңелен шул уй ярып узды.

Интернет, телефон, асфальт юллар заманында, дөнья үзенең миллиардерлары белән мактанган чорда, авыл юлын чистартырга трактор табалмаган бер «чабаталы түрә» синең җаныңа төкерсен әле... Юллары булмаса да, Гөлзифаның үз сукмагы – игелек сукмагы бар, Аллага шөкер. Нинди генә авырлыклар очрамасын, ул шул сукмагыннан атлар. Ак халатны иңнәренә матурлык өчен генә салмады ла ул. Шифалы куллары, җылы сүзләре белән кешеләргә ярдәм итә алганда, үз җанының ярасы турында онытып торыр...

– Әни, әни! – Тәрәзәдән күрепме, улы, өстенә-башына кимәгән килеш, баскычка атылып чыккан икән. – Әни! Әни! Әти кайтты! Әти кайтты... Ул... елый... – диде малай, яланаякка үрмәләгән боз салкыныннанмы, эчтәге ялкынынннанмы, баскычта сикерә-сикерә...



## Гөлфәгыйзә Юлышева

# МИН ИСӘН!

хикәя

Тау башында мәңгелек дип әйтерлек карт имән агачы бар. Олылар сөйләве буенча элек яшь-җилкенчәк, егет-кыз шунда очрашканнар. Ул үзе дә апаларына ияреп йөрде, карга боткасы пешергәнне генә түгел, ашаганын да бик яхшы хәтерли.

Бүген дә ул чираттагы балалар йортыннан качкач, тау башына менде. Таш өстенә утырып, балалар акылы белән уй йөртсә дә, табигать матурлыгына сокланып, озак уйланды. Җәйнең иң гүзәл көне иде бу аның өчен. Табигатькә сокланып, тауда икешәр морҗалы оя ясап, тереклек алып баручы әрлән-йомраннарның хәрәкәтен күзәтеп, озак кына утыргач, авылына апасы янына кайтуны кирәк дип санады...

***

Табигатьнең, дөресрәге, Ходайның нинди генә көнендә дә тереклек, яшәү дәвам итә. Тышта күз ачкысыз буран иде. Әгәр морҗаның ике катлы япкычы булмаса, җил кереп, бөтен почмакларны барлап, ишектән чыгып китәр иде, тулгактан интеккән хатында аның хәбәре дә булмас иде. Менә шундый төннәрнең берсендә Өмелхая ире Кәрамга: «Сиңа әйтәм, тор әле, тор, бар, Зөләйха карчыкны кереп ал. Нигәдер эчем авырта, пошыргаланып торам, бар, бар, тиз бул. Яңа кеше дөньяга килергә ашыга, ирәвәннәмә», – дип, ирен озаткач, үзе җайлап, урынын көйләп ятты. Тулгак тоткан саен лә-хәүләсен укыды. Кендек әбисе килеп җитүгә, бала туган, бары кендеген кисү өчен генә әби кирәк булды. Дөньяга җан иясе – малай аваз салды. Аларның алдагы ике кызына биш һәм өч яшь иде. «Малай туды, малай!» – дип, ире Кәрам бөтерелеп йөрде. Тыштагы буран өйгә кергәндәй ыгы-зыгы башланды. Малайга Зикаф исеме куштылар.

Көн артыннан көн үтте. Сагынып көткән җәй җитте. Әтиләре Кәрам яңа өй салу өчен агач кайтарып аударды. Ә үзе «малай туды», дип сөенеп, яңа өйгә күченеп йөргәндә, тотты да дөнья куйды. Кичен урынына ятты, иртән: «Сиңа әйтәм, торасыңмы?» – дип, хатыны күпме генә эндәшеп карамасын – кыймылдамады. Өмелхая өч баласы белән яңа йортта берүзе торып калды.

Кайчакта бәхет килә дә кеше сөенеп, кош тоткандай йөри. Ә кайвакыт кинәт килгән бәхет, үзенә бәрабәр итеп, кайгы да китереп өя – чыдасаң чыда, чыдамасаң үл дә кит дигәндәй, Зикафның әткәсенә дә малай туу, яңа йорт

җиткерүне Ходай күпсенде, ахрысы... Өмелхая көн арты көн сулды, саргайды. Ире артыннан монысы да китәме инде, диеште күршеләре. Ниндидер ярдәм күрсәтүдән баш тартмадылар тартуын. Әбиләре дә килгәләп йөрде, тик аның ерак авылда үз тормышы, карты да гел авырып тора.

Зикафларның тормышлары иркен. Сыерлары да бар. Олы мал асрау четерекле эш дип, сатарга уйлады әбисе, ләкин олы кызы, әнкәй сөт белән генә тора, сатмыйбыз дип кырт кисте. Соңгы килүендә, әбисе аңа: «Алайса үзең саварга өйрән инде», – диде. Тик әниләрен дә сөт кенә коткарып кала алмады, язгы кояш нурын сибеп, җир өстен иркәли башлауга бакыйлыкка күчте.

Алар өч бала. Иң олысына ун яшь, уртанчы кызына сигез яшь, ә иң кечесе – Зикафка биш яшь.

Әниләрен җирләгәч, әбисенең үзең өйрән дигән сүзләрен исенә төшереп, олы кыз сыерның җиленен тарткалап карады. Тик малкай ник кенә сөтен бирсен. Ятып имеп тә карадылар, укшып-косып сикереп тордылар да: «Юк, башка болай эшләмибез, савабыз, бетте-китте, вәссәлам», – диделәр.

Әллә аларның кулларына көч керде, әллә сыерлары күнекте: бала-чаганың нәзберек бармакларына, әйтергә кирәк, сөтен бирә башлады. Тик кечкенә энеләреннән аерылу газабы аларның бала күңеленә үтмәс сагыш булып урнашты – РОНОдан килеп Зикафны балалар йортына алып киттеләр. Аерылмаска бик теләсәләр дә, ай-вайга карамадылар. Зикаф андагы мохитне яратмады: качты, тагын алып киттеләр, тагын качты. Әмма үзе гадел булып калды, яхшы укыды. Шулай арлы-бирле йөреп, ун классны тәмамлады. Ничек кенә әле – гел «5»легә генә. Әмма алтын медаль алучылар исемлегенә кертсәләр дә, Зикафка бирмәделәр. Сәбәпләре бар: берничә мәртәбә детдомнан качуы да йогынты ясагандыр инде...

***

Малайлар арасында ул үзара кимсетү, урлашу, әләкләшү, ялган белән күзгә-күз очрашты һәм кыенлыклар белән берүзе көрәште. Аны яклаучы табылмады. Киресенчә, сулагай малайлар кичен тәрбиячеләр кайтып киткәч, аны кладовкага ябып куялар иде. Бер ябуда аны кумаклар бик нык куркытты. Йоклап киткән иде, аягын тешләп авыртуга уянды һәм ишеккә ташланды. Ишекне нык төйгән тавышка дежурный Бәһия апасы килеп ачмаса, ни булыр иде?!. Һәм Зикаф бернигә дә карамыйча, урамга чыгып чапты.

Ак кар өстендә аягыннан тамган кан эзе буйлап өенә килделәр – тапмадылар. Бу аның инде икенче тапкыр качуы иде. Шул көннән башлап, Зикаф урам малайлары белән подвалда яши башлады. Монда аны төрле начар йомышларга йөртергә уйладылар. Зикаф үзенең болай йөреп, юлдан язуын аңлады һәм шәһәр хастаханәсенең канализация коесына урнашты. Көн күрү, ашау проблемасы ягыннан бер санитарка белән дуслашты. Санитарка аңа калган азыктан өлеш чыгара иде. Бик нык ачка интеккән бер мәлне үкереп елады, нык елады. Аннары үз-үзен кызганып җырлап җибәрде:

Ярсыма, йөрәк, ярсыма,
Бу дөньяны тарсынма.
Җирдә яшәү хакына
Чыда син барсына.

Торбалар карап йөрүче ир җырны ишетеп, коега иелеп караса, исе китеп,

чак егылып төшмәде. «Шундый моңлы итеп, синме соң, малай, җырлыйсың», – дип сораша башлады.

– Җырламыйм мин, абый, елыйм. Миңа бик авыр, абый. Бу дөнья нигә шулай кырыс? Минем соң ни гаебем бар, – дип, аның аяк астына ауды. – Әнием вафат, әтине белмим дә. Детдомнан качтым, анда да бит гаделсезлек. Адәм баласына гел шулай интегеп яшәргә дигәнме, ә?

Абый кеше аны өенә алып кайтты, юындырды. Әзрәк хәл кертеп, чыгарып җибәргәндә:

– Син, улым, яхшылыкка явызлык эшләргә тиеш түгел. Бу безнең соңгы очрашу булсын, – диде.

Чыгарылыш кичәсеннән кесәсенә аттестат тыгып, сөенеп кайтканда, юлында ике ир-егет очрап сөйләшеп торганын Зикаф абайламый да калды. Боларның берсе сөйләштергән булып, аның җилкәсенә кулын салды, шуннан соң ни булганын анык хәтерли алмый гына бит Зикаф.

Ямьле июль ае. Ул таң атуга башы авыртып, үлән арасында уянды. Бер әйберенә тимәгәннәр, таныклыгы да түш кесәсендә. Гаҗәпләнерсең дә. Зикаф уйларын бер төенгә укмаштырырга теләп әкрен генә өйләренә кайтты. Үтереп башы авырта, түзәрлек түгел, муенын да боралмый, сыйпап-капшап карагач, үзенә укол кадаганнарын белде. Белде һәм елап күл буена килде, ярсып, суга сикерде. Зикаф ачуын җиңәргә тырышты. Нигә бу дөньяда яхшылык-сөенечләр әшәкелек-кайгы белән чиратлаша?

Өенә кайтканда, аның юлында тагы ике ир пәйда булды. Алар: «Дикъкать белән тыңла, шәһәргә барасың, менә сиңа юллык акча, шул урамга төшәсең. Син менә бу сигаретларны берәмләп кенә сатасың, кич акчаны безнең кеше килеп алыр. Полный расчёт ясыйсың. Хәзер син безнең кеше», – дип инструктаж уздырдылар да китеп бардылар.

Зикаф ничек тә үз чире белән үзе генә көрәшергә, кешеләргә зыян-зарар салмаска тырышты. Энәгә утыруның, аннан котылуның коточкыч авыр икәнлеген белсә дә, берничә мәртәбә ычкынды, бичара, аңа бу афәтне исенә төшереп кенә түгел, аны эзләп табып, өстәп тордылар. Энәдән төшү юлын зиһене бераз ачылуга үзенә максат итеп куйды. Китап-җыентыклар тапты, күп укыды. Һәрбер өянәк вакытында нык интекте. Аның кулбаш сөякләре асылынып төште, буын сөякләре тотмас булды. Чираттагы өянәгендә үзенең үлемен көтеп, ямьле җәй иртәсендә авыл зиратына – әнкәсенең каберенә килде. Кабер өстенә ятып, гафу үтенде. Хәле китеп, беркавым йоклап алгандай булды. Шушы кыска гына йокы вакытында, әллә төш, әллә өн – аның янына ак киемнән бер бабай килеп басты.

«Улым, хәлең бик авырмы? Авырдыр, беләм. Менә, улым, сине әниең Ходай кушуы буенча дөньяга тудырган, инде син зур егет, җитмәсә, искиткеч чибәрсең. Кара әле, улым, синең бу чирдән интегүләрең әнкәеңнең сине тудыргандагы бер тулгагына да тормый. Менә шуларны уйла да түз! Өчкә кадәр түзсәң, чиреңне җиңәрсең. Әгәр дә теге явыз җаннар эзләп табып, агуларын өстәмәсәләр, җиңәрсең иншалла. Бу зират бакчасында чишмә бар, шул чишмәдән су эч, шикләнмә! Бу су зираттан түгел, әнә теге таудан килә, әйтергә кирәк – тау чишмәсе. Кузгалак, балтырган, җиләк, бөрлегән аша, күп су эч, суның шифасы көчле, бар тереклеккә булыша, сиңа да иншалла шифасы тияр, терелерсең. Бүтән энәдәшләр белән аралашма, икенче җиргә күч, туганнарың бардыр бит. Хуш, улым, син тәмам терелгәч, без тагын очрашырбыз. Мин сине кайда да эзләп табармын. Минем сүзләрне алга таба исеңдә тотсаң, бар да яхшы булыр. Минем белән очрашуны

һичкемгә дә сөйләмә. Үзеңнән көлүләре бар. Явызлар явызлык кылып, кешене туры юлдан яздырып яшәүдән тәм таба. Үзең җае чыккан саен кечеләргә-өлкәннәргә, хәлсезләргә булышырга тырыш. Бәхеткә юл уңнан туры, ә сулда угрылар юлы! – дип, сүзен бетерде дә җил-җил атлап, агачлар арасына кереп югалды.

Зикаф иң беренче чишмәне эзләп тапты. Эчәсе килмәсә дә, көчләп су эчте, битләрен юды. Хәл кергәндәй булды, башына уй йөгергәнен сизде. Бабайның сүзләрен берәм-берәм хәтеренә китерде. Таныган үләне кузгалак булганга аны өзеп чәйнәде. Әчкелтем тәм авыз эчендә генә түгел, бөтен тәненә җиңеллек бирде. Чишмәдән ерак түгел сөзәк җирдә күзенә кызыл бөрлегән чагылды, аны кепкасына җыйды да тагы әнисенең кабере янына килде. Утырып бөрлегәнен ашады һәм туктаусыз әнисе белән сөйләште. Аның әнкәсе белән сөйләшеп, серләрен чишкән саен зиһене ныграк ачылуын тойды. Ул әле генә бабайдан ишеткән киңәшләрне дә ап-ачык хәтерләде, эченнән генә рәхмәт әйтеп, тагы чишмә янына килде, кинәнеп су эчте. Чишмә янында куакка эленгән калай банканы алып, яхшылап юды да су алып өенә – апаларына кайтты. Аны күрүгә апасының: «Әй энем, нинди су бу? Өйдә су агып тора бит», – диюенә, Зикаф: «Апа, төпченмә, миңа бидоныңны бир, мин тагы суга киттем», – диде дә чишмәгә юнәлде. 10 литрлы бидонын тутырып су алып кайтты. Туктаусыз шул суны эчте. Аның бер апасы кияүдә инде, баласы бар, сатуда эшли икән. Кечкенәсе дә житкән кыз, шәһәрдә югары белем ала. Зикаф күп вакыт өйдә берүзе генә була. Ялгыз калып, өянәге тигәндә, күпме кирәк шулай интегә, аны кызганучы да, көлүче дә юк дигәндәй...

Ул үзенең өянәгенә алдан әзерләнде, тәнен-күңелен катырды. Туктаусыз су эчте, су эчкән саен чеметеп тоз капты, аның саен: «Мин исән! Мин исән! – дип кабатлады.

Апасы ашарга китерде, ләкин Зикафның карыны каршы торды. Икенче көн иртә белән гүя аның тәнен чәнечкеле тимер чыбыклар кысты, аунады, бөгәрләнде, сызланды, түзде. Богау чыбыкларын сындырды, бөкте. Шушы мәлдә апасы эштән кайтып керде. Апасы биргән кружкадан теләмәсә дә, тончыга-тончыга су эчте, әкрен-әкрен язылды, чире белән көрәшеп арыды. Аннан йокыга талды. Бу юлы аны краннан су сибеп тынычландырырга туры килмәде. Зикаф озак йоклады. Апасы карап ала да чыгып китә. Башка наркоманнар кебек зыян салмавына сөенә иде.

Зикаф бер тәүлек йоклады. Ул шундый рәхәтлек белән уянып, тышка чыкты. Аяз күккә карады. Әни янына барам әле дигәч, апасының коты очты:

– Авызыңнан җил алсын, зиярәт кылам диген!

***

Беркөн иртән ихатасында яныл-пешеп эшләп йөргәндә, апасының кызы йөгереп килеп керде, тыны-көче бетеп: «Абый, абый, кара, сине бер кеше эзли», – диде. Зикаф, алдан ук уйланылган хәйлә буенча, кар базына чумды.

– Абый, бер үк күренә күрмә. Әни сине энәдән үлде, дип әйтте ул кешеләргә, бүтән эзләмәсеннәр өчен шулай эшләде, – диде дә арткы яктан өйләренә чапты.

Зур апасы да яхшы сәбәп уйлап тапкан. «Әйдәгез, зиратка, каберен күрсәтәм», – дигән булды. Ошбу хәлне күрше әби дә тәкрарлап хуплады. Менә шундый ялган белән котылды ул үзен эзәрлекләп, акча эшләүчеләрдән. Егетне инде тынычлыкта калдырырлар, шәт.

Ул колхозда җизнәсе белән тракторда ярдәмче булып эшли башлады. Кайчак өянәге килүен алдан сизеп сызлана башласа, беләген чәйнәп ала, йотлыгып

су эчә, чеметеп тоз каба, тагы су эчә, трактордан сикереп төшә дә кыр буйлап чаба һәм шулай өянәген җиңә. Зикаф тормышның мәгънәсен танып белү өчен, кемнеңдер үз янында булуын, хәрәкәт, хезмәт, кешеләргә изгелек кылу кирәклеген аңлады. Ул белә: мондый авыр чакта яныңда аралашып сөйләшергә кеше булмаса, яшәү ямен югалтырга мөмкин. Алар җизнәсе белән нык дуслаштылар. Җизнәсе: «Сиңа карап, мин яшь чагыма кайткан кебек булам, кайнеш», – дип көлә. Иген кырыннан хәтсез җәяү атлыйсы бар, Зикаф төшке ашны өйгә кайтып ашый да җизнәсенә басуга алып бара.

Бер кайтуында ни күрсен, күл буенда халык кычкырыша, өзгәләнә, ярдәмгә чакыра, кул болгый. Йөгереп килсә, Зикафтан ике генә яшькә кече Мәһәҗүрә исемле кыз суга баткан. Амбарда эшләүче Шаһит абый белән Ильяс исемле егет күл төбеннән эзлиләр бугай.

Зикаф кечкенәдән йөзәргә өйрәнгән иде. Башта суга чишенми генә сикерсә дә, соңыннан күлмәк-чалбарын салып, су өстенә атты да чумып-чумып эзләргә кереште. Тик озак эзләргә туры килмәде Зикафка, маңгае кызның йомшак тәненә тиюен тойды. Һәм Зикаф су сөлеге кебек җитезлек белән кызны җир өстенә чыгарып салды! Ә бит кыз чибәрнең дә чибәре. Ләкин шул чибәрнең бүген гомере өзелергә мөмкин иде... Ул исән!!!

***

Ару гына үз тормышын җайга салып яшәп ятканда, армия хезмәтенә чакыру кәгазе килеп төште. Егетнең апасы:

«Шулай инде, Зикаф интеккәндә, кул сузучы юк иде, эшләр уңайга барганда, күрделәр әнә. Хәер, аларга кеше саны гына кирәктер», – дип сукранып куйды.

Зикаф нык борчылып, иртә белән хәрби комиссариатка килде. Комиссия аннан, чир тапмагач, ничекләр сөенгәнен үзе генә белә!..

Зикафны Новосибирскига алдылар. Хезмәткә керешкәч үк, шофёрлыкка укыттылар да командирны йөртә башлады. Элек армия хезмәтен үткәннәрдән яхшы ук хәбәрдар булганга, дедовщина аны куркытмады. Карт солдатлар аңа оекбашларын, итекләрен юарга кушып карады. Ул бу башбаштаклыкны авыр кичерде, әмма керләрен юмады. Суга чылатып, бер почмакка өеп кенә куйды. Аны нык кына кыйнадылар. Ул тибеште. «Әһә, әле син тибешәсеңме», – дип, аягын бордылар. Тешләште. Тешләшмә, дип, авызыннан кан койдырдылар. Зикаф өчен бу сынау беренчесе һәм соңгысы иде. Үзе дә аптырады – башка аны кыерсытучы булмады. Ә менә старшина үзенчә рәнҗетергә уйлагач, Зикаф моның колак төбенә «сылады». Старшинаның күзләреннән яшелле-зәңгәрле очкыннар очты. Шушы очрактан соң старшина карт солдатларны Зикафны акылга утыртырга котыртып караган иде. Ходай рәхмәте, аңа каршы җыелып килгән чукмар куллы солдатлар: «Әй, мәхлук, йә, ярар, мир», – дип, берәм-берәм кулын кыстылар. Киресенчә, старшинаның үзен «акылга» утыртырга булдылар. Старшинаның яшь солдатлардан акча җыйнавын һәм күп кенә тәртипсезлекләрне яздылар да хатны тоттырып, Зикафны командир бүлмәсенә төртеп керттеләр. Командир Зикафның курка-курка гына сузган хатын дикъкать белән укыды. Шактый күп солдатларның имзаларын күргәч, алар бик тиз аңлашты. Ул бу хәлләрне элегрәк тә белә иде, ничектер вакыты җитмәдеме, әллә шушы мөрәҗәгатьне көттеме?.. Төтенсез ут булмый дип, тәртип урнаштыруны кече старшиналардан башлады. Берничәсен дисбатка озаттылар...

Хезмәт итү яхшы гына бара. Зикаф командирның ышанычын аклау өчен барын да эшли. Шулай дуслашып, нәкъ ел ярым хезмәт иткәч, ун көнгә

отпускка җибәрергә булдылар аны. Озатканда: «Ишетсен колагың, тешләгәндә телең өзелмәсен дисәң, авызыңны ачма», – диделәр.

Менә ул авылына кайтты. Әй, сагындырган да соң туган авылы! Кояш киң кырларга, чиксез басуларга, хуш исле болыннарга үзенең канатын җәя. Чәчәкләр янында каласы, яшел үләнгә ятып ауныйсы, Ык буенда ялан тәпи йөрисе, чалбар балакларын сызганып, тездән суга керәсе килә. Дөньяда иң матур җир монда гынадыр.

Зикаф кыр буенда, зират янында ук төшеп калды машинадан, үзен сихәтләндергән чишмәгә килде, битләрен юды, йотлыгып суын эчте.

Балаларына күчтәнәчләр өләшкәч, әй сөенде апасы! Җизнәсе дә кырдан кайтып җитте: «О-о, кайнеш, менә ичмасам кунак дисәң дә кунак! – диде. Хәзер өстәлгә хәмер куеласын чамалап, Зикаф сүзне икенчегә борды.

– Кара әле, апа, кич вечерлар буламы авылда? Бүген клубка чыгам әле, – диде.

– Бездә Зифа Басыйрованың концерты бүген, тик билетлар сатылып беткән, диләр, клуб та кечкенә инде...

– Әйе, апа, минем бик тә концерт карыйсым килә, барам, Зифа апаның үзен сәхнә артыннан булса да күрим.

Тик анда ишеккә якын килерлек түгел. Тәрәзәгә дә өелгәннәр, нишләргә? Күп уйлап тормады Зикаф. Клубның артистлар гына йөри торган ишеген шакыды һәм ник шакыганына үкенде, чөнки ишекне Зифа Басыйрова үзе ачты.

– Кемнең бик керәсе килә? Әй, Ходаем, шушы гына җитмәгән?

Ул караңгыда Зикафның солдат кителен милиция киеменә охшатты, ахрысы.

– Зинһар гафу итегез. Мин армиядән отпускага гына кайттым, билетлар да юк икән, – дип акланды. Аның моңарчы Зифа Басыйрованың үзен беркайчан да күргәне юк иде.

– Әй балакай, – дип, Зикафка бер күтәрелеп карады. – Әйдә, кер, хәзер берәр җаен табарбыз, – диде. Егетне култыклап сәхнә аша залга үткәрде.

Зифа Басыйрованың концертыннан соң, Зикаф үзен бөтенләй яңа кеше итеп тойды. Гүя бала чагына, үсмер чагына кайтып килде... Үз-үзе белән көрәшеп, чирен җиңәргә ихтыяр көче тапканга сөенде. «Мин – исән!» – дип пышылдады. Җәйге тын һавада аны бу уйлардан кырыс ирләр тавышы һәм өзек-өзек еламсыраган кыз бала тавышы бүлде. Шул тарафтан җил-җил атлап, бер ир-ат узып китте. Зикаф, нидер сизенеп, сагая калды. Сизенүе дөрес икән: әкрен генә башын түбән иеп, аңа таба бер кыз якынлашты. Зикаф аны куркытмас өчен йомшак кына тамак кырды. Кыз борылып карагач кына:

– Гафу итегез, сезгә ярдәм кирәкмиме? – дип сорады.

Кыз исә:

– Юк! – диде.

– Узып киткән кеше сезне рәнҗеттеме? Сез мине белмисез, мин сезне дигәндәй, безнең сөйләшү ике арада гына калачак.

– Юк шул, Зикаф, мин сине бик яхшы беләм. Ә менә син армиягә киттең дә оныттың. Егетләр армиядән вакыт уздыру өчен генә дә адрес табып, кызлар белән хат алыша, ә син авылдаш булып, бергә уйнап үскән егет мине үлемнән коткардың да югалдың... Эх, син! – диде дә төн караңгылыгына кереп югалды. Зикаф баскан җирендә каккан казык кебек катып калды.

– Менә сиңа, мә! – диде үзенә-үзе. – Миең үрдәк күлендә җебегәнме әллә синең? Бу бит мин коткарган кыз – Мәһәҗүрә! Һәм ул ике дә уйламый, кызның өенә юнәлде. Ләкин өйдә ут-фәлән юк, ишектә йозак иде. Зикаф иртәгәсен тагын барды бу өйгә, ләкин кызны очратмады. Төн караңгылыгын ерып, аның кырыннан

узган кеше – егетедер дип уйлады ул. Шулай кыз белән аңлашмыйча гына авылдан китте. Тик Зикафның уйлар өермәсе гел Мәһәҗүрә турында чуалды. Ул үзе дә сизмәстән күзгә күренмәс җепләр белән шул сылуга уралганын төшенде.

***

Зикаф, армия хезмәте тәмамлануга, Новосибирск шәһәренең медицина институтына имтиханнар тапшырды. Укырга керүен әйтергә кирәк дигән максат белән авылына кунакка кайтты. Апалары, әлбәттә, хупладылар, нинди бүлектә укыйсың, дип сорауларына: «Хыялым авыр хәлдә калган кешеләргә ярдәм итү, нарколог булырмын, Алла бирса», – дип кенә җавап бирде. Казандагы институтка керсәм, кайтып йөрергә якынрак булыр иде дә, ләкин анда үткән яшүсмер чагын хәтерләүчеләр булыр, бармак төртеп күрсәтүчеләр табылыр, дип уйлады.

Зикаф шәһәрдә тулай торакка түгел, аерым кешеләргә урнашты, чөнки ул тулай торак тормышын элеккечә итеп бик яхшы күзаллый иде. Ул бик мәрхәмәтле өлкән кешеләр – әби белән бабай фатирының йокы бүлмәсендә яшәде. Кирәгенчә өлкәннәргә булышты. Алар үз чиратында аны уллары кебек күрделәр. Беренче курсны бетерүгә, практика үтү өчен аны моргка җибәрделәр. Беренче мәртәбә мәетне күрүгә үк аның башы әйләнде. Практикага килгән башка егетләр дә мәетләрдән куркып, тубалдан чәчелгән бәрәңгеләр кебек, чыкканы бере җиргә тәгәрәп укшыды. Бу күренеш педагогларга да ошамады, беренче карашка кызык тоелса да, чынлыкта бу бик кызганыч хәл иде. Менә шуңа кайбер моргка кертеп тә тормадылар. Теориягез бишле булсын, ишетсен колагыгыз, дияләр иде. Бу бәхет Зикафка да елмайды. Әле мәетне ярып өйрәнергә кушсалар, нишләрсең, күзеңне йом да, Зикаф, тай моннан, диярсеңме? Ләкин ул бит әллә нинди авыртуларга, кыйналуларга да түзде! Җиңәргә тиеш мин, тиеш, үземең күңелемне генә түгел, бөтен булмышымны, эчке тойгыларымны җиңәрлек көч табарга тиеш...

***

Зикаф кулына икенче хирург дипломы да алгач, эшкә юлламаны иң ерак җиргә – Камчаткага бирүләрен сорады. Комиссиядәгеләр, аптырап, бер-берсенә карашып алдылар да: «Әһә! Дөнья читендә оҗмах күрәсең килә икән, әйдә, рәхим ит, корякларны дәваларсың», – диделәр. Ә бит алар аны шушында, Новосибирскида калдырырга тәгаенлап куйганнар иде югыйсә. Синең холкыңны беләбез, гел үзең хәл итәргә яратасың, юлыңда очраган киртәләрне кемнеңдер алып атуын көтеп ятучылардан түгел. Әгәр дә сине кемдер кызгана икән, ул кеше сиңа җен булып күренә. Көчле кешене кызганырга ярамый шул. Кызгану – кешене кимсетә, рухын сүндерә, үзенә ышанычын киметә!..

Камчаткага киткәч, тиз генә яллар да тәтемәс дип, туган авылына кайтып килергә булды Зикаф.

Июль башы...

Тауда җиләк чүпләүче хатын-кызлар күренде. Алар – печән җыючылар, төшке ашка кайтып барышлары икән. Ул уйларыннан айный алмый атлап барган килеш кемнеңдер аяк тавышын үз янында ук тоемлап алды. «Ялгышмасам, Зик-Зик-Зикаф син», – дигәнгә борылды да карашы белән кызны туктатты. Йөрәге чабышкы аты кебек тибенә, ниндидер сәер тойгы, ток йөреше кебек, җилкә тамырыннан табанына чаклы авырттырып узды. Күпме күзләр арасыннан, әллә кайларда йөреп тә мондый татлы хис кичермәде бит әле ул. Баксаң, үз авылында, үзе аунап үскән тауда өлгергән икән ләбаса аның

мәхәббәт җиләге Мәҗәһүрә! Йа Ходай! Бүз – җөе белән, сүз – җае белән диләр бит. Вакытында әйтелгән сүз генә йөрәккә барып җитә. Моны инде егет яхшы белә. Мәҗәһүрә: «Кара! Анда җиләкләрне таптыйсың», – дигәч, Зикаф: «Юлда кем йөрмәс, миннән алда», – дип кенә җавап бирә алды. Кыз Зикафның бу сүзен үзенә киная итеп аңлады.

Зикаф кызның күзләрендә моңсулык күреп, аны тынычландырырга ашыкты.

– Кара әле, Мәҗәһүрә, яшәү болай да мизгел генә, гомерне үз кулыбыз белән кыскарту кирәкмәстер. Бу җиләкле тау безнең язмыш тавы булсын. Әйдә, утырыйк әле, сөйләшик. Мин бит сиңа бөтенләй чит кеше түгел.

Кызның болай да сынык күңеле бөтенләй тулышкан икән. Зикафның иңенә башын куеп, үксеп елап җибәрде. Ничек кенә еламаска тырышса да, булдыра алмады...

Иртәгәсен ишегалдында аркылы-торкылы яткан утыннарны өештереп йөргәндә, Зикаф килде һәм өйләнешү турында сүз кузгатты.

Никах алдыннан ата-ананың хәер-фатихасы булыр дигәндәй, әүвәл әниләренең каберен зиярәт кылдылар. Һәр икесе дә якыннарына серен чишкәч, тау буенда йөрделәр. Эңгер-меңгер төшкәч кенә, Мәҗәһүрәнең өенә керделәр. Монда ут бармы, дип сорагач, Мәҗәһүрә: «Юк... бар, ләкин яндырмыйбыз, – дип пышылдады. – Мин, мин бит сиңа 15 яшьтән гашыйк! Син, син генә гел... – дип хисләрен тыя алмады.

Озакламый якын туганнары белән никах мәҗлесе уздырып, апаларының хәер-фатихасын алып, Петропавловск-Камчаткага очтылар.

Аларга фатирны да хастаханә яныннан гына бирделәр. Мәҗәһүрә читтән торып укыды, акушер һөнәрен үзләштерде.

Зикаф Заманов сәламәтлек саклау өлкәсендә зур тырышлык куеп эшләр. Олютрск районында гына түгел, аны өлкә күләмендә дә белерләр. Ул монда билгеле бер урын биләп тора торган көчле ихтыярлы шәхес булып өлгерер. Аны районның баш табибы итеп куярлар. Камчаткада аз санлы милләт халкын саклап калу һәм яңа туган балаларның үлем очракларын булдырмауда зур өлеш керткәне өчен аңа Хөкүмәтнең югары бүләге – Фидакарьлек ордены бирелер. Үзе белән бергә эшләгән докторлар Замановны остазлары итеп горурланыр.

Пенсиягә чыккач, чит кеше исеме астында истәлек-хатирәләр китабы чыгарыр, наркоманнар турында берничә җыентыгы дөнья күрер... Әлегә, Зикаф Хәерович әйләнә-тирәгә нур чәчеп, кешеләрнең гомерен озайта. Командирының «Үзең ул кешене коткар» дигән боерыгы буенча яктылык өләшеп яши...

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

# ИДАРӘЧЕ ДӘ, ИГАНӘЧЕ ДӘ

ОЧЕРК


Наил Закир улы белән үткән гасырның туксанынчы елларында танышырга насыйп булды миңа. Ул чорда колхозлар тулы тормыш белән яшәп, авыллар гөрләп тора иде. Әтнә районының «Чулпан» колхозы – миллионер хуҗалыкларның берсе булып, районның гына түгел, республикабызның да горурлыгы иде. Ләкин аңа хәтле таушалган, таланган күмәк хуҗалыкны аякка бастыру өчен яшь колхоз рәисенә бик күп көч түгәргә, түзәргә туры килә!

28 яше дә тулырга өлгермәгән Наил Сабировны 1960 елның 17 февралендә «Нәкъ Сезнең кебек кешеләр белән җылы мөнәсәбәт таба белә торган, заман таләпләрен үти алырлык яшь җитәкче кирәк, югыйсә хуҗалык таралачак», – дип, «Чулпан»га билгелиләр. Укытучы булырга хыялланган егет ул чагында читтән торып, Казан университетында укый. «Өч елдан кулга диплом алам һәм шул хезмәтемне дәвам итәр идем», – дигән фикерен район җитәкчелегенә җиткерә ул. Бюро әгъзалары: «Өч елыңны эшләп кара, укуың беткәч, мәктәп директоры итеп куярбыз!» – дип күндерәләр. Наил Закир улы партия әгъзасы буларак, бюро тәкъдимен кабул итә. Наил абый ул елларны үзе: «Колхозда эшли башлагач, райком секретаре: «Миңа килгән кунакларны каршы алырга бер колхоз кирәк! – дип, басым ясый башлады. Бөлгенлеккә төшкән колхоз җилкәсенә аларны ашату-эчертүне дә салсам, авыл кешеләренең, бигрәк тә тырышып хезмәт куйганнарының, намуслыларының күзенә ничек караган булыр идем икән? Мин каршы килдем. Райком секретаре исә үзе идарә иткәндә, шуны гел искә төшереп, аяк чалып торды. Безгә дип кайткан молоковозны бирдертмәде. Бәрәңге алу чоры җиткәч, гадәттәгечә, педагогика училищесы студентларын җибәртмәде. 350 гектар бәрәңгене колхоз көче белән алып бетердек. Өстәвенә, кырларында эш начар бара, дип бәйләнә иде. Ярты еллап эшләгәч, хет ярыл, җир тишегенә кер, әмма колхозчыларга хезмәт хакы түләргә акча табарга кирәклеген аңладым һәм шуны тормышка ашырдым. Икенче мөһим эш: өч авылда да комплексы бригадалар төзеп, иң булдыклы, тәҗрибәле кадрларны бригадир итеп билгеләдем. Искеманһгәрлеләргә нәсел фермасы һәм таналар тәрбияләү, бәхтиярлеләргә үгезбозауларны симертү һәм сарык фермасын рентабельле итү эшен йөкләдем. Олы Мәңгәргә исә савым сыерларын асрау һәм дуңгыз ите җитештерү фермалары беркетелде. Иң мөһиме: экономия ясаучыларга өстәмә түләүләр системасы эшләнде», – дип искә ала. Шундый җитәкче белән колхозда көчле команда оеша, хуҗалык аякка баса. Керем арткан саен төзелеш эшләре гөрли, яңа техника сатып алу мөмкин була башлый. Яңа фермалар, машина-трактор парклары, амбарлар, зур ындыр табаклары белән беррәттән социаль-мәдәни объектлар калка. Төзелешләр, нигездә, хуҗалыкның үз көче белән башкарыла. «Шәхси йортлар салганда исә, матди яктан тәэмин итеп, транспорт һәм колхоздан төзүчеләр биреп, йорт салучы үзе теләгәнчә төзергә мөмкинлек тудырылды. Шулай гына каралты-кураның, йорт-җирнең кадере була! Мин эшли башлаганның унынчы елында, ниһаять, ссудалар алмыйча, үзебезнең акчага яши башладык. Колхоз исә районда гына түгел, республика күләмендә дә алдынгылар рәтенә күтәрелде. Шулай да район җитәкчесе тарафыннан тискәре мөнәсәбәт тә бетмәде.

Депутат күрсәтү Сезнең колхоздан булса да, парторгыңны сайлыйбыз, ди. Әгәр дә башка кешебез юк икән, аны үткәрербез инде, дим, сер бирмәскә тырышып. Үзенчә тагын бер үч алуы булды. Шуңа карамастан, 1978 елда ун күчмә байракның тугызын

без алдык. Өстәвенә, ВДНХныкы да безнең хуҗалыкка насыйп булды. 1980 нче елларда колхоз нык алга китте. Техника җитәрлек, хәтта күрше-тирәләргә дә булышабыз, – ди ул.

Наил Закир улы беренче көннәреннән үк алны-ялны белмичә эшли, максатына ирешер өчен алдынгы хуҗалыкларның эш тәҗрибәсен өйрәнә. Бигрәк тә «Северный» совхозының директоры Нәкыйп Сафин һәм «Искра» колхозы рәисе Фәйзи ага Галиев маяк булып торалар аңа. Шуны да искәртеп китәргә кирәк: өч ел эшләгәннән соң, хисап-сайлау җыелышында Наил агага халык: «Без сине яраттык, үз иттек, пенсия яшенә хәтле җитәкче булырсың, китмә бездән», – ди. 34 ел хезмәт куйгач – 62 яшендә дә эшен дәвам итүен сорыйлар.



*Наил Сабиров*

Наил Сабиров 1932 елның 22 августында Әтнә районының Дусым авылында дөньяга килә. 1940-1950 елларда туган авылында башлангыч, Күәмнең җидееллык, соңыннан Олы Әтнәдә урта мәктәпне тәмамлый. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын исә, алдарак искәртүемчә, читтән торып тәмамлый. Хезмәт юлын бик иртә – 1950 елны Түбән Көек җидееллык мәктәбендә немец теле укытучысы булып башлый, 1952-1954 елларда Арыда дәвам итә. Кешеләр белән бик тиз уртак тел таба ала торган егетне 1954 елны Әтнә районына ВЛКСМның 2 нче секретаре итеп билгелиләр. Спортта ярышып, сәхнәдә рольләр уйнап үскән Наилнең бирегә килүе әлеге оешманың эшен активлаштырып җибәрә. Нинди генә чаралар уйлап тапмый алар. Спорт бәйгеләре, театраль фестивальләр, авылларга чыгып концертлар кую, ветераннарның хәлләрен белү, ярдәм итү дисеңме – барысы да алар кулында була. Озак та үтми, яңалыкка омтылучы, ярдәмчел, тырыш егетне 1957 елда ВЛКСМның беренче секретаре итеп күтәрәләр. Ул анда «Чулпан»га колхоз рәисе итеп билгеләнгәнчегә кадәр хезмәт куя. Яшьтән үк колхозчыларның кул көче күп сорала торган тормышын җиңеләйтү, коммунизм төзү идеаллары белән хыялланып йөргән Наил Закир улы күпмедер дәрәҗәдә шул югарылыкка ирешә дә: хуҗалыкның өч авылында да мәктәпләр, балалар бакчалары, медпунктлар төзетә. Урамнарда суүткәргечләр сузыла, районда иң беренчеләрдән булып, йортларга газ керттерә. Алдынгы ысуллар куллану, хезмәт дисциплинасы, лаеклы хезмәт хакы, уңай шартлар, сменалы эш таулар күчерә ала икән. Балаларга хоккей мәйданчыклары төзетү, спорт киемнәре белән тәэмин итү, җиһазлар алу да гади бер күренешкә әйләнә. Сәбәпсез эш калдыру, исереп, иптәшләреңне кыен хәлгә кую очраклары юкка чыга.

Авыл хуҗалыгының фидакарь хезмәткәрләренә ял йортларына юлламалар даими бирелеп тора. Берәр бәла-каза килсә дә, колхоз шундук ярдәм кулы суза. Ике катлы, иркен Олы Мәңгәр мәдәният йортында халык театры иҗат итә, бию, шахмат, баян, көрәш секцияләрен колхоз финанслый. Наил ага эшләгәндә, «Чулпан»ның өч бригадасында да җылы гаражлар, техника кую һәм төзәтү бинаалары торгызыла. Механизаторлар хуҗалыкның абруйлы кешеләренә әйләнәләр. Бу эшкә яшьләр дә тартыла. Колхозның соңгы елларында гына да 98 механизатор әзерләнә. Күпме данлыклы авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре үсеп чыга шул чорларда! Механизатор Минзыя Сафин – Хезмәт Кызыл Байрагы, Зөлкарам Абдуллин – «Почёт Билгесе» ордены, Фәүкать Гыйләҗев – Хезмәт Кызыл Байрагы, Мансур Габдрахманов һәм Сәвия Ибраһимовалар III дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары белән бүләкләнә. «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән Фирая Муллагалиева, «Почёт Билгесе» орденлы, алдынгы сыер савучылар Нурия Җиһаншина, Венера Сәфәргалиевалар – бүген дә авылның горурлыгы. Тракторчы-механизаторлар Рәшит Мөхәммәтҗанов, Габдерафыйк Нигъмәтҗанов, Камил Габдрахманов, комбайнчылар Әлтаф Мөхетдинов, Нурулла Хисмәтуллин, көйләүче-оста Рузинар Галимов, Сәгъдулла Сафиуллиннарны



*Татарстан Республикасының Беренче президенты М.Шәймиев Әтнә кырларында. Сулдан уңга: Н.Сабиров, М.Шәймиев, Ф.Галиев.*

зур ихтирам белән искә ала бүгенге көндә 87 яшен тутырган Наил ага. Олы Мәңгәр китапханәсе үзе ни тора! Рухи камиллек, тиңдәшлек, бердәмлек шигаре астында эшләп, укучыларның дөньяга карашын киңәйтүдә, белемгә омтылуда зур эш алып баралар. Китапханә белән Наил абыйның тормыш иптәше Ләлә Сабирова җитәкчелек итә, шулай ук Надия Сәфәргалиева да укучыларны төрле кызыклы китаплар белән таныштыра. Аларның фидакарь хезмәтләре «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем белән бәяләнә. Наил абый мәдәният йортына яңадан-яңа китапларны кайтарып тора. Хуҗалык белән идарә итсә дә, укытучы һөнәренә, китапка мәхәббәте саклана аның. Н.Сабировның тырышлыгы, югары бусагаларны таптавының нәтиҗәсе буларак, Каенсар урманында район балалары өчен ял лагере ачыла. Исем эзләп ерак китмиләр – «Чулпан» дип кушалар. Әлеге лагерь бүгенге көндә бөтен дөньяга танылды – чит ил балалары да үз итте аны.

Наил Закир улы инде күптән лаеклы ялда булса да, әле дә халыкка хезмәттә. Аның ярдәме белән туган авылы Дусымга асфальт юл килеп җитте. Бер түбә астына кертелеп, мәктәп, балалар бакчасы, ашханә, идарә йорты салынды. Җыйнак кына, матур мәчет тә авылга иман нуры тарата.

...Бүгенге көндә хезмәт стажы 70 елга тулган Наил ага – җаваплылыгы чикләнгән «Дусым» ширкәтенең Директорлар советы рәисе. «Олы улым Рөстәм пенсиягә чыкса да, үзенең фирмасында төзелеш эшләре белән шөгыльләнә. Бер малае, ягъни оныгым да үзе белән, икенче оныгым башкалада рестораторлык эшендә. Икенче улым Илһам – бүгенге көндә Арчада нефть эшендә җитәкчелектә, безнең белән дә хезмәттәшлек итә. Төпчегем Азат – танылган врач, шәхси клиникалары бар. Ләлә апагыз исә өй тирәсендә генә инде, оныкларга тәрбия бирә».

«Дусым» ширкәтенең бүгенге көндәге башкарма директоры Ленар Сәмигуллин: «Наил абый турында кечкенәдән ишетеп, белеп үстек. Легендар шәхес бит ул. «Чулпан» колхозында эшләгәндә, түрәләр күзенә артык чалынмас, колхозчыларның тискәре карашына дучар булмас өчен ул шөрепне дә үз акчасына сатып ала торган була. Тормышын да иске генә йортта яшәүдән башлый. Хәтта үзенә дигән бүрәнә һәм такталарны да нәрсәдер төзергә кирәк булгач, ике дә уйлап тормыйча колхозга илтеп бирә. Хуҗалык ныклап аякка баскач кына, яңа йорт салырга алына ул. Андый кешене колхозчылар ничек үз итмәсен инде. Менә шулай итеп абруй туплый Наил абый. Бүгенге көндә зур үрнәк ул!» – дип хөрмәтләп сөйли.

Әлбәттә, Наил Закир улының фидакарь хезмәте совет чорында да бәяләнмичә калмады. Ул – «Почёт билгесе» ордены, күпсанлы медальләр, мактау кәгазьләре, дипломнар иясе. 1983 елда районда иң беренчеләрдән булып, аңа «РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеме бирелә. Татарстан Югары Советының унберенче чакырылышына депутат итеп сайлана, аның эшендә актив катнашып, зур абруй казана. Наил ага – хезмәт халкына чын күңеленнән игелекле тормыш төзергә омтылган, шул юлда зур уңышларга ирешкән сирәк шәхесләрнең берсе.

**Рәдиф СӘГЪДИ**

# ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАРДА ПОСТ-ПОСТМОДЕРНИЗМ: БОРҺАН СОНМЕЗНЕҢ «ИСТАНБУЛ ИСТАНБУЛ» РОМАНЫ

Төрки телле әдәбиятлар арасында төрек әдәбиятының урыны үзгә. Бу аңлашыла да. Элеккеге СССР территориясендә аерылып, тимер пәрдә артында рус әдәбияты йогынтысында яшәгән төрки әдәбиятлардан аермалы буларак, ул XX гасыр буена дөнья әдәбияты дулкынында үсә. Дөнья, Европа әдәбиятларында барган күренешләр аңа турыдан-туры үтеп керә. Кайбер очракларда исә, әйтик, Орхан Памук иҗаты мисалында, дөнья әдәбиятындагы процессларны җитәкли дә. Шунысы кызык: бүген төрки телле әдәбиятларда постмодернизм объекты булып киткән күп кенә мотивлар башлап, Орхан Памук иҗатында күренгән иде: шәрык һәм гареб мөнәсәбәтләре – «Белая крепость» («Ак кирмән», 1985); традицияләр һәм яңачалык мөнәсәбәтләре – «Меня зовут Красный» («Минем исемем Кызыл», 1998); дин һәм заман мөнәсәбәтләре – «Снег» («Кар», 2001); китап – «Новая жизнь» («Яңа тормыш», 2017) һ.б. Башка төрки (элеккеге СССР территориясендә яшәгән) халыклар әдәбиятында постмодернизм күренеше тугач һәм аның гаять үзенчәлекле сыйфатларга ия булуы беленгәч, «Европа тибындагы постмодернизм» һәм «йомшак постмодернизм» төшенчәләре төрек әдәбиятын – беренче төркемгә, ә инде башка төрки халыклар әдәбиятын – нигездә, икенче төркемгә аера.

Әмма бүгенге сүзебез постмодернизм турында түгел. XX гасырның соңгы елларында әдәбият-сәнгатьнең постмодернизм этабын үтүе, постмодернизмнан соңгы, ягъни пост-постмодернизм дәвере туу хакында фикерләр әйтелә башлый. Шунысы кызык: Европа әдәбият белеменнән килүче әлеге төшенчәләр үзгәрешсез диярлек безнең җирлеккә дә үтеп керә. Әмма шул ук чит әдәбиятлар авторларының аерым әсәрләренә кагылышлы кулланыла. Постмодернизм һәм пост-постмодернизм әдәбиятының аермалары хакында бүгенге көнгә кадәр бәхәсләр бара. Гади генә итеп күзаллаганда, бер текст эчендә берничә «авторы» булган берничә текстны (2-4) берләштергән постмодернизмнан аермалы буларак, пост-постмодернизм күпсанлы текстларның башлангычын үз эченә ала. Әмма анда, классик әдәбияттагы кебек, автор берлеге сакланып, мәгънәләр исә уен алымының интертекстуальлек чикләрен үтеп чыгып, зуррак масштабларда кулланылуыннан туа.

Без сайлаган әсәр – төрек язучысы Борһан Сонмезнең «Истанбул Истанбул» романы рус теленә тәрҗемә ителгән пост-постмодернизм үрнәге булып тора, ул Казан китап кибетләрендә сатуга чыкты. Әдәбият яратучылар китапны да, яңа әдәби юнәлешне дә үз итәрләр дип исәплим.

Соңгы сүз итеп, романга Мансур Халлаҗ сүзләре сайланган: «Тәмуг без газап чиккән урында түгел. Тәмуг – безнең газапларга беркем дә игътибар итми торган урын». Ул әсәрне, бер яктан, суфи-мөселман күзаллавына урнаштыра; роман эчендә Мансур Халлаҗны телгә алу исә тормышны үзгәртергә алынган кешеләрнең (романда бу үзгәреш үткәннән азат булу – үткәнгә табынудан арыну кебек аңлатыла, шуның янәшәсендә тоталитаризм – үткәнне үзгәрешсез саклау механизмына әйләнә) теләсә кайсы заманда, илдә булуы турындагы фикерне ныгыта. Икенче яктан, модернизм, постмодернизм яки пост-постмодернизмның төп сыйфаты – тормыш-яшәеш сурәтен хаос, газап оясы хәлендә сурәтләү икәнлекне (тормыш – тәмуг) тагын бер кат ассызыклый. Романны укып чыккач, ул тагын бер яңа мәгънә ала: әсәр Данте Алигьериның «Илаһи комедия»се (1321) белән аваздашлыкта, әдәби диалог формасында иҗат ителгән. Дантеның тәмугның 9 катын сурәтләве һәм 10нчы итеп чистарыну урынын куюы романның 10 бүлектән гыйбарәт структурасына тәңгәл килә.

Данте тәмуг һәм оҗмах сурәте тудырып, кешеләргә хас сыйфатлар хакында сөйләсә, төрек язучысы җәмгыятьнең тәмугтан да явызрак булуын исбатларга алына, шул ук вакытта тәмугтагы кешеләрдә оҗмахка лаек сыйфатларны да барлый.

Романда тарихлар күп, дидек. Язучы җир астындагы төрмәдә утыручы дүрт тоткынның: студент Демиртай, Доктор, чәчтараш Камо һәм Күхейлан абзыйның берберсенә, вакытны уздыру өчен, төрле тарихлар сөйләве алымын куллана. Геройлар тормышында булган дип бирелгән тарихларның да уйлап табылган икәнлеген ассызыклап, язучы Докторның «тикшерүчеләрнең сорау алуы вакытында, җәзалауга түзә алмыйча, монда ишеткәннәрне сөйләү куркынычын» әйтеп, Камоны кисәтүен кертә.

Тарихлар арасында төрек фольклорыннан, аерым әдәби әсәрләрдән өзекләр бар. Шул ук вакытта роман турыдан-туры тагын бер текст белән бәйләнештә: ул – Джованни Боккаччоның «Декамерон»ы (1354). Тарихлар арасында «Декамерон»ның өченче көндә сөйләнгән унынчы новелласы – Алибәк тарихы бар. Бишенче көнне сөйләнгән бишенче новелладагы хатыны – сеңлесе булып чыгу тарихы романда үзгәрәк, тагын да катлаулырак табышмак итеп файдаланылган.

Романның тугызынчы бүлегендә геройлар да «Декамерон»ны искә төшерәләр. Аның исеме 10 көн сүзеннән булуы телгә алына. Бу очракта әсәрнең ун көн эчендә җәмгыять тормышын төзү турындагы уйланмасы Сонмез романының уйланмасын тәгәлләштерә: җир астындагы төрмәдә дүрт кешенең ун көн эчендәге тормышын тасвирлап, төрек язучысы кешелек җәмгыятенең сурәтен тергезүгә алына. Сонмезнең дүрт герое – дүрт кеше тибы, ул моны беренче бүлектә Достоевский геройларына бәйле ассызыклый. Алар, Боккаччо геройлары кебек үк, үлем белән очрашканнар. Үлемгә барганда да, алар өчен холык-фигыльләрендәге төп сыйфат үзгәрешсез кала: Демиртайда – тугрылык, Докторда – дәвамчанлык, киләчәкне кайгырту, Камода – мәхәббәт, Күхейланда тормышны идеалга охшатып үзгәртү омтылышы ул. Аларның һәрберсендә башка кеше өчен гомерен дә бирергә әзер булу сыйфаты өстен булып чыга. «Декамерон» белән уен язучыга кеше фәлсәфәсен җиткерергә ярдәм итә. Беренче бүлектә кабатланган, хакыйкатьнең – кешенең үзендә булуы турындагы фикер дә шуны ассызыклый.

Фәлсәфи мотивлардан, вакыт фәлсәфәсе; язмыш; тормышның уен булуы; ялган күзаллаулар белән яшәү фәлсәфәсе калку. Аларны укучы мөстәкыйль тарихларга әйләндерә ала. Төп фәлсәфи мотив булып, тормышның ялган, уен, уйлап табылган чынбарлык булу фикере күренә. Ул сөйләнгән тарихларда кабатланып бара, картограф төшергән утрауның Истанбул булып чыгу турындагы унынчы бүлектәге тарих аны алга чыгара.

Романдагы төп тарих – тоталитар җәмгыятьнең ирек, хакыйкать эзләүчеләрне эзәрлекләү тарихы. Әмма шуның белән янәшә күпсанлы тарихлар һәм тарихка әйләнергә сәләтле мотивлар бар. Чын мәхәббәт тарихы (Камо-Махизәр); ата белән ул тугрылыгы (Доктор); хыянәт (Али Кремень исемен файдалану) һ.б. Һәр укучы әсәрдә үз тарихын беренче планга чыгарырга сәләтле. Гаҗәеп ассоциацияләр уята торган, тормышның бик күп якларын калкуландырып, укучыны аерым бер нәтиҗәләр ясауга алып килерлек, җәмгыятьтәге күп катламнарның тормышларына кагылган роман мәгънәләр-фикерләрнең масштаблылыгы белән гаҗәпләндерә. Бер яктан, аның Европа мәдәниятендә билгеле ике текстны нигезгә алуы әсәрне шушы мәдәниятка якынайта. Романда төрек мәдәни кодларының көчле булуы аңа милли колорит бирә. Бу сукмак башка төрки әдәбиятларда да табылырмы – анысын киләчәк күрсәтер.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА**

# 2020 елда дини бәйрәмнәр
# һәм истәлекле көннәр

## МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1441-1442 ҺИҖРИ ЕЛЛАР

**25 февраль** – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең эти-энисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**20-21 март** – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**8 апрель** – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**24 апрель** – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн.

**21 май** – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**24,25,26 май** – Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**30 июль** – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**31 июль** – Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Мөселманнарның иң зур бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**1,2 август** – Тәшрикъ көннәре. Әлеге көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, махсус сүзләр әйтәләр.

**20 август** – 1442 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**28,29 август** – Гашура бәйрәме. Сөнниләр – Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнен мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**14 октябрь** – Сәфәр ае башланган көн.

**28 октябрь** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Әлеге изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрәсимнәр уздырыла.


*Төзүче-мөхәррир –*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН**




*Әтисе артист Хәким Сәлимҗанов белән.*



*Әнисе артистка Галия Нигъмәтуллина белән.*



*Марсель Сәлимҗанов - балыкчы.*



*Марсель Сәлимҗанов - фехтование буенча спорт мастеры.*



*Хатыны Гөлнар белән.*



*Минтимер Шәймиев Марсель Сәлимҗановны 65 яше белән котлый. 1999 ел.*



*Марсель Сәлимҗанов – «Алтын битлек» иясе. 2001 ел.*



*Орск гастрольләре. Әнисенең туган йорты.*

*Фотолар Г.Камал театры музееннан алынды.*

# ТАЯНУ НОКТАСЫН ЭЗЛӘГӘНДӘ...

## Хакыйкать якында гына икән

Әдәбиятта, бигрәк тә аның тезмә төрендә, кайчак гади мантыйк белән аңлатуы кыен, анда сиземләү, экзистенциаль сурәт дәрәҗәсендә эчке якынлык яши. Күрәсең, уртак милли мохиттә, тулаем халык язмышында, җәмгыятьтә барган үзгәрешләр, гайре табигый хәлләр төрле юнәлешләрдә иҗат итүче шагыйрьләрне тематик эзләнүләр уртаклыгына алып килә торгандыр. Икенче яктан, язучы күпне күрә, күпне ишетә (хәтта кирәкмәгәнне дә) дип, юкка гына «теш кайрамыйлар». Ике шагыйрьнең берүк вакытта диярлек үзләре яшәгән урамнарына чыгулары, гади генә булса да, сәфәрләре татар шигърияте яңа сурәтләү чараларына четерекле социаль-икътисади, милли мәсьәләләрне калкытып куярга мөмкинлек биргән нечкә күзәтүләргә баета. Шул ук вакытта һәркайсы үз урамын үзенчә күрә, бәяли.

Берсе «Булгария» теплоходының изге юлдан кайтканда, төрле буын кешеләре белән су астына китүе тудырган авыр тойгыларыннан арыну, ял итү нияте белән үзен сыендырган Толстой урамына чыкса, икенчесе – көне буена өстәл артында утырып талчыккан аяк-кулларны яздыру нияте белән һәм җан тынычлыгы эзләп, урамга юл тота. Бу сәяхәтләрдән Р.Харис «Урам», Р.Шәрипов «Эт урамы» (төп «каһарманы» дүрт аяклы җан иясе булгач, поэманы «Урам эте» дип әйтәсе килеп изаландым) дигән әсәрләрен «алып кайталар».

Беренче шагыйребез Казанның кыл уртасында урнашкан Толстой урамына сыланып утырган Бутлеров, Тургенев, Горький (яшәсен татар «интернациональлеге», үзем дә исем кушучылар кавеменнән булгач, ялагайлыгы дип бәяләргә телем тартмый) исемнәрен йөрткәннәрен дә атап үтә. Үз урамын аркылыга-буйга иңләп, «сәяхәтче» укучысын шунда урнашкан бик күп оешмалар, кибетләр белән таныштыра. Бала тудыру йорты янынннан үтү аның кәефенә сихәт өсти. Яшь ата-ана бәхете, илнең киләчәге турында уйлану яшәүгә, дәвамчанлыкка мәдхия кебек кабул ителә. Бернинди тормыш авырлыкларына карамыйча, яңа буын туа тора, димәк, тормыш дәвам итә.

Әлбәттә инде, хәзерге татар сатирасының иң «кәттә» әсәрләреннән берсе – «Чехов базары»ның нигезен тәшкил иткән сату-алу үзәген дә шагыйрь читләтеп үтә алмый.

*Аякларым, гәүдәмне күтәреп,*
*Чехов базарына юл алды.*

Иске танышларының, әдәби персонажларының күбесен очрата алмагач, «базарчы» «ил кешене бездә җәлләми» дигән нәтиҗә ясый. Сатучы вә алучылар арасында күренеп торган байларның азаюында ул халыкның елдан-ел ярлыланып баруын чамалый.

Урамның «эчтәлеге» белән гади таныштыру шәхес белән тирәлек арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыруның беренче катламы гына икән. «Чирәм җирнең» икенче буразнасыннан барчабызны иләсләндергән иҗтимагый, икътисади, милли мәсьәләләр калкып чыга. Шагыйрьнең бәгырен телгәләгән төп уе – Россия һәм аңа бәйле татар язмышы, туган телебезнең киләчәге. *«Россия ул – чиксез базар» дигән уйда ныгыйм тора-торып мин», «чирле илем-бәгърем таба алмый әле дәваны»* кебек кискен фикерләре үзебезнең милләткә дә, хәтта башкалабызга да нисбәтле икән. *«И Казаным, син дә бүген сырхау Россия күк, чирле пәйгамбәргә охшаган».* Ошбу тиңләү-чагыштыруда Казанны «чеметеп» алу белән беррәттән, шул ук вакытта аның кадерле вә изге булуына инану да ачык төсмерләнә.

Шагыйрьне әхлаксызлык, җиңел яшәү ысулларын эзләүче узгынчыларның

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

ишәюе борчый. Дипломны сатып алу яисә тир түкмичә, чалбар туздырмыйча гына компьютердан «суырып алу» очраклары күбәю күңелен тырный.

*– Дипломмы, әллә курсовоймы?*
*– Нинди фәннән, кайчан срогы?*

Шуларны күреп, гарьлек каралта шагыйрьнең «күңел сөлгесен».

Бу гамәлләрнең нигезендә фундаменталь фәнни эзләнүләрне, нәзари ачышларны югары аттестация басмаларында, чит илләрдә, нигездә, инглиз телендә нәшер ителә торган SCOPUS журналларында чыккан берничә битле, автордан башка берәүгә дә хаҗәте булмаган түләүле мәкаләчекләрнең алмаштыруы ята. Югары уку йортларында, фәнни институтларда галимнәр шул аратага куып кертелде ки, әлеге таләпләрне үтәмәсә, эш урынын бушатырга тиеш була. Мондый борылыш үзебезнең тел, әдәбият фәне үсешенә дә киртә куя. Сүз сәнгатебезнең, телебезнең меңъеллык тарихын иңләгән Х.Госман, Г.Халит, Л.Җәләй, Д.Тумашева, И.Нуруллин, Н.Юзиевларның саллы фәнни хезмәтләре абруйда йөргән чорны сагынып сөйләргә генә кала.

Шагыйрь гаманынча, кәсепчелек, битарафлык кебек ямьсез күренешләр яшәешебезнең һәр тармагына үтеп керә. Әйтик, *«Урамда кеше ята, ярдәм итүче юк тукталып»*. Тыйб фәнендәге торгынлыкны иҗатчы *«врач күз даруын салды колакка»* дип, бер җөмләдә әйтеп бирә. Элеккечә күзгә-күз карашып, кул бирешеп, хәл-әхвәлләр белешүне алыштырган замана хикмәтләренә шагыйрьнең үз шәхси мөнәсәбәте бар.

*Һәр телефон – хаин, оста шымчы!*
*Ул кесәдә тып-тын ятачак.*
*Ә вакыты җиткәч, хуҗасын да,*
*Кемне теләсә – шуны сатачак.*

Шагыйрь үз урамында рәсми фәхешханәдән башка барча «ихтыяҗи» оешмаларны таба. Хатын-кызны сатып алуның, сатылуның серенә төшенү өчен аңа язучылар төркемендә Парижга сәфәрен искә төшерергә туры килә.

Өч язучы сүз куешып, шыпырт кына Сен-Денига «кызыл фонарьлы» йортка кереп чыгарга булалар. Чөнки *«кызыксыну уятты шундый көчле – күрү дәртен күз дә сүндерми»*. Шагыйрь тротуарда ике яклап басып торган «төнге күбәләкләрне» күреп, хыялын «бәйдән ычкындыра»:

*Кайбер түшләр – кабак, кайберләре –*
*Куна тактасыдай яссылар.*
*Йомры тезләр күзнең явын ала,*
*Мини итәкләре астыннан.*

Чагыштыруларының күбесе (кабак, куна тактасы, күз явы) татарның фикерләү рәвешеннән туганнар.

Лирик зат үзе «алган» кызның гүзәллеген, аерым алганда, сыгылмалы, «озынборын кебек» нечкә билен фламанд рәссамнарыдай сурәтләп, ир белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләрне күзаллауда тиңе булмаган француз язучысы Ги Де Мопассанны көнләштерерлек югарылыкта тасвирлый. Аның төп максаты *«фахишә җанның сәбәп-серләренә төшенү – тән сатарга, гөнаһка батарга ни этәрә бүген кешене?»* Ни өчен төн туташын сатып алуын күрше бүлмәдә саклап, тыңлап торган хатынына болай дип аңлата:

*Бу тәҗрибә өчен хатын мине*
*«Карт тиле», – дип, кабат орышты.*
*Ә мин иҗат өчен кирәк, диеп,*
*Кабат аңлатырга тырыштым.*

Буржуаз дөньяны фаш итү максаты белән кертелгән бу өстәмә төп мәүзугътан

читкә алып киткәндәй тоелса да (ул аны аерым шигъри новелла итеп тә язарга мөмкин иде, мондый чигенүләр аның башка әсәрләренә дә хас), шагыйрь аның дәвамын кеше «канын сатып яшәгән» Россиягә, «баскетболчыларны сатып алып», бездә уйнаткан Казанга китереп бәйләве белән читкә «тайпылуын» аклый кебек.

Кыскасы, шагыйрь дөнья сурәтен йөрәге, җаны аша уздыра. Урамнар, кеше шикелле үк, төрле «холыклы», үзенчә яши, кайный, «йокыга тала» икән.

Р.Шәриповның күңелендә, йөрәгендә, илһам утын шулай ук үз урамы «кабыза». Шагыйрь язу өстәле артында хисләнеп, үткәнен, яшьлеген сагынып утыра да урамга юл ала.

*Чыгып бастым. Ә алдымда*
*Тыз-быз килә шаулы урам.*

Миллионлаган утлары белән ялтырап яшәгән, ыгы-зыгыга чумган шәһәр күңел тынычлыгы бирми. *«Кеше йөзе... Кеше йөзе... / Чиксез төркем уртасында / Шул ук кеше, тик берүзе»*, ә тирә-юньдә машиналар, һәркем кичектермәс эше булгандай, ахырзаман җиткәндәй, каядыр ашыга. Шунда ул үзенең яшьлеген, тормыш, яшәү тынычлыгын искә төшереп ала.

*Унбер яшьтә биш чакрымны*
*Җәяүләп бара идек.*
*Шул ук гомер, шул ук вакыт,*
*Һаман шул бер ара инде.*
*Барысына өлгергәнбез,*
*Укырга да, уйнарга да.*
*Шул ук көннәр баскычында*
*Киләчәкне уйларга да.*

Өлкән буын вәкилләренең күпчелегенә үзәк өзгеч якын бу юллар. Аның авылында хәзерге шау-шулы тормышка үткәннең, ачлы-туклы булса да, үзенә бер табигый ритм белән яшәвен капма-каршы кую ята. Кафияле булса да, кемдер 8-7 үлчәмле юлларны шигъри проза, дип бәяләячәк.

Ә бу истәлектә мин хәзерге тормыштан канәгатьсезлек тудырган эчке киеренкелекне сизәм. Каләм иясенең хәзерге халәтенә ироник карашы аңа хөрмәтне арттыра.

*Ә мин нидер язган булам,*
*Имеш, ниндидер эш кырам.*

Үткән белән хәзергене чагыштырып, янәшәлек аша дөреслекне «эзләгәннән» соң, шагыйрь урамга күз ташлый һәм сурәт үзәгенә алырдай «каһарманын» таба:

*Күзем төште – ерак түгел,*
*Гамьле күңелемне өтеп,*
*Үпкәле бер әрнү белән*
*Карап тора урам эте.*

Алдарак шагыйрь хыялында хәзер берәүгә дә кирәге булмаган *(«Көн аралаш ач тамакка / Бөтен дөнья дошман иде»)* этнең юлбарысны, угрыны куркытып торган, бәхетле, тук тормышта яшәгән чорын күз алдына китерә.

Әүвәл үз халәте, язмышы, тормыш юлы, аннан урам эте турындагы уйланулары бертөслерәк хикәяләү кебек күренсә дә, сүз чынлыкта төпле мантыйкка утыртылган милләт язмышы турында уйлану-әрнүләргә килеп тоташа. Дөресрәге, урам эте язмышы турында уйланганда, ул күңелен бимазалаган борчуының сәбәбен аңлый: халкының, туган теленең язмышы телгәли икән аның бәгырен. Мул табигатьле, урман-сулы, җир асты байлыгы, хезмәт сөючән кешеләре белән дан казанган татар иленең буйсынган хезмәтче булудан башка бер хокукы да калмавы бимазалый икән авторны.

Урам этенең язмышы да безнең файдага булмаган чагыштыруга этәрә. Шигырь юллары шул ук гади, самими, көйле ритмда калса да, авторның тавышы кырыслана, фикер-бәясе кискенләшә, ярымтоннарга урын калдырылмый. Чөнки ул ихластан урам этен кызганса да, үз халкының рухи, сәяси хәле исенә төшкәч, дүрт аяклы «танышының» тормышы ireклерәк икәнлеген танырга мәҗбүр була. *«Аның теле күзләрендә, минем тел киселгән бит»*. Милли аңыбызның үсеш дәрәҗәсенә дә аның бәясе катгый:

*Риза булып чылбырга да,*
*Кистерәбез телебезне.*
*Кулыбызда бәхет иде,*
*Суга салдык та агыздык.*

Гамьсезлекнең, «безнең алдан» йөргән куркуның нәтиҗәсе ачык:

*Басып кергән кисеп-суеп,*
*Җиребез бар, илебез юк.*

Поэма тоташ экзистенциаль сагыш, югалтканнар өчен үкенү, вакытында илне, мөстәкыйльлекне саклап кала алмаган бабаларыбызга рәнҗү рухында, шул ук вакытта гаепне аерым затларга кайтарып калдырмау рухында, бер тында язылган. Шигъри әсәрнең беренче юлларыннан ук күңелне айкарлык куәсе булмаса, аны «бушагачрак» укырга калдырасың да читкәрәк этеп куясың! Тамак хакына дөнья куугa корылган яшәештә буш вакыт каралмаган. Рәниф поэмасында эчке сөйләм (әйтик, эт монологы), эндәш, сорау алымнарын киңрәк кулланып, ритмикасын (гел 9-8, 8-7 генә түгел) төрлеләндеребрәк җибәрсә, нур өстендә нур балкыр иде дип «мыгырданып», поэманы кабат укып чыкканымны сизми дә калдым, ә инде соңгы юллары аеруча йөрәкне телгәләде.

*Хокуксызлар төрмәсенә*
*Кертеп салды безне язмыш.*
*Яна-яна, елый-елый*
*Хәзер инде шул төрмәнең*
*Зиратына кереп барыш.*

Бу юлларда, ягъни поэманың соңгы аккордларында С.Хәким әрнүе, И.Юзеев борчылуы, М.Әгъләм, Л.Шагыйрьҗан усаллыгы, Ф.Яруллиннар кыюлыгы дәвамын таба шикеллле.

«Эт урамы» поэмасының кискен, очкынлы чагыштырулары, хакыйкатьне «бәбәккә» бәреп әйтүләре берәүне дә битараф калдырмагандыр дип уйлыйм.

Шул урында урамнарга багышланган поэмалар белән соклануны туктатып, башкарак мәүзугъларга багышланган лиро-эпик әсәрләргә тукталыйк.

## Мәхәббәт өянәге

Р.Харис иҗатының буеннан-буена сузыла килгән һәм иң яратып үстерә торган темаларның берсе – мәхәббәт, сөю-сөелү хисен олылау. Һәркемнең башыннан, йөрәгеннән уза торган бу тойгы турында суфый шагыйрьләрдән (инсанга мәхәббәт аша Аллаһ мәрхәмәтенә лаек булу) һәм Кандалыйдан кала татар әдәбиятында Р.Харис дәрәҗәсендә язган, «мәхәббәт тавының» иң югары ноктасына күтәрелгән башка шагыйрь юк дип беләм. Аның ошбу теманы яктырткан күләмле әсәрләренең беришесен генә атап үтү дә күп нәрсә турында хәбәр бирә: «Өч үбешү», «Сәйдәш яры», «Тукайның мәхәббәт төшләре», «Тәүбәсез мәхәббәт», «Зөләйха», «Евнух», «Гармунчы», «Карлыган сатучы кыз» һ.б.

Р.Харисның мәхәббәт лирикасын казаныш санаган тәкъдирдә дә, «кеше җанындагы интим һәм иң саф матурлыкны» поэма жанрында үзәккә алуына игътибарны юнәлтәсе килә. Бер караганда, айга багып хозурланып, сөйгәне турында хыялланып утырудан ерак эчтәлекле, иҗтимагый рухлы әсәрләрендә дә Р.Харис жанр таләбе

белән «исәпләшмичә», мәхәббәтнең савыктыргыч көчен искә төшерә. Шәхес культын фаш иткән, мәкер, хыянәт, көнчелек, хөсетлек кебек төшенчәләр турындагы «Уба» поэмасында җаннарны сафландыручы сөю хисен олылау белән тәмамлый.

Хәят юллары нинди генә сикәлтәле, катлаулы булмасын, киләчәккә өметне югалтмаска иде, иң кыен мизгелләрдә мәхәббәткә, сөю-сәгадәткә таянырга кирәк дигән ышаныч белән нокта куя поэмасына шагыйрь. Соңыннан, ераккарак китеп өстәлгәндер дигән тәэсир калдырган бу өзекне аклау да табыла. Мәхәббәт, гыйшык маҗараларыннан башка «булмый әсәр... Сөю хисе безнең җанны ача» дип, искә төшерә шагыйрь.

Гашыйк-мәҗнүннәр шатлыгын вә хәсрәтен, сөенечен, янып-көюен үзәккә алган иң соңгы елларда иҗат ителгән поэмасы «Мәхәббәт» дип атала, ягъни кичереш исемгә үк чыгарылган. Әсәр мәгънәви һәм фәлсәфи яссылыкта «Өч үбешү»гә якын торса да, андагы мотивларны кабатламый. «Мәхәббәт»тә төп вакыйга, сюжет төене чишелешендә әүвәл экзистенциаль сызлану рухы өстенлек алса, бетеме якты моң, шатлыклы аһәң белән тәмамлана.

Поэма шагыйрьнең яраткан алымы – фикер-хисләрне капма-каршы куеп «чәкештерү», фәнчә әйтсәк, антитеза алымы белән башланып китә.

*Мәхәббәт ул – бәхет!*
*Бәхәсләшмим!*
*Мәхәббәт ул – газап!*
*Килешмим!*

Алдагы юлларда «килешмәвенең серен» ачуга омтылыш ясала:

*Мәхәббәтне бөтен кеше белә,*
*Ә аңлата алмый беркем дә.*
.........................................
*Мәхәббәт ул кыюсызлардан да*
*Эшләттерә үлмәс батырлык.*

Бу олы хисне күңелләргә сеңдергән, *«Кеше җанындагы тиле һәм иң саф матурлык», «Мәхәббәт ул – бер йөрәккә сыйган гүзәл коллык, котсыз азатлык»* кебек чагыштыру-сынландырулар, дога юллары кебек, күңелләргә кереп утыра. Мәхәббәт ул – Күкләр тарафыннан иңдерелгән, берәү дә аның адәмне җәннәттән кудырткан кызыл алма кебек кайчан «өзелеп» төшәсен белми торган гаҗәеп серле хис.

Сөю-сөелү турындагы фикер-уйларын шагыйрь ике шәхеснең мәхәббәте, ярату-яратмау каршылыгы мисалында калкытып куя. Лирик каһарман-талиб күрше факультетта укучы кызга гашыйк була, *«мәхәббәте» әле утка сала, әле бозлы суда агыза»*, дип, мәгъшукасы турында уйлап утырып, онытылып, дәрес вакытында кычкырып җырлап җибәреп, сөюнең «сәрхушлеккә» охшаш булуын раслый. Студент халкына кызык кирәк, әүвәл көлеп җибәрәләр һәм доцентның үзен бүлдергән өчен әрләвен, «җырчыга» шелтә белдерүен көткәндә, гаҗәп хәл була: – *«Көлешмәгез! – диде. – Ул – гашыйк... / Ул бәхетле... ә менә мин гашыйк була алмый / күпме гомер йөрим каңгырып...»*

Соңрак, алар укытучыларының бу «кыланышының» сәбәбеннән хәбәрдар була. Мөгаллимнәре хатыны белән бер атна гына торып кала, аны сугышка алалар. Олы мәхәббәтен йөрәгендә саклап, ашкынып туган учагына кайтканда, җиңүчене фаҗига көтә. Хәләле башка ир белән аңа хыянәт иткән һәм инде көмәнле дә икән. Мондый «каршы алуны» күз алдына да китерә алмаган ирнең җаны ката, күп кенә гүзәл затлар белән очрашып караса да, берсенә дә гашыйк була алмый. Яратырга теләүчеләр ул бер генә түгел икән. Шунда шагыйрь Г.Моратның кемгәдер тәкълид итеп язылган «Яратырга телим» дигән шигыре искә төшә:

*Син дә әллә яратмыйсың?*
*Ә мин*
*Яратырга телим.*

Укытучыларының *«күпме гомер йөрим каңгырып»* дигән иңрәүле сүзләрен ишеткән сыйныфның чибәр старостасы аны кызганыпмы, әллә күңелендә хисләр уяныпмы, доцентның өенә үк килеп, аны яратуы турында әйтеп, чишенеп үк ташлый. Доцентның *«Мәхәббәтсез ләззәт, сиздермәстән, җанындагы дымны киптергән»* булып чыга һәм ул кыздан баш тарта. Староста хурлыгыннан укуын ташлап, шәһәрдән үк чыгып китә һәм аның язмышы турында беркем, берни белми.

Шул арада ун ел вакыт узып та китә. Элеккеге студентлар очрашуга җыелалар. Инде профессор дәрәҗәсе алган укытучыларының күрше авылдан берәүгә гашыйк булып, өйләнүе турында ишеткән булалар. Ул бәйрәмгә хатыны белән килеп төшсә, һәммәсенең күзе шар була, чөнки аның сөйгәне элеккеге старосталары булып чыга. Әүвәл ике йөрәкнең бер-берсенә тартылып та, берсе шуны танымыйча, бәхетсезлеккә (кыз укуын ташлап китә) дучар булуларында суфыйчылыкның фаталь сагышы чагылса, Аллаһ кодрәте белән ахыры бәхетле бетемгә – «happy end»ка алып килә.

Р.Харис бу юнәлешкә аерым басым ясамаса да, гомернең чикле булуын аңлау мәхәббәтне олылау юлына чыгара. Укучы буларак, фронтовикның мәхәббәтен табып, бәхеткә таруына шатланасың, аеруча поэманың соңгы юлларының һәр җөмләсен, сүзен тукталып, кичерешләр байлыгына, хисләрне ачу сәләтенә сокланып туймыйсың! Р.Харис сөю-сөелү турында күпме генә язмасын, аның сүз-сурәт куәсе, тел катламы бай, һәрвакыт яңача һәм төрле. Иң борынгы һәм гасырлар дәвамында җырлана, тасвирлана килгән мәүзугъ турында яңа сүз әйтеп була икән дип уйлап куясың! Биергә өйрәткән хис тә шул ук мәхәббәт икән ләбаса:

*Кешене бию биетми,*
*Аны сөю биетә.*

## Хәтер җебе югалмасын...

Поэма жанры үсеше турында сүз алып барганда, аның риваять вә мифларга өстенлек биргән тармагы турында да онытырга ярамый. Бу төр әсәрләр татар әдәбиятында элек-электән иҗат ителә килсәләр дә, Тукай бу юнәлешне «Шүрәле», «Су анасы», өлешчә «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» поэма-шигырьләрендә яңа мәгънәви вә сәнгати югарылыкка күтәрде. Бөек шагыйребезнең эзләнүләре татар сүз һәм рәсем сәнгатенең алдагы елларда үсешенә дә тирән тәэсир ясадылар. Р.Харисның «Ант суы», «Идегәй», Г.Моратның «Алма-риваять», З.Мансуровның «Ике егълау» һ.б. бик күп житди әсәрләрнең нигезендә риваять-истәлекләр, мифик аң күзәнәкләре ята. Р. Харисның «Бәкер сазы», шагыйрә Рәсимә Гарифуллинаның «Мөнәҗҗимгә-мөнәҗәт» поэмаларының асылында халык хәтере, халык ышанычы ята.

Р.Харисның «Бәкер сазы» халык арасында киң таралган риваятьне нигез-өлге итеп алып, хыялы, тоемлавы белән тулыландырып язылган әсәр.

Бәкер шифаханәсендә ял иткән яисә аның үзенчәлекләре турында ишеткән кеше якында гына җәйрәп яткан сазлыкның савыктыргыч илаһи көче, шуннан терелеп, яшәреп кайткан адәмнәр яисә терлекләр турындагы сөйләкләрдән хәбәрдар булмый калмас. Бәкер шифаханәсенең төп тарту көче – буыннары, сөякләре, кан тамырлары авырткан чирлеләрне дәвалый торган шифалы балчыгы.

Гадәттәгечә, халык ул сазлыкның файдалы көче турында арттырып, үзеннән өстәп тә сөйли. Р.Харис шул риваятьләрне сюжет канвасы итеп алып, шигъри хикәяләүне берничә гасырга арткарак күчереп, ханга хезмәт иткән атлар язмышын үзәккә ала.

Хыял уенына чикләнмәгән мөмкинлекләр биргән реалистик шартлылык, төрле яссылыкларда яткан күренешләр арасында якынлык табарга юл ачкан романтик аллегория «Бәкер сазы» поэмасында тиешле урынын таба.

Атлар барча халыкларның, бигрәк тә дала төркиләре – кыпчакларның, тормыш-яшәешендә дә, хәвефле елларда да иң ышанычлы терәкләре булып торалар. Аларны яратып тәрбиялиләр, яңа төрләрен үстерәләр. Хәзер дә Сабан туйларында «татар аты» дигән токым ярышларда катнаша.

Р.Харис иҗатында атка аеруча хөрмәт зур, аның «Ат иярләү» исемле психологик

анализны сюжет канвасы дәрәҗәсенә күтәргән поэмасында ат әдәби образ буларак тәнгәлләшә. Төрле сылтаулар белән сугыштан качып калу юлларын эзләгән Кәрам аты белән шартлы әңгәмәдән соң, «малы иясенә охшар» дигән әйтем аны уйланырга мәҗбүр итә. *«Бу ат, димәк, минем күңел...»* дигән фикергә килә. Шул ук шартлы сөйләшү нәтиҗәсендә. Кәрам үзеннән акыллы атыннан оялып, сугышка китә һәм рейхстагның диварына авылының исемен язып, җиңүче данын алып кайта.

Югарыда карап үткән («Уба»дан башка), шул исәптән «Бәкер сазы» поэмасы урнаштырылган җыентыгын (2016) автор «Атлар чаба»[1] дип атаган һәм җыр булып киткән шул исемдәге шигырен дә тәкъдим иткән.

«Бәкер сазы» әсәрендә Р.Харисның атларны яратуы, тирән ихтирамы исем-төсләрен яхшы белүендә дә күренә. Нинди генә чалымнары юк атларның. Исең-акылың китмәле: җирән кашка, туры, кара айгыр, күк кашка, алмачуар, «Бурлы бия – очлы колак», «Сабан туй батыры – Канат бәкәл бия», «Таштояк», «Әдрәс» һ.б.

Хан да атларын гаилә әгъзалары кебек ярата, якын итә. Мәгәр алар да мәңгелек түгел, картаялар, чирлиләр, имгәнәләр. Атчы шундыйларны иткә җибәрергә тәкъдим итә. Хан аның теләгән кире кага: *«Атлар гомер мизгелләре, тормыш юллары ласа»*.

Бу дәлиле генә ышандырмас дип, төп фикерен калкытыбрак куя:

*Бу атлар – минем гомерем,*
*Ил йортның – тарих юлы*
*Тарихны сугым итәргә*
*Күтәрелер кем кулы?!*

Кыскасы, хан атларны үз ирекләренә куеп, чыгарып җибәрергә куша. Маллар төрлесе төрле якка таралышалар. Көндәлек мәшәкатьләр белән мәш килеп, яраткан атлары үлеп яисә ерткычлар тарафыннан юкка чыгарылгандыр дип фараз кылып яисә алар турында бөтенләй онытып, шактый вакыт узгач, хан яраннары белән ауга чыккач, җәйрәп яткан сазлык янында узганда, могҗизага тап булып, күзләренә ышанмый тора. Атларның барысы да исән-сау гына түгел, киресенчә, тазарып, элеккедән дә матураеп, елык-елык итеп торуларына шаһит булалар.

Шагыйрь киң таралган риваять-ышануны тезмәгә күчерү өчен генә язмый поэмасын. Ул – халык хәтеренә сәяхәт аша тарих белән рухи дөньяны бәйләү юлына чыга. Үзәктә туган табигатьнең шифалы көченә ышану, аның белән горурлану һәм күңелләрдә бу байлыкны, тирә-юньнең матурлыгын саклау ихтыяҗын уяту нияте ята.

Мифик күзаллауга, риваятьләргә таяну-поэма жанры үсешенең бер үзенчәлекле төрен тәшкил итә дигән идек. Бу җәһәттән соңгы чорда иҗат ителгән әсәрләрдән шагыйрә Р.Гарифуллинаның «Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт» поэма-легендасы игътибарга лаеклы. Лиро-эпик жанр аның өчен яңа төр түгел. «Чулпы җыры», «Ак сарайда серләр бар» һ.б. поэмаларында да ул тарихи үткәннәргә үз шигъри бәясен бирү нияте белән юлга чыкса да, вакыйгалар артыннан эзмә-эз ияреп бару әсәрләренең мәгънәви-сәнгати офыгын тарайткан иде. Алгарак китеп булса да, искәртик: яңа поэмасының ирекле композициясе һәм әдәбиятыбыз өчен яңарак мөндәриҗә-эчтәлек авторга шигъри куәсен тирәнрәк ачарга мөмкинлек бирә.

Яңа иҗат җимешенә шагыйрә «Эзотерик поэма» дигән ачыкламыш куйган. Эзотерика рәсми фән түгел, ул яшертен, серле гыйлем, магия, аны «кара сихер» диючеләр дә бар.

Кешенең төшен юраучыларны, яшәп киткән, мәгәр үзе турында истәлек-гоманнар калдырган күренешләрне дә, мәсәлән, Атлантида цивилизациясен дә эзотерикага «теркиләр».

«Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт» атамасының беренче сүзе йолдызларга багып, язмышларны әйтеп бирүче (звездочёт) күрәзәчене күздә тотса, мөнәҗәт – халык иҗаты белән язма поэзия бердәмлегендә булган көйле әсәр. Аның эчтәлеге Аллаһның берлегенә ышанып, аңа табынып, авыр, хәсрәтле уйлардан, кайгылардан арынуны аңлата.

Шагыйрә әсәрнең жанр хасиятен билгеләүне укучының «үзенә» калдыра: *«Кем мөнәҗәт дияр, бәлки, кемдер бәет дип атар»*. Поэма исә, көтелмәгәнчәрәк, Сөембикә шәхесенә «мөрәҗәгать» белән башланып китә.

[1] Җыр 2014 елда узган «Turkvision» ярышында икенче урынга чыга.

*Сөембикә, манараңның*
*Ае суларга карый.*
*Ай нурында йөзә-йөзә,*
*Су кызы чәчен тарый.*

Шундый ифрат җылы лирик башлангыч авторга Казанның меңъеллык тарихын, Сөембикәнең «Патшалык тәңкәсе»н искә төшерергә һәм дикъкатьне әсәрнең серле, мистик каһарманы, йолдызлар телен белүче, бик борынгы да, замандашыбыз да Мөнәҗҗим «шәрифләренә» юнәлтергә һәм аның «һөнәрләрен» алгы нәүбәткә чыгарырга мөмкинлек бирә: *«Җиде катлы манарадан күккә багып, ай-йолдызларны күзәтеп»*, галәм серләрен ачучы икән ул.

М.Мирзаның «Бакы – кубарык җил» поэмасында да борынгы кәрваннар *«Йолдызларга багып, юл табып»* алга баралар. Бу ышанычның асылында Кешене күк белән җир бөтенлегендә арадашчы дип бәяләү ята.

«Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт» – вакыт белән ара төшенчәләрен, аларның төп эчтәлекләрен үзенчә аңлаткан, irekle, дөрес, полифоник композицияле әсәр. Әйтик, автор моннан дүрт мең еллар элек астрономия, астрология фәннәренә нигез салучы Зәкәрия пәйгамбәрне дә ихтирам белән искә ала. Татар халкының күңеленә, хәтер җебенә ничек килеп кергәндер, мин, Алабугада эшләгәндә, бу исемне йөрткән кешене очраттым. Күрше йортта яшәүче, берничә балалы сукыр ханымның олы малаен, ярдәмчесен, урамга чыгып: «Зәкәрия, Зәкәрия, улым, син кая, өйгә кайт», дип дәшкәне хәзергәчә колагымда чыңлап торгандай. Зәкәрия хәзер ир уртасы, Чаллыда җаваплы хезмәттә, шигъри җанлы шәхес, үзе чыгарган җыентыклары да бар. Кем белә, бәлки, ул бөек астрологның ерак оныгыдыр? Һәрхәлдә, бу исем гасырлар кичеп, һәр яңа буынга тапшырыла килеп, безнең көннәрдә яшәвен дәвам итә икән бит.

Мөнәҗҗимнәр, олы тарихи барышта, кешелекне юкка чыгудан саклап калганнар, дигән фараз да бар. Ул поэмада да искә алына.

Олы Бозлык чорының һәлакәт алып килүен йолдызлар хәрәкәтеннән сизенгән күрәзәчеләр, Киек Каз юлы буйлап халыкны *«Һиндстан якларына, туып-үскән җирләреннән ерак төбәкләргә алып киткәннәр»*. Туган якларын сагынсалар да, күбесе шунда калган.

Әлбәттә, поэманың «умыртка баганасын» татар халкы язмышы, аның аянычлы тарихы турында уйлану тәшкил итә. Мөнәҗҗимгә дә дәгъва зур. Ул *«кыпчак, болгар-татарларның / Алда ни күрәчәген», «Сөембикә ханбикәнең, Илдән сөреләчәген»* белгәндер, җиһанны калтыратып торган татар ханлыкларының би-бәкләрнең ваемсызлыгы аркасында булганны югалта барулары нәтиҗәсендә Казан дәүләтенең яулап алыначагыннан да хәбәрдар булгандыр.

Төрле фиркаләргә бүлгәләнеп, мал бүлешеп яткан бәкләр Казанның борын төбендә Явыз Иванга Зөя кальгасын салырга ирек биреп, илләрен саклауга чын-чынлап әзерләнмәгәннәр. 1552 елда төзәтеп булмаслык фаҗига киләсен Мөнәҗҗим сизенгән. Мәгәр, язмышны үзгәртеп булмасын аңлап, чаң сукмаган.

Кем төзеткәне ачыкланып җитмәгән Сөембикә манарасына, Казанның меңъеллыгына, бөтен татарның *«Бигрәк ямьле дә, сөйкемле / Җир йөзендә Казаным»*га мәдхия поэманың буеннан-буена сузылып килә.

Авторның астрономия фәненнән, астрологиядән шактый хәбәрдар булуы, эзотерика гыйлеменең суфый символларына, мистикасына барып тоташканын аңлавы хисләрне куерта, яшәешнең чикле булуын искә төшереп тора.

Мифологик зат – Мөнәҗҗим халкыбызның үткәнен һәм бүгенгесен, һәр адәми затның язмышын сиземләүче рәмзи (символ) дәрәҗәсенә күтәрелә: *«Саксыз әйткән бер сүз белән Кешене үтереп була», «Һәркемнең уч төбендә / Тормыш юлы язылган»*.

Аерым хөрмәткә вә хикмәткә җидегән йолдыз ия, ул Тимер күчәре тирәли елга бер тапкыр гына әйләнә дә, «Тәүлек саен» үзгәреп тора икән. *«Күк йөзендә Зөһрә йолдыз, Җидегәнгә төс кенә»* төрле исемнәр белән аталса да, аның төп үзенчәлеге – хис, мәхәббәт күрке булуы. Мәгәр халык күңеленә иң якыны, гелән үзгәреп торучан, тыйнак нурлары белән ялтырап, тулы чагында илаһи бәхетне хәтерләткән ай. Татар шигъриятенә дә ул ямь бөркеп тора. Әүвәл Дәрдемәнднең «Тиң булырмы

йолдыз тулган айга» исемле мәхәббәт шигыре искә төшсә, Тукайның «Су анасы»нда караклыгы аркасында авыр хәлдә калган малайга ярдәмгә килеп җитә.

«Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт» авторы ни-нәрсә турында язса да, эчке мантыйк тәгәрмәче әледән-әле мөстәкыйльлекне югалту фаҗигасенә әйләнеп кайта. Әсәрнең тарту көчен вакыйга теркәү түгел, ә хис, кичереш динамикасы тәшкил итә.

## Язмыш сынавында
## *(Нәтиҗә ясарга иртә әле)*

Укучыга тәкъдим иткән язмаларымда, мөмкин булган тәкъдирдә, татар теле, димәк, халкы өчен иң авыр чорларның берсендә, ягъни соңгы унъеллыкта иҗат ителгән (мотлак тулылыкка дәгъва итмичә) поэмаларга бәя бирергә тырыштым. Меңъеллык тарихлы жанрыбыз бер урында таптанмаган, милләт мәнфәгатьләре белән яшәп, сыкрана-сыкрана булса да, эзләнү-уйлануларын дәвам иттергән. Һәр чор әдәбиятының кабатланмас үзенчәлеге була. Әйтик, XX гасыр башында, сугыш һәм аннан соңгы дәвер дә, бигрәк тә 60нчы һәм «торгынлык чоры» дип тарихка кереп калган елларда татар поэмасы гөрләп үсә, замана чалымнарын һәм шәхеснең рухи дөньясын чагылдыруда гаҗәеп зур уңышларга ирешә. Мин С.Хәким, И.Юзеев, Ә.Баян, Р.Харис, Р.Мингалим, Г.Рәхим, Ф.Гыйззәтуллина, Роб.Әхмәтҗанов, З.Мансуров, Р.Фәйзуллин, Ә.Рәшит һ.б. күпләрнең күңеленнән өзелеп төшкән поэмаларын күз алдында тотам. Шул чорда С.Батталның «Чирмешән якларында», Ә.Давыдовның «Йокысыз төннән соң», бераз соңрак Р.Харисның «Исемсезләр» шигъри романнары иҗат ителүе турында да онытырга ярамый.

Иҗат серлелеге, көтелмәгәнлеге һәм шул ук вакытта иҗтимагый вазгыять мөмкинлек биргәнчә, ирекле булуы белән кадерле. Мәгәр теләсә кайсы шагыйрь, хәтта Р.Харис та гелән «Ат иярләү», «Рәссам», «Чехов базары», «Ант суы» кебек шедеврлар гына «коеп» тора алмый. Соңгы чорда иҗат ителгән һәм әле генә дөнья күргән «Унөчкә унөч» поэмасын да («К.У., 2019, №7) кертеп, Р.Харисның югарыда аталган әсәрләре сафына эчтәлеге, кичереш тирәнлеге, сәнгатьчә эшләнеше белән «Татар Титанигы» поэмасы үзенә түрдән «урын» дәгъвалап тора.

Мәкаләмнең исемен дә тикмәгә генә «Таяну ноктасын эзләгәндә...» дип куймадым. Чөнки хәзер элеккеге кыйммәтләр белән яшәп, татар егетләре, кызлары тарихи барышта уртак Ватаныбыз чәчәк атсын дип, Мәскәүне Наполеоннан азат итүдә катнаштылар. Беренче, Икенче дөнья сугышларында, олы һәм кече бәрелешләрдә алгы сафларда булдылар, кешелекне фашизмнан азат итү өчен башларын бүкәнгә салдылар, татар яугире беренчедән булып, Рейхстагка байрак кадады (анысын да әле рәсми танымаска тырышалар) дип мактанып, күкрәккә сугып йөрүнең файдасызлыгын, буйсынган халыкларга мөнәсәбәтнең үзгәрмәгәнлеген аңларга вакыттыр.

Һәр сүзен кат-кат уйлап, сәяси сак Ә.Баян, Тукайның атаклы гыйбарәсен шигырьнең атамасына чыгарып, ачынып, гарьләнеп болай дип язды:

*Без тарихта эзле, без – батырлар,*
*Байрак, кылыч алып кулларга*
*Коллык тырнагыннан планетаны,*
*Барча кавемнәрне*
*Коткарырга чыгып юлларга,*
*Кайтканбыз да җиңеп... кайткан саен*
*Әйләнгәнбез үзебез колларга.*

СССР таралгач, Аллаһның кодрәте белән, уйламаганда, көтмәгәндә, элек мөстәкыйль дәүләте булмаган кайбер халыкларга тулы бәйсезлекне «кулларына» тоттырдылар. Элек-электән Урта Азиядә яшәүчеләргә белем-мәгърифәт алып бардык, әдәбият-сәнгатьләре үсешенә ярдәм иттек, дип мактанып, масаеп йөрүнең файдасы да, мәгънәсе дә юк, чөнки аларның берсе дә безгә ярдәм кулын сузарга ашыкмый. Хәтта Акмуллалар алып барган «мәгърифәт утын» күпчелек галимнәре, язучылары «без аларны чакырмадык, тамак ялына йөргәннәрдер», дип тә ычкындыралар. Димәк,

татарның татардан башка олы җиһанда берәүгә дә кирәге юк. Урталыкта калган халыклар кол да түгел кебек, азат та түгел.

Аерым алганда, без каләмдәшләребезгә, рус язучыларына телебезне, милли рухыбызны саклап калуда ярдәм сорап мөрәҗәгать итеп карадык. Яклап чыгучы гына түгел, җавап сүзе катучы да булмады. Мотлак үзәкләшкән хакимияттән курыктылармы, әллә рус сүз сәнгате дә сыекланып, араларында А.Твардовский, В.Астафьев, А.Чаковский, К.Симонов, В.Быков, Е.Евтушенко кебек бөек шәхесләр, кыю каләм ияләре булмау сәбәпче идеме?

Кемдер илдәге сәясәт турында фикер йөртүнең поэма жанры үсешенә турыдан-туры мөнәсәбәте бармы, дип шикләнсә, әдәбиятны «тормыш көзгесе», дибез икән, димәк, җәмгыятьтә хөкем сөргән вәзгыять аның үсешенә дә тәэсир итә, кыйбласын табарга да булыша, юлын да күрсәтә барыр.

Урталыкта калган буйсынган халыкларның телләренә, димәк, милли яшәешләренә каршы алып барылган һөҗүм башкачарак фикер йөртүне таләп итә. Минем уемча, татар әдәбияты, шул исәптән поэмасы, беренче чиратта, халкыбызда елдан-ел кими барган горурлык хисен уяту, данлы, шанлы үткәнебезне онытмырмау аша үзаңын үстерүгә хезмәт итәргә тиеш. Милләтебезне саклау, татарлыгыбызны ныгыту өчен милли каһарманнарыбызны, төрле дәверләрдәге азатлык өчен көрәшчеләребезне күтәрергә, шигъри образ-сыннарын тудырырга тиешбез. Мөстәкыйль рәвештә халыкны көрәшкә күтәрүгә ирешкән Карасакал, Батырша, Акай, Морад мулла кебек шәхесләребез янәшәсендә Пугачёв фетнәсендә катнашып, күренекле урын тоткан Бәхтияр Канкаев, Салават Юлаев, Мәсәгут Гомәров кебек кыю, тәвәккәл затларны, тарихи шәхесләрне күтәрергә тиешбез. Бу юлда И.Юзеев үрнәк биреп калдырган иде.

Ошбу юнәлештә безгә халык иҗаты, аерым алганда, дастаннар, бигрәк тә бәетләр, тарихи җырлар үрнәк була алырлар иде. Әйтик, «Пугачёв бәете», «Шамил бәете», «Пугачёв явы», «Салават бәете», «Бәхтияр», «Күчем хан», «Себер батыры» кебек бәетләрдә, тарихи җырларда халык Россиянең колониаль сәясәтенә каршы күтәрелгән, азатлык өчен көрәш тарихында тирән эз калдырган батырларның гамәлләрен хуплый, олы йөрәкле уллары белән соклануын яшерми. Поэмаларыбызда җәмгыятьне, милли мәнфәгатьләрне кайгырткан көчле шәхесләр язмышын үзәккә алу, шулар мисалында милләтнең куәсен, аң үсеше дәрәҗәсен, мәдәни мирасын саклавын сәнгатьчә югарылыкта күрсәтү лазем. Тарих төпкелләрендә мәгълүм эз калдырган «белешмәләргә» эләкмәгән затлар да игътибарга лаек. Һичшиксез, шәкли тарафтан поэма жанрлык хасиятләрен саклар. Аның кичерешләр дулкынында язылган лирик төре, эпик һәм драматик юнәлешләре дә сакланыр, гиперболага һәм мифологиягә таянганнары да үзләре турында «хәбәр» бирерләр. Хәзерге татар поэмасының тел-сурәт, тасвирлау өлкәсендәге уңышлары, «көчле позициясе» сакланыр. Борчылу күбрәк эчтәлек, сәяси юнәлеш, кыйбла турында барырга тиештер. «Телебезне кисәләр, милләт буларак бетеп, караңгылык базына кереп барабыз» дип, балавыз сыгып, аһ-ваһ килеп, артка чигенүләребезне Мәскәүгә генә сылтап, аклану ноктасын шунда гына эзләп, әллә ни еракка китеп булмастыр. Заманалар агышына бәйле рәвештә, буйсындырылган халыклар үзләрен яклый алып, үз мәнфәгатьләре турында онытмаска тиешләр.

Татар шигъриятенең, шул исәптән поэмасының икенче юнәлеше сатирик һәм юмористик булырга тиеш дип саныйм. Халкыбызның хәзерге халәтен шаяртып, телне бозып сөйләшүчеләрдән көлеп, мыскыллап, Г.Афзал дәрәҗәсендәге тирән, усал фикерле сатира әсәрләре кирәк.

Шигъриятнең әйдәп баручы жанры поэма – чынбарлыкның гади сурәтчесе, «шәүләсе» генә була алмый. Ул үз халкының мәнфәгатьләрен яклау юлында гомумирәк һәм әһәмиятлерәк вакыйгаларны үзәккә алырга, башка әдәби төрләрдә, бигрәк тә лирик поэзиядә алып барылган эзләнүләргә таянып үсәргә тиеш дип уйлыйм.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

# 2019 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ**

2019 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

«Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында. №6

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Г а л и у л л и н Р. Яңа елга – ак ышаныч белән! №1

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

А й т м а т о в Ч. Чыңгызханның ак болыты. «Бер көн – бер гомер» романына нисбәтле повесть. *(М.Вәлиев тәрҗемәсе)*. №№1,2

Ә м и р х а н о в М. Сәҗидә. *Повесть*. №4

Б а й м ө х ә м м ә т о в А. Урам балалары. *Повесть*. №11

Г а б д е л х а к о в а Р. Кышлары салкын булса да... *Хикәя*. №3

Г а д е л А. Итекче. *Бәян*. №4

Г ы й м а т д и н о в а Н. Шундый инде без... *Повесть*. №3

Г а л и у л л и н Т. Сукыр Гаваз. *Повесть*. №4

Д и н д а р о в И. Каршылыклар кыры. *Повесть*. №№2,3

Җ а м а л е т д и н о в а Ф. Галәм гөле ташны ярган... *Повесть*. №8

З ә й д у л л а Р. Кол Шәриф. *Романнан өзек*. №6

И м а м о в Ф. Вакытсыз вакыт... *Фантастик роман*. №№7,8

И с м ә г ы й л е в Х. Калымчы Җәүдәт. *Повесть*. №11

К а р а К. Җиләкле алан. *Повесть*. №7

К ә б и р о в М. Дога. *Повесть*. №6

К ә р и м о в К. Исемсез хат. *Роман-элегия*. №№9,10

К о р б а н Р. Ватан. *Роман*. №№1-3

Л а т ы й п о в Р. Күрәксез нефтьчеләр. *Повесть*. №7

М о т а л л а п о в Ә. Гаилә. *Бәян*. №11

М ө х ә м м ә д и е в Р. Ак кәгазь нидән саргая... *Роман*. №№5,6

М ө х ә м м ә т ш а Р. Хәл бу ки. *Кыйтгалар кыйссасы*. №12

М у ш и н с к и й Ә. Иренка-иркәм. *Хикәя. (М.Вәлиев тәрҗемәсе)*. №7

С а д р и е в Ф. Алмалы күлгә китү. *Хикәя*. №9

С а ф и у л л и н Ә. Кытай Гайфулла. *Повесть*. №9

Т а җ и е в Н. Чиккән кулъяулык. *Хикәя*. №12

Т у ф и т у л л о в а Р. Язмыш җиле. *Роман*. №№4,5

Х ә л и м А. Кара төннең карасында. *Хикәя*. №1

Х ә л и м А. Искитмәле Исмәгыйль. *Хикәя*. №10

Х ә с ә н о в а Г. Кадер. *Хикәя*. №9

Х ө с н и я р З. Канатсыз фәрештәләр. *Хикәя*. №12

Ш ә й д у л л и н а - М у р а т Р. Үксезләр. *Повесть*. №8

Ш и к а л ё в М. Мулла кызы. *Хикәя*. №10

**ШИГЪРИЯТ**

А х у н җ а н о в а Р. Бишек җыры көйләп тирбәтә җил... *Шигырьләр*. №6

А ш и р о в И. Уйлар гел туган якта... *Шигырьләр*. №5

Ә х м ә т җ а н о в а С. Күңелнең җегендә моң-мәкам ярала. *Шигырьләр*. №8

Б а т т а л о в а Г. Дала исе килә кырдан... *Шигырьләр*. №9

Б ә д и г ы й Х. Авылдан килгән чыпчык. *Аллегорик поэма*. №11

Б ә ш ә р Р. Сыена уем кошлар янына. *Шигырьләр*. №10

Г а д е л ш а  Ш . Яшен атарга тиеш... *Шигырьләр*. №9

Г а р и ф у л л и н  Д . Үткән белән сөйләштерә чын тарих... *Робагыйлар*. №5

Г а р и ф у л л и н а  Р. Туры сүз дә кайчак яралый. *Шигъри хикәят*. №10

Г а ф ф а р  Ә . Без – Ак барс. *Поэма*. №1

Г ы й з з ә т у л л и н а  Ф . Мин фал ачам бүген киләчәккә... *Шигырьләр*. №2

Г ы й з з ә т у л л и н а  Ф . Гасырларга еллар үрелгән... *Шигырьләр*. №12

Д ә ү л ә т б а е в  Ф . Бар ул хаклык... *Робагыйлар*. №9

Җ а м а л  Р. Сагынуларым сиңа барыберме?.. *Шигырьләр*. №11

З ө л к а р н ә й  Л . Нугай йорты. *Садактагы ун кыйсса*. №№8,9

И б р а һ и м  Б . Татар булып гомер итү кирәк... *Шигырьләр*. №1

Ибраһим Х. Чайкала җәйге рәшә... *Шигырьләр*. №7

И м а е в  Р. Табасы иде чишелешен... *Шигырьләр*. №12

И с л а м о в а  З . Тапшырыла дәвер үтенече. *Шигырьләр*. №12

К ә б и р о в  М . Һәркем җирдә үз бәясен яулый. *Шигырьләр*. №11

Л е р о н  Л . Һәрвакыт иңдә йөк... *Шигырьләр*. №10

М а н с у р о в  З . Яңабаштан язмас тәкъдир каләме. *Шигырьләр*. №7

М и р з а  М . Җир – үз күчәрендә... *Цикл*. №6

М о р а т  Г. SMSтан юлланмаган юллар. *Шигырьләр*. №8

М ө с л и м о в а  Ф . Җәйнең җылы, кояш тулы аяз көне... *Шигырьләр*. №7

М ө х ә м м ә т ш а  Р. Минем Такташ. *Кечкенә опера өчен либретто*. №6

Н и з а м и  Р. Кайда ялган, кайда дөреслек?.. *Шигырьләр*. №2

Р а х м а н  Р. Милләтем барында яшим мин... *Шигырьләр*. №5

Р а х м а н и  Р. Милләтебез яшәеше һәм фәлсәфи аңында «Хак» феномены. Кеше хаклары. *Фәнни-поэтик трактат*. №5

С а ф и н  Ф . Мәңгелектән килгән көнем... *Шигырьләр*. №1

С а ф и н а  Н . Мин тарихка мәңгелектән килгән... *Шигырьләр*. №3

С и т д ы й к о в а  Ә . Чор бураны авыл эчендә... *Шигырьләр*. №4

С ө л ә й м а н  Җ . Аяктагы тышау әле коллык түгел... *Шигырьләр*. №2

С ү л т и  Р. Ком күчә, бархан күчә... *Шигырьләр*. №10

Т у к а й  Г. Ваксынмыйм. *Шигырь*. №4

Х а р и с  Р. Унөчкә унөч. *Поэма-бәян*. №7

Х ә м ә т ш и н  Э . Еллардан маяк куям... *Шигырьләр*. №11

Ш ә е х  Л . Кеше булып калыйк соң чиктә! *Шигырьләр*. №12

Ш ә м с у а р о в  Т. Хәтерләрне яңарт тын гына... *Шигырьләр*. №4

Ш ә р и п о в  Р. Вафирә. *Поэма*. №3

Я н с у а р  Л . Үз жаныңа гына хөкемдар бул... *Шигырьләр*. №4

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

З ә й н и е в  И . Туганнар-тумачалар. *Татар тормышыннан сәхнәләр*. №10

Х ә к и м  З . Хәтер хөкеме. *Драма*. №3

Ш ә р и ф  Р. Мин сине мәңге сөярмен. *Моңсу комедия*. №5

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

А б д р а х м а н о в а  А . Син – каһвә. *Хикәя*. №8

А б з а л о в  Р. Һәр көн – ачыш... *Шигырьләр*. №2

Ә х м ә д у л л и н а - А р х и п о в а  Г. Ташлар телен өйрәнәм мин... *Шигырьләр*. №1

Б и к м у л л и н а  А . Уйда – таулар, ымсындыргыч үрләр... *Шигырьләр*. №12

В а х и т о в  А . Уйлар дәрьясында йөзгән чагым... *Шигырьләр*. №9

В ә л и е в а  Н . Яшәүдән туймагыз! *Шигырьләр*. №10

Г а й н у л л и н а  А . Дустым, сердәшем... *Хикәя*. №4

Г а л и е в а  Г. Мин яратам сине, әй тормыш... *Шигырьләр*. №7

Г а ф у р о в а  М . Көн дә дога... *Шигырьләр*. №9

Г ү з ә л ә  ( Г ү з ә л  З а к и р о в а ) . Мин чиксезлек кадәр синдә. *Шигырьләр*. №10

З а к и р о в а  З . Бер-берсеннән матур уйларым бар... *Шигырьләр*. *(Э.Шәрифуллинаның кереш сүзе белән)*. №4

С ә л а х о в а  А . Кулдашым. *Хикәя*. №6

Т и м е р б у л а т о в а  Р. Сагыну. *Хикәя*. №5

Х а ж и е в а  Ч . Әсәлем... *Хикәя*. №2

Х а н ә ф и  Г. Яши белеп яшәү – акыл күрке... *Шигырьләр*. №6

Х ә б и б у л л и н а  Л . Мин ирек ягына юл алам... *Шигырьләр*. №3

Х ә с ә н о в а  Ф . Сурәт янса, җан – мәңгелек. *Шигырьләр*. №11

**ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ**

Д у м б а д з е  Н . Кан авазы. *Хикәя. (Р.Бәшәр тәрҗемәсе)*. №6

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ**

А н д р о с о в  Г. Узу кирәк утның үткеленнән... *Шигырьләр. (Якутчадан Л.Шәех тәрҗемәләре)*. №8

Ә б д и к ә р и м о в  Ш . Хәсрәтләнә халкым өчен күп сүзем... *Шигырьләр. (Казакъчадан Р.Корбан тәрҗемәләре)*. №9

В ә л и е в а  С . Бар минем бер хатым... *Шигырьләр. (Азәрбайҗан теленнән Р.Сәлах тәрҗемәсе)*. №3

В ә л и  О . Бадәм артларыннан күтәрелә ак ай… *Шигырьләр. (Төрекчәдән Р.Аймәт тәрҗемәләре)*. №11

Х а м д а м  У. Гөлҗимеш. *Мини роман. (Ф.Сафинның кереш сүзе белән)*. №4

Х а м д а м  У. Күңелем дәрьясы. *Хикәя. (Үзбәкчәдән Ф.Сафин тәрҗемәсе)*. №4

**«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ**

А й з а т  Г. Саф чишмә. *Хикәя*. №5

Ә х м ә т г а л и е в а  Г. Сукмак. *Хикәя*. №12

Б а һ а у о в  И . Табылдык. *Хикәя*. №3

Г а б д е л х а к о в а  Р. Кышлар үткәч кайтырмын... *Мистик бәян*. №11

Г а л и у л л и н а  Г. Локман карт хикмәтләре. *Хикәя*. №4

Г ы й л ь м е т д и н о в а  Н . Йөрәкнең дүрт кылы. *Хикәя*. №8

Г ы й м а е в  З . Кендек бабай. *Хикәя*. №10

Д ә ү л ә т б а е в а  Г. Энҗе. *Хикәя*. №7

Җ а м а л е т д и н о в а  Ф . «... кисмә безнең канатларны!». *Хикәя*. №2

З а р и ф  Ф . Мин дөньяны күрәм. *Хикәя*. №11

З а х а р о в а  З . Елама, әни! *Хикәя*. №6

С ә ү б а н о в а  С . Диагноз. *Повесть*. №9

Х ә к и м  З . Хирург. *Повесть*. №12

Х ө с н и я р  З . Доктор Байчурин. *Хикәя*. №8

Ю л ы ш е в а  Г. Мин исән! *Хикәя*. №12

**«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ**

Ә х м ә т г а л и е в а  А . Ошбу җиһанда якты юл. *Очерк*. №6

Ә х м ә т г а л и е в а  Г. «Нәселемнең мин бер тәрәзәсе». *Очерк*. №2

Г ә р ә е в а - А к ч у р а  А . Ике әни. *Очерк*. №11

Г ы й л е м х а н о в  Р. «Халкым җырын саклый алсам иде...». *Очерк*. №5

Г ы й л е м х а н о в  Р. «Кая әле, үзем!». *Очерк*. №9

Г ы й м а д о в а  Г. Рәсемле язмыш. *Очерк*. №7

Җ а м а л е т д и н о в а  Ф . Бер горурлык хисе. *Очерк*. №9

З ө ф ә р о в а  А . Күңел кушканны тыңлап... *Очерк*. №10

И м а м и е в а  А . Туган җирнең бәрәкәте – күкрәп үскән иген кырында. *Очерк*. №6

С ә г ъ д и  Р. Мәгарә. *Очерк*. №8

С ә г ъ д и  Р.  Идарәче дә, иганәче дә. *Очерк*. №12

Т а һ и р о в  И . Онытылмас еллар хатирәсе. *Очерк*. №5

Ф ә т т а х о в а  Л . Кайтаваз булып кайту. *Очерк*. №3

Х ә с ә н о в  Н . «Малайка». *Очерк*. №1

**«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ**

Г ы й м а е в  З . Зилзиләдән соң. *Хикәя*. №1

Ю л ы ш е в а  Г.  Бәхет. *Документаль хикәя*. №1

«Хәзинә» конкурсы  нәтиҗәләре. №1

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Г а л и у л л и н  Т. Таяну ноктасын эзләгәндә... №№11,12

З а к и р җ а н о в  Ә . Өч китапта – өч хикмәт *(Т.Галиуллин иҗатына бер караш)*. №4

М и н һ а җ е в а  Л . Могҗизалар ачар сүз остасы *(Г.Гыйльманов иҗаты турында)*. №4

**ҖӘҺӘТ ТӘНКЫЙТЬ**

Айгөл Абдрахманова. «Син – каһвә». №8

Айсинә Сәлахова. «Кулдашым». №6

Алинә Бикмуллина шигырьләре. №12

Альбина Гайнуллина. «Дустым, сердәшем...». №4
Булат Ибраһим шигырьләре. №1
Гөләндәм Галиева шигырьләре. №7
Гүзәлә шигырьләре. №10
Ләйлә Хәбибуллина шигырьләре. №3
Миләүшә Гафурова шигырьләре. №9
Розалина Тимербулатова. «Сагыну». №5
Фәридә Хәсәнова шигырьләре. №11
Чулпан Хажиева. «Әсәлем..». №2
*(Сәхифәне Д. Заһидуллина алып бара.)*

**ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Мир-Хәйдәров Р. Шагыйрьнең соңгы мәхәббәте. №4
Мусабәкова Р. Тукай: Пушкиннан «игътибас иткән бу баш». №6
Рахман Р. «Килде-китте кеше түгел без!». №1
Рахман Р. «Үз иманы белән яши кеше...» №4
Рахман Р. Хатирәләрне яңартучы шигърият. №5
Рахман Р. Мөхәммәт Садри: «Минем серләр ачык алар, син тыңласаң». №7
Рахман Р. Уйлы сәгатьләрне кайтарган шагыйрь. №9

**ТАРИХ**

Хәмидуллин Б. Алтын Урда цивилизациясе һәм аның мирасы. №8

**ФӘН**

Бикмаев И. Галәм серләре. №4
Заһидуллина Д. Китаби (кулъязма) дастаннар. №3
Көмеш касә серләре *(И.Госманлы белән Д.Заһидуллина сөйләште)*. №7
Ситдыйков А., Заһидуллина Д. Хәзәр каһанлыгының башкаласы. №2
Ситдыйков А., Заһидуллина Д. Кубрат хан токымнары язмышын ачыклау. №6

**БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 75 ЕЛ**

Мостафин Ш. Янып яшәлгән гомер. №8

**ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ**

Такташ Һ. Скрипкә егълайдыр. *Нәсер. (Р.Шиһабдиновның кереш сүзе белән)*. №1
Заһидуллина Д. Әсәргә караш. №1

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

Гайнанова Л. Сәгадәт. №2
Шакиров Ә. Артист язмалары. №4

**ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ**

«Ак калфакның табылган чагы...» *(«Ак калфак» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе К.Идрисова белән А.Имамиева әңгәмәсе)*. №4
«Иман һәм гаилә – тормыш нигезе» *(И.Шәңгәрәев белән Л.Әбүдәрова әңгәмәсе)*. №6

**ЮБИЛЕЙЛАР**

ДӘРДЕМӘНДНЕҢ ТУУЫНА – 160 ЕЛ

Рәмиев Җ. Газаплы язмыш. *Шигырь*. №11
Хәмидуллин Л. «Соңгы тамчы каным фида...». №11
Фотоархив: *фотолар Л.Хәмидуллин архивыннан алынды*. №11

ГАБДРАХМАН СӘГЪДИНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Хәмидуллин Л. Татар, үзбәк әдәбиятлары тарихын барлаучы галим. №3

СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Замандашлары Сәгыйть Сүнчәләй турында *(З.Рәмиевнең кереш сүзе белән)*. №8

ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Мотыйгуллина Ә. Әдип иҗатында милли идеянең бирелеше. №3
Фотоархив: Әмирхан Еники тормышыннан мизгелләр. №3

МОСТАЙ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Миңнуллин Р. Кадерле истәлекләрем... №10

КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Фотоархив: Кыям Миңлебаев тормышыннан мизгелләр №6

ШӘРИФ ХӨСӘЕНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Фотоархив: Шәриф Хөсәенов тормышыннан мизгелләр №11

ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Миңнуллина Й. Чана юлы ком. Кытыршы... *Шигырь*. №8
Фотоархив: Фәрваз Миңнуллин тормышыннан мизгелләр. №8

МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВНЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Фотоархив: Марсель Сәлимҗанов тормышыннан мизгелләр. №12

ФӘНЗАМАН БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Р а х м а н  Р. Адашмаган каләм. №2

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ТУЫНА 80 ЕЛ

Фотоархив: Фаил Шәфигуллин тормышыннан мизгелләр. *Фотолар Эльмира Шәрифуллина архивыннан*. №5

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА 100 ЕЛ

Тарихың зур, юлың ерак, галиҗәнап татар китабы... *( Татарстан китап нәшриятының генераль директоры И.Сәгъдәтшин белән Ф.Җамалетдинова әңгәмәсе)*. №7

«ЯЛКЫН» ЖУРНАЛЫНА 95 ЕЛ

Фотоархив. №3

«САБАНТУЙ»ГА – 95 ЕЛ
(элекке «Яшь ленинчы» газетасы)

Фотоархив. №10

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ
ОЕШУГА 85 ЕЛ

Х ә м и д у л л и н  Л . Өмет-хыялларга юл ачылган чаклар бар иде. №9

Фотоархив. *Фотолар Л.Хәмидуллин, Р.Фәйзуллин һәм Язучылар берлеге архивыннан алынды*.

РӘФЫЙК ШӘРӘФИЕВКӘ 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. №2

ФӘРИТ ЙОСЫПОВКА 80 ЯШЬ

Х и с а м о в  О . ,  М и ң н у л л и н  Б . ,  М и р х ә е в  Р. Таш кыяларга язылган тормыш җыры. №5

НАДИР ДӘҮЛӘТКӘ 75 ЯШЬ

В ә л и е в  Р. Минем Надир Дәүләтем... №7

ӘХӘТ ГАФФАРГА 70 ЯШЬ

С в е р и г и н  Р. Богаулардан арыну. №1

ДАМИР ГЫЙСМЕТДИНГӘ 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

ГАЗИНУР МОРАТКА 60 ЯШЬ

Фотоархив: *Газинур Морат тормышыннан мизгелләр*. №8

КИМ МИҢНУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

М ө х ә м м ә т җ а н о в а  Л . Заман сулышын тоеп... №1

ДАНИЯ ЗАҺИДУЛЛИНАГА 55 ЯШЬ

Ә м и н е в а  В . «Язу – акыл һәм йөрәк эше...». №10

«ИДЕЛ» ЖУРНАЛЫНА – 30 ЕЛ

Фотоархив. №7

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Б а р г а н  Һ . Шанлы сакчы *(Аяз Гыйләҗевнең Төркиядә басылган әсәрләре турында)*. №4

Г а б и б б е й л и  И . Шигъри дуслык күперләре. *(А.Имамиева тәрҗемәсе)*. №11

Г ы й л ә җ е в  И . Казан ханлыгы турында яңа хезмәт. №9

Д ә ү л ә т ш и н  Г. Прототөрки бабаларыбызга юл яручы китап. №7

**ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАР ҺӘМ ЗАМАН**

З а һ и д у л л и н а  Д . Камал Абдулланың «Сихерчеләр үзәнлеге». №9

З а һ и д у л л и н а  Д . Үзбәкстан әдәбиятында модернизмның яңаруы: Фирганә мәктәбе. №11

З а һ и д у л л и н а  Д . Төрки әдәбиятларда пост-постмодернизм: Борһан Сонмезнең «Истанбул Истанбул» романы. №12

**ХӘТЕР**

Р ә х и м о в а  Б . Гамьле фикерләр. №4

Х ә й р у л л и н а  Ф . Илаһи сагыш. №3

**ШИГЪРИ ХӘТЕР**

К ә р и м  Ф . Илең турында уйла... *Шигырьләр*. №1

С а д ә  Г. Һәр учакның җаны, үз теле бар... *Шигырьләр*. №2

**МУЗЕЙЛАРЫБЫЗ**

А б и л о в а  Г. Бакый Урманче музеена 20 ел. №9

Ә х м ә д у л л и н а  А . Шиһабетдин Мәрҗанинең Ташкичүдәге музее. №6

Г а б и д у л л и н а  Х . Мөхәммәт Мәһдиев музее. №10

Г о б ә й д у л л и н  Л . Ризаэддин Фәхреддиннең мемориаль музее. №1

Г о б ә й д у л л и н  Л . Гаяз Исхакыйның тарихи-мемориаль һәм этнографик комплексы. №2

Г о б ә й д у л л и н  Л . Фатих Кәримнең музей-йорты. №5

Л е р о н  Л . Дәүләкәндә Әмирхан Еники музее кирәк! №3

С а б и р о в а  А . Туфан Миңнуллин музее. №8

Т ө х ф ә т о в а  Г. Габдулла Тукай әдәби музее. №4

Я н с у а р  Л . Казан үзәгендә – «Татар китабы йорты». №7

**«ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН...»**

С ә г ы й д  К . Атаклы татар әдибе Фатих Әмирханның авыруы, үлүе, күмелү мәрәсиме *(И. Гомәровның кереш сүзе белән)*. №№9,10

**АК ҖИЛКӘН**

Г а н и е в а  З . Онытылмас батырлык. Шигырь. №4

С а б и р о в а  А . Өченче хатың кайда? Хикәя. №4

**БӘЛӘКӘЙЛӘР**

Г а т а у л л и н а  Л . Бәләкәй Лилия. №1

З а к и р җ а н о в  Ә . Бәләкәй Әлфәт. №10

М и ң н е г у л о в  Х . Бәләкәй Хатыйп. №5

**БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ**

И к с а н о в а  И . Сәпит. *Хикәя*. №10

М а с к и  А . Бүренең «туганлыгы». *Шигъри әкият*. №6

Х а ф и з о в а  Р. Әти кайткан көнне. *Хикәя*. №2

**КАЙТАВАЗ**

Б а т т а л о в  Ф . Нәфрәт уятмады, ләкин күңелне кайтарды. №6

Г а б д е р ә х и м  Ф . Ачык хат. №1

Г а л и м у л л и н  Ф . Ватан дигән татлы сүз. №6

И б р а һ и м о в а  С . Сокланып укыдым. №9

Ф ә т т а х о в  И . Язмыштан узмыш юк... №10

Х ә л и м  А . Иҗатыңа ак юл синең, бала! №7

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

Г а н и е в  Ш . Шаян парчалар. №1

З а р и ф  Ф . Зарифизмнар. №1

Ш ә р и ф  Р. Шәрифизмнар. №11

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Ә х м ә т х а н о в а  М . Уены-чыны бергә. №12

Г ы й м а д и е в  А . Уены-чыны бергә. №9

К ә р и м о в  К . Уены-чыны бергә. №11

М о р а т  Г. Уены-чыны бергә. №8

М а н с у р о в  З . Уены-чыны бергә. №7

Уены-чыны бергә.*Сәхифәне М . Г а л и е в алып бара*. №1,2,3,4,5,6,10

**БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ**

ГАЛИӘСГАР КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ. №1

**БЕР ҖЫР ТАРИХЫ**

«Солдатым» *(М.Ногман сүзләре, С.Садыйкова көе)*. №5

Бер фото тарихы. №1

Д у б и н  А . 2020 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. №12

«Казан утлары» архивыннан. *Сәхифәне Р.Фәйзуллин алып бара.* №1,2,4,5,6

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12

Яңа китаплар. *Сәхифәне Г.Морат алып бара.* №3,4,5,8,9,10,11

Хушлашу сүзе. Мөсәгыйт Хәбибуллин. №2; Илһам Шакиров. №2



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

## Шәхесләр чираты

*Мин үзем күп еллар сатучы булып эшләдем. Китапны, әдәбиятны бик яратсам да, хезмәт сукмагым ул юлдан китмәде шул...*

*Г.Камалның оныгы, Әнәс Камалның кызы, Рәис Даутовның (язучы) хатыны Диләрә Әнәсовна миңа: «Миңлегөл, бу сиңа хас эш түгел бит, каян килеп кердең сату эшенә?» – ди торган иде. Рәхмәт аңа, миңа шундый бәя биргәне өчен.*

*Әйе, 32 ел гомерем сату эшендә, күбесенчә Кызыл Байрак урамындагы яшелчә кибетендә үтте. Кешеләрне бик ярата идем, күңелем киң, бәлки, шуңадыр сату эшен дә үземчә яраттым. Әмма сату гадел эш түгел инде, бигрәк тә без эшләгән заманда әйберләре дә юк иде бит, гел таныш-белеш аша аласы иде. Кешедә юк, ә миндә бар. Бу гаделлекме? Нишлисең, язмышым шулай булгандыр, дип юатам үземне.*

*Әмма шунысы куанычлы: кибеттә эшләү дәверендә күпме күренекле кешеләр белән очрашырга, үзләре белән сөйләшергә туры килде. Алар белән күрешеп кенә калган мизгелләр дә минем өчен бик кадерле...*

**Миңлегөл ӘХМӘТХАНОВА.**
*Казан шәһәре*

**Салих Баттал.** Салих абыйның ни өчендер нәкъ менә кышкы киемнән кереп йөргән чаклары истә калган. Өстендә тун, сырган калын чалбар кигән, башында лётчиклар бүреге. Мин аны балыкчыга охшата идем. Зур, таза гәүдәле кеше. Хатыны белән икәүләп керерләр иде. Әйберләрне Салих абый үзе ала, ул күп сөйләшми торган кырысрак табигатьле булып тоела. Ә хатыны кара кашлы, кара күзле, бик чибәр хатын, аны биюче, диделәр. Ире әйбер алганда, кырыйда елмаеп кына басып торыр иде.

Салих абый сугыш вакытында очучы булган. Самолёты янган килеш җиргә төшеп утырган, шуннан исән калган. Ә картаймыш көнендә өендә янып үлгән дип ишеттем, дөрес булса...

***

**Рөстәм Яхин.** Уртача буйлы, тазарак кына гәүдәле кеше иде. Әкрен генә кереп, бик итагатьле итеп исәнләшә. Өс-башы да чиста, пөхтә, матур. Әз сөйләшә. Ул бигрәк тә кипкән җимешләр алырга ярата иде. Шунысы истә калган: бер кергәндә, йөзәр грамм төрле җимешләр үлчәтте дә, мин аңа: «Сездән 98 тиен», – дидем. Ул: «Шул да бер тәңкә булдымы?» – дип аптырап сорады. Ә мин эчемнән генә: «Рөстәм абый акчаның кадерен белеп тотучы, ахры», – дип уйлап куйган идем...

***

**Рафаэль Ильясов.** Ул безнең кибеткә еш керде. Әйберләрне гел үзе ала иде. Бәлки, акчаны белеп, чамалап тотучы булгандыр. Ул вакытта чират зур, тыныч кына, сабыр гына басып торыр иде.

Минем әтинең иң яраткан артисты ул, «Моннан да шәп җырлаучы юк», – дия иде. Әти соңга таба начар ишетә башлады, әмма колагын радиоалгычка куеп, шушы артистны тыңлар иде. Шуңа күрә Рафаэль Ильясов кибеткә кергәч, мин аңа гел игътибар итә идем. Хәзер дә урамда очрашсак, бик озаклап сөйләшеп торабыз...

***

**Шәриф Хөсәенов.** «Әни килде» спектакле өчен генә дә хөрмәтем зур иде аңа. Мин аны да кышкы пальтодан күз алдыма китерәм. Башында ондатра бүрек. Бүрек астыннан бөдрә чәче чыгып торыр иде. Төз, озын гәүдәле, зәңгәр күзле, чибәр кеше иде. Ишектән керер дә, зур-зур атлап, һәрбер бүлекне (биш бүлек) карап йөрер, аннан ничек керсә, шулай чыгып та китәр иде.

Мин аның әйбер алганын хәтерләмим.

***

**Айрат Арсланов.** Аның хатыны Мәрьям апа бездәге сатучылар белән (берсе сугышта да булган) сөйләшеп торырга бик ярата иде.

Бервакыт мондый хәл булды: кичтән карбызның бәясен төшерделәр (1,50 тиеннән 1 сумга). Икенче көнне мин, бу хакта онытып, карбызны Айрат абыйга кичәге бәясе белән сатканмын. Соңыннан гына искә төште. Өйләдән соң, күрше кибеттә Айрат абыйны очраттым. Әй сөендем инде, артык алган акчаны үзенә кайтардым. Нинди акыллы, сабыр кеше булган ул! Мин шулай-шулай, дип аклангач, «әйе шул», дип кенә куйды. Белә торып миңа авыр сүз әйтмәде, берәү булса, кара тавыш чыгарыр иде...

***

**Габдулла Шамуков.** Ул безнең кибет тирәсендә торган булса кирәк. Аның яратып алган әйбере – гранат белән каражимеш иде. «Ашыйк әле, кеше эчеп тә бетерә», – ди торган иде. Бер күргәндә, Фуат абый Халитовның үлеме турында бик борчылып сөйләде, алар бик дус булганнар икән.

«Кем уйлаган шулай булыр дип... Санаторийга барырга медосмотр үтеп йөргәндә, канының анализы әйбәт булмаган», – дип сөйләгәнен хәтерлим. Фуат абый озак авырмыйча гына үлеп тә китә, рак авыруыннан дип беләм. Бу 1981 елның башы була.

Көннәрдән бер көнне кибеткә яшьрәк кенә марҗа керде. Аны Габдулла абый миңа җибәргән икән. Бу хатын аның килене булып чыкты. «Әти авырый, аңа гранат белән каражимеш кирәк иде», – диде ул. Каражимеш бар иде, ә гранат булмады. Озак та үтмәде, Габдулла абыйның вафатын ишеттем, ул да шул авыру белән үлгән икән. Бу 1981 елның ахыры иде.

***

**Зәки Нури.** Беркөнне озын буйлы бер абый кереп, әйберләр ала башлады. Сөйләшүе матур – бу йә укытучы, йә язучыдыр инде дип уйлыйм. Аларның сөйләшүләре бөтенләй аерылып тора бит. Түзмәдем, тәки сорадым: «Абый, сезне кайдадыр күргәнем бар, сез кем?» – дим. Ул җавап бирми, үзе миннән сорый: «Син кайсы районныкы?» – ди. Мин әйтәм: «Балтач районыннан». «Ә-ә, алайса бер мәҗлестә утырганбыздыр инде», – ди. «Юк, абый, андый мәҗлестә булганым юк», – дидем. Алган әйберенә акча түләде дә кесәсеннән визит карточкасын чыгарып бирде һәм бер сүз әйтмичә чыгып та китте.

Мин аны үзебезнең кибеттә бүтән күрмәдем.

***

**Мөхәммәд Садри.** Җәйнең эссе көне иде. Мөхәммәд абый тирләрен сөртә-сөртә, стенага терәлеп, бик озак сөйләшеп торды. Кулында таягы да бар иде. Кибет кечкенә булганлыктан, утырырга урын юк. Соңыннан бик үкендем, ник урындык чыгарып бирмәдем икән дип. Ул күп сөйләде, әмма, ни кызганыч, берсе дә исемдә калмаган.

***

**Заһит Хәбибуллин.** «Хатыным авырый, карарга кеше таба алмыйм, кеше акчага кызыкмый хәзер. Эшләгәч, үзем җитешә алмыйм, күлмәкне дә үзем тегеп кидертәм, кибетнеке ярамый. Кызым еракта, Уфада тора», – дип, эчен бушатып чыгып китте бер кергәнендә... Ишеткәнемчә, Заһит абый үзе үлеп киткән, ә авыру хатыны калган.

***

**Шәйхи Маннур.** Бик чиста, пөхтә киенеп йөри. Кибеткә керсә гел бал белән кызыксына иде: иснәп карый, ялап карый...

Мин балаларыбызга «Яшь ленинчы» газетасы ала идем, анда бер төркем укучылар арасында шушы абыйны күрдем, әмма исеме язылмаган, бәлки, үзем игътибар белән карамаганмындыр. Бер кергәч сорадым: «Абый, сезне укучылар арасында күрдем, сез кем?» – дип. Ул: «Шәйхи абыең булам», – диде. Миннән сорый: «Ә синең исемең ничек?» «Миңлегөл», – дим. Мин югында кибеткә кереп: «Кая минем гөлем?» – дип сорый торган булган. Бер кергәндә: «Шәйхи абый, бик әйбәт бал бар, алмыйсызмы?» – дидем. «Ярар, алырмын, балым бар иде әле барын, булып торсын», – дип, 250 граммлы банка белән (!) тәки бал алды.

***

**Ширияздан Сарымсаков.** Хатынын ишек төбендәрәк, тәрәзә буенда калдырган да үзе чиратта тора. Аның хатыны Галия апа (артистка) авырый башлаган икән, басып торуы да, елмаюы да икенче төрлерәк иде. Көннәрнең берендә Ширияздан абыйны 4 нче трамвайда очраттым, ул мине таныды, исәнләштек.

«Ширияздан абый, нихәлләрегез бар?» – дим. Ул: «И-и сеңлем, минем хәлләр әйбәт түгел әле, Галия апаңны җирләдем бит», – диде.

Күпме вакыт үткәндер, Ширияздан абыйны тагын трамвайда очраттым. Хәлен сорадым. Ул: «Сеңлем, минем хәлләрем әйбәт, өйләндем бит әле, илле ел элеккеге танышымны алдым», – диде.

1996 елны Шәхсәнәм апа Әсфәндиярова вафат булды, гәүдәсен Камал театры залына куйганнар, кеше күп иде һәм шунда янә Ширияздан абыйны очраттым. Тыштан керә торган ишек турысында барьер булгандырмы (урындык түгел) – шуңа утырган, алдында таягы, ике кулына таянып, башын игән. Теге вакыйгалардан соң ун-унике ел вакыт узган. Мин исәнләштем, әллә танымады, әллә сөйләшәсе килмәде...

Аннан соң, ул анда утырып торырга тиешле кеше түгел иде бит, аның урыны түрдә булырга тиеш иде. Чөнки ул шушы театрның элекке, данлыклы режиссёры иде бит...

***

**Мөхәммәт Мәһдиев.** Ул безнең кибеткә кергәч, гел сатучы Наилә апа белән генә сөйләшеп торыр иде. Ишектән кергәндә үк: «Наилә, мин бүген бер төш күрдем әле», – дип башлар иде.

Мәһдиевнең Рәшит абыйсы да, Роза апасы да керә иде. Рәшит абый сугышта булган, фронт хәлләрен сөйләр иде... Роза апа Бауманда «Бүләкләр» кибетендә эшләде.

Мөхәммәт абый белән үземә сөйләшергә туры килмәсә дә, аны якыннан күргәнемә дә бик риза мин үзе...

***

**Зәкия Рәсүлова.** Язучы Атилла Расихның хатыны. Атилла абый үзе дә Габдулла Тукай яратып йөргән Зәйтүнәнең улы бит. Бездә эшләүче Наилә апа Тукай нәселеннән булганга күрә, Зәкия апа аның янына килә иде. Гомумән, ул Тукай эзеннән йөреп, китап чыгарды. Ул китап миндә дә бар, Наилә апа бүләк итеп бирде.

***

**Мөсәгыйт Хәбибуллин.** Ике чакыру билеты биреп китте. Аның илле еллык юбилее иде, ахрысы. Бара алмадык. Соңыннан бик үкендем инде, хөрмәт йөзеннән генә булса да, барырга кирәк булган. Ул чын күңелдән, кешегә санап чакырган иде бит...

***

**Шаһидә Максудова-Ахунова.** Лаеклы ялга чыккач та, әдәбият-сәнгать өлкәсендәге кешеләр белән күрешкәләп тордым.

Бервакыт Яшел Үзән районының 774 км тукталышында поезд көтеп торам,

бакчадан кайтышым. Минем янда арба тарткан бер ханым да басып тора. Поездга бергә утырдык. Әз-мәз сөйләшкәләп кайттык. Бу ханым сөйли: «Ирем вафат булды. Аллага шөкер, бөтен йоласын да үтәдем, бу арада 51 нче көне иде, аны да укыттым», – ди. «Бакчада җыелыш иде, мин шунда киттем, ул ятып калды. Кайтсам – үлгән иде», – диде ул.

Бу сөйләшү Казанга кайтып җиткәндәрәк булды. Юлыбыз 35 минутлык иде. Мин Туфан Миңнуллинның әнисенең сүзләрен әйтергә җыенган идем (ул болай дип язган: «Әти үлгән, сузылып ята, ә әни, әтиегез бәхетле әле, дип сөйләнеп йөри. Мин аны олыгайгач кына аңладым, ир кешенең хатынынннан алда үлүе хәерлерәк икәнен»), әмма әйтергә өлгерә алмадым... Әлеге ханым: «Минем ирем Гариф Ахунов», – дигәндә, Казанга кайтып җиткән идек инде. Ул уйлагандыр инде, бу хатын язучыларны белми торгандыр дип... Без поезддан төштек тә аерылыштык. Ичмаса, төшкәч әз генә сөйләшеп тормадык. Мин бит Шаһидә ханым белән кайтканмын! Их, әгәр дә белгән булсам, минем сүзләрем бик күп иде бит. Чөнки мин, Г.Ахуновның «Йолдызлар калка» китабын укыган кеше. Анда авторның тормыш юлы, авыр чакларда ачлы-туклы укулары турында, Шаһидә белән ничек танышып, бергә булулары һ.б. турында күп язылган иде.

Мин бакчага поезд белән йөргәнлектән, юлда гел китап укый идем.

«Йолдызлар калка» китабы 1980 елны басылган. Болытлы, яңгырлы көн, бакчага барышым, шушы китапны укып барам. Анда язучы, ягъни Г.Ахуновның иптәшләре белән поездда Әлмәткә командировкага барулары тасвирланган. Монда Ширияздан Сарымсаков белән Шәйхи Маннур да бар. Төн, салкын, икесе пәлтәләрен ябынып ята, ә Шәйхи абый өстеннән салмый, чөнки аның пәлтәсе яңа, яхшы. Мин дә беләм Шәйхи абыйның пөхтә, матур итеп киенеп йөргәнен! Шәйхи абый белән Ширияздан абыйларны белгәнгә күрә, китапның эченә кереп киткәнмен... Күтәрелеп карасам – ят тукталыш, ике яклап урман! Болай да көн болытлы, яңгыр, караңгы... Димәк, мин үземнең тукталышны үтеп киткәнмен! Нишләргә дә белмәдем, бу 772 км тукталышы иде инде.

Васильевода төшеп, вокзалга кереп, укуымны дәвам иттем, чөнки поезд килергә ярты сәгать бар иде әле...

***

**Вафирә Гыйззәтуллина.** Безнең оныклар М.Гафури урамындагы 1нче татар гимназиясенең 3 классында укыйлар иде. Аларны каршы алырга килдек, дәрес беткәнне көтеп утырабыз. Сентябрь ае. Явымлы, авыр, ямьсез көн.

Вафирә белән сөйләшеп киттек. Ул: «Авырып торам әле, әллә салкын тигән, бер дә кәефем юк», – диде. Мин әйтәм: «Күз дә тия торгандыр инде, сәхнәгә чыккач, күпме кеше текәлә бит сезгә», – дим. Ул әйтә: «Сәхнәгә чыкканда, үземне-үзем өшкереп чыгам инде, аннары Нурулла мәчетеннән Фәрит хәзрәт Кадыйров та айга бер мәртәбә Коръән укып өшкерә», – диде. Аларның шәһәр үзәгендә торганнарын белгәч: «Малаегыз (Камил иде бугай) мәктәптән үзе дә кайта алырлык икән», – дидем. Ул: «Что син, мин аны үзен генә йөртәмме соң?» – диде. Шуннан соң ничә көн үткәндер, күңелсез хәбәр ишеттем... Вафирә үзенең кызы белән туган авылына кайткан булган. Менделеев районы Камай авылыннан Казанга килгәндә, юл һәлакәтенә очраган...

Соңгы тапкыр күрешеп сөйләшүебездә үлем исереклеге кергән булгандыр, шуңа кәефсез, моңсу булгандыр инде ул, дип тә уйлап куйдым. Урыны җәннәттә булсын!

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстан китап нәшриятына 100 ел тулу уңаеннан Казандагы «Ногай» кунакханәсенең Г.Тукай клубында – «Китап нәшер итү тарихы һәм китап сәүдәсенең заманча үсеш тенденцияләре» дип аталган фәнни-гамәли конференция, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында әдәби-музыкаль кичә булып үтте. Конференциядә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин нәшриятның 100 еллык эш нәтиҗәләрен югары бәяләде. Ул Татарстан китап нәшриятына ТР Дәүләт Советының Рәхмәт хатын тапшырды. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев кәгазь бәясе артса да, нәшриятның эшен киметмәвен, Россиядә үткәрелгән һәм дөньякүләм күргәзмәләрдә катнашуын әйтте. К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында узган бәйрәмдә коллективны ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева котлады.

Татарстан китап нәшриятының 100 еллыгына багышланган чаралар республикабыз районнарында да үтте.

***

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында шагыйрь Дәрдемәнднең тууына 160 ел тулуга багышланган «Аһ, туган каумем газиз!» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булып үтте. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, әдәбият галимәсе Дания Заһидуллина, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис чыгыш ясады. Экранда Сибгат Хәкимнең Дәрдемәнд шигъриятенә бәяләмәсе яңгырады. Видеоязмада Лирон Хәмидуллинның чыгышы тәкъдим ителде. Яшь шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтшин, Гөлүсә Батталова, Йолдыз Миңнуллина үзләренең шигырьләрен укыдылар. Кичәдә Г.Камал, К.Тинчурин исемендәге театр артистлары катнашты.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында тууына 100 ел тулу уңаеннан каһарман-шагыйрь Шәрәф Мөдәррисне искә алдылар. Монда «Яшәү көче» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булып үтте. Анда язучылар, галимнәр, Г.Камал театры артистлары, Казан театр көллияте студентлары, Ш.Мөдәррриснең якташлары, туганнары катнашты. Кичәдә чыгыш ясаган Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов каһарман-шагыйрьне туган ягы – Чүпрәле районында да зурлап искә алуларын, аның бюстына чәчәкләр салуларын, мәдәният йортында кичә үткәрүләрен әйтте. КФУ доценты Нурфия Йосыпова Шәрәф Мөдәрриснең иҗаты турында сөйләде. Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис аның чуваш телен дә яхшы белүен, тәрҗемә белән ныклап шөгыльләнгәнен әйтеп үтте. Татар әдәбиятында шигъри тәрҗемәгә фәнни нигез салучыларның берсе булуын искәртте.

***

«Газинур Морат дусларын җыя». Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрь, публицист Газинур Моратка 60 яшь тулу уңаеннан үткәрелгән кичәнең шулай аталуы юкка түгел. Ул көнне сәхнәдә юбилярның әсәрләрен укучылар, җырчылар, биючеләр – барысы да язучылар, бәйрәмдарның дуслары иде. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, шагыйрьнең каләмдәшләре Рабит Батулла, Рәдиф Гаташ, Ркаил Зәйдулла (ул Г.Моратка ТР Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хатын тапшырды), Гәрәй Рәхим, Камил Кәримов, Фоат Галимуллин, Ләбиб Лерон, Хәлим Җәләй, Алмаз Хәмзин, Рүзәл Мөхәммәтшин, Шәмсия Җиһангирова, Галимҗан Гыйльманов, Марат Закир, Рифә Рахман, Илсөяр Иксанова, Фатих Кутлу, Миләүшә Гафурова, Казандагы Ш.Мәрҗани исемендәге 2нче гимназия укучысы Фәридә Гатина чыгыш ясады. Юбилярны хезмәттәшләре – Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләре котлады. Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев үзләренең котлау сүзләрен видеоязмада ирештерделәр. Экранда Г.Моратның канатлы гыйбарәләрен укырга мөмкин иде. Кичәне прозаик һәм шагыйрь Марат Кәбиров алып барды.

Газинур Моратның юбилеена багышланган кичәләр шагыйрьнең туган ягын-

да – Кукмара районының Зур Сәрдектәге К.Шакиров исемендәге гимназиядә, Мәдәният йортында да булып узды. Бәйрәм шатлыгын уртаклашырга каләмдәшләре Алмаз Хәмзин, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рифат Сәлах кайтты. Мәдәният йортында узган кичәдә Кукмара муниципаль районы хакимияте башлыгы урынбасары Равия Кәримуллина чыгыш ясады һәм шагыйрь Газинур Моратка «Кукмара районының шәрәфле гражданины» исеме бирелүен игълан итте.

Кукмара шәһәренең А.Булатов исемендәге күппрофильле лицеенда район укытучылары һәм укучылары арасында Газинур Морат шигырьләрен сәнгатьле уку буенча конкурс булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулла катнашты.

### ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Тукай районында шагыйрь Фәннур Сафин истәлегенә багышланган Татар әдәбияты көннәре булып узды. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, язучылар Рабит Батулла, Равил Фәйзуллин, Фоат Садриев, Хатыйп Миңнегулов, Фоат Галимуллин, Ркаил Зәйдулла, Вахит Имамов, Рөстәм Галиуллин, Ләбиб Лерон, Факил Сафин, Айдар Хәлим, Алмаз Хәмзин, Шәмсия Җиһангирова, Эльмира Шәрифуллина, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәүзия Солтан, Айгөл Әхмәтгалиева, Рәдиф Сәгъди, Рафис Сәлимҗанов, Сирень Якупова, Мирһади Разов, Лилия Садриева, Лилия Фәттахова, Галиәхмәт Шаһи, Айрат Суфиянов район мәктәпләрендә укытучылар һәм укучылар белән очраштылар. Кичен Яңа Троицк авылы Мәдәният йортында «Җырымда юатырмын» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Фәннур Сафин сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Тукай муниципаль районы хакимияте башлыгы Фаил Камаев белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов язучы-сатирик, җырчы-композитор Алмаз Хәмзин һәм ветеран-язучы Рубис Зариповка Фәннур Сафин исемендәге премия тапшырдылар.

### С.СӨЛӘЙМАНОВА ПРЕМИЯСЕНЕҢ ЯҢА ЛАУРЕАТЛАРЫ

Әлмәт Татар дәүләт драма театрында Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия тапшыру тантанасы булды. Быел бу олы бүләккә язучылар Фәүзия Галиуллина (Фәүзия Солтан), Рәмзия Габделхакова, Тәүфикъ Кәримов лаек булды. Кызыксындыру бүләге Лира Вәлиди, Рухия Ахунҗанова, Александр Аввакумовка бирелде. Тантанада С.Сөләйманова стипендиясен алачак студентларны да котладылар. Бүләкләрне «Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, С.Сөләйманованың улы Әнвәр Маликов тапшырды.

### СӘФӘР

Шагыйрьләр Марат Закир, Шәмсия Җиһангирова, Галия Гайнетдинова, Фәнил Гыйләҗев Уфада «Йөрәк сере» бәйгесен тамаша кылды. Анда театр артистлары, режиссёрлар катнашты. Татарстаннан килгән кунаклар Уфаның мөселман зиратында Ризаэддин Фәхреддин, Мостай Кәрим, Фәридә Кудашева, Әнгам Атнабай, Равил Бикбаев каберләренә чәчәкләр салды, аларның рухына дога багышладылар.

### ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Чаллының М.Җәлил исемендәге үзәк китапханәсендә шагыйрь, прозаик Нияз Акмалны искә алу кичәсе үтте. Анда язучының каләмдәшләре, сабакташлары Рафис Сәлимҗанов, Ләбиб Лерон, Рафис Корбан, Марат Закир, Фәйрүзә Мөслимова, Наилә Вилданова, Гөлсәрия Басыйрова, бертуган энесе, журналист Нәсим Акмал һ.б. чыгыш ясады.

### КӨН ТӘРТИБЕНДӘ – АЛТЫН УРДА

Төркестан шәһәрендәге Әхмәд Ясәви исемендәге казакъ-төрек университетында Алтын Урданы өйрәнүгә багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция булды. Бу гыйльми чарада Казан федераль университеты вәкилләре дә катнашты. Профессор Хатыйп Миңнегулов пленар утырышта «Татарстанда Алтын Урда әдәбиятын өйрәнү тарихы» темасына доклад сөйләде, секция белән җитәкчелек итте. Доцент Марат Гатин «Бертольд Шпулер хезмәтләрендә Алтын Урда» темасына чыгыш ясады.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар шагыйре, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Ленар Шәех «Дөнья генераллары Тынычлык өчен» («Генералы Мира за Мир») халыкара иҗтимагый ассоциациясенең – «Тынычлык күгәрчене» («Голубь Мира») медаленә лаек булды. Тынычлыкны, дуслыкны һәм халыклар арасында үзара аңлашуны ныгытуга багышланган иң яхшы әсәрләр өчен бирелә торган әлеге бүләк татар шагыйренә Европа Берлегенең үзәге – Брюссель шәһәрендә узган VIII Open Eurasian Literature Festival and Book Forumында тапшырылды.

2019 елның 29 ноябрендә 69нчы яшендә Татарстанның халык артисты, Казан дәүләт консерваториясе доценты, редакциябезнең якын дусты **Рафаэль Әхәт улы Сәхәбиев** вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть З.ХАКИМА «Хирург», рассказ З.ХУСНИЯРА «Бескрылые ангелы», рассказ Н.ТАЗИЕВА «Расшитый платочек»; лирические рассказы Р.МУХАМЕТШИНА «Такие обстоятельства»; стихи Л.ШАЕХА, Ф.ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Р.ИМАЕВА, З.ИСЛАМОВОЙ.*
*«Новые имена»: стихи А.БИКМУЛЛИНОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: рассказ Г.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Тропинка», рассказ Г.ЮЛЫШЕВОЙ «Я живой!».*
*«Татарстан. История. Личности»: очерк Р.САГДИ.*
*«Тюркские литературы и современнось»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Фотоархив»: 85 лет со дня рождения М.Салимжанова.*
*«Литературная критика»: статья Т.ГАЛИУЛЛИНА.*
*Библиографический список произведений, опубликованных в 2019 году.*
*Религиозные праздники и памятные даты в 2020 году.*
*«Страницы юмора»: подготовила М.АХМЕТХАНОВА.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Государственный литературно-мемориальный музейный комплекс в деревне Новый Кырлай – резиденция Кыш Бабая. Фото Б.Рахматуллина; поэт Фаниль Гилязов.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: story by Z.KHAKIM «The Surgeon», story by Z.KHUSNIYAR «Wingless angels», story by N.TAZIEV «Embroidered handkerchief»; lyric stories by R.MUKHAMETSHIN «Such circumstances»; poems by L.SHAEKH, F.GIZZATULLINA, R.IMAEV, Z.ISLAMOVA.*
*«New Names»: poems by A.BIKMULLINA.*
*«Actual criticism»: the section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*Competition «Healing Hands»: story by G.AHMETGALIEVA «Path», story by G.YULYSHEVA «I am alive!».*
*«Tatarstan. History. Personalities»: essay by R.SAGDI.*
*«Turkic literature and modernity»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Photo Archive»: 85th anniversary of M.Salimzhanov.*
*«Literary criticism»: article by T.GALIULLIN.*
*Bibliographic list of works published in 2019.*
*Religious holidays and memorial days in 2020.*
*«Pages of humor»: prepared by M.AHMETKHANOVA.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: The State Literary and Memorial Museum Complex in the village of New Kirlay - the residence of Kysh Babay. Photo by B.Rakhmatullin.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Яңа Кырлайда Г.Тукай Дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексы – Кыш Бабай резиденциясе. *Б.Рәхмәтуллин фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь Фәнил Гыйләҗев.